ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2008



# КАЗАНДА ХӘТЕР КӨНЕ













**Казан утлары**

**Qazan utlarï**

2008

**10**

**(1032)**

**<u>*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*</u>**
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

**<u>*НАШИРЕ:*</u>**
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Юл—озын, гөмерләр—урау... *Шигырьләр.* 5
Рәис САФИН. Атландым атның биленә. *Чик сакчысы язмалары.* 9
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Иске моң—галиҗәнап... *Шигырьләр.* 44
Роза МУЛЛАНУРОВА. Өрәңге өрәге. *Хикәя.* 48
Әхмәт ГАДЕЛ. Тормыш дигән япан кырда... *Шигырьләр.* 56
Рәмзис КАДЫЙРОВ. Сугыш. *Документаль повестьтан өзек.* 60
Фирдания ГЫЙЛФАН. Аккоштай кагынып... *Шигырьләр.* 84

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Данил САЛИХОВ. Таш сандык. *Ике пәрдәле сатирик комедия.* 86

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Ленизa ВӘЛИЕВА. Безнең серне саклар күкләр. *Шигырьләр.* 112

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Себер иленә сәяхәт. 115

**ХӘТЕР**

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр.* 130
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* 175

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Тәрҗемәне онытмыйк. 139

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Мәхәббәт иле. 147
Нурфия ЙОСЫПОВА. Балачакка сәяхәт. 151

**СӘНГАТЬ**

Идрис ГАЗИЕВ. Татар җыры—йөз ел элек 153

**ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВКА 80 ЯШЬ**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Ил агасы Әлмәндәр. 166

**ФӘН**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Таҗеддин Ялчыгол. 170
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. 173

**ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ**

Рафаэль МОСТАФИН. Мирсәй Әмир гаепleme? 181

Берлекнең яңа әгъзалары 184
"Казан утлары" архивыннан 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": Р. САФИН. "Оседлал я коня" (заметки пограничника);
Р. КАДЫРОВ. "Война" (отрывок из документальной повести);
рассказ Р. МУЛЛАНУРОВОЙ "Клён"; стихи Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ,
Р. ЗАЙДУЛЛЫ, А. ГАДЕЛЯ, Ф. ГИЛЬФАН.
"Драматургия": Д. САЛИХОВ. Комедия "Каменный сундук".
"Творчество молодых": стихи Л. ВАЛИЕВОЙ.
"Публицистика": Ф. БАЙРАМОВА. "Путешествие в Сибирь".
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство—как первый стих"; А. РАШИТ. "У каждого своя судьба"—воспоминания.
"Литературная критика": Л. ХАМИДУЛЛИН. "В поле зрения—перевод".
"Книжное обозрение": рецензии Р. АХМЕТЗЯНОВА на книгу Р. ФАЙЗУЛЛИНА "Книга любви" и Н. ЮСУПОВОЙ на книгу Б. РАХИМОВОЙ "Мальчик-всадник".
"Искусство": статья И. ГАЗИЕВА о 100-летней истории татарской песни", статья Г. БАЙРАМОВОЙ к 80 летию Ш. Биктимерова.
"Наука": Х. МИННЕГУЛОВ. "Таджеддин Ялчыгул".
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Познакомившись с новым произведением": Р. МУСТАФИН. "Виновен ли Мирсай Амир?"
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Казань в XVI веке. Картина Р. ЗАГИДУЛЛИНА; писатель Лукман Бадыкшанов.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": R.SAFIN. "I saddled a horse" (notes of frontier guard); R.KADYROV. "War" (fragment from documentary story);
story by R. MULLANUROVA "Maple"; verses by F. GIZZATULLINA,
R. ZAYDULLA, A. GADEL, F. GILFAN. "Dramatic art": D. SALIHOV. Comedy "Stone chest".
"Youths' creativity": verses by L. VALIEVA. "Publicism": F. BAYRAMOVA. "Travel to Siberia".
"Memory": N. FATTAH. "Childhood is like first verse"; A. RASHIT. "Everyone has his destiny" - memoirs.
"Literary criticism": L. HAMIDULLIN. "Translation is in sight ".
"Book review": R. AHMETZYANOV. "Travel to love country".
N. YUSUPOVA. "Travel to childhood".
"Art": I. GAZIEV about a 100-year-old history of Tatar song ".
Article by G. BAYRAMOVA to 80th anniversary of Sh.Biktimerov.
"Science": H. MINNEGULOV."Tadjeddin Yalchygul".
Pages from "Tatar encyclopaedia".
"Having got acquainted with new work": R.MUSTAFIN. "Is Mirsay Amir guilty?"
New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 17.09.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т-1262 Тираж 4784.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Флера
Гыйззәтуллина

## ЮЛ—ОЗЫН, ӨМЕТЛӘР—УРАУ...

### Керфекләр чыклы чордан

Үзләрен сихри
    тылсымнар
Ышыклап торгангамы,—
Хыялда балкып утыра
Абага урманнары.

...Белмичә тылсым утында
Җемелдәп яначагын,
Калды бит шушы урманда
Минем дә бала чагым.

Шигырьгә күчкәннән бирле
Мин дә бит—утлы урман!
Шаулыйсы тылсымнарым да—
Керфекләр чыклы чордан!

Куша чор: кирәк сүзеңне
Соңармый өлгер әйтеп...
...Сугарам һәрбер хәрефне
Керфектә мөлдерәтеп.

Хыялым мине алдаса,
Чәчәген ата-ата...
Тормышның ялганы белән
Киләм якага-яка.

Киләм... һәм минем күрәшне
Расларга килә вакыт:
Чәчәктә йомылып калган
Сабый чаклардан калкып...

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА—*шагыйрә; "Чишмә җыры", "Йөрәгемдә шаулый карурман", "Башкаемда дөнья исәпләре" һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге һәм "Татнефть"нең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Без—юлда!

### I

Кузгалдык олы юлга без
Егәрләп заман атын...
Ә тарих өерә алга
Елларның яманатын.
Һәр кеше кичә үзенчә
Замана сиратларын.
Тиз көннән җитәр минем дә
Чигенмәс чиратларым.
...Кичәрмен...
Язмышым алга
Әҗәлем калкытмаса...
...Юл озын! Өметләр—урау:
Кайгыдан шатлыккача.

### II

...Өзелми өмет...
Тәкъдиргә
Бирсә дә тарих—талак!—
Без бит үз Ватаныбызда:
Йөрмибез илләр талап.
Юк яман уртак эшебез;
Без җилдән тумаганбыз.
"Сөям!" дип антлар эчкәндә
Гөл исе сулаганбыз.

Яманлап таркатылудан
Йөрәкләр ярылса да,
Ватаным өермә белән
Уратып алынса да,
Иманлы, тугры юлда без:
Безгә Тәңребез юлдаш!
Антларны исбат иткәндә
Илнең сабыры сынмас...

### III

...Ничек булмасын—Ил гаме:
Гел безнең өстә бит ул!..
Кылычтан үткен сиратлар
Кылдан да нечкә бит ул...
Тыштан елмайган булса да
Эчтән ут йота-йота—
Һәр кеше шушы сираттан
Чыгуга өмет тота.
Өметен тота яман зат—
Күзләрен ачып шардай...
Җәннәттән тәмугка кадәр
Бары... бер адым ара!

## Бушан инде көзге үкенечтән

Җил сораганда да буран бирә,
Чыдам бирә Ходай түзгәнгә...
Карурманнар, кар-бураннар җырын
Җырлап кердек быел көзләргә.

Аптырама, таң буранлап атса,
Юлларына япса карурман...
Безнең тыелгысыз хыялларга
Буран шаукымнары кагылган.

...Җил сорадык...
Чөнки кирәк иде
Җанны җиләслеккә төрергә...
Бушан инде күзге үкенечтән,
Бураннарга каршы йөгер дә!

## Бала багу—дала багу

...Җан тели дип, сорамагыз балан!
Җаным минем хәзер—гөлле алан.
Янәшәмнән килә денле балам:
Артта калды инде җилле далам.

Далаларны иңләп йөрмәс борын
Бер Тәңредән сорамагыз бала.
Далаларда калган хәтер күзем
Үзәгемне өтеп-өтеп ала.

Бала багу—дала багу бит ул!—
Сез аңарга җиңел карамагыз.
Киләчәккә илткән бу җир шарын
Килер хаталардан аралагыз!

## Сөю сурәсе

...Кочагыңда болын чәчәкләре...—
Рухың чәчәк аткан, күрәмсең!
Болын юлы буйлап йөгерә-йөгерә
Төшләремә килеп керәсең.

Гөлчәчәккә торган мәхәббәтне
Борынгылар саный—изгедән.
Изге рухың, тәкыяма үреп,
Идел суларында йөздерәм.

Тирән Иделләргә дәвам тапкан
Җыр-моңнарың күктән ишетәм.
Җырдан яратылган саф мәхәббәт—
Бигрәкләр дә бөек хис икән!

***

Кочагыңда болын чәчәкләре...—
"Исталеккә!"—диеп бирәсең.
...Баш очымда җиде катлы күкләр
Көйли миңа сөю сурәсен.

Шушы көйдән рухи кодрәт алып
Җир өстенә Кояш калыкса—
Ошбу хозурлыкка
чәчәкләрнең
Кызылы да шаһит...
Алы да.

Син дә—шаһит!..
Мин үзем дә шаһит
Чынлыгына бергә чакларның...

...Бу чәчәкләр—дөнья бәясе бит,—
Сулдырмыйча ничек сакклармын?

Күкләр белән тоташ бу җанымның
Сөю серен кемгә чишәрмен?..
Сүзләремә ышанырсың микән:
"Җан сердәшем—син бит..."—дисәм мин?

Ышанырсың микән: "Юк, төш түгел.
Өндә сөйдем сине",—дисәм дә...
Сөю исән... Җирләр, Күкләр исән—
Тәүге ышанычлар исәнгә.

## Ил агасы илдә ат чаптыра

Кыйбла яктан канатлы җил исә,
Эч серләрен гөлләр җилгә чишә.
Мин сер отам шушы чишелештән—
Җилгә исәп салган кичерештән.

Сабан эше беткәч, җыен җыеп,
Ил агасы илдә ат чаптыра.
Атка, Илгә булган мәхәббәтем
Йөрәк тибешемне капшап тора.

Ачыласы кыйбла җыеннарын—
Мин дә бәлки атта әйләнермен.
Пар канатлар булып бәйләнермен
Иңнәренә гомер бәйрәмемнең.

Сабан тургаена җыр юлламмын:
"Сабанчы" дип, минем нәсел-затым.
Шигърияттә мәйдан тоткан атым
Акламыйча аумас канат хакын.

Чаптарыңның ялын чал сыйпагач,
Ил агасы, син дә нечкәрерсең:
Күңелеңнең тулып түгелгәнен
Искәрерсең әле, искәрерсең...

## Бакыйлык

...Көн туды исә
Җирдә үлем-китем!..
Ник соң Чорым
Чара тапмый моңа?
Мин дә китеп барам
Бакыйлыкка...
Тәкъдир хәлен
Чорга такмый гына.

Мин дә китеп барам,
Васыять булып,
Күмәк хорда
Кала тавышларым...

Җаның яктан-якка
Авышканда
Мөһим мескенлеккә
Сабышмавың!

Мөһим тагын—
Җаның саклар өчен—
Тотынмавың
Дөнья ваклыгына...
...Җан таләбе
Җитмеш чатлы була...
Ә бакыйлык—
Һәрчак хаклы була.



Рәис Сафин

# АТЛАНДЫМ АТНЫҢ БИЛЕНӘ

ЧИК САКЧЫСЫ ЯЗМАЛАРЫ

## Әфган җиле

Памирда мин ике тапкыр адаштым. Шуларның кайсын гына искә төшерсәм дә, хәзер дә аркаларым чымырдап китә. Соңыннан, еллар үткәч, Джек Лондонның «Алтын бизгәге» шәлкемендәге "Яшәү теләге" хикәясен укып, мин янә бер кат тетрәндем. Шул хикәядә Джек Лондонның герое, ач һәм хәлсез килеш, берьялгызы, карлы-бозлы дала-кыр буйлап океан ягына, аны коткарачак ярга таба шуыша, артыннан ияреп килгән карт һәм хәлсез, шулай ук ач бүре белән үзара зур тартыш, яшәү өчен көрәш бара: кем-кемне? Менә шунда, инде соңгы өметләре өзелер-өзелмәс калган бер мәлдә, үзенең бармакларына гаҗәпләнеп, аптырап, фәлсәфи уйларга батып карап тора ул: кайчандыр рояльдә, пианинода уйнаган шушы житез бармакларын бүре чәйнәгәнен күз алдына китереп, ул да калтыранып-калтыранып куя...

Ярар, Джек Лондонның геройлары алтын артыннан, байлык һәм романтика артыннан кугандыр, ә менә без Памирда алтын эзләмәдек, без ул чакта Совет иленең гап-гади солдатлары, чик сакчылары идек. Әфган җилендә өшеп үлүнең никадәр мәгънәсез үлем икәнен аңлап-белеп тору да җанны өшеткән иде ул чакларда...

Солдат гомере өчен куркыныч мизгелләр аз булмый инде ул армиядә. Анда, бигрәк тә «учебка»да чакта, хәтта бер «кояш астында» үз урыныңны табу, яклау өчен дә бугазга-бугаз килгән чаклар була. Ләкин бер тату гаилә сыман яшәгән чик сакчылары арасында мондый хәлләр сирәк булгангамы, алар инде хәтердән юылган, онытылганнар. Ә менә Әфган җиле, үзәкләргә үткән шушы ачы, комлы-буранлы җил һич кенә дә онытылмый, һич тә хәтердән чыкмый.

Мин инде армиядә, элемтәчеләр әзерләү отделениесендә хезмәт итә башлап, анда бер хохол ефрейторы белән «чәкәләшеп» өлгергән, соңыннан кавалеристлар взводына күчкән идем. Ә теге «чәкәләшү»нең һәм «күченү»нең тарихы болай булды.

Беренче көннәрдә үк взвод командиры, армиягә тикле радист-элемтәчеләр

Рәис САФИН (1935) — *язучы; "Йөрәк парчалары", "Бабайлар чуагы", "Бер мәхәббәт тарихы" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

курсында укып йөргәнем турында таныклыгымны карады да:

—О-о, син коеп куйган радист икәнсең бит инде, укып та торасы юк!—дип, мине шундук элемтәчеләр отделениесенә беркетте.—Өлкән лейтенант Калганов бүгеннән синең командирың булыр, турыдан-туры аңа гына буйсынырсың,—дип тә өстәде. Әйтүен әйтте дә бит, әмма взвод командирының радист-элемтәчеләр отделениесе буенча ярдәмчесе ефрейтор Киреенко да бар икән бит әле. Менә шул Киреенконың минем «махсус белемле» радист булуыма җен ачулары чыга иде. Башка солдатлар исә, чорына күрә белемле саналган, сугыш вакытында һәм аннан соң ачлы-туклы укып, җиде класс белем алып чыккан егетләр.

Киреенко мина бәйләнепме бәйләнә:

—Синең барыбер укыйсың юк, болай да барысын да беләсең,—дип, дәрес-өйрәнүләрдән алып, мине көнаралаш дип әйтерлек, йә кухняга савыт-саба юарга җибәрә, йә башка бер эшкә куша, каршы әйтсәң, наряд чәпи. Отбойдан соң туалет чистартырга куша.

Башта мин аның бу гамәленең серенә, бу гадәтенең асылына төшенә алмый йөдәдем. Әмма тора-бара аңладым. Сержант булырга хыялланган, сержант дусты гимнастеркасын киеп фотога төшеп мактанып-масаеп, аны өенә, сөйгән кызына җибәргән ефрейтор минем татарлыгыма кочына икән ләбаса. Ничек инде татар кешесе белемле булырга мөмкин, янәсе.

Тәбәнәк кенә, әмма калын гәүдәле, иягенә таба очлаеп килгән түгәрәк йөзле, ана үрдәк сыман як-якка ава-түнә атлап йөри торган Киреенконы мин үзем дә яратмас-сөймәс, хәтта күралмас булдым. Ятсак та, торсак та—ул безнең белән. Дөресрәге, без аның белән. Отделение тулысынча аның карамагында, ул аның командиры. Солдатның көндәлек тормышын күз алдында тоткан шушы командирга көннәрдән-бер көнне үземнең дәгъвамны белдердем.

—Мине бу отделениегә элемтәче-радист һөнәрен яхшы белгән белгеч булыр өчен билгеләделәр. Ә мин әле кухняга эшкә йөрүдән, әле ишегалды себерүдән бушый алмыйм. Бу турыда мин, сез рөхсәт итсәгез дә, итмәсәгез дә, штабка барып әйтәчәкмен,—дидем.

—Ах ты, татарин голопобый!—дип, ефрейтор касыгыма китереп төртмәсенме! Ни булганын үзем дә аңлап бетермәдем. Касыгым авыртудан түгел, татар дип мыскыллавына җен ачуым килде, эчемдә давыл булып бөтерелгән нәфрәтем өермәдәй тышка бәреп чыкты. Мин ефрейторның якасыннан алып, колак төбенә шундый итеп кундырганмын, ул туп кебек очып барып төште, аңына-акылына килә алмый ятты. Гололобый татаринның йодрыгын татыган ефрейтор көч-хәл белән торып, бер сүз әйтми, башын аска иеп казармадан чыгып китте. Бу хәлне карап торган солдат егетләр дә бер сүз әйтмәде. Бу эшнең болай гына бетмәсен, командирга кул күтәрүнең ни-нәрсә икәнен алар яхшы аңлый иде.

Мин исә Киреенко бу хәлне взвод командирына җиткерер, мине эссе табага бастырулар башланыр дип шүрләп йөрдем. Шунда Казан егете Торгашов килеп:

—Молодец, Рәис. Егет икәнсең! Юкка гына сине Петров паркында егетләр хөрмәт итмәгәннәр икән. Ә моның өчен сиңа берни булмый. Чөнки без әле присяга кабул итмәгән,—диде.

Әмма ефрейтор үчне үзенчә алды. Новосибирскидан килгән берничә урыс егетен котыртып, ялгызымны, төнлә өстемә одеал каплап, мине эт урынына тукмап ташладылар. Әнә шулай итеп мин иртәгесен санчастька эләктем. Аның башлыгы—Надыйров фамилияле татар капитаны, Казан егете иде. Бераз алга китебрәк әйтим, Азат Надыйров гомеренең соңгы көннәренә кадәр Уң Болак урамындагы түләүле поликлиникада баш табиб

булып эшләде. Без аның белән еш кына күрешеп, бергә үткән хезмәт елларын искә ала идек.

Капитан Надыйров кара көеп шешкән урыннарымны, сыдырылып-тырналган җирләремә сак кына орынып:

—Нәрсә булды?—дип сорады.

—Турниктан егылып төштем.

—Юк, егеткәем. Монда солдат итеге эзләре бар.

Ул: «Сынган-тайган җирләрең юкмы?—дип, аяк-кулларымны, кабыргаларымны сыпырып үтте. Бармакларымны кыймылдатып карады.

—Болай беренче карашка әллә ни булган кебек түгел... Ләкин эчке әгъзаларыңның хәлен киләчәк күрсәтер. Кан космадыңмы?

—Юк.

—Ә шулай да нәрсә булды соң? Ни сәбәптән кыйнадылар үзеңне?

... Сүземне кыяр-кыймас кына башлап, үземнең моң-зарымны түкми-чәчми сөйләп бирдем.

—Да-а...—дип сузды якташ капитан.—Ефрейторның синең татар булуына бәйләнүе сагайтты бит әле. Кем өчендер без һаман да бөкәй икән, ә? Ул бит сине генә түгел, мине дә, без татарларны—бөтенебезне дә рәнҗетә булып чыга. Нишләргә соң?

Капитан уйга чумды. Мин дә, нишләргә белми, уңайсызланып утыра бирдем.

—Мин, әлбәттә, лейтенант Калганов белән сөйләшермен,—диде ул, ниһаять.—Күрше Мари республикасыннан ул, акыллы егет кебек күренә. Хәлне аңлар.

—Ул аңлар да бит, ләкин өлкән лейтенант безнең белән бер казармада тормый шул. Анда ефрейтор һәм аның куштаннары хуҗа. Солдатларның күбесе мина теләктәшлек белдерсәләр дә, берсенең дә кухняга нарядка барасы, йә ишегалды себерәсе килмәс...

Шунда башыма тагын бер уй китереп сукты.

—Булмаса, әллә Мургабның диңгез өсте тигезлегеннән 3600 метр биеклектә торуын сәбәп итикме?

—Ничек?

—"Рядовой Сафин климат шартларына ияләшә алмый, башы авырта" кебегрәк белешмә сыман нәрсә әмәлләсәгез, ничегрәк булыр икән?

—Шуннан?

—Шуннан кавалерия взводына күчәрмен. Үзебезнең Казан егетләре дә шунда.

—Мондый очраклар элегрәк тә булгалады. Ләкин бу беткә үч итеп тунны ягу кебек килеп чыга бит. Ә Памирда туннан да кирәк нәрсә юк, туган!

—Әгәр ул тун тәнеңне җылытмаса, нишлисең инде?

—Бүген җылытмаса, иртәгә җылытыр. Әллә кавалериядә җинел дип беләсеңме?

—Үзе егылган еламас, диләр, ничек тә түзәрмен.

—Ярар, әүвәл Калганов белән сөйләшим әле, аннары күз күрер.

Берничә көннән мин тагын санчастька бардым.

—Өлкән лейтенант отряд командиры белән сине кавалериягә күчерү турында киңәшләшеп карарга булды,—диде капитан.—Тагын ике айга түзсә, өч ел буе җылы бүлмәдә радист булып үткәрер иде, дип тә өстәде. Тик үзенең ефрейтор белән каршылыкка керергә теләге юк.

—Гаделсезлеккә чик куярга теләми, димәк.

—Ул синең күзлектән караганда гына шулай кебек. Бер кешенең мәнфәгатьләре коллектив мәнфәгате белән туры килмәскә дә мөмкин. Армиядә хәрби тәртип дигән нәрсә дә бар бит әле, ул һәркемнең көен

көйләп бетерә алмый. Аннары Калгановның үз стратегиясе һәм тактикасы булуын да онытмыйк, аның да үсәсе, погонына яңа йолдызлар өстисе килә. Ә инде Киреенко кебекләр—бу эштә аның уң кулы.

Мин инде китәргә җыенган идем. Капитан янә сүз башлады:

—Бер уйлап карасаң, өлкән лейтенант хаклы бит. 40-45 градус салкыннарда, күз ачкысыз бураннарда чик буенда унар сәгать сакта тору уен эш түгел. Монда зур чыдамлылык, физик ныклык кирәк. Ә мин сине бу таләпләргә җавап бирәсең дип әйтмәс идем. Радист булып җылы бүлмәдә утыру—өстеңдә җылы туның бар дигән сүз инде ул. Әллә тыпырчынмыйсыңмы соң?!

... Мине кавалерия взводына күчерделәр. Мин Киреенконың бетмәс-төкәнмәс нарядларын үтәп йөргән арада, яшь кавалеристлар уку-өйрәнү, ат өстендә күнегүләр ясау буенча хәйран алга киткән булып чыкты. Аларны куып җитү өчен гөрләвек-гөрләвек тир агызырга туры килде.

Ат өстендә катлаулы күнегүләрне цирк артистлары дәрәҗәсендә диярлек башкара алуың күнелдә горурлык уятса, "конная подготовка"дан соң ике сәгатькә сузылган тактика дәресләре җанны ала инде. Бәлкем ат корсагы кочып, камыштай бөгелеп каткан аякларны турайту өчен ул шулай кирәк булгандыр да. Ләкин ияр каешына ышкылып чиләнгән ботлар, бәрелгән-кырылган арт сан белән сафта йөрү, бигрәк тә хәрби дирбияне инбашына асып, бил каешына тагып йөгерүләр, ай-һай, бер дә җинел эш түгел иде шул.

Әйе, кавалерист булу, ат менеп кукыраеп йөрү генә түгел икән. Моның өчен башта гаҗәеп зур тырышлык белән күнегүләр ясап, осталыгыңны камилләштерү мөһим.

Җайдакның уңышы атын яхшы һәм дөрес итеп иярләүдән башлана. Атның сыртында бернинди дә сыдырылган, күпкән җәрәхәтләр булырга тиеш түгел, аны чиста, коры итеп сөртеп, иярне җайлап-уңайлап саласың. Өзәнге кирәгеннән артык тарттырып бәйләнгән булса, атның тыны кысыла, бу хәлдә ул рәхәтләнеп йөри дә, иркенләп чаба да алмый. Монда инде аның сыртын сержантның каеш чыбыркысы каезлаячак. Әгәр дә киресенчә, каеш-баулар бушрак итеп бәйләнсә, ат өстеннән иярен-ниең белән бергә шуып төшкәненне сизми дә калырсың. Мондый хәлләр булмасын өчен, үз атыңның холкын-фигылен белү кирәк. Кайбер ат өзәнге каешын бәйләгәндә, хәйләгә керешеп, корсагын кабартып куя. Тиктомалдан бөтен тәненне будырып йөрү кемгә рәхәт инде ул?!

Атны иярләгәч, тезгененнән алып, аны матур сүзләр әйтеп, мактый-мактый, җайлап кына абзардан алып чыгасың. Атыңның сул ягында торып, сафка басасың. Командирның "По коням!" дигән командасы ишетелүгә, ияргә уктай атылып менәргә тиеш буласың. Әлбәттә, тиешен төгәл үти алсаң. Нәкъ шушында башлана да инде ыгы-зыгының зурысы. Берәүләрнең аты хуҗасы менеп атланганчы ук кузгалып китә, икенчеләренеке атландырасы килмичә борсалана. Әнә, Макаровның кылычы өзәнге арасына кереп кысылган. Әгәр шулай эшләргә кирәк булса, син аны анда кертә дә, шушылай чыкмаслык итеп кыстыра да алмыйсың. Ә ул нииндидер могҗиза белән кергән дә кысылган. Аны алганчы вакыт уза, башкалардан артта каласың. Димәк, арт саннарын күтәрә алмый калганнар һәм, әлеге дә баягы, кылычларына абынып соңарганнар белән беррәттән атка атлану күнегүләрен кабатларга мәҗбүр буласың. "Мен дә төш, мен дә төш"ләр күз алларың карангыланганчы дәвам итә. Чөнки чын кавалерист атка "Эһ" дигәнче атланырга тиеш. Баста! Билендә кем утырганын, өзәнгене нинди кул тотканын ат бик яхшы тоемлый. Үзеңне аның хуҗасы итеп таныта алмасаң, ул сине санламый, кушканыңны үтәми башлый. Син аңа карата

ягымлы да, шул ук вакытта таләпчән дә булырга тиешсен. Шундый жайдакларны ярата, тынлый атлар. Взводның калган өлеше манежга юнәлә. Аны берничә тапкыр әйләнеп, атларны "кыздыргач", уртага баскан командир озын чыбыркысын уйнатып, "Учебной рысью ма-а-арш!" дигән әмер бирә. Бу инде, жанкисәгем, синнән чын кавалерист ясауның мөһим бер этабы башланды дигән сүз. Жайдак, аякларын өзәнгедән чыгарып, туп-туры утырган хәлдә, үз авырлыгы белән арт санын бәрә-бәрә ияргә сикергәләргә тиеш була. Егылып төшүдән куркып, иярне кочып алган ботлар ышкылып сыдырыла. Шул рәвешчә, манеж тирәли әйләнәсен дә әйләнәсен. Артың ияргә төя-төя утырган жайдакның бер-берсенә бәрелә-сугыла биешкән эчке әгъзаларыннан бөтен шлаклары коелып, тәне чистарып кала.

Күнегүләрнең бу өлешен женем сөйми иде. Чөнки әле кичә генә чиләнгән күт битләре, суелып беткән ботлар төзәлеп тә житмәгән. Син аларның кипшерә башлаган элпәләрен ертып, кутырларын куптарырга тиеш буласың. Шулай берникадәр вакыт изалангач, юка, нәфис бот тиреләрең эт каешына әверелә.

Бу сырхауның ни дәрәжәдә булуы атына да бәйле. Әгәр ул песи кебек йомшак, яшь киленнәр сыман сак, жайлы йөрешле булса, син бәхетле, аттан ундым дип әйтә аласың.

Минем атым үзем шикелле тәбәнәк, көрән төстә, халкыбыз әкиятләрендә макталган кырыкмыш тайга охшаган иде. Төс-кыяфәте, буй-сыны кеше кызыгырлык булмагач, хужа табылмыйча, абзарда ята биргән. Монгол токымына тартым шушы атым шулкадәр сак, йомшак чаба иде ки, әйтерсең лә ул йөзеп кенә бара. Читтән карап торышка "шыксыз үрдәк бәбкәсе"нә охшаган булса да, күнегүләрне ул жаны-тәне белән бирелеп, зур тырышлык белән башкарды. Миңа калса, башкалардан көнләшеп, кечкенә булсам да, эчем тулы төш кенә дигән сыман йөри иде атым. Аның шушы күркәм сыйфатлары үзе кушаяклап томырылып чапкан чагында миңа корсагы астыннан өзәнге бавы буйлап икенче якка үрмәләп чыгарга һәм янәдән ияргә менеп утырырга, чабып барган шәпкә ат өстендә "кайчы" ясап, артка борылырга һәм мишеньга төбәп мылтыктан атарга мөмкинлек бирде. Иң авырлардан саналган бу күнегүләрне жиренә житкереп үтәүчеләр сирәк иде. Монда инде үземнең дә кечкенәдән үк агач башына оста үрмәләвем, спорт белән шөгыльләнүем файда биргәндер.

Әлбәттә, күнегүләрнең берсе дә жиңел түгел, һәрберсенең үзенә хас катлаулы ягы бар. Шул кыенлыкларны егетләрчә үтәр өчен түземлелек тә, максатчан кыюлык та, ихтыяр көче дигәне дә кирәк.

Менә без атларыбызны янәшә куеп, иптәшләребезнең киртә-чокырларны сикереп үтүләрен күзәтәбез. Алардан ерак түгел, чыбыркысын тотып, сержант Рөстәм Яушев баскан. Ул үзе бу күнегүләрнең барысын да зур осталык белән башкара. Гарнизонда аңа тиңләшерлек кеше юк. Аның көч-куәте ургып торган тимер мускуллары хәтта гимнастеркасы аша ташып чыккан. Алар һәрвакыт биеп торалар кебек. Ятимнәр йортында тәрбияләнеп үскән бу татар егете борынгы грек сыннары кебек, үзе бер сәнгать әсәре иде. Без күнегүләрне яхшы итеп башкарсак, аның какча йөзе ачылып, кыйгач иреннәре жәелеп китә. Әгәр инде булдыра алмасак, атланган аты өстендә үзенә урын таба алмый башлый. "Колбаса ты ливерная!"—дип орыша безне. Бу аның эчке бер әрнү белән әйтә торган сүзе.

Ниһаять, чират миңа килеп житте. Атымның муеныннан сөеп алдым да, без алга ыргылдык.

—Повод, отпусти повод!

Сержантның бу сүзләре аңыма барып житкәндә мин инде сикереп үтәсе киртәнең теге ягында тәгәрәп ята идем.

—Колбаса ты ливерная! Син аңгыра түгелдер бит, тагын кабатлыйм: атың сикерер алдыннан йөгән сабагын бераз бушата төшәргә кирәк. Югыйсә, атның алга сузылган муены сине иярдән йолкып, үзе белән ияртәчәк. Нәтиҗәсен үзең күрдең. Анладыңмы?

Мин җирдән күтәрелгәндә монгол атым, гаепле сыман башын түбән иеп, янымда басып тора иде. Без күнегүне кабатларга тагын чиратка бастык.

Чират Казан егете Олег Кардашовка килеп җитте. Аның аты минекенең нәкъ киресе инде: зур гәүдәле, адымнары эре, һавалы. Чапканда тоякларын лап-лоп басып, җайдагын сикертә-чөя. Шуңа да Олегның сыдырылмаган җире юк иде. Тәбәнәк буйлы бу егет үзенең айгыры өстендә чүрәкәй генә булып тоела. Бу күнегүләрне җаны-тәне белән сөймәгән Олег, атының ялына чытырдатып ябышкан хәлдә, киртәгә якынлашып килә. Хуҗасының өстенлеген санламаган айгыр кинәт алгы аякларын терәп туктап калды. Җайдак, ат сикерәсе киртә аша очып, җиргә барып төште. Сыртында сержантның зәһәр камчысын татыган айгыр да "эһ" дигәнче Олег артыннан сикерде. Ничек әле аның өстенә басмады хайван.

—Колбаса ты ливерная!—дип пысылдады сержант.

... Очларына талчыбык беркетелгән казыклар алдына килеп бастык. Бу күнегүне башта сержант үзе күрсәтеп бирде. Аңа карап торсаң, сокланмый мөмкин түгел. Ул ике кулына ике кылыч алып, өзәнгегә басты һәм үзе кебек елгыр кара атын кушаяклатып чаптырып китте. Аның яшен тизлеге белән ялт-йолт иткән кылычлары казык башларындагы талчыбыкларны кисеп тә төшерде. Алар өстән аска таба кыеклап шулкадәр оста киселгәннәр иде ки, әйтерсең лә моны кеше түгел, ә шушы эш өчен көйләнгән махсус станок башкарган! Ә мин бу күнегүне үти алмыйча изаланам. Йә атым казыклар рәтен узып киткән була, йә кылыч кулдан төшеп кала. Хәтта талчыбыкка суккан очракта да ул киселми, каһәр. Инде өзәнгегә дә дөрес басам шикелле, тезгенне дә атның башы бераз күтәрелебрәк торырлык итеп кыска тотам. Юк, булмаса булмый бит ул. Кабатларга, тагын, тагын кабатларга туры киләчәк. Минем эше булдыксызларны манежга көндезге йокыларыннан өзеп алып чыгалар. Башкалар ял иткәндә без, пешмәгәннәр, күнегүләр өйрәнеп интегәбез.

«Конная подготовка»дан соң, әйткәнемчә, тактика дәресләре башлана. Тешне кысып булса да, түзәсең инде.

—Запевай!—дип команда бирә командир.

—По долинам и по взгорьям
Шла дивизия вперед...

Җыр күңелләрне күтәреп җибәргәндәй итә. Кан саркып торган яраларның әрнүе онытылгандай була. Ул арада яна боерык ишетелә:

—Га-а-зы!!!

Противогазларны киеп, чокырларга төшеп яшеренәбез, таш артларына посабыз. Ул да булмый, "В атаку ма-а-арш!" дигән команда килә. Без, противогаз кигән йөзсез солдатлар, тауга ташланып, өскә үрмәли башлыйбыз. Противогазның ян-яктагы керешләре тир белән биткә чәпелдәп ябышкан, күз турындагы пыяласыннан эре-эре тамчылар тама, алда ни барын һич күреп булмый. Болай да 38 процент кислород җитешмәгән бу Мургаб җирендә противогаз бугазы аша саркып кергән һава гына көч бирә алмый. Тын кысылудан күз аллары караңгылана, анны югалткан кебек буласың. Противогаз керешен ияк астыннан умырып, берничә йотым саф һава сулап өлгерәсең. Моны командир күрсә, чираттан тыш наряд алдың дигән сүз. Ул, гадәттә, бәдрәф чистарту була. Анысын да әле солдатлар йокыга яткач эшлисең.

Ниһаять, тын бетеп, таш өстенә авабыз. Чалгы белән кыркып ташлангандай түнгән, хәлсез солдатлар тау өстеннән йә корсакларында шуышып, йә тәгәрәшеп, аска коелалар. Аларнын күзләре акаеп, тонып калган, йөзләреннән ермак-ермак тир ага.

Бераз ял итеп, хәл алгач, кайчандыр, бездән күп еллар элек хезмәт иткән солдатлар казый башлаган окопларны чокырга керешәбез. Әйе, әйе, без аны фәкать чокый гына алабыз. Чөнки монда көрәк батырып казырлык жир юк. Һәр тараф тау-таштан гыйбарәт.

Төшке аштан соң бер сәгать йокы ялы бирелә. Бу инде хәтере калмасын өчен генә йокы дип әйтерлек бер нәрсә була. Әле генә йокыга оеый башлыйсын, ул арада дневальныйнын "По-о-одъем!" дип кычкырган тавышы ишетелә. Кургашындай авырайган күз кабакларын сержантнын "Выходи строиться!" дигән сүзләре ачып жибәрә. Ике-өч минут үтүгә син инде командир билгеләгән урында сафта басып торасын. Әгәр аяк чолгауларын рәтләп урарга өлгермәсән, үзенә үпкәлә! Шунда ук ике сәгатьлек "Выше ноги, шире шаг!" дәресе башланачак. Устав кушканча йөрергә, гәүдәнне төз тотып, кулынны уң як чигәгә куеп, честь бирергә өйрәтәчәкләр. Әгәр шап-шоп итеп атлый алмасаң, бу дәреснең синең өчен дүрт сәгатькә сузылуы да бик ихтимал. Иптәшләрең рәхәтләнеп ял иткәндә гарнизон ишегалдын аркылыга-буйга "раз-два"га атлап йөрисен дә йөрисен. Армиядә шулай: белмәсәң—өйрәтәләр, теләмәсәң—мәжбүр итәләр.

Ләкин солдат тормышын ниндидер устав кысаларына гына кертеп бетереп буламы соң? Юк, һич тә юк! Чөнки тормыш дигәнең гажәп катлаулы, бихисап киң төшенчә. Әллә нинди устав-кагыйдәләр язсан да, анын үз тәртибе, үз кануннары бар. Юк, мин боларны кемнедер куркыту, гайрәтен чигерү өчен язмыйм. Солдат хезмәтен һич кенә дә каралтып күрсәтәсем килми. Иза-газаплар, кыенлыклар кичеп, авырлыкларны шыншымый-зарланмый гына жиңеп чыккан яшь егет әнә шулай ир булып чыныгып житә. Андыйларны тормышның зилзиләләре, жил-давыллары да куркыта алмас. Безнең бабайлар юкка гына:

> Әй, нужалар, нужалар,
> Безнең баштан узалар.
> Нужа күрмәгән егетләр
> Нужадан да хуже алар,

—дип жырламаганнардыр.

Жылы, иркен бүлмәләрдә "морзянка" тукылдатып утырган "армия интеллигенциясе"—радистлардан һич кенә дә көнләшмим. Тормышта һәр кешенең үз урыны бар.

Шулай ук һәр нәрсәнең унай һәм тискәре яклары була. Радистлар кичләрен дә һаман шул "морзянкалары" белән баш катырсалар, без, якташлар, бергә жыелышып гармун уйнаштык, биештек, көлештек. Әйе, солдат дигәч тә, ул да туктаусыз эшләп торучы механизм түгел, анын да ял сәгатьләре бар, ул да, башкалар кебек үк, уйный-шаяра, көлә-күнел ача. Андый ял сәгатьләре, гадәттә, кичке аштан соң була. Көндезге тузаннарны кагып, күнитекләрне көзгедәй ялтыратып, чиста гимнастерка киеп, казарма алдындагы эскәмияләргә чыгып утырабыз. Памирда кичләр салкынча булса да, әлегә яшьлек дәртен сүндерә алырдай көч тумаган! Шушы күнелле жыенда сөйгән ярлардан килгән хатлар укыла, кадерле хатирәләр искә алына, барсы да уртага салып сөйләшенә, хәл ителә. Монда солдат та, командир да бер дәрәҗәдә калып, якын кешеләргә әйләнә. Шуна күрә политбүлек офицерлары мондый чакларда безнең арада буталып, үзләренә кирәкле мәгълүмат жыя иде.

Безнең взводта Сарман якларыннан Ильяс Ибәтов дигән егет хезмәт итте. Урта буйлы, нык бәдәнле, чуерташтай шома-тыгыз тәнле, һәрвакыт көләч йөзле, бик тә ягымлы кеше иде ул. Күзләренең зәңгәрлеге шулкадәр саф, карашы якты иде ки, тутырып бер караса, офыклар киңәеп киткәндәй була. Ильяс—гарнизонның рухы. Гомерлек юлдашы хромкасын бер сайратып җибәрсә, бөтен гарнизон аякка баса. Татар егетләре бигрәк тә инде. Мин дә бит кечкенәдән үк тальян гармун уйнап үскән малай. Икешәр тәүлеккә сузылган туйларның башыннан ахырына кадәр туктаусыз күрек тарткан чаклар да булгалады. Ләкин минем уйнау белән аның уйнавының чагыштырмасы—җир белән күк арасы. Ул һәр көйнең бормалы яшерен почмакларына кереп, аның асыл мәгънәсен гаҗәеп аһәңгә төреп яңгырата. Шуның өстенә ул көйләрне үз ягының үзенчәлекләре, башка төбәкләрдә булмаган аерым бормалар-мелизмнар белән дә оста итеп бизи белә. Ул "Шахта көе"н сызып җибәрсәме? Һә-ә-әй! Көйгә салынган моң-зарлар, сагыш-сагынулар бәгырьләрне телгәләп үтә. Ильяс бу авазларны шахталарның караңгы, тирән базларына төшеп, кешеләрнең үги-ятим көнелләреннән алып менә кебек. Ә инде дәртле бию көйләре уйный башласа, сикергәләп биеп киткәнеңне сизми дә каласың. Без атта йөргәндә кырылган-сыдырылган җирләребезне онытып, күмәкләшеп биибез, сикерешәбез. Шунысы гаҗәп: теге, "армейская интеллигенция" безнең бу тамашада катнашмый иде. Килгәннәре да, читтән генә карап торудан ары узмады.

"Армиягә барсаң иде
Сөйгән ярларың белән",

—дип җырласалар да, анда күзләрен тәрәзәдән алмый, кайнар ашын суытмый көтеп торучы кадерле әниең дә, кочагын җәеп каршы алучы сөйгән ярың да юк шул. Әзергә-бәзер булып, "ашау—байдан, үлем—Ходайдан", дип кенә ята алмыйсың. Бөтен эшне дә үзеңә башкарырга туры килә. Ашарына да пешерәсең, керен дә уасың, ертыгын да ямыйсың, төймәләреңне дә тагасың. Казарманы да, кунак көткән хуҗабикә кебек, ялт иттереп юып куясың.

"Әллә каян күренеп тора,
Солдатта булган диләр",

—дип язган бит, әнә, шагыйрь дә.

Бу бигрәк тә чик сакчыларын күздә тотып әйтелгән кебек. Аларның хезмәте—үзләре генә белергә тиешле серле хезмәт. Монда чит-ятларның булуы мөмкин түгел. Без тәүлекнең теләсә-кайсы вакытында чик сакларга китәбез. Күктән таш яуса да, сакта булабыз. Бездә—катгый хәрби тәртип, аптекадагы кебек төгәллек. Хәтта ат абзары да зур тырышлык куеп, вакытында чистартылган булыр. Без ул якын дустыбызны вакытында ашатабыз, эчертәбез, тәннәрен кыргычлый-кыргычлый чистартабыз, юабыз. Командирның ап-ак чүпрәге ат тәненә ышкып алганда аз гына тапланып китсә дә, бу кыру, чистарту, юуларны кабат-кабат башкарырга мәҗбүр булабыз. Атланып йөрисең икән—тиешле хөрмәтен дә бир, рәхмәтле дә була бел. Һәм белә дә идек. Ашханәдә бирелгән шикәребезнең бер өлешен атка каптырдык, кесәләребезне тутырып ипи сыныклары алып килергә дә онытмадык. Үткән-барганда, урлап булса да, солы салып чыгу—гадәти күренеш иде. Ә инде үзеңне ат абзарына дневальный итеп билгеләсәләр, Такташның Мохтар карты кебек, солыны да, печәннең йомшак, хуш ислесен дә үз атыңа күбрәк саласың. Бу көнне ул синең кунагың була.

Мин дневальный булган көннәрнең берсендә ат абзарына Ильяс килеп керде. Тәмәке кабызып, хәл-әхвәл сорашып торган бер мәлдә, Ильясым йөзен читкә борып, үксеп елап җибәрмәсенме!

—Нәрсә булды? Әллә өйдәгеләрдән берәр күңелсез хәбәр алдыңмы?

—Юк. Барысы да исән-сау, Аллаһыга шөкер,—ди бу.

—Соң, нәрсә дип елыйсың, тик торганда?

—Рәис дус, мин ат абзарында аунап үскән малай, үлеп яратам мин аларны. Хәтта менә шушы тирес исе дә рәхәтлек бирә, күңелем җырлый, җаным бии башлый сыман. Әгәр мөмкин булса, мин ат абзарыннан бер дә чыкмас идем. Ә сержант мине монда җибәрми. Башка нарядларга куйса куя, ә монда—юк. Сәбәбен һич кенә дә аңламыйм. Нәрсә дип болай эшли ул? Югыйсә, гаебем дә юк бит инде.

Мин нәрсә дип әйтергә дә белми аптырап калдым. Кара бу гаделсезлекне. Мине ниндидер хохол ефрейторы башымны кухнядан чыгармый газаплады, Ильясны шашып яраткан атлары янына җибәрми иза чиктерәләр. Сержантыбыз үзебезнең татар егете ләбаса. Нәрсә бу? Сержант Яушевка ни җитми?

Һай, бу кеше дигәннәрең, нигә шул кадәр рәхимсез була икән? Шушы өч көнлек дөньяның ләззәтен тоеп, бер-береңә игелек күрсәтеп яшисе генә бит, югыйсә. Юк шул, үзең кебек кардәшеңә этлек күрсәтеп, кыерсытырга кирәк.

Бераздан Ильяс тынычланган кебек булды. Ул тагын тәмәке төреп кабызды.

—Рәис дус, әгәр ачуланмасаң, ат асларын үзем чистартыймчы?

Мин нәрсә дип әйтергә дә белми торган арада, Ильяс себерке, көрәк алып, эшкә дә керешәте. Мин аның житезлеген, өлгерлеген күреп, сокланып карап тордым. Ул бу эшләрне шул кадәр оста итеп, рәтен-җаен белеп башкарды. Ильяс эшне җиренә җиткереп, булсын дип, үзенә бер төрле канәгатьлек алып эшли. Гармунында уйнаган кебек итеп. Ул мина төне буена житәрлек эшне төгәлләп тә куйды. Бер очтан атларга печәнен дә салып чыкты.

—Син дневальный булып торган чакта килсәм, ничек булыр икән?

—Әлбәттә кил, Ильяс дус. Мин шат кына булырмын. Ат җанлылык ерак бабаларыбыздан мирас булып, буыннан-буынга күчеп килә татарга. Бу күркәм гадәтләрне безгә Бөек Дала үзе иңдергән!

### Төнге маҗара

... Буран котырганнан котыра гына барды. Мондагы бураннар бездәгечә түгел. Бездәге бураннарның, кем әйтмешли, өйрәсе сыек. Аның бөртекләре сирәк тә, ул үзе дә үтә күренмәле кебек. Алдыңдагы әйберләрне әле шәйләп була...

Ә мондагы буран исә шулкадәр куе, тыгыз булып бөтерелә ки, әйтерсең лә кар югарыдан ишелеп-ишелеп төшә сыман. Ул бөтен тирә-якны тәмам каплап, сырып, чорнап ала ки, тоташ кар болытларының эчендә, уртасында калган шикелле буласың. Болытларны тишеп күккә ашкан, башлары мәңгелек кар вә боз белән капланган тау түбәләреннән җилләр куптарып тузгыткан катламнар өермә булып өстеңә ябырыла, күз ачып йомганчы ул сине ап-акка төреп, "кыш бабай" ясап куя. Син башкаларга күренмәс халәткә керәсең, юкка чыгасың...

* * *

Дүрт айлык әзерлек курслары үткән яшь солдатлар белән тулы машинабыз, юлдагы чүмәлә-чүмәлә булып өелгән кар көртләрен ерып чыга алмыйча, туктап калды. Безне озата баручы капитан Вершинин, лейтенант Волков солдатларга шәхси әйберләрен алып, машинадан төшәргә куштылар.

һәрберебезнең юл капчыгында ике күлмәк азык-төлек—икешәр "кирпеч" ипи һәм кием-салым бар иде.

Безне тезеп бастырдылар. Капитан Вершинин, машинабызның алга таба бара алмаячагын әйтеп, безне бишәр-бишәр итеп төркемнәргә бүлде. Без, иң якын заставага кадәр булган житмеш-сиксән чакрым араны, ясле балалары кебек кулга-кул тотынышып, аерылмыйча, бер-беребезгә ярдәм итеп барырга тиеш идек. Ул үзе юл ярып алдан барачагын, ә сержант арттан безгә күз-колак булачагын әйтте. Берәр хәл була калса, шунда ук үзенә житкерү кирәклеге турында да кисәтте. Бер кат тәмәкеләр тартып, юл тотарга әзерлегебезне белгәч:

—Минем арттан!—дип команда яңгырады.

Биштәрләребезне ингә асып, тирә-ягыбызны аклык урап алган кар өермәләре эченә кереп чумдык.

Капитан безне төркемнәргә бүлеп, арадан беребезне башлык итеп билгеләсә дә, юл башында тез тинентен, тора-бара исә бил тинентен үк кар ерып бару, әле беребезнең, әле икенчебезнең егылып китүе яки арып утырып калулары бу бишлекләрне чуалта барып, ары таба рәтләребезне бөтенләйгә таркатып бетерде.

Кар торган саен ныграк, буран аның саен көчлерәк котыра. Тирә-якны инләп-буйлап кочып алган бу табигать шаукымы көртләр ерып, көч-хәл белән билгесезлеккә таба атлаган, изрәгән солдатларны бөтенләй аяктан екты. Егылган-чүгәләгәннәрне "әһ" дигәнче күмеп тә китте. Кешеләрне жыеп, аларны берәр түбә астына тупларга мөмкинлек тә юк иде шул... Бу хәлдә аларны бәладән йолып алып, коткарып калу берәүнең дә кодрәтеннән килмәс иде. Язмыш кочагына ташланган без мескеннәрнең киләчәге бары тик үзебезгә генә бәйле иде. Чыдам-түземлегебезгә, рухи халәтләребезнең ныклыгына, жан-тәннәрнең көч-куәтенә бәйле иде... Бу—сынау, табигый сайланыш иде! Егерме яшьлек егетләрнең шушы кыенлыкларга әзерлеге ничек булган? Монысын иртәгесе көн күрсәтер... Бүген әле берәү дә берберсенә ярдәм итә алмый. Чөнки ул үзе шундый ук ярдәмгә мохтаж.

Әллә юлыбыз башка якка борылды, әллә инде жил үзенең юнәлешен үзгәртте, таш араларыннан аждаһа кебек сызгырып, битләрне кыздырып-яндырып әфган жиле исә башлады. "Әфгани" дип Памир тауларын инләп-буйлап искән жилгә әйтәләр. Ул үзенең әчелеге белән, куырып-өшетеп ала торган рәхимсез салкынлыгы белән дан тота. Ул сине, үтәли үтеп, желекләренә төшә, тәннәреңне ятып ялый. Аннан бары тик каядыр кереп качып котылып кына була.

Шул мәрхәмәтсез аркасында күтәрелгән шинель якаларыбыз исә берберебез белән әзме-күпме булган элемтә-аралашуларыбызны да киметте. Вакыт-вакыт нindидер авазлар ишетелгән кебек булса да, ул авазларның кай тарафтан килгәнен абайлап булмый. Бу авазлар, жил белән кушылып, бертоташка әйләнеп, юк була иделәр. Әйләнә-тирәмдә кыймылдаган солдаткарачкылар торган саен сирәгәя барды, кар-буран аларны кочагына алып, йота торды. Әйе, бүген берәү дә янәшәдәге иптәшенә, аны кочаклап бергә катудан башка, ярдәм күрсәтә алмый иде. Ул үзе дә шундый ук ярдәмгә мохтаж хәлсез бәндә бүген... Алдан әйдәп баручы капитан да, арттан күзәтеп килергә тиешле лейтенант та юк иделәр инде. Тирә-якта бары тик билгесез бушлык та, язмышың белән син берүзең...

Инде бу хәлләргә кырык алты ел гомер үткәч, "Ни-нәрсә уйладым икән ул вакытта мин?"—дип, үз-үземә сорау бирәм. "Өшеп-катып үлүем шушы икән",—дипме, әллә—"Ничек кенә булса да аяктан егылмаска кирәк!"—дип микән? Тәгаен: "Аяктан егылмаска кирәк!"—дигәнмендер. Шуңа күрә шинелемнең күтәрелгән якасына ышыкланып, атладым да атладым...

Берзаманны, атылган кош сыман, лапылдап барып төшкәч... Карасам— боз өстендә ятам икән. Әйе, табадай шоп-шома боз өстендә! Карангыда анын зурлыгын абайлап булмаса да, күз күргән кадәрле өлеше, анын куе зәнгәр өслеге караңгыга кереп югала. Боз өстеннән җәяүле буран йөгерә. Яр кырыйларын кар каплап киткән.

Шул хәлдә күпме ятканмындыр, инде черем итә дә башлаган кебек идем, янымда гына шапылдап төшкән тавышка айнып киттем. Йокы килүдән авырайган күз бәбәкләремне ачар-ачмас кына тавыш килгән якка карадым. Анда минем шикелле үк бер солдат ята иде. Йә Аллам, бу мәхшәрдә миннән гайре тере кешеләрен дә бар икән бит әле! Без бер-беребезгә таба шуыша башладык. Борыннарыбыз килеп төртелгәч кенә, үзебезнен Казаннын Киров районы егете Олег Кардашовны танып алдым. Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше бер очраша дигәннәре шушы була торгандыр инде. Олег белән әүмәкләшә-әүмәкләшә күрештек. Бу икебез өчен дә Аллаһынын чиксез рәхмәте белән, анын илаһи кодрәте белән эшләнгән изгелеге иде. Никадәр бәхетле идек без бу минутларда! Әгәр без икебез дә, башкалар кебек, кар астында йоклап калмаган икәнбез, димәк, тәндә көч тә, тере калырга өмет тә бар әле?!

Олег белән бер-беребезне күптәннән, әле военкомат юлламасы белән радист-элемтәче курсларында укыганда ук танышып, белешә идек. Еш кына Петров паркында кичләрен очраша идек. Анын фамилиясенен нигезендә без төркинен "кардәш" сүзе ятса да, ул үзе—чеп-чи урыс. Ләкин төсе-бите белән иллә дә мәгәр, кисеп каплаган татар инде. Димәк, кайчандыр, анын ерак бабасы безнен кавемнән булган. "Һәр урыснын тамырыннан татар каны да ага",—диюләре шулдыр инде. "Жан тартмаса да кан тарта",—дигән халкыбыз. Алга китеп булса да әйтим, хәрби хезмәтне үтәп кайткач та, без бу дуслыкны өзмәдек. Ул дуслык бүгенгә кадәр, үзара хәбәрләшеп, хәл-әхвәлләребезне белешеп-сорашып, кайгы-хәсрәтләребезне уртаклашып дәвам итә.

Олег белән бер кат тәмәкеләр көйрәтеп алгач, бер-беребезгә тотынып-ябышып дигәндәй, аякка бастык. Аста ялтырап боз ята... Каян килгән монда—дингез өсте тигезлегеннән өч мен сигез йөз метр биеклектә булган тау араларына—мондый күл?! Гажәп бит! Һәм бу турыда безгә берәүнен дә әйткәне булмады.

Бер-беребезгә сыенышып, итекләребезне боздан шудырып кына диярлек итеп, алга киттек. Ләкин боз барыбер үзенекен итте. Без әледән-әле егыла тордык. Егылган саен, кулыма тоткан консерваларымнын берәрсе тәгәрәп, каядыр китеп югала тордылар. Әллә күлне урап йөрдек инде, әллә ул үзе шулай зур булды, без шактый вакытыбызны мәтәлә-тора үткәрдек. Күлнен читенә житкәндә итле-боткалы консервалар да юк иде инде. Рюкзактан нибары бер бөтен ипи һәм куертылган сөт консервасы килеп чыкты.

Һәрнәрсәнен бер унай ягы булган кебек, исән калган ипиемне култык астына кыстырып, буш кулларымны шинель кесәләренә тыгып жылыта башладым. "Погранпаек" дип аталган бу ашамлыклар, без, солдатларга мулдан бирелә иде.

* * *

...Без бераз ял итеп алырга туктадык. Әйләнә-тирәбездә бер генә шәүлә-карачкы да күренми, бер генә жан иясенен дә барлыгы сизелми. Тирә-як буп-буш, аны дөм караңгылык чолгап алган. Жилкәләребезне жилгә куеп, Аллаһынын бер үзенә тапшырып, янә китеп бардык. Безнен исәп буенча, күлнен яр буйлары кыя-тауларга килеп тоташырга тиеш. Ул шулай булып чыкты да. Кая барганыбызны белмичә йөри торгач, ниндидер ташларга

килеп абындык. Без коры җирдә! Алдыбызда кар белән капланмаган каракучкыл кыя басып тора! Ә кыялар куышсыз-ярыксыз булмый. Бөтен өметебез шундыйрак бер урын табып, бу аяусыз җил-бураннан яшеренеп төн уздыру, ял итеп алу иде. Биштәрләребезне таш өстенә куеп, шундый оя-куыш эзләргә керештек. Һәр биш-ун минут саен әйберләребезне куеп калдырган урында очрашырга дип сүз куештык. Олег—сул якка, мин исә абына-сөртенә уң якка китеп бардым. Карны капшап ерак та үтмәдем, аягым ниндидер куышка кереп китте. Чүгәләп, теге чокырны актарырга тотындым. Актарган саен эчкәрәк үтә бардым. Эчкә үткән саен куыш авызыннан кергән карлардан ераклаштым. Һәм таш-диварга килеп төртелдем. Кесәмнән шырпы алып, оямны яктыртып җибәрдем. Әйе, бу нәкъ без хыялланган куыш иде! Ул дүрт-биш метр озынлыкта булып, уң як почмагындагы кул сыярлык ярыктан җылы дымлы һава өрә. Конуска охшаган түшәме биеккә, карангылыкка кереп югала. Кыскасы: Аллаһының рәхмәте белән юлыккан менә диган кыя ярыгы иде бу!

Шатлыгымны әйтергә Олег янына ашыктым. Ул да борчылып мине көтеп тора иде инде.

Ниһаять, без оябызга кереп, анын туфраклы, комлырак бер почмагын балчык-ташлардан арындырып, биштәрләребезне астыбызга салып җиргә аудык. Йә Аллам, үлем тырнагыннан котылу шатлыгы минутларын да күрергә насыйп иттең. Тормышнын гүзәллеген-күркәмлеген, гомернең кадерен-кыйммәтен нәкъ менә шушындый кискен, язмышын хәл ителгән вакытларда гына тоясың да икән ул. Аллаһы Тәгалә үзенең илаһи галәмәтләрен күрсәтеп, адәмнең иман ныклыгын, калебенең сафлыгын сыный. Әгәр зур гөнаһларыбыз булса, бу оя-куышны безгә юлыктырмас та иде ул. Монда кар-буран да юк, "әфгани" да йөзләребезне, тәннәребезне яламый. Мин, аякларымны сузып, Казанда тегелгән бүрегемне батырыбрак киеп, башымны кыя ташына терәдем. Йә Аллам, нинди рәхәтлек! Бөтен тәнемне инләп-буйлап җиңелчә кайнарлык йөгереп үтте. Салкыннан изрәгән битләрем кызыша башлады. Кызулык, әкрен-әкрен төшеп, аяк бармакларымны да кочып алды. Миңа шулкадәр рәхәт булып китте. Гомерем эчендә сөйгән кызыма өйләнеп, балаларым туу шатлыгын кичереп тә, мондый шатлыклы рәхәтне тоймадым шикелле. Бу—яңадан туу шатлыгына бәрабәр иде...

Култык астымда йөргән ипине сындыргалап, Олег белән тамак ялгап алырга булдык. Ул салкыннан таш кебек каткан булса да, миңа гаҗәеп тәмле тоелды. Олег үзенең консерваларын, минем кебек, югалтмаган. Ул аларны рюкзагына салып куйган икән. Тәмәке кабыздык. Сәгать төнге өч тулып килә. Димәк, без тугыз сәгатькә якын кар-буран ерып йөргәнбез! Тугыз сәгать шушы котырган өермә-давылда йөреп тә исән калганбыз! Бу, һичшиксез, зур бәхет иде. Әти-әниләребезнең безгә биргән хәер-догасы, үзебезнең ниндидер яхшылыкларыбыз өчен зур бүләк, мәрхәмәт, шәфкать һәм олы гыйбрәт тә иде бу.

Без иптәшләребез өчен дә борчылдык. Җае чыккан саен, сүз алар турында кузгалмый калмады. Менә хәзер дә, үзебезнең куыштан канәгать булган хәлдә, ачынып аларны искә алдык.

Кайда алар, күпмесен кар-буран күмеп киткән икән? "Ярый ла безнең кебек берәр куышка кереп поскан булсалар?"—диде Олег.

Әйе, кайда соң башкалар? Таң җилләре нинди хәбәрләр алып килер? Хәвефле булмасмы алар? Нигә шушылай чәчелешеп, таралышып беттек соң әле? Кем гаепле бу афәт-фаҗигагә?

Шинель якаларын күтәреп, без тынып калдык. Көне буе буранда иза чигүләр яхшы ук талчыктырган иде—озакламый тирән йокыга да

талганбыз.

Берничә мәртәбә йокымнан айнып, анга килгәндәй булсам да, ихтыяр көчен туплап, изрәгән тәнемне жыярлык, күзләремне ачарлык көч тапмадым. Бөтен тәнем куәс кисмәгеннән ташып чыккан камыр сыман иде. Бу, әлбәттә, кичәге арыганлык галәмәте. Шулай да, каты туңудан калтыравым, дерелдәвем төртеп уяткан кебек итте. Кар ерып йөрүдән лычма су булган чалбар балаклары ботларыма, тезләремә ябышып каткан иделәр. Аяк бармаклары да оеган. Итекләремне бер-берсенә суккалап маташсам да, файдасы тимәде. Аякларым—таяк сыман. Мәгарә ташларына ябыша-тотына аякка басмакчы булдым. Ләкин алар гәүдәмне тотарлык хәлдә түгел иде. Мин тәгәрәп киттем. Хәрәкәтләнергә кирәк! Озак тәгәрәдем мин. Кул-аяк белән төрле хәрәкәтләр ясый-ясый "кыздырдым" үземне. Озакламый аякка да баса башладым. Тик чалбар ябышып каткан тез урыннары гына әрни, әчетеп сызлый иделәр. Алар өшегән икән. Җәрәхәтләрнең җөйләре, ул хәвефле көннәрнең аяныч хатирәләре булып, бүген дә саклана.

Мин Олег янына килеп:

—Туңмыйсыңмы?—дип сорадым.

—Юк, нормально,—диде ул.

Инде таң аткан, аның яктылыгы куышыбызга да үтеп кергән иде. Мин борылып, янә Олегка карадым. Үземнең акылсызлыгымны күреп,маңгаема сугып куйдым. Менә нигә туңмый утыра икән ул, мәйтәм. Аның өстендә йон тукымадан тегелгән калын кышкы кием иде. Ә мин, җүләр, бу киемнәремне биштәремдә, көне буе җилкәмә асып йөрдем. Шушы җүләрлегем аркасында, биштәремә сыймаган консерваларымны да югалтып бетердем. Ну, бу татарлыкны! Юкка түгел икән: "Татар акылы төштән соң"—дип әйтүләре. Иске яңаны саклый, имеш.

Өстемне алыштырдым. Өр-яңа күлмәк-ыштан кидем, аяк чолгауларын да яңалары белән алыштырдым. Менә кайда икән ул рәхәтлек! Ул минем биштәремдә яткан икән ләбаса. Ярар, "үткән эшкә салават"—диләрме әле? Әүвәлнең ахыры хәерле булсын! Тез капкачларым бераз сулкылдап сызлый сызлавын, ләкин түзәрлек. Мин аларны аяк чолгауларым белән ышкып, әйбәтләп бәйләп куйдым. Төзәлерләр, иншалла. Иң мөһиме—мин исән. Димәк, тормыш дәвам итә дигән сүз.

Мүкәли-мүкәли яктылык бөркелгән якка үрмәләдем. Тышта буран басылган, тирә-як ап-ак карга төренгән. Тик тырпаеп торган текә кыя яңаклары гына үзләренең кызыл-саргылт төсләрен саклап калганнар. Мин борылып үзебезнең шәфкатьле кыябызга карадым. Безне кочагына алып, җил-давыллардан саклап калган бу мәһабәт табигать һәйкәл-хәзинәсенә башымны иеп, ихтирам белән сәлам бирдем. Аның тирән ермаклар, уентык, ярыклар белән чуарланган, киртләч-киртләч сырлар белән бизәлгән йөзе елмаеп куйган сыман булды. Мәчет манаралары кебек очлаеп күкләргә ашкан сөңгеләре кузгалып,чайкалып киткәндәй тоелды. Әйтерсең, ул да миңа сәламли иде кебек.

Куышыбыз ике тау култыгы арасында булып чыкты. Бер якта кыяның ялангач ярлары тырпаеп торса, каршы якта ап-ак карга төренгән тау сузылган. Ул һаман биегәя барып, аның башлары болытлар арасына кереп югалган. Шуны да әйтү кирәктер: таулардагы карның җете дә ак булуы өстенә, ул әле гаҗәеп тә чиста, пакь тә. Чөнки монда табигать үзе сабый хәлендә, үзгәрешсез саф булып калган. Карның энҗе кебек җемелдәп торган аклыгыннан-сафлыгыннан күзләр камаша. Кояшлы көннәрдә аңа карап та булмый. Күз аллары тимер эретеп ябыштырганда бөркелгән ялкынга караудан чагылган, өтелгән кебек, әлҗе-мөлҗе килә башлый. Әгәр вакытында дару тамызмасаң, һич югында кисеп бәрәнге телеме куймасаң,

төне буе йокы бирми кырып чыгачак. Шуңа күрә, без кара күзлектән йөри идек.

Әйләнә-тирә тып-тын. Шылт иткән тавыш та юк. Кайда безнең иптәшләр, озата килүче офицерлар кайда? Алла белсен... Ак юрганнарга төрелгән гигант кибәннәргә охшаш таулар арасында бары тик мин. Мин—тауларныкы, таулар—минеке. Алар басып тора, мин дә басып торам. Тып-тын. Мондый шомлы сихри тынлык бары тик монда гына булуы мөмкин.

Тәмәке кабызган шырпымны ыргытканда күзем карга батып кергән чокырларга төште. Тукта дим, бу кеше эзләре түгелме сон? Дөрес, аларның күбесен буран күмеп киткән. Ләкин аларнын яртылаш күмелгәннәре дә шактый. Бу чокыр-уемтылар иптәшләребезнең аяк эзләренә бик тә ошаганнар лабаса. Мин аларның формаларына карап, юнәлешләрен чамаладым һәм эзләр буенча киттем. Алар мине шушы ук кыяның бездән әллә ни ерак булмаган борылышындагы тау тишегенә алып килделәр. Әйе, бу безнең эт оясы түгел инде. Күзгә ташланган өлеше дә зур залны хәтерләтә. Аның киртләч-киртләч түшәмнәреннән зур-зур имчәкләр аска сузылган. Диварларын һәм аяк асларын тоз сыман матдә каплап алган. Һавасы гаҗәеп саф булып, сихәтле хуш ис бөркелеп тора.

Мине үзебезнең Казан егете Әхмәдуллин Солтан кочагын җәеп каршы алды. Сүз уңаенда шуны да әйтим: ул менә дигән шофер иде. Хезмәтен тутырып, бүген-иртәгә өйгә кайтырга әзерләнеп йөргәндә... машинасы белән упкынга төшеп, фаҗигале рәвештә һәлак булды. Мин, исән-сау кайтып, әти-әнисенә, туган-тумачаларына хәлне бәйнә-бәйнә сөйләдем. Алар мине үз иттеләр, уллары кебек яраттылар. Бу дуслык дистә еллар шулай дәвам итте...

Без Солтан белән солдатка алынып, поездга утырганның беренче көненнән үк танышып, дуслашып киткән идек. Ул Казанның чыршы, нарат, каен агачлары белән урап алынган иң гүзәл, иң сөйкемле урыны саналган, бөтен Казан халкын җәен-кышын үзенә җәлеп иткән, үзенә тартып торган, тирә-ягын һәрвакыт шыгрым тулы ял итүче халык чолгап алган Тирән күл буендагы йортларның берсендә яшәгән. Әтисе Һидиятулла абзый сугышка киткәнчегә кадәр һәм фронтта бер аягын югалтып кайткач та, урман каравылчысы булып эшли. Әнисе Галимә апа иренә булышып, һәрвакыт ярдәм итеп яши. Абыйсы Мөнир, энесе Госман, сеңлесе Сания ул елларда әти-әниләре белән бергә торалар. Алга китеп шуны да әйтим: хәрби хезмәттән соң мин бу күркәм гаиләдә бик еш булдым. Алар мине үз уллары, үз туганнарыдай итеп, якты чырай белән каршы алдылар, хәзинәдә барын куеп сый-хөрмәт иттеләр. Мин дә аларга гаиләмә кайткандай килә идем.

Солтан бервакытта да алдый, ялганлый белми торган, гаҗәеп эчкерсез кеше иде. Ул энҗе кебек ап-ак тешләрен күрсәтеп көлгәндә, елмайганда тирә-якка ямь бөркелә, аның яшькелт күзләре нур сибә сыман. Битендәге беленер-беленмәс сипкелләре күктә йолдызлар җемелдәгән шикелле булып китә. Очлары чак кына өскә таба бөгелеп килгән озын керфекләренең салмак кына җилпеп торулары кешеләрнең күз карашларын үзләренә бәйләп куя. Ул зур гәүдәсен бераз алга сөреп, аякларын як-якка җәеп атлар. Аның адымнары һәрвакыт эре, нык булырлар. Иң яратмаган шөгыле—стройда йөрү иде. Ул анда йөри дә белмәде. Шоферлар курсына солдатлар җыялар дигән хәбәрне ишетүгә, ике дә уйламады, шунда җибәрүләрен сорады. Курсны яхшы билгеләренә генә тәмамлаган, аз сүзле, басынкы холыклы, эшен яратып, җиренә җиткереп эшләүче Солтанга ГАЗ-69 машинасы бирделәр. Ул отряд офицерларын йөртүче булып китте. Аның машинасы һәрвакыт төзек, чиста булды. Үзе дә пөхтә киенеп йөрергә яратты. Мин

аны бормалы-сырмалы, төпсез упкыннар кырыеннан, менә-менә өскә ишелеп төшәр сыман тоелган кыяларга сыланып үткән Памир юлларына хәерле юл теләп озата һәм исән-сау кайтуына шатланып каршы ала идем. Аның юлга һәр чыгуы күңелемә шом, борчу сала иде. Әйтерсең аны ниндидер хәвеф сагалый кебек тоелды. Мин һәрвакыт аның өчен куркып тордым. Солтан да мине ышанычлы дусты итеп санады. Без, бертуганнар шикелле, бер-беребезне хөрмәт итеп, кирәк чакта яклап, шатлык-кайгыларыбызны уртаклашып, уй-хисләребезне бүлешеп хезмәт иттек. Безнең бу дуслыгыбыздан көнләшүчеләр дә юк түгел иде. Эчкерсез шушы дуслыгыбыз тәэсирендә туган уй-хисләремне шигырь юлларына тездем:

Таулар белән таулар күрешмиләр.
Кеше белән кеше очраша.
Акыл белән акыл, хис белән хис
Табышканда җаннар сайраша.

Тау астыннан чыккан саф чишмәләр
Инешләргә килеп кушыла.
Җан тартканнар, ихлас яратканнар
Дуслар була, ишкә куш була.

Авыр шөгыль тауга менүләре,
Урап үтә аны бүтәннәр.
Тик синең күк кыю ир-егетләр,
Тәвәккәлләр—тауга менгәннәр!

Болытларга ашкан кыя-таулар
Тоташканнар кочып бер-берен.
Яшик әле, дустым, җанга салып,
Таулар холкын, таулар гомерен.

... Бу хәбәр бөтен отрядны тетрәндерде. Туганым кебек кадерле дустым, якын кешем Солтан юл фаҗигасенә тарыган икән бит. Алай гына да түгел, ул һәлак булган, ул үлгән. Ышаныргамы моңа, әллә юкмы? Бәлкем әле... Бу коточкыч хәбәрне ишетү миңа гаҗәп авыр булды. Күз алларым караңгыланып китте, башым мингерәүләнде. Әйтерсең, кемдер аңа күсәк белән орды. Ничек булган бу афәт? Әле иртән генә күрешкән идек ләбаса. Бернинди дә хәвеф-хәтәр булыр кебек түгел иде бит. Кайгыдан әрнегән җаныма, хәсрәттән сыкранган күңелемә сихәт таба алмыйча, мин каршыдагы тауга менеп киттем. Үземне җиргә басып түгел, һавада кангырып очып йөргән кебек тойдым. Сагышларым белән кайтып кергәндә көн кичкә авышкан, солдатлар казармага җыелган иделәр. Алар төркем-төркем утырышып, акрын гына бүгенге фаҗига, Солтанның аяныч һәлакәте турында сөйләшә иделәр. Взвод командиры Дондышны шоферлар урап алган. Мин дә алар янына килеп бастым. Барыбызның да башлары түбән иелгән, бер-беребезнең йөзләренә туры карарга кыймый, гаепле кешеләр шикелле тын гына торабыз.

—Хәзергә фаҗиганең ничек булганын тәгаен белмим. Радиограммада Солтанның һәлак булганы турында гына әйтелгән,—диде командир.

Солтанның гәүдәсен отрядка отбойдан соң алып кайттылар. Ләкин берәү дә йокламаган иде әле. Без барыбыз да тәрәзәләргә ябырылдык. Аны санчастьнең янкормасына кертеп куйдылар.

Ул төнне мин тузга язмаган төшләр күреп, саташып беттем. Рота командиры капитан Рындин, взвод командиры өлкән лейтенант Дондыш

яныма килгәндә әле иртәнге энгер-менгер иде. Мин тиз генә торып киендем һәм без урамга чыктык.

—Мөселманнарның мәетне юып, кәфенгә төреп күмгәннәрен беләм. Барысын да ислам шәригате кануннарына туры китереп житкермәсәк тә, булдыра алганын эшләргә тырышырбыз—диде капитан.

—Мин күмү йолаларын жентекләп белмим. Ә менә юып, чиста киемнәр кидереп жирләсәк яхшы булыр иде,—дидем.

—Табутсыз да мөмкин булмас—дип, өлкән лейтенант та сүзгә кушылды.

Шулай хәл ителде: балта остасы Ибраһимга табут ясарга, поварларга күп итеп су жылытырга кушылды.

Иртәнге аштан соң Солтанның мәете янына киттем. Без медпунктта эшләүче Мөхәммәт белән янкормага кердек. Солтанны колашага сузып салганнар. Өстенә япкан жәймәне ачтым. Солтанның башы бөтенләй юк иде. Анда таланып, ертылып беткән тире кисәкләре һәм шул кисәкләре ябышып, эленеп торган баш һәм янак сөякләренең кыйпылчыклары гына калган. Иң зур өлге булып, аның сәлек калдырып алынган чәчләре тырпаеп торган баш өсте тиресе иде. Шушы тире кисәге мәетнең Солтан гәүдәсе икәнен исбатлаучы бер дәлил иде. Миңа бу коточкыч афәтне күрү тәэсирле һәм бик авыр булды. Инде тылсымлы елмаюлары белән үзенә әсир иткән Солтанның йөзе дә, Солтан үзе дә юк иде.

Текә кыяларның диварларын кисеп салынган юлның тар, иң куркыныч өлешен үткән чакта, отряд начальнигы утырып барган машина кинәт кенә туктап кала. Шоферның әйтүенә караганда, полковник үзләре артыннан килгәннәрне “сак булыгыз!” дип, кисәтмәкче булган. Алар артына сыенып килүче Солтанның кисәк тормозга басуыннан көпчәк асларындагы кар шомарып, бозга әверелә. Машина шуыша башлый. Аның як-якка уйный башлаган бер арткы көпчәге, күз ачып йомганчы төшеп, кыя ярына эленеп кала. Арткы урындыкларда утырган округ офицерлары куркуларыннан ишеккә ыргылалар. Аз гына да селкетергә ярамаган машина тигезлеген югалтып, упкынга мәтәлә. Ташларга эләгеп сыдырылулардан, бәрелеп-сугылулардан брезентлары ертылып, бөгелеп, яньчелеп беткән машинаның өсте ачылып китә. Чираттагы әйләнештә, инде көпчәкләренә басар дигән соңгы өметне кыя ташлары кырына килеп бәрелгән запас көпчәк чәлпәрәмә китерә. Ул шундый көч белән килеп бәрелә ки, округ офицерлары шешә башыннан атылып чыккан бөкеләр сыман очып, бернинди зыян күрми, ташлар өстенә төшеп утыралар. Әйтерсең, аларны фәрештәләр үз канатларына утыртып, бу бәладән коткаралар. Сулыйсы сулышың, ашыйсы ризыгың бетмәсә, әжәл дә көчсез була икән. Ә Солтанның машинасы бәреп жибәрелгән туп шикелле очып, упкын төбенә китә. Үз күзләре белән күрмәсә, мәңге ышанмаслык бу фажигане карап торган, сугышның башыннан ахырына кадәр булып, фантастик очракларга юлыккан фронтовиклар да, аңлап та, аңлатып та булмаслык бу могжизаны күреп, хәйран калалар.

Әйе, бу дөньяда аңлап та, аңлатып та булмаслык могжизалар, адәми затның ан-акылы колачлый алмас, зиһененең көч-куәте житмәс серле, сихри-тылсымлы табигать күренешләре, сәер хәлләр тормышта әледән-әле булып торалар. Галим-голәмә халкы бу серләрнең, гаҗәеп могжизаларның сәбәпләрен аңларга никадәр генә тырышып, төрлечә аңлатып карасалар да, серләр һаман да сер булып кала.

Кешеләрнең төштә күргән вакыйгалар эчендә реаль тормыштагы кебек эш-гамәлләр кылып йөрүләре дә, шундый серләрнең берсе булып санала.

Мин алда: “төне буе сәер төшләр күреп, саташып беттем”—дигән идем. Әйе, Солтанның кыядан упкынга очу мизгеле минем дә төшемә реаль сурәт булып керде. Солтанның кып-кызыл канга манчылган башы ташларга

бәреләсугыла упкынга очып бара, имеш. Ул кыя читләренә ябышып үскән агачларга тотынып калмакчы була. Ләкин ниндидер илаһи көч аны йолкып алып, аска чөеп җибәрә. Баш чарасызлык фаҗигасе кичерә. Анын кан баскан күзләреннән мөлдерәп яшь ага. Ул нидер әйтмәкче булып, авызын ача. Ләкин тавышы чыкмый. Ниһаять, баш телгә килде:

—Әй, Рәис дустым, кайда минем гәүдәм? Зинһар тап минем гәүдәмне. Әтием-әнием, туганнарым янына гәүдәсез кайта алмыйм бит инде. Кайда минем гәү-дә-әм?—диде.

Солтанның жан ачысы белән сыкранып әйткән сүзләреннән күкләр күкрәгәндәй булды. Кыя-таулар тетрәнде. Аваз тау битләреннән үрелеп, кыя очларын селкетте. Бөтен тирә-якта: "Хуш, бәхил булыгыз"—дигән кайтаваз янгырап үтте. Ул арада упкын төбеннән чок иткән аваз ишетелде. Упкын төбе, асылташлар сибелгәндәй, балкып китте.

Застава начальнигы капитан Азаматов упкын төбенә үзенең сержантлары белән, кыя ташына бәйләнгән юан арканга тотынып төшәләр. Алар урындык белән аска таба бөгелеп килгән машина руле арасына кысылып калган Солтанның гәүдәсен көч-хәл белән алып, тактага яткырып бәйләгән хәлдә, өскә күтәрәләр.

Сәгать унберләрдә отряд Ватаныбызның иминлеген саклап һәлак булган чик сакчыларының тау итәгендәге каберлеге янында сафка тезелеп басты. Яна киемнәренә әле авыр солдат хезмәтенең ачы тире сеңәргә өлгермәгән яшь солдатлар бер якта, инде юа-кия торгач чалбар, гимнастеркалары агара төшкән өлкән солдатлар икенче якта. Бу ике сафны тоташтырып, тау кырыена сыенып, офицерлар тезелгән. Уртада кабер. Анын янындагы колоннада Солтанның башсыз гәүдәсе ята. Хәер, ана башны Ибраһим печән учмасыннан ясап, өстен иртәнге шәфәкъ алсулыгы төсендәге яулык белән каплап куйды. Отряд начальнигы офицерларга каршы басып, фуражкасын уң кулына алды.

... Полковник сүзен тәмамлап, капитан Рындинга карап баш какты. Бу анын "башлагыз" дигән командасы иде. Ибраһим, Мөхәммәт, мин ак җаймәгә төрелгән Солтанның гәүдәсен жир куенына иңдердек. Ибраһим үзе әзерләп куйган ләхет такталарын тезде. Тирә-якны сискәндереп залп авазлары янгырады. Бу авазлар тау, кыя башларына бәрелеп, тарлавык, упкын, ермакларның тын почмакларын урап, кайтаваз булып, озак янгырап торды.

Хуш, бәхил бул, кадерле дустым Солтан. Авыр туфрагынны жинел, урынынны җәннәттән әйләсен.

Каберлек солдатлардан бушап калды. Мулла абзый Солтанның рухына багышлап дога кылды. Ибраһим, Мөхәммәт һәм мин Солтанның кабер кырыйларын ташлар белән түшәдек. Бирелә, тау-таш арасында яшәүче жирле халык каберне тирән итеп казый алмый. Кыргый жанварлар мәеткә кагылмасын өчен, алар кабер авызын авыр яссы ташлар белән каплап куялар.

Яныбызга элемтә взводы командиры өлкән лейтенант Жиһангиров килде. Безнең татарча эндәшүләребезгә урысча җавап бирүче бу кеше бүген бөтенләй башка яктан ачылып китте. Ул отряд начальнигы полковник Хиль янында булып, Солтанны табутка салып түгел, ләхет уеп, мөселман дини йолаларына, татарның гореф-гадәтләренә туры китереп жирләүне сораган. Полковникнын фатихасын алгач, Мургабка барып, кыргыз мулласыннан бу гамәлләрне эшләүне үтенгән һәм аны күндереп, үзе белән алып та килгән иде. Алар Мөхәммәт белән Солтанны юып, ана үзенең өйгә кайтканда киярга дип әзерләп куйган өр-яңа күлмәк-ыштанын кидереп куйдылар. Ә шундый ук өр-яңа чалбар-гимнастерка һәм башка әйберләрен чемоданы

белән мулла абзыйга сәдака итеп бирделәр. Мулла җеназа намазы укып, Аллаһыдан Солтанның дөньялыкта белеп вә белми кылган хата-гөнаһларын ярлыкавын сорап дога кылды. Ә мин исә: "Син татар түгел, мөселман түгел, тамырларыннан татар каны акмый дип, әйтеп кара хәзер Җиһангировка"— дип, уйлап куйдым. Кеше карбыз түгел, ярып карап булмый шул.

Миннән элек кайтып, мине Казанда каршыларга вәгъдә биргән Солтанны мәңгегә Памир таулары куенына калдырырга туры килде.

Хәер, төнге мажарага кире әйләнеп кайтыйм әле. Солтан белән тау куышы янында очрашуыбызны шәрехли идем ләбаса.

—Рәис дус, исән-сау икәнсең ләбаса—дип, кочаклап алды мине Солтан. Без озак еллар күрешмәгән якын туганнар кебек, кочаклашып күрештек. Кичәге мәхшәрдән исән калу—үзе бер могҗиза булып, шатлыгыбыз да чиксез иде, әлбәттә. Куыштагыларга Олег белән мине дә кушкач, тагын тугыз кешебез җитми булып чыкты. Тамак ялгап алганнан соң, куышта ике солдатны дежур калдырып, башкаларыбыз ике төркемгә бүлендек. Беренче төркем себер егете Попов җитәкчелегендә кар-буран күмеп киткән иптәшләребезне эзләргә тиеш булды. Икенче төркемне Солтанга тапшырдылар. Ул төркемдә мин дә булып, без төнлә боз өстен чыкканда чәчеп калдырган консерваларыбызны эзләргә киттек. Күл дигәннәре, безнең Аккош күленнән әллә ни зур түгел иде. Минем шикелле егылып, ризык-ашамлыкларын югалтучылар аз булмаган икән. Табылганнарга төрле консервалар, колбаса, ипи, берничә шешә ак аракы белән тулы ике биштәр дә өстәлде. Без ашамлыклар белән төялеп, юл уңаенда Олегны да үзебез белән алып, тау куышына кайтканда капитан Калганов, сержант Киреенко да анда иделәр. Алар солдатлардан бераз читкәрәк китеп, сүзсез генә, башларын түбән иеп утыра иделәр. Әгәр күреп белмәсәк, бу—һәрвакыт чиста-пөхтә, башын бераз югары чөеп йөргән горур офицер Калганов; бу—мактанып-масаеп, үзен башкалардан өстен куеп йөргән тәкәббер ефрейтор Киреенко дип һич кенә дә әйтә алмас идек. Капитанның ап-ак туны, сержантның өр-яңа көрән шинеле буй-буй кара-кучкыл төскә кергән. Киез итекләре пычракка баткан. Бөтен тирә-як ап-акка төренеп, шыгырдап каткан бу халәттә каян килгән бу пычрак, кара-кучкыл төсләр... Алла белсен. Дуңгыз үзенә пычрак таба, диюләре хак сүз икән.

Капитан биштәрләрне күреп, җанланып киткәндәй булды. Ул әсәрләнеп:

—Солдат, синең иңнәреңдә безнең биштәрләр. Бирегә китер син аларны,—диде ул, үзенең аяк очлары янынннан урын күрсәтеп.

—Без аларны боз өстеннән табып алдык, кемнеке икәне язылмаган. Әгәр сезнекеләр икән, алып кайтканга рәхмәт әйтеп, үзегез килеп алыгыз,—дип, киң җилкәле, имән кебек нык бәдәнле солдат биштәрләрен җиргә куйды.

—Солдат,—дип кабатлады капитан,—күп телеңә салышмый гына әйткәнне эшлә. Бу—приказ. Юкса...—Капитан пистолеты салынган кобураны чишеп куйды.

Сүзгә озын буйлы, таза гәүдәле Василий Родыгин кушылды. Ул армиягә кадәр Ижау шәһәрендәге корал заводында слесарь булып, данлыклы Калашников автоматларын җитештергән.

—Гафу итегез, сез хәзер командирга караганда, күбрәк урам сәрхушләренә охшагансыз. Приказны аек кешеләр генә бирергә тиеш.—Родыгин тиз-тиз атлап, бәласеннән баш-аяк дигәндәй, куыштан ук чыгып китте.

Чыннан да, капитанның да, сержантның да чырайлары сыер чәйнәп ташлаган чүпрәккә охшап калган. Йөзләре сытык, күзләрен томан баскан.

—Сержант, алып кил биштәрләрне,—диде капитан Киреенкога. Сержант

көч-хәл белән урыныннан торып, ана үрдәк кебек, як-якка ава-түнә биштәрләрне өстерәп, капитан янына китереп куйды. Капитан калтыранган куллары белән, тиз-тиз биштәрләрнең авызларын чишеп, ярты литрлы аракы шешәсе алып, шешә авызыннан гына йотлыга-йотлыга эчә башлады. Ул эчүдән туктап, бераз чыраен сытып торганнан соң колбаса сындырып капты. Аны чәйни-чәйни:

—Россия—алкашлар иле. Гомер-гомергә шулай булган, шулай булып калачак та. Югыйсә, буран буласын белә торып, җирле халык кисәтә торып, безне чыгарып җибәрмәсләр иде. Мондый буранда яхшы хужа этен дә куып чыгармый.

—Мә, эч,—диде ул яртылаш аракы калган шешәне сержантка биреп. Сержант капитан шикелле кисәкләп-кисәкләп йотып тормады. Ул аны чиләктәге суны кисмәккә бушаткандай итеп, «эһ» дигәндә бетереп тә куйды.

—Ох, әйбәт булды. Кичә күбрәк киткән, шайтан алгыры. Кая ятканымны да белмәгәнмен. Ниндидер чишмәдән ятып су эчкәнем генә хәтеремдә калган,—диде сержант, колбаса, ипи сындырып алып.

—Аракы эчмәсәк, без синең белән, әнә теге солдатлар кебек, (ул бармагы белән төртеп, без утырган җиргә күрсәтте) аяк-кулларыбызны өшеткән, бәлкем катып үлгән дә булыр идек әле. Ә безгә үләргә ярамый. Безнең гаиләләребез бар.—Капитан биштәреннән икенче шешәне тартып чыгарды...

Ул арада Себер егете Виктор Попов җитәкләгән төркем дә кайтып килде. Алар таулардагы көчле кайтаваздан файдаланып, аваз сала-сала өч солдатны табып кайттылар. Өчесенең дә хәлләре яхшыдан түгел иде. Тагы дүрт кеше җитешми. Дөресен генә иткәндә, безнең беребезнең дә хәле мактанырлык түгел. Барыбыз да күпмедер өшегән. Кайберләребез йөри дә алмаслык иде. Шулай булмый ни... Бит безнең өстә юка солдат шинеле дә, аякта күн итекләр генә иде шул.

Боз өстеннән җыеп кайткан консерваларны ачып, каткан ипиләр белән бер кат ашап алгач, аякларында йөри алганнар берничә төркемгә бүленеп, янә теге югалган дүрт солдатыбызны эзли киттеләр. Куышта калганнар исә, бер-берләренә ярдәм итешеп, өшегән урыннарын ышкып-уып, коры чүпрәкләр белән төреп бәйләделәр. Чөнки һәрберебезнең биштәрендә запас киемнәр бар иде. Бу тырышлыкларыбыз бушка китмәде кебек. Күбесенең өшегән урыннары әкрен-әкрен үз хәлләренә кайткан шикелле булып, алар аякка басты.

Караңгы төшкәнче дип, без тагын боз өстенә барып кайтырга булдык. Бу юлы күлне аркылыга—буйга йөреп, бар булганын җыеп бетердек шикелле. Тик югалган иптәшләребезне эзләүчеләрнең генә юллары уңмаган. Дүрт кешенең берсен дә тапмый кайтканнар. Хәтта эзләрен дә күрмәгәннәр.

Көн урталары үтеп озак та узмады, машиналар гөрелтесен ишетеп, без куышыбыздан йөгереп чыктык. Бездән ерак түгел өч машина туктап тора иде. Болар безне эзләп килүчеләр булып чыкты. Солдатлар "ура" кычкырып, шунда йөгерделәр. Барыбызның да шатлыгы баштан ашкан, җанда өмет шыткан иде. Машиналарга төялеп солдатлар килгән! Берничә офицер, Мургаб погранотрядының командиры подполковник Вековшинин үзе дә килгән. Җылы киемнәр, кайнар чәй, итле карабодай боткасы да алып килгәннәр. Казан мех берләшмәсе теккән ап-ак туннар киеп, аякларда үзебезнең киез итек комбинаты баскан киез итекләренең җылылыгын тойгач, күнелләр күтәрелеп китте. Их, мин әйтәм, башта ук бу киемнәрне кидерткән булсагыз соң?! Хәлләребез дә бу кадәр аяныч булмас иде ләбаса.

Без чәйләр эчкән арада подполковник, безне озата баручы капитан Калганов, сержант Киреенко янына барып, сак кына сөйләшергә кереште. Өзек-өзек ишетелгән сүзләрдән: "Тәртибегез, үз-үзегезне тотуыгыз совет офицеры дигән горур исемгә тап төшерә. Сез аңа лаек түгел. Салыгыз погоннарыгызны",—дигәннәре колакка килеп иреште.

—Ул погоннарны сез такмадыгыз, салдырырга да хакыгыз юк. Әгәр кирәк тапсалар, башка җирдә башка кешеләр, сездән башка да эшләрләр,—диде капитан Калганов, көчкә аягында басып торган хәлдә.

Отряд командиры, кайсы кая таралышып утырган солдатлар алдына басып:

—Балакайларым,—диде.

Аның какча ябык яңаклары тартышып куйдылар. Болай да кыска буе тагын да кечерәеп калган шикелле тоелды. Эчкә баткан күзләре яртылаш кысыла төшкән иделәр.

—Мин, фронтовик офицер,—дип дәвам итте ул сүзен.—Сугышның башыннан ахырына кадәр булып, иң якын дусларымны, иптәшләремне югалтканда да мондый олы хәсрәтне кичермәдем. Чөнки анда сугыш-үтереш иде. Бүгенге тыныч заманда кеше язмышы белән шаяру, аның тормышына битараф булу, җавапсыз карау—җинаять! Сезне юлга озатканда үзем частьтә булмасам да, командир буларак, бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, сездән гафу үтенәм...

Куыш каршына ниндидер атлар килеп туктады. Подполковник алар янына чыгып китте. Болар заставалардан безне алырга килгән чик сакчылары иде. Алар үзләре белән иярләгән атлар да алып килгәннәр. Юлда килешли без эзләп-эзләп тә таба алмаган дүрт иптәшебезне һәм подполковник кушуы буенча, аларны эзләргә җибәрелгән теге, Мургабтан килгән солдат, офицерларны да ала килгән иделәр. Югалган себер егетләренең сүзләренә караганда, алар дүртәү, төне буе барганнар да барганнар. Тик иртән, яктыра башлагач кына, ял итәргә дип, тау ышыгына сыенып утырганнар. Арыганлык үзенекен иткән. Заставалардан килүче чик сакчылары аларны уятып, үзләре белән алып килгәннәр.

Подполковник биштәрләребезне алып, урамда тезелергә кушты.

—Кемнәрнең хәле авыр, үзләрен начар хис итә, ике адым алга,—диде ул. Сафтан унбер солдат аерылып чыкты. Шунысы гаҗәп: алар арасында бер генә татар егете дә юк иде. Тегеләрне машиналарга утыртып, кире Мургабка кайтарып җибәрделәр. Ә без исә, атларга атланып, заставаларга таба юл тоттык. Безне инде подполковник үзе озата барды.

Без, ике солдат, чик сакчылары салган сукмактан атка атланып, заставаларның берсеннән икенчесенә күчә-күчә, тик дүртенче тәүлек дигәндә генә билгеләнгән урыныбызга исән-сау килеп җитә алдык. Бу Ләнгәр заставасы иде.

## Застава

Инде застава ның эчке кагыйдәләренә күнегеп, чик буенын, аны саклаучыларның үзенчәлекле тормышына ияләшә дә башлаган идем.

Көннәрдән бер көнне яшь солдатларны шоферлар әзерләү курсларына җибәрәләр икән дигән хәбәр таралды. Мин моңа әллә ни әһәмият тә бирмәдем, исем дә китмәде. Шофер булу мине һич кенә дә кызыксындырмый иде. Әгәр тәкъдим иткән булсалар да, төрле сәбәпләр табып, бармаска тырышкан булыр идем. Памирда шофер булу—гомереңне кыл өстенә кую дигән сүз.

Миңа язмыш гаҗәп тә мәрхәмәтле булды. Яшь солдатларның дүрт

айлык уку-өйрәнү курсларын яхшы гына узып, 1954 елның декабрь азакларында мин Ләнгәр заставасында хезмәт итә башладым. Заставам шаулап, котырып аккан Пәнҗ елгасы буенда, шул ук таулар арасында булса да, уң як флангтагы заставалар кебек, җәен-кышын кар бураннары эчендә утырмый. Ул, бер яктан, башларын мәңгелек кар-боз каплаган, сөңгеләре болытларга ашкан таулардан ыжгырып торган салкын җилләрдән яшеренеп, аларның кояшлы итәкләренә сыенып, үзәнлек ышыгына посып утырган булса, икенче яктан, шушы унай шартлар тудырган яшеллек дөньясының бер читендә тора иде. Без Таулы Бадахшан автономияле өлкәсенең баш шәһәре Хорог белән, Кыргызстан республикасының район үзәге булып саналган Мургабның ике арасында, алардан бер чама диярлек ераклыкта идек. Нәкъ безнең застава каршында, ике дәүләт чиген бүлеп аккан Пәнҗ елгасының теге ягында, Әфганстан солдатларының крепосте булуы Ләнгәрдә комендатуралы зур застава төзергә мәҗбүр иткән. Биредә штаб, аның башлыгы, хуҗалык эшләре белән махсус шөгыльләнүче аерым взвод та бар. Анда хезмәт итүче солдатлар чик буенда сакта тормасалар да, кирәк була-нитә калса, заставага ярдәм күрсәтергә һәрвакыт әзер иделәр. Югыйсә аларның төп эшләре—фланглардагы заставаларны, бигрәк тә уң яктагыларын, азык-төлек, кием-салым, ягулык материаллары һәм башка шуның ише кирәк-яраклар белән тәэмин итеп тору. Монда кирәкле дарулар, медицина приборлары, төрле җиһазлар тупланган зур медпункт, аның табибы, сәләтле татар егете капитан Зарипов, һәрвакыт елмаеп, якты йөз белән каршы алучы, шәфкать туташы булып эшләүче хатыны Әлфия ханым да бар. Бирегә килгәндә котырган буранда адашып өшеткән тезләремне савыктыручы, аяк-кулларымны гангренадан, киселүдән саклап калучы игелекле кешеләр дә алар булды инде. Аллаһының чиксез рәхмәте яусын үзләренә.

Аяк-кулларымның өшегән урыннары һаман да тернәкләнмәү сәбәпле, мине дә вакытлыча ярдәм взводына күчерделәр. Ләкин ярдәм взводында хезмәт итүче солдатлар да чик буен саклаудан азат түгелләр иде. Алар әле застава буенча, әле ат абзарында дневальный булалар, әле ГСМ складында постта торалар. Чик буйларына дозор булып.

Мин казармада кизү тора идем. Ул төн шулкадәр карангы булды ки, күзенә төртсәләр дә күренмәслек иде. Иртәнге сәгать биш тулып килгәндә коточкыч көчле шартлау авазы бөтен тирә-юньне тетрәтте. Кинәт яшен яшьнәгәндәй итеп, кызыл ракеталар кара төннең пәрдәсен ертып, күкне айкады. Бу сул як флангтагы чик сакчыларының ярдәм сораган сигналы иде. Шартлау авазын ишеткән, кызыл ракеталарны күргән старшина Белов заставаны "корал"га күтәрде. Мин карабинымны алып, ишек төбенә бастым. Күп тә үтмәде, застава башлыгы капитан Дмитриев, штаб башлыгы майор Мелкозеров, башка офицерлар да казармага килеп керделәр. Бу вакытта солдат, сержантлар стройга басып, приказ көтәләр иде. Атларын иярләп, «тревожная группа»ны застава начальнигы шартлау булган якка алып китте. Тагын бер төркем, атларга атланып, алар артыннан юлга чыкты. Тулы хәрби әзерлектә булган янә бер төркем штаб башлыгы карамагында резервта калды.

Шомлы ике сәгать вакыт үтте. Инде таң атып, көн туды. Кояшның алсу нурлары Сәрхан тарлавыгыннан үрмәләп чыгып, тау битләренә, үзәнкырларга үрелде. Алар тирә-якка җан өрде. Зунг кышлагыннан килгән кышлак советы рәисе Сәидморадов Рәсул, колхоз рәисе Хәмзәев Абдегафар да нәрсә булганын белергә дип заставага килгән иделәр.

Менә старшина Белов һәм ике солдат имгәнеп, җәрәхәтләр алган кече сержант Аношкинны атка атландырып, як-яктан тоткан хәлдә, заставага

алып кайттылар. Аны тиз генә санчастька салгач, бу хәвефле вакыйгага бераз ачыклык керде.

Иртәнге бишләр тирәсендә Ассор үзәне каршындагы биеклеге 3000 метрдагы «Әфган» тавы җимерелә. Җимерелү шулкадәр көчле була ки, әйләнә-тирәне зур тизлек белән шуышкан бинһаяя масса күмеп китә. Һавада ташлар оча, тузан өермәсе куба.

Бу хәлгә берничә минут кала чик сакчыларының атлары кыбырсына башлый. Бәйләп куйган җирләреннән чабып китәләр. Кече сержант Аношкин атларны тотмакчы булып, аларның артыннан йөгерә. Новосибирскидан килеп, икенче елын хезмәт иткән солдат Тарутин Алексейның язмышы әлегә билгесез булып кала.

Штаб башлыгы майор Мелкозеров резервтагы группаны алып, вакыйга булган җиргә китте. Аңа кышлак кешеләре дә иярде.

Көнозын килеп, әледән-әле яңарып торган хәбәрләрдән кичкә таба барысы да ачыклана. «Әфган» тавы җимерелү, кар-бозлар шуышу аркасында Аношкин, Тарутин сакта торган урында тагы бер зур тау барлыкка килә. Солдат Тарутинны көне буе эзләсәләр дә таба алмадылар. Ул тау астында калып, һәлак булгандыр, диделәр. Бик аяныч, әлбәттә. Ә менә тау җимерелгәндә һава дулкыны безнең якка ыргыткан атлы әфган кешесенең гәүдәсен табалар. Ул яна хасил булган таудан ераграк була.

Штаб башлыгы Хорогтагы отряд командирыннан рөхсәт алып, мәрхүмнең гәүдәсен Әфганстан ягына чыгарып бирделәр.

Бу төшләрнең янә бер искитмәле үзенчәлеге—аның тау итәкләреннән саркып чыккан күп төрле чишмәләре. Аларның сыйфатлары ашказаны, эчәк авыруларын, бавыр-бөерләрне дәвалауда кулланыла торган шифалы сулар белән бер дәрәҗәдә иделәр. Тагын бер үзенчәлек: тау битеннән ургып чыгып торган кайнар суы. Ул улаклар буенча агып, солдатлар казып, эч әйләнәсен цемент белән катырып эшләнгән зур чокыр-бассейнга килеп төшә. Суны үзенә җитәрлек кадәр җыясың да, рәхәтләнеп кереп утырасың. Ләкин чамасын белеп кенә. Чөнки ул Сочи мацест ванналарындагы кебек, күкертле-водородлы су. Исләре дә бер үк—сасыган йомырка исле. Менә шушы могҗизалы су минем сәламәтлегемне уңай якка хәл итте дә инде.

Капитан Зарипов (кызганыч ки, аның исеме истә калмаган) киңәшен тотып, төштән соңгы ял вакытымда, командир рөхсәте белән, таш араларыннан сузылган бормалы-сырмалы, меңәле-төшәле, тау сукмагы буйлап, тылсымлы-шифалы суның рәхәтен, дәвасын күрергә барам.

Мунча рәвешенә китереп, тышы таштан, эче такта белән эшләнгән бу бинаның калын ишеге бикләнмәсә дә, ул һәрвакыт нык итеп ябылып, тимер элмәк белән эләктереп куела. Бассейнның да, ял бүлмәсенең дә, коена торган өлешенең дә кырыйларына ятып ял итәрлек сәндерәләр куелган. Чишенә торган алгы өлеше идәннәре калын такталар белән түшәлгән. Бинаның балчык түбәсе кышлактагы йортларныкы кебек яссы булып, тау төшү ягына сөзәкләп эшләнгән.

Әлбәттә, гадәти мунчаларда булырга тиешле мич монда юк. Кышын чокыр аша аккан күкертле кайнар суны буып, аның җыелганын көтәсең. Шаулап-ургып аккан су озак көттерми. Ул арада кайнар судан бина бераз җылына төшә. Өстеннән җинелчә пар чыгып, күкерт исе аңкып торган шушы шифалы суга кереп, 10-15 минут тыныч кына утыргач, тәнне сөлге белән җинелчә киптереп аласың. Табиб капитан Зарипов кешене сәламәтләндерүче, гаҗәеп тылсымга ия бу шифалы суның нәфесен тыя алмаган кешеләрне һәлакәткә дучар итүе хакында әледән-әле искәртеп торды. Бу турыда әйтелгән язма да диварда эленеп тора иде. Без инде Хорог отряды штабыннан килгән майорның фаҗигале үлеме турында да

беләидек. Бөек Ватан сугышының утлы-ялкынлы, канлы-яшьле, мең төрле үлем очракларын үткән әлеге майор да, үзенең комсызлыгы аркасында, бассейннан да чыга алмый вафат була. Һәрнәрсәнең чамасын белергә кирәк шул.

Һичшиксез, ел әйләнәсендә кар-буран котырган заставаларда хезмәт итүче солдатлар белән чагыштырганда, безнең яшәү шартлары күпкә җайлы-уңайлы иде. Бездә агач-куаклар да үсә. Ала-кола тау битләрен, елга буйларын, үзәнлекләрне яшел хәтфә үлән бизи. Үләннәрнең әрсезләре хәтта таш араларыннан шытып чыга. Бу җирләрдә яшәүче халыклар уч төбе кадәрле җирен дә бик оста файдалана. Алар тигезрәк урыннарны, тау итәкләрен ташлардан чистартып, чүп үләннәрдән арындырып, кат-кат китмәнләгәннән соң яшелчә, бәрәңге, кабак утырталар. Үзәнлеккә исә арыш-бодай чәчәләр. Хәтта трактор белән сукалардай урыннары да бар. Монда җирнең һәр мыскалы кадерле. Уныш зур тырышлык куеп, тир түгеп алына. Кешеләр көннәр буе яртылаш вак таш белән аралаш шул җирләрендә мәш киләләр. Берәүләре камыш, балчык кушып катырган кирпечләрдән йорт җиткерә, каралты-курасын төзи, аларның әйләнәсен төрле җимеш агачлары утыртып бизи. Һәркем—үз эшендә, һәркемнең үз шөгыле бар.

Халык үзенең ризасызлыгын ачыктан-ачык әйтмәсә дә, безне яратып бетерми, өнәми. Бу канәгатьсезлек аларның чырайларына ук чыга. Ләкин без-татарларны—хөрмәт итәләр. Бу табигый да. Чөнки без алар кебек мөселманнар. Югыйсә, аларның ирекләрен чиклибез, үзләренчә яшәргә мөмкинлек бирмибез. Иң уңдырышлы җирләрендә чик буе полосалары сузып, чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алганбыз. Ул полоса буйлап куелган яшерен сигналларга куян яки шуның ише берәр җанвар кагылып үтә калса, застава тревогага күтәрелә,чик буена ыргыла. Бу хәлләр дә аларның тынычлыгын боза. Һәр милләт үзенчә яшәргә күнеккән. Ул шулай итеп яшәргә тели дә. Һәм тиеш тә!

Көннәрнең берсендә штаб башлыгы майор Мелкозеров мине үзенә чакыртып алды. Кердем. Хәрбиләрчә үземнең килүемне әйттем. Ул ихтирам белән миңа урын тәкъдим итте. Майор сүзне ерактан урап башлады. Сүз барышында әби-бабаларымның кем булуларын, әти-әнием, абый-апаларымны да онытмый, аларның хәл-әхвәлләрен сораштырды. Ничек көн күрешебезне, туганнарымның кайда, кем булып эшләүләрен дә белеште. Ул моны әңгәмәгә оста итеп бәйләп, күңел кылларына бик бәрелмичә, җанга кагылмый, аны рәнҗетми генә, үтә нечкә, зәвыклы итеп башкарды. Аның бу өлкәдә зур тәҗрибәсе барлыгы сизелә иде.

Майор безгә штаб башлыгы булып күптән түгел генә килде. Ул үзе белән ныклы хәрби тәртип, уставларның төгәл үтәлешен дә алып килде.

Майор үзенә карата да бик таләпчән иде. Ул һәрвакыт чиста киемнән булыр. Киемнәре уртача буйлы ыспай гәүдәсенә үлчәп теккән кебек, җыйнак, пөхтә иделәр. Аның текә маңгаендагы кыйгач карасу кашлары купшы ханымнарныкы кебек тәртиптә булып, куе коңгырт күзләре уйнаклап торган яшь айгыр күк. Ул елмайганда йөзе әле генә ачылган көнгә охшап, яктырып, ягымлыланып китә. Бу вакытта аның ике бит уртасында түгәрәк чокырлар хасил була. Алар әйләнә-тирәдәгеләрне үзләренә караталар да куялар инде. Чак кына калку кызгылт иреннәре җәелеп киткәндә, тәмәке тартып саргаймаган ап-ак тешләренең кардай җемелдәве, ямь өстенә ямь өстәп, аны хатын-кызлар хыялланган чын иргә әйләндерә. Тик монда, Памирда майорга әсир булып, мәхәббәт утында янардай хатыннар юк иде шул. Кырынганнан соң сөртелгән одеколоннарының хуш исләрен дә җилләр тарата...

Майор төгәллеге белән дә башкалардан аерылып торды. Аның көн

тәртибенә карап сәгатенне дөреслəп куярга мөмкин иде. Әйтик, солдатлар юып-чистартып биргән ак атына атланып йөрергә чыккан икән, димәк, сәгать бер тулган. Бу инде солдатларның көндезге аш вакыты дигән сүз.

Үз-үзен тотышына карап, ул тормышыннан канәгать, хезмәтенә ихтирам белән карап, аны зур тырышлык белән башкарып, аннан ләззәт ала иде шикелле. Күрәсең, бу хезмәт аңа ерак буыннардан, ата-бабаларыннан күчеп килә булса кирәк. Ул бөтен барлыгы белән чын профессионал, японнар белән бәрелештә өтелеп кайткан офицер иде.

—Өлкән лейтенант Бариев сезне мактап туя алмый, валлаһи. Сез аңа бик ошагансыз. "Тукта әле—мин әйтәм,—нинди кеше икән ул, Бариевны шул кадәр үзенә гашыйк иттергән"—дип, үзегез белән якыннан танышырга булдым. Тыйнаксызлык күрсәткән булсам, гафу итегез. Аннан соң, теге яшь лейтенантларның да борыннарына чиертә алуыгыз ошады. Молодец. Бу һичшиксез мактауга лаек хәл!

Майор күптән түгел булып үткән бер бәхәскә ишарә ясый иде.

Шулай беркөнне, кичен җыелып тәмәке тартып утырганда, солдатлар арасында бәхәс купты. Анда майор әйткән теге лейтенантлар да бар иде.

—Американнар атом бомбасын Хирасима шәһәренә генә ташладылар,—ди болар.

Мин әйтәм:

—Хирасимадан тыш Нагасакига да, дим.

Бу сөйләшүне майор да ишетеп торган икән.

—Солдат дөрес әйтә,—дип, мине җөпләп куйды.

—Әйдәгез, каршы килмәсәгез, мәктәп елларын искә төшереп алыйк әле,—дип, майор минем алдыма кәгазь-каләм куйды.

—Языгыз!

"Мой дядя самых честных правил,
Когда не в шутку занемог
Он уважать себя заставил
И лучше выдумать не мог."

Әлеге диктантта мин хата җибәргән булып чыктым. "Занемог" тагы "за" кисәкчәсен "немог" сүзеннән аерып язганмын. Әлләни зур хата булмаса да, бу майорның кәефен җибәрде. Югыйсә, ул мине штабка писарь итеп алырга җыенган икән. Нишлисең инде, әүвәле-ахыры хәерле булсын. Сугыш елларында авыл мәктәбенең җиде классын эттем-төрттемгә бетергән татар малаеннан күпне өмет тә итеп булмый шул.

Әлбәттә, майор кебек үтә таләпчән кеше белән эшләве миңа да җиңел булмас иде. Ләкин без язмышның түгел, язмыш безнең куллардан тотып йөртә шул. Ашыйсы ризык, эчәсе су тәгаенли кешенең барыр юлларын. Мине дә язмыш өлкән лейтенант Бариев белән очраштырды. Ул шушы комендатурада интендант хезмәтендә иде. Начальствоның күзенә бер чалынсаң, ул сине бик үк онытып та бетерми. Теге, югарыдагыларның номенклатура исемлегенә кергән кеше кебек, агым кая таба акса, син дә шул юнәлештә йөзәсең дә йөзәсең. Өлкән лейтенант Бариев мине майордан сорап, үзенең ярдәмчесе итеп алды. Хәзер мин складларга кергән-чыккан барлык азык-төлек, кием-салым кебек әйберләрнең исәп-хисабын алып бара башладым. Аена бер мәртәбә складта булган әйберләрнең санын күрсәтеп, Хорогка отчет җибәрәбез. Ләкин мин—начар хисапчы. Эшнең зур өлешен өлкән лейтенент үзе башкара, хаталарымны төзәтә. Мондый эш аны, әлбәттә, канәгатьләндерми. Ләкин без үзара тату яшәдек. Еш кына әдәбият турында сөйләшәбез, сәнгать әһелләрен искә алабыз. Мин аңа

үземнең әлегә чиле-пешле шигырьләремне укыйм. Ул аларның житешмәгән якларын әйтә, аларда образ дигән нәрсәнең конкрет түгеллеген күрсәтә. Чөнки ул үзе дә әдәбият белән якыннан таныш кеше. Татар кешесе китапны элек-электән яраткан, аны хөрмәт иткән, үзе дә жыр-шигырьләр язарга хәвәс булган лабаса. Өлкән лейтенант та шундыйларның берсе иде. Ул һәр татар язучысын, аның үзенә генә хас язу стилен, әсәрләрендәге үзенчәлекне нечкәлекләренә кадәр белә иде. Тальянда уйнап, калын тавышы белән моңлы итеп жырлап та жибәрергә булдыра. Аның яраткан һәм күп вакыт борын астыннан жырлап йөргән жыры:

> Кәккүкнең тавышы
> Таннарда тынар микән?
> Мин иркәмне бик юксынам,
> Иркәм юксына микән?

Ул Ташкентта яшәп яткан хатынын, сөекле кызларын өзелеп тә сагына иде шул.

Өлкән лейтенант Бариев майор шикелле ыспай, үрә каткан офицер түгел. Андый булуның аңа әлләни кирәге дә юк. Чөнки ул саф офицеры түгел, ә гаскәрне бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итеп торучы тәэминатчы. Ул зур гәүдәле, көрәшчеләрнеке кебек киң жилкәле, теге жырдагы:

> Баскан эзләрем калсын дип,
> Каты басам жирләргә!

—дигәндәй, адымнары ышанычлы, жил-давылларга бирешмичә, аякларында нык басып тора алган, үз кадерен үзе белеп, горурлыгын жуймаган ир уртасы булган татар кешесе иде. Ул атлангач, атлар да сыгылып куя иде. Аның, шомырт кара, ат яллары кебек купшы кара чәчләре матур итеп артка таба таралган, йомшак жылылык, нур бөркеп торучы зәңгәр күзләре һәрчак елмайган булыр. Әйтерсең лә, алар дөньяны иркәләргә ачылган гөл бәбәкләре, әйтерсең лә Бариевның көләч йөзендә язгы таң ата сыман. Аның бу халәте эш-гамәлләрендә дә чагылыш таба. Ул гажәп юмарт, игелекле кеше иде. Кемнедер рәнжетү, хур-мәсхәрә итү холкында юк нәрсә иде.

Безнең заставаның койма кырыенда, теге бассейн-чокырга таба баручы юл буенда, волейбол мәйданчыгы бар. Солдатлар, офицерлар ял көннәрендә, нарядтан буш вакытларын шул мәйданчыкта йә түгәрәк ясап, йә челтәр-сетка аша туп сугалар. Күп вакыт кышлакның мәктәп балалары да шунда мәш килә. Беркөнне өлкән лейтенант Бариевның башына застава белән хужалык взводы арасында волейбол ярышы уздыру фикере килә. Жиңүче якка ул үз акчасыннан биш кило "Радий" шоколад конфеты алып бүләк итәргә була. "Әйткән сүз—аткан ук"—дигәндәй, аның бу фикере житәкчеләр тарафыннан хупланып, ярыш киләсе ял көненә билгеләнә.

Әйтелгән вакытта застава үзенең алты кешелек командасын мәйданчыкка тезеп тә куя. Күптән түгел генә мин күчкән хужалык взводында хезмәт итүчеләрнең күбесе—шоферлар, складларда эшләүчеләр һәм шуның ише һөнәр ияләре. Аларның кайсылары үз эшләрендә булып, кайсылары уйный белмибез дип, уеннан баш тарттылар. Взвод данын саклау сержант Иманаевка һәм миңа йөкләнде.

Тыйнаксызлык күрсәтеп тә, мактанып та әйтүем түгел, волейбол, футбол уеннарын мин яратып һәм оста уйнадым. Ул минем кечкенәдән күңел юаткычым булып, кулымнан туп төшмәде. Без яшәгән Ягодный бистәсендә футбол, волейбол мәйданчыклары житәрлек иде. Без, малайлар, жае чыккан саен урамга урам бүленеп тә, еш кына Пороховой малайлары белән узара бу

уеннарның ярышларын да уздыра идек. Ял көннәрендә Аккош күле буена ял итәргә барсак та, кояшта кызынып, сулар коенып чыккач, тагы шул тупны чөйдек. Минем кулга кергән туп җанланып киткән сыман була. Мин аның белән цирк жонглеры кебек кыланам. Бигрәк тә минем подачаларым мәкерле, зәһәр иделәр. Артына кәттә итеп сугып җибәргән тупларым зыр-зыр әйләнеп оча иделәр. Мондый тупларны алу тәҗрибәле уенчыларга да бик кыенга туры килә. Чөнки алар сабын шикелле, кулдан шуалар. Ә инде һавага сикереп, бар көчкә өстән аска кадап тондырылганнан соң, ук кебек кадалып, томырылып төшүче тупка каршы тору—зур волейбол осталарының гына кулыннан килә торган гамәл. Кулларына беренче мәртәбә туп алган кичәге авыл егетләренең мөмкинлекләре бу очракта аз һәм чикле, әлбәттә. Кыскасы, без үскән чорда, әле телевизор дигән сихри тартмалар юк чакта, эштән кайтып, ашап-эчкәч, бөтен шөгылебез—туп тибү, волейбол уйнау, кичләрен Петров паркына танцыга йөрү булды.

Мәйданчыкның әйләнә-тирәсен офицерлар, аларның гаиләләре, кышлак таҗиклары, бала-чага уратып алган. Әйткәнемчә, каршы якта алты солдат, без икәү уйныйбыз. Уенның беренче өлешендә каршы якның бер-берсенә бәрелә-сугыла, егыла-тора булса да, җинүгә ирешү омтылышы зур булды. Ләкин, егетләрнең теләк-тырышлыклары үз араларында аңлашу булмау аркасында, подачаларның сетканы да үтеп чыга алмаулары кебек хаталарга кереп батты. Һәм алар уенның нәтиҗәсен дә билгеләде. Ул 15 кә 7 белән тәмамланды. Икенче өлештә уйнаучыларның кайберләрен башкалары алыштырды.

Кыскасы, уен безнең файдага 3:0 булып бетте. Әлбәттә, безгә дә хәйран тир түгәргә туры килде. Һавадагы туп артыннан йөгереп йөрү һич тә җиңел түгел.

Әлбәттә, уен офицерлар катнашы белән узган булса, бүтәнчә тәгәлләнер иде. Ә бу бары тик солдатларның үзара ярышы гына булды. Уен беткәч, өлкән лейтенант яныма килеп, аркамны какты. Молодец, диде. Читтән генә безне күзәтеп торган майор Мелкозеров та баш бармагын күрсәтеп, күзен кысып куйды.

Бүләккә бирелгән биш кило "Радий" конфеты барыбызга да җитте. Аны, бик теләсәң дә, жиде-сигездән артыгын ашап булмый, тиз туйдыра икән.

Юк, мин счет төймәләрен кучереп, сан санап утыручы "тыл күсесе" түгел. Һәркайсыбыз дүрт-биш сәгатькә дозор булып, яки берәр офицер белән сактагыларның уяулыгын тикшереп кайтабыз. Әлбәттә, бу йөрүләрдә мин әле кече наряд булып кына, өлкән нарядтан сигез-ун адым ара калдырып барам. Һәм һәр икебез дә көтелмәгән хәлләргә әзер булып барабыз.

Шундый нарядларның берсеннән йөреп кайткач, карабинымны җәһәт кенә чистартып кую теләге белән, шомполның юан башына чүпрәк урап, карабинның көпшәсенә тыктым. Чүпрәк күбрәк булдымы, әллә салкыннан кергән көпшә үзенә ябыштырып алдымы, ул яртылаш кереп, туктап калды. Аны никадәр аска батырырга тырышсам да, бармый гына бит, каһәре. Янымда яткан тунымның җинен шомполның югары очына куеп, сул кулымның уч төбен аңа салып, нык кына басуым булды, шомполның очлы башы тун җиңе белән уч төбемне үтәли тишеп, кул аркасына килеп тә чыкты. Көтелмәгән бу хәлдән аптырап, үз күзләремә үзем ышанмый карап торам шомпол очына. Кеше күреп, хурлыкка калганчы дип, аны кире тартып чыгардым. Кул бер ай буе үзәккә үтеп сызлады. Шулай, көннәрдән бер көнне иртәгесен кулыма карасам, ул танымаслык булып, күпереп шешкән иде. Табиб капитан Зарипов янына санчастька йөгердем. Ул кулымны җентекләп карагач:

—Нәрсә белән тиштең моны?—дип сорады. Мин моннан бер ай элек

булган хәлне сөйләп бирдем. Табиб сул кулымның ике бармак арасын ярып, шомпол һәм тун җине белән ияреп кергән шакшылардан, йон кисәкләреннән чистартып, тегеп куйды. Җөе әле дә беленеп тора. Укол ясап, бер-ике көн ятып торырга кушты. Температурам 39°ка кадәр күтәрелеп, берничә төнне йокысыз үткәрдем. Ләкин кулны чүпрәк белән муеныма асып, хезмәткә йөрдем. Үзе егылган еламас диләр бит. Еш кына казармада, йә конюшняда дневальный булып торам. Мондый нарядлар мина складлардан әйбер алырга теләүчеләргә кирәкле документ-кәгазьләрне язып бирергә мөмкинлек тә бирә. Монда берәү дә эшсез тормый. Чик буена солдат-офицерларны кирәк кадәр генә итеп җибәргәннәр. Шуңа күрә, бөтен эшләрне дә үзебезгә эшләргә туры килә. Ләкин иң изге бурычыбыз, һичшиксез, дәүләтебез чик буйларын һәрвакыт йозакта тоту. Бигрәк тә безнең застава карамагына кергән араны. Чөнки бу арада чик бозарга теләүчеләргә мөмкинлекләр күп. Пәнҗ елгасы буенда куе камышлар үсеп утыруы, вак куаклыкларның куелыгы һәм елганың тарлыгы да унай шартлар тудыра. Елганың ике ягында да—зур-зур кышлаклар. Аларда яшәүче таҗиклар үзара кардәшләр, күбесе якын туганнар да әле. Алар рөхсәт ителгән кадәрле урынга килеп, утын, камыш җыйган, тегесен-монысын эшләгән сыман итеп, теге яктагылар белән җырлар аша сөйләшәләр, хәбәрләшәләр, хәл-әхвәлләрен сорашалар. Ә җырны кем тыя алсын ди!? Юк, әлбәттә. Чик бозу очраклары да бар. Безнең яктан бер таҗик агае үзе белгән яшерен сукмаклар аша теге, каршы якка, чуеннан коелган казаннар, алюминий савыт-саба ташый диләр иде. Ләнгәр кышлагы кибетендә бу әйберләр тулып ята, ә тегендә аларны акчага да табып булмый. Көн дә ашарга пешерергә казан кирәкме?—Кирәк! Савыт-сабасы белән дә шул ук хәл. Тик тотылмаган карак—карак түгел. Мин анда алты ай хезмәт иткән дәвердә аны тота алучы булмады. Кышлакта яшәп, бөтен төр яналыкларны, хәвеф-хәтәр китерерлек хәлләрне застава башлыгына яшерен рәвештә җиткереп торучыларның хәбәрләренә таянып, чик сакчыларын берничә мәртәбә яшерен постларда, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр, тәүлек буена җибәреп карасалар да, нәтиҗәсе булмады. Шушындый бер ауда мина да катнашырга туры килде.

Заставада тәүлек исәбе кичке сәгать сигездән башлана. Застава башлыгы солдат, сержант, офицерларны тезеп куеп, киләсе тәүлектә кемнең кем белән, кайчаннан алып, кайчанга кадәр, атка атланыпмы, әллә җәяүме, нинди наряд рәвешендә чик буен сакларга барасын әйтә. Ул көнне мин Казан егете сержант Латыйпов Тәүфыйк белән барырга тиеш булдым. Инде юлга чыгарга әзерләнгәч кенә безне застава башлыгы үзенә чакырып алды.

—Сезгә өченче постта секрет хезмәте үтәргә приказ бирәм!—диде ул.

Без кесәдәге тәмәке, шырпы, шылтырарга мөмкин булган барлык әйберләребезне почмактагы тумбочка сәндерәсенә куйдык. Бушап калган кесәләребезгә өстәл читендә торган, погран паек дип аталган: шикәр, куе сөт, ит, ит белән кушып пешерелгән дөге, карабодай боткасы консервылары белән тутырдык.

—Суны флягаларга арыктан алырсыз. Карагыз аны, тыныгыз чыкмасын. Әгәр савыт-саба «сәүдәгәре» Сәмигулланы тотсагыз, ун көнгә өйләрегезгә ялга җибәрәчәкбез. Мәсьәлә отряд командиры белән килешенгән,—диде ул безне озатып.

Өченче пост Әфган чик сакчылары торган Кала-и-Пәнҗ крепосте каршындагы зур гына тау куышында иде. Без шыпырт кына, яшерен юллар белән килеп, ташның киң яссы өстенә менеп, аллы-артлы булып яттык. Тирә-як тып-тын. Шылт иткән тавыш та юк. Бөтен җирне чем караңгылык урап алган. Мондый абсолют тынлык бары тик тауларда гына

була. Табигатьнең шушы серле тынлыгында бөтен җан иясе изрәп йокыга талган. Әйтерсең, тереклек каядыр китеп барган. Тик Тәүфыйк белән без генә күзне шар ачып, колакны үрә торгызып, ара-тирә бер-беребезгә төрткәләп, әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп ята бирәбез. Иң гаҗәбе шул: башка вакыттагы кебек йокы килүдән тилмерүнең исе дә, һушы да юк. Без җете уяулар. Әллә застава башлыгының: "ун көнгә өегезгә отпускка кайтасыз!"—дигән сүзләре айныткыч тәэсир иттеме?

Ниһаять, Әфган ягыннан агып төшеп, Пәнҗ елгасына көмештәй суын койган Сәрхан дәрьясы тарлавыгыннан, сизелер-сизелмәс булып кына, таң беленә башлады. Караңгылык пәрдәсе тау өсләренә күтәрелә иде. Күп тә үтмәде, каршы якта Әфган гаскәриләре торган Госхан крепостеннән мәзиннең иртәнге намазга чакырган азан авазы яңгырый башлады. Тылсымлы Коръән моңының, Коръән аһәңенең илаһи бу авазы күңелнең иң тирән җирләренә кереп, иң нечкә кылларын тибрәтте. Ул сихри авазны тыңлаганнан-тыңлыйсы, ишеткәннән-ишетәсе килә иде. Совет власте безне имансыз дәһриләр итеп тәрбияләргә тырышса да, ата-бабаларыбыздан безгә әманәт булып күчкән бу тылсымлы моң, тылсымлы аһәң йөрәккә кереп, кан тамырлары буйлап йөгерде. Шушы моңга, шушы аһәңгә сусаган җан авазы, дин әһеле авазы белән кушылып, тау-кыялар, болын-тугайларны урап узды. Аның кодрәтле кайтавазы бөтен тәнемне биләп алды.

Кояшның көмештәй иртәнге нурлары тау битләренә, кыя ташларына үрелде. Әкрен-әкрен табигать тә җанлана башлады. Куе камыш араларыннан кыр үрдәкләре күтәрелде. Алар якындагы яшел тугайның куе үлән араларына кереп югалдылар. Без Тәүфыйк белән тау куышына кереп утырдык. Монда дымлы һәм хәйран гына салкынча иде.

—Их, бәрәр тәмәке булса иде,—ди Тәүфыйк.

—Соң?! Әнә нинди юан төпчекләр аунап ята. Суырырга гына түгел, тончыгырга да җитәрлек,—дидем мин.

—Тончыга, йөткерә генә күрмик. Югыйсә, бөтен эшне бозып куюыбыз бар.

—Әллә берәр консервы ачабызмы?

Без шулай эшләдек тә. Берочтан куертылган сөт ачып, флягадагы суга болгатып эчтек. Кем әйтмешли, тамак тук, өс бөтен! Чик буен бозып, теге якка кереп-чыгып йөргән Сәмигулланы тота алмасак та, көнелләр күтәрелеп китте.

—Рәис, әллә бераз черем итеп аласыңмы? Мин кизү торырмын,—диде Тәүфыйк.

Ул бинокль алып, куыш кырыендагы таш артына ятты.

Әйе, миллион еллар элек барлыкка килгән бу тау куышына кемнәр генә кереп сыенмагандыр да, кемнәр генә качып ятмагандыр. Нинди генә хәзинәләрне яшереп сакламагандыр ул. Бәлкем, бу куыш без сагалап яткан Сәмигулланың да ышанычлы качу урыныдыр? Бәлкем, вак ташлар белән түшәлгән идәне дә, киртләч диварлары да «күзле-колаклы»дыр? Әллә нинди серләр яшеренеп ятадыр? Әнә бит, ял итәр өчен нинди уңай ятак әмәлләнгән. Хуш исле печән белән түшәлгән. Бәлкем, әле безнең үзебезне дә туктаусыз күзәтеп торалардыр? Ничә еллар чик бозып, кереп-чыгып йөргән Сәмигулланың да тотылмау сере монда яшерелгәндер?

Мин уянганда сәгать телләре унбердән узган иде инде. Беркат ашап-эчкәч, Тәүфыйк ял итәргә ятты, мин кизү тора башладым. Һава искиткеч шәп, тын. Бер генә болыт әсәре дә булмаган зәңгәр күк йөзендә сентябрь кояшы елмая. Еракта, тау сыртларында, кыя башларында гасырларның кар-бозлары җемелди. Аларның нурлы шәүләләре Пәнҗ суларында тибрәлә. Елга буендагы саргылт камышлар, вак куаклыклар кояш нурларында

коеналар. Алар башларын иеп йокыга талган сыман. Ямь-яшел Ассор болынында колхоз көтүе йөри. Алма, чия агачлары арасына кереп яшеренгән Зунгван кышлагы бүген аеруча жанлы. Бәрәнге басуларында да кызу эш кайный. Колхоз машиналары кышлак белән басу арасындагы юлдан тузан туздырып бәрәңге ташыйлар. Алар бормалы тар урамнарга кереп, күздән югалалар. Туктаусыз гүләп торган мотор тавышлары колак төбеннән китми. Каршыдагы фермадан як-якларына зур кәрҗиннәр элеңгән ишәкләр яңа гына уңышы җыелып алынган басуга тирес ташый. Баш очларына су тулы чиләк куйган хатын-кызлар кышлакның бормалы урамнарына кереп югалалар. Йорт морҗаларыннан чыккан саргылт төтен баганалары, тау битләренә сыланып, югарыга үрмәли. Алар теләр-теләмәс кенә таралып, тын һавада юкка чыгалар. Ипи кибетенең ишеге укучы балаларның туктаусыз кереп-чыгып йөрүләреннән ябылырга да өлгерми кала. Майланмаган тупсаларының шыгырдап ыңгырашуы аерым-ачык ишетелеп тора.

Мин биноклемне каршы якка борам. Анда—ташып, шаулап аккан Пәнҗ елгасы. Сентябрь аеның кояшлы булуы, көннәрнең җылы торуы тау итәкләрендәге ап-ак кар өемнәрен, кыя башларындагы мәңгелек бозларны эретеп юкартты. Елгалар тулып, җәелеп киттеләр. Үзән-тугайларны су ташкыны басып алды. Пәнҗ елгасының тар урыннарында су ташкыны шулкадәр көчле ки, ул күз иярмәс тизлек белән ага. Балык тәнкәләренең кояшта чагылышларыннан су өсте көмеш кебек ялтырап тора. Куе чирәмгә күмелгән елга буйларында куяннар, әрләннәр йөгерешә. Алар уйнаша-уйнаша камышлар арасына кереп югалалар. Алардан курыккан кыр үрдәкләре бакылдый-бакылдый һавага күтәреләләр. Елга өсләрен кыйгачлап берничә мәртәбә әйләнәләр дә, янә тугайларга, үзәннәргә төшеп утыралар. Елга буйларын вак куаклыклар сырып алган. Бары тик «боевой остров»ның өстен генә вак чуер ташлар түшәгән. Бирелә 1942 елны чикне бозып кергән әфган солдатлары белән канлы бәрелеш булган. Даханләрья белән Пәнҗ елгалары арасындагы бу утраучыкта берничә сәгать канлы сугыш барган. Әфган солдатлары күп кенә сугышчыларын югалтып, чигенергә мәҗбүр булганнар. Әлбәттә, безнең яктан да югалтулар аз булмаган. Ул сугыш каһарманнарының каберләре застава ишегалдында.

Бездән уң якта Әфганстанның Кала-и-Пәнҗ кирмәненең җимерек хәрабәләре калкып тора. Алар кемгәдер үпкәләгән нәүмизләр кебек басып калганнар. Алардан ерак түгел генә төзелгән яңа крепость әйләнәсендә сирәк-сирәк әфган солдатлары күренгәләп ала. Алар әледән-әле крепостьтан чыгып, безнең якны күзәтәләр. Тагын шуны да әйтергә кирәк: әфган солдатларының өстендә көндәлек тормышта киеп йөргән халат, йәки якасыз, күкрәк турысы ачыла төшкән бишмәт булыр. Алар сугыш коралларын да бик сирәк очракта тоталар. Ә менә командирлары яшел сукнодан тегелгән хәрби формадан йөриләр.

Тау итәкләреннән үткән тар сукмактан, иске җилән-халатларын алларына җыеп, ишәкләргә атланган кешеләр узып тора. Алар үзара кычкырып сөйләшәләр, нәрсә хакындадыр кызып-кызып бәхәсләшәләр. Сәрхан елгасыннан утын, чыбык-чабык төялгән чүл кораблары—дөяләр чайкала-чайкала, акрын гына тар сукмактан Ишан кышлагына таба атлыйлар. Дөяләләр каршыга очраган кешеләр белән кулларын күкрәккә куешып күрешәләр. Җинелчә генә иелә төшеп аерылышалар. Кара пәрәнҗә япкан хатын-кызлар ирләрдән читләшеп, башларын читкә бора. Нинди генә төстәге чүпрәк юк алар кигән күлмәк, халатларда! Күпме генә ямау кермәгән ул мескеннәргә.

... Менә сукмак ыгы-зыгы йөрүчеләрдән бушап, тынып калды. Ләкин бу пауза озакка бармады. Беркадәр вакыттан соң Госхан постыннан бер

җайдак, ике җәяүле чыкты. Алар Крип кышлагын читләтеп үтеп, Сәрхан елгасы аша салынган, сират күпере сыман, тар күперне кичеп, әфганлылар әрле-бирле йөри торган, әлеге дә баягы, үзәк тар юл-сукмактан юлларын дәвам иттеләр. Җайдак, күрәсең, бер зур түрә булса кирәк, аның өстенә кигән киемнәре затлы булып, башына ап-ак чалма чалган. Ул кыска камчысы белән, башын күтәреп, биеп баргандай мәһабәт ак атына җиңелчә генә орынгалап ала. Баскан урынында тик тора алмаган, атлар солтаны булган бу юргага камчының кирәге дә юк кебек. Атның әле алдына чыгып, әле артына төшеп йөгереп барган җәяүлеләр түрәдән күзләрен алмыйлар. Алар икесе дә хәйран таушалган кара халатлардан булып, башларындагы аксыл чалмалары да ата-бабаларыннан мирас булып калганга охшаган. Менә алар иртән мәзин азан әйткән, әфган солдатлары хезмәт иткән крепостька килеп җиттеләр. Шуларны гына көткән бер адәм, уктай атылып чыгып, әле туктарга да өлгермәгән атның йөгән сабагын эләктереп алды. Түрәне озатып килгән кешеләр шунда ук йөгереп килеп, тиз генә чүгәли төшеп, үзләреннән баскыч ясадылар. Түрә аларның сыртларына басып җиргә төште. Ул кулларын болгый-болгый, бу мескеннәргә нидер әйткәннән соң, крепостька кереп китте. «Ут белән суны кушып булмый» ди әфган мәкале. Менә бу—шушы мәкальнең бүгенге космос заманындагы ачык чагылышы.

Йөрәк әрнеткеч күңелсез уйларымны моңлы музыка авазы өзде. Биноколемне сулга бордым. Күз алдыма унбишләп җайдак килеп басты. Бу—туй иде. Җайдакларның алда барганнары думбра чиертеп, барабан кагып, янә дә үзгә төр милли уен коралларында уйный баралар. Башкалар аларга кушылып моңлы-аһәңле җырлар җырлыйлар. Артта баручылары кода-кодагыйлар булса кирәк. Алар кызып-кызып сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Ләкин дәртле җыр, илаһи музыка дулкыннары тау башларын, кыя очларын инләп, тарлавыкларга, үзәннәргә төшеп җәелә. Менә алар минем белән тигезләнделәр. Мин аларның һәрберсен уч төбендәге кебек итеп, аерым-ачык күрәм. Уртада, ак атка атланганы, башын ак җәймә белән каплаганы, килен булса кирәк. Чөнки аның өстендә төрле чәчәк бизәкләре төшерелгән, тубыкларына кадәр житешле зәңгәрсу күлмәк. Атланган атының дилбегәсендәге тәңкәләр дә кояшта ялт-йолт килеп, нурлар уйната. Ул төрле төстәге кульяулыклары белән дә чуарланган. Аның артыннан кияү аты атлый. Егетнең бүген шатлыклы, тантаналы көне булса да, ул нигәдер сүрән. Зур чалма чалган башын түбән игән. «Дөяне күпер астына яшереп булмый»,—дип әйтә әфган халкы. Музыкантлар әле алга чыгып, әле артка төшеп бик тырышып уйнаса, җырласа да, кияүнең күңеле боек, аны нindидер тынгысыз уйлар борчый кебек... Алар ашыкмый гына Крип кышлагына кереп, күздән югалдылар.

Ул арада Тәүфыйк та уянып, ашарга-эчәргә хәстәрли башлады. Җылытып торырга мөмкинлек булмаганлыктан, погран паекларыбызның майлы кисәкләрен читкә этәреп, беркат тамак ялгап алгач, миңа да бераз ял итеп алырга мөмкин булды. Бу вакытта кояшның кайнар нурлары сүрелә төшеп, тау күләгәләре каршы якның тау итәкләренә сузылып ята башлаган иде. Караңгы төшеп, көндезге ыгы-зыгы, ары-бире йөрүләре тынып, кышлактагы утлар сүнә башлагач, безне алыштырырга сакчы иптәшләребез килде.

Атна-ун көн узды. Безнең кебек тагы дүрт төркем «секрет»та торучы чик сакчыларының борыннарына чиертеп, аларны төп башына утыртып, Сәмигулланың барыбер теге якка чыгып кергәне мәгълүм булды. Бәлкем, мин күргән туй ашларын да ул алып чыккан казанда пешергәннәрдер әле?!

Чик буйлары күп серләр саклый шул. Шундыйларның берсе хакында

мин дә сөйләмәкче булам. Вакыйганың моннан ярты гасыр элек булганын, Пәнҗ елгасы чик буйларының инде башка дәүләтнеке икәнен дә исәпкә алсак, ул хәзер сер дә түгелдер.

—Бар, атыңны иярлә! Застава башлыгы белән постлар тикшерергә барасың,—дип, кизү торучы сержант йокыдан уятты.

Мин җәһәт кенә киенеп, ат абзарына йөгердем. Анда кизү торучы солдат, застава башлыгы капитан Дмитриевнең атын иярләп, йөгән сабагыннан тоткан хәлдә, аны көтеп тора иде. Күп тә үтмәде, төз, чандыр гәүдәле, нык, житез адымлы капитан да килеп житте. Без атларны житәкләп, ишегалдына чыктык.

—Атлан атыңа,—диде башлык. Иярга менеп утыруга, ул миңа юл капчыгы тоттырды. Без кузгалып киттек. Мин артта, башлыктан тугыз-ун адымга калыша төшеп, аякларымны ияр өзәңгеләренә нык терәп, йөгәнне ике кулым белән бар көчемә үземә таба тартып, атымны көч-хәл белән генә тыеп барам. Шашып чабып китүдән аны бары тик тимер авызлыклар гына тыеп тора, дәртен баса.

Атның миңа бик кайнары эләкте. Юлга чыккач, хәле беткәнче бер чабып алмаса, аның күңеле булмый. Шушы шашкын гадәтен тыя алмыйча, ул берничә солдатны өстеннән мәтәлдереп тә төшергән. Шуңа күрә, аннан ваз кичкәннәр, башка атларны сайлаганнар. Ә бу исә, яңа килгән яшь солдатларның кавалерия һөнәре осталыгын белү-белмәүләрен күрсәтүче, аларны сынау аты гына булып, үзенә лаеклы хуҗа таба алмый, нәүмиз хәлдә, ирекка чыгарга, чабарга ашкынып, бәйләүдә кала биргән. Ара-тирә аны офицерлар да иярләп, сабак бирмәкче булганнар. Тик берчак заставага керә торган капка төбендәге арата-шлагбаумны жилдәй сикереп үтеп, ияр өстендә утырган замполит тар юлдан баручы кешеләрне чак кына таптамый кала. Бу хәлдән соң, шашкын дәртле, дуамал аттан бөтенләй кул селтиләр. Бәласеннән баш аяк.

Яшь солдат буларак, мин дә сынау үттем аның уйнаклап торган кыбырсык билендә. Мин дә шактый мәтәлдем. Нишләтәсең, чир китәр, гадәт китмәс, диләр бит. Тик һәр йозакның үз ачкычы булган кебек, һәрнәрсәнең дә бер жае була. Мин дә таптым аңа жай-әмәл. Дөресрәге, атым үзе табып бирде ул жай-әмәлне миңа. Шулай бер кичне, чик буена нарядка барырга чыккач, тотынды бу котырынып чабарга. Һич кенә дә тыяр хәл юк. Житмәсә, авызлыкларга да оныткანмын. Жилдәй чабып барганда, атым нәрсәдәндер өркеп, юл читендәге зур таш каршына килеп, аңа башын терәп, тынып калды. Бу көтелмәгән хәл мәсьәләне чиште дә куйды бит, әй! Ә Памирда зур ташларга, кыя-тауларга мохтажлык юк.

Без әфган солдатлары хезмәт иткән крепость каршындагы юл кырыена килеп туктаганда, сәгать төнге дүртенче киткән иде.

—Бар, Олы таш артына барып бас. Мине шунда көт,—диде капитан.

Мин атымның башын (үзе өйрәткәнчә) ташка терәп куеп, көтә калдым. Бераздан кирмән эчендәге мәчет манарасыннан әфган мәзиненең иртәнге намазга чакырып азан әйткән моңлы авазы яңгырады. Аның ягымлы тавышы изрәп яткан тау-кыяларны урап, кышлак йортларына үтеп керде. Йортларда «тычкан» утлары кабынды. Кешеләр ихлас күңелләреннән Аллаһ ризалыгы өчен намаз гыйбадәте кылырга хәзерләнергә керештеләр. Әфган мәкалендә: «Әтәч тавышы таң аттырмый» диелсә дә, әтәчләр дә вакыт житкәнен белдереп, тирә-якка аваз салды. Якында гына су чупылдаган, нәрсәдер кыштырдаган, кемдер пышылдаган сыман булды. Мин коралымны әзер тотып, алга, караңгылыкка бактым. Күп тә үтмәде, ниндидер шәүләләр пәйда булды.

—Стой! Кто идет? Пароль?

—Тише ты. Это мы, свои,—диде капитан, ярым пышылдап. Аның белән тагы ике кеше шәүләсе дә шәйләнде. Шәүләләрнең атлаганда чалбар балакларының чаж-чож килеп ышкылулары, киемнәренең юеш икәнлекләре, аларның әле генә судан чыкканнарын әйтеп тора иде. Кемнәр алар? Каян килгәннәр? Нинди суда булганнар? Әллә Пәнж елгасын кичеп, теге яктан чыкканнармы?

Капитанның:

—Отдай им вещмешок,—дип әйтүе уйларымны бүлде.

Шәүләләр тиз-тиз генә өсләрендәге киемнәрен салып, биштәрләреннән корыларын алып киделәр. Юешләрен капчыкка тутырып миңа тоттырдылар.

—Атыңны бу иптәшләргә бир. Үзен минем атыма күчеп утыр, икәү кайтырбыз,—диде капитан, һаман дә әле ярым пышылдап. Шәүләләр минем атыма менеп атлануга, шуны гына көткән кебек, атым уктай атылып, алга ыргылды. Артта утырган шәүлә артка чөелеп, дөп итеп җиргә килеп төште. Ул беренче мәртәбә телгә килеп, җиде кат оятсыз сүзләр белән урысча сүгенеп алды. Без тиз генә янына килгәндә башын ике куллары белән тотып, ысылдый-ыңгыраша башының арт ягын уа иде.

—Уңайсыз егылдың, ахыры. Берәр җирең имгәнмәде микән?—дип сорады капитан, атыннан төшеп.

—Иңбашымны кузгаттым, ахры. Башым да ташка бәрелде.—Ул янә ачы гына сүгенеп алды.—Инде,—дип, дәвам итте сүзен—иншалла, илгә исән-сау кайтып җиттем дигәндә, кирәк бит шушындый, көтелмәгән җүләр бәлага тарырга?!

—Гафу, монда беркемнең дә гаебе юк кебек...

—Мин берәүне дә гаепләргә җыенмыйм. Ләкин заставада атларның барысы да чыгымлый торган, котырган түгелдер ләбаса. Анда юаш, итәгатьлеләр дә бардыр, югыйсә,—диде ул үпкә катыш.

—Монда атның бер гаебе дә юк. Йөгән сабагын ныграк тотарга кирәк иде. Ә иптәшең шулай эшләргә өлгерми калды кебек. Ә атларның барысы да ашаган җирләренә тизрәк кайтырга ашкыналар,—диде капитан, үзен аклап.

—Бу шайтан атын иблис үзе дә тотып тора алмас. Минем белән дә алай-болай булганчы, алыгыз атыгызны,—дип, шәүләнең икенчесе безнең янга килде. Ул русчаны яхшы белә, ләкин төрки халыкларда булган акцент үзен сиздереп тора иде.

—Бар, үз атыңа атлан,—диде капитан миңа.

Мин атлануга, атым үзен гаепле сыман итеп, тынып калды. Әйтерсең аны алыштырып куйдылар.

—Әнә бит нинди тыңлаучан, яхшы ат ул,—диде капитан, әлеге чакырылмаган кунакларга карап.

Егылган кеше капитан белән, мин аның иптәше белән атларга атланып, заставага таба юл тоттык.

1955 елның 25 апрелендә иртән иртүк бүлмәгә өлкән лейтенант Бариев килеп керде. Ул походча киенгән иде.

—Мин бүген уң як флангтагы заставаларга чыгып китәм. Аларның отчетларын тикшереп, күп мәсьәләләргә ачыклык кертү кирәк. Син монда тулы хуҗа булып каласың. Бөтен эшләренне уйлап, җиде кат үлчәп эшлә. Бер грамм ким дә бирмә, артыгын да җибәрмә. Безгә кеше өлеше кирәкми. Өстебезгә хәрәм өймик, җаннарыбызны гөнаһлардан саклыйк,—диде ул.

Өлкән лейтенантның йөзе бүген аеруча житди иде. Күзләре монсу, менә-менә ташып китәрләр сыман мөлдерәмә иделәр. Аларны ниндидер пәрдә каплаган шикелле. Һәрвакыттагыча артка тарап куйган жете кара

чәчләрендә дә үзгәрешләр бар кебек тоелды. Мин аны болай тынычсыз, борчылган хәлдә беренче мәртәбә күрдем. Бу хәл мине дә әсәрләндереп, көрсендереп җибәрде. Чөнки мин аны бертуганым кебек итеп, чын күнелемнән яраттым, намуслы, туры сүзле кеше буларак хөрмәт иттем.

Шунадыр да, аның белән аерылу миңа җинел булмады. Ата тәрбиясе күрмәгән сугыш чоры баласына ул икеләтә кадерле иде. Һәм бу аерылышу гомерлеккә булып чыкты. Без башка очраша алмадык.

Бер кирегә китсә, китә бит ул, шайтан алгыры. Өлкән лейтенант китеп күп тә үтмәде, мин каты авырып, урын өстенә яттым. Температурам дүрт көн утыз сигездән төшмәде. Вакыт-вакыт ул хәтта кырыкка житеп, аңымны югалтып та торганмын. Бу чир йөрәк белән бәйләнгән булып чыкты. Ничек кенә булмасын, монда климат башка иде шул. Сулый торган һава составында утыз процент кислород житмәве, һава торышының сәгать саен диярлек үзгәреп торулары организмга тискәре йогынты ясады, күрәсең.

Көннәрдән беркөнне киномеханиклар әзерләү курсларына озатырга бездән бер кеше кирәк икән, дигән хәбәр таралды. Бу мине жилкендереп жибәрде. Ул кино дигән нәрсәнең ничек булуын, ак полотнода без күргән вакыйгаларны нинди сихри көчләр хәрәкәткә китерүе гажәп тә кызыксындыра иде.

Шушы, әлеге дә баягы, кино сәнгате серләрен белү-төшенү теләге мине чик сакчыларының Урта Азия округы тарафыннан оештырылган курсларга алып килде.

Округка кергән заставалардан җыелган утыз биш солдат арасыннан без ике кеше—инде гражданкада чагында ук киномеханик булып эшләгән урыс егете Носков һәм мин—курсларны отличнога тәмамлап, икенче категорияле кино-радио механик таныклыгына лаек булдык. Кайбер солдатларның белемнәре хәтта өченче категориягә дә тарта алмаганнарын исәпкә алсак, бу зур уңыш иде. Укылган фәннәрдән сынауларны "5" билгеләренә биргән, барлык төр аппаратураларның, көчәйткечләрнең төзелешен һәм эш принципларын яхшы үзләштергәнлектән, мине Мургаб отряды заставаларының иң югарысына жибәрделәр. Үземне округның, Хорог, Мургаб отрядларының зур, иркен залларында кино күрсәтергә калдырмауларының сәбәбен заставада хезмәт итә башлагач кына аңладым. Күп еллардан бирле ремонт-фәлән күрмәгән, искереп тузуның актык чигенә житкән бу аппаратура-көчәйткечләрне, бер тактлы движокны эшләтү өчен чын белгеч кирәк булган шул.

Бу, "Башгөмбәз" (баш каберлек) дип аталган, диңгез өсте тигезлегеннән биш мең ике йөз метр биеклектәге тауда кислородның кырык ике проценты житешми, салкыннар—кырык-кырык биш градуска житә. Әгәр инде тау араларыннан әфган жиле дә сызгырып исә башласа, ул жилекләреңә кадәр үтеп, тәнеңне үтәли кисеп йөри. Бу чакта Казан мех фабрикаларында тегелгән бүрекләр дә, сарык туннары да, киез-итек комбинатында басылган киез итекләр дә жылынны саклап кала алмыйлар. Сине бары тик хәрәкәт кенә жылыта. Сигез, ун сәгатькә чик буен сакларга билгеләнгән урынга килгән ике кешелек нарядның берсе чик буен күзәткәндә, икенче иптәше күтәрә алган ташларны бер өемнән икенчесенә ташый булыр. Шулай чиратлашып, таш ташып кына жылынырга мөмкин. Тик атланып йөргән атларыбызга гына кыенга туры килде. Алар таш ташый алмаганлыктан, ташлардан өеп үзебез ясаган яшерен куышларда хәрәкәтсез торырга мәжбүр иделәр. Шуңа күрә ул мәхлукларны әледән-әле алыштырып тора иделәр.

Ә инде кар ява башлап, бураны да купса, бөтен тирә-як ап-акка төренеп кала. Кар-буранның тыгызлыгы шуның кадәр була ки, әйтерсең ул өстеңә ишелеп төшеп тора. Хәтта, заставадан ярдәм сорап атылган кызыл төстәге

ракеталар да, тиешле югарылыгына менеп житкәнче үк томаланып, күздән югалган була. Чик сакчыларына маяк хезмәте күрсәткән тау-ташлар, аерым билгеләр күмелеп кала.

Шушындый хәвефле төннәрнең берсендә чуаш егете Василий белән нарядта идек. Заставадан унике чакрым тирәсе ераклыкта безне кар өермәсе урап алды. Күз ачып йомганчы юл-сукмакларыбыз кар белән тигезләнеп, юкка чыкты. Тирә-як дөм караңгылыкка чумган. Минем арттан эзгә-эз бастырып килгән Василийны чак-чак күреп була. Атларыбыз кар көртләренә бата-чума кайтыр юнәлештә баралар кебек. Бөтен ышаныч аларда хәзер. Озак, бик озак йөрдек без кая барганыбызны белми. Ул вакыт эчендә застава белән безнең араны берничә мәртәбә әйләнеп кайтырлык булды инде. Әгәр туктап калсак, һичшиксез өшеп-катып үләчәкбез. Шулай йөри торгач, берзаман атларыбыз туктап калды. Башларыбызны күтәреп карасак, алдыбызда киез чатырлар тора. Болар безнең заставага каршы, Әфганстан жирендә сарык, кәжә көтүләре көтеп яшәп яткан, совет властеның кан дошманнары булган, элеккеге басмачыларның чатырлары иде. Өстемә кайнар су коелгандай булып китте. Каз тәннәре чыгып, калтыранып куйдым. Әгәр бу адәмнәр сизенеп, безне эләктереп алсалар, ахыры, һичшиксез, фажига белән бетәчәк. Йә суеп үтерәчәкләр, йә кол итеп сатачаклар иде. Хәзер үзебезнең кайда икәнебезне ачыклагач, тавышсыз-тынсыз, шыпырт кына, тизрәк киту ягын карарга кирәк иде. Көтмәгәндә, нәни чакта әбием өйрәткән, ләкин күптән укымаганлыктан онытылып ук барган догалар апачык булып, исемә килеп төштеләр. Мин аларны тиз-тиз укый башладым. "Йә Раббым, үзеңә тапшырдым, рәхмәт-шәфкатеңнән ташлама", дим. Шулчак кешегә әйтеп, кеше ышанмаслык могжиза булды. Безнең алдыбызда бүрек кадәр нур йомгагы пәйда булып, застава юнәлешенә тәгәри дә башлады. Ул арада атларыбыз да аңа иярделәр.

Тылсымлы нур йомгагы безне заставага кадәр озата барып, ничек пәйда булса, шулай ук юк та булды. Застава начальнигы өлкән лейтенант Шилов чик сакчыларын күтәреп, үзен кая куярга белми, бераз яктырганны көтеп тора иде. Безне үтә дә шатланып каршы алдылар. Ләкин үзебез бу шатлыкның никадәр зур икәнен, аның үлем белән яшәү арасында туганын аңлар хәлдә түгел идек әле.

Мин, наряд башлыгы буларак, өлкән лейтенантка хәлнең ничек булганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

—Сез дәүләт чиген бозып, күрше Әфганстан жиренә кергәнсез. Бу очракта сезнең бер гаебегез дә булмаса да, әгәр төрмәләрдә черисегез килмәсә, бу вакыйганы берәүгә дә, бер кайчан да сөйләргә тиеш түгелсез,—диде ул.

Без сөйләмәскә ант иттек. Бу минем, шул вакытта биргән антымны, 50 ел вакыт үткәннән соң, беренче мәртәбә бозуым.

Шушындый, үтә кырыс шартларда үз вазыйфаларын чын ир-егетләрчә үтәгән чик сакчыларының, берәүләренең чәчләре коелып, берәүләренең тешләре төшсә дә, бу үзгә, күнекмәгән табигать кочагында яшәп, гомерлеккә йөрәк-кан тамырлары авырулары алсалар да, берсенең дә зарланып, язмышын каргый-каргый шыңшыганын ишетмәдем. Өйдән язган Яңа ел белән тәбрикләү открыткаларын, хатларын беренче май бәйрәме көннәрендә алсак та, һичкемгә дәгъва белдермәдек. Чөнки тормыш шартларыбыз шундый иде. Ике ай тирәсенә сузылып, жәйне хәтерләткән арада, янә дә үзәк өзгеч салкын, өермәле кар-бураннары белән кыш башлана. Перевал ябылуга дөнья белән булган бәйләнеш-мөнәсәбәтләребез бары тик яшерен уздырылган телефон элемтәсе аша гына кала. Ләкин физик сыйфатлары ягыннан дөньядагы күп кенә жан ияләреннән калышкан, кеше дигән шушы иң нәфис, иң асыл зат бер генә жан иясе дә түзә алмаган авырлыкларга

түзә ала, чыдый ала, сабыр була ала. Чөнки ул—акыл иясе. Кеше, әфган мәкале әйткәнчә: "Таштан каты, чәчәктән йомшак зат."

Илебез чикләрен безгә сакларга ышанып тапшырганнар икән, димәк, бу зур ышанычны намуслы хезмәтең белән акларга да кирәк. Мондый дәүләт дәрәҗәсендәге эш-гамәлләрне бары тик лаеклы ир-егетләргә генә йөклиләр ләбаса.

Мин чагыштырмача бәхетле гомер кичердем. Янәшәмдә үзләренең күркәм кешелек сыйфатларын саклап калган чын иптәшләр булды. Алар үзләренең игелекле ярдәмнәрен тәкъдим итәргә әзер тордылар. Кешене авырлыклар сыный, ул кыенлыклар аша сынала. Нужа күрмәгән, лаеш шулпасы чөмермәгән, тормыш сикәлтәләрен үтеп чыныгу алмаган ир-егетләр һәр очракта да ышанычлы була алмыйлар. Заставада ундүрт ай хезмәтем дәверендә кырыс сынаулар үтеп, чыныгулар алган кешеләрнең никадәрле кешелекле, рәхимле-шәфкатьле булуларын күрдем. Застава башлыгы өлкән лейтенант Петр Шилов шундыйларның берсе булды. Иленә, үз-үзенә һәрвакыт тугры калган, чандыр гәүдәле, какча яңаклы, гәүдәсен хәрбиләрчә төз тоткан, өс-башын һәрвакыт чиста, пөхтә йөрткән, эчкерсез күңелле, олы йөрәкле бу затны мин бервакытта да онытмадым. Ул миңа һәрвакыт үрнәк булды. Хәрби хезмәт елларыма инде илле ел вакыт үтсә дә, мин аны зур ихтирам белән искә алам.

---



## "КАЗАН УТЛАРЫ" ЕЛЪЯЗМАСЫ

**журналыбызда дөнья күргән:**

70 ел элек (1938)—**Абдулла Алишның "Сер тотмас үрдәк"** әкияте;

65 ел элек (1943)—**Тажи Гыйззәтнең "Даулы көннәр"** драмасы, **Салих Батталның "Шинель"** шигыре;

60 ел элек (1948)—**Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"** романы, **Әмирхан Еникинең "Кояшлы иртә"** хикәясе;

55 ел элек (1953)—**Мирсәй Әмирнең "Ялантау кешеләре"** романы;

50 ел элек (1958)—**Юныс Әминевнең "Гөлчәчәк"** драмасы;

35 ел элек (1973)—**Шәйхи Маннурның "Агымсуларга карап"** повесте;

5 ел элек (2003)—**Мәдинә Маликованың "Мендем биек тауларга"** повесте.



Ркаил
Зәйдулла

# ИСКЕ МОҢ—ГАЛИҖӘНАП...

## Китап битләре

**Китап битләре пышылдый,
Эндәшә, тыңлый белсәң.
Йөземне яшерәм аңа:
Сез исән, ди, сез исән.**

**Китап битендәге юллар—
Гүя җиңелмәс гаскәр.
Сафлары төгәл, тоташтан,
Мәңгегә өзелмәсләр.**

**Китап битләрен актарам...
Чыга да саксыз җиле,
Гасырларны айкап кайта,
Коела китап көле.**

**Тарихның олы юлыннан
Мәхрүм булып калсак та,
Татарның түрендә китап
Торган диләр һәрчакта.**

**Китап битләре пышылдый,
Кемнең сәлам юллавы?
Монда дала сабырлыгы,
Үлгән урманнар шавы.**

**Китап битләре пышылдый,
Аңлый белсәң—эндәшә.
Йөземне яшерәм аңа...
Ул, елап, бәхилләшә.**

## Ул

*Ренат Таҗетдинга*

**Ул сәхнәгә яшәргә дип килде...
Тормыш сыман сәер уен бу,—
Гасырлардан килгән татар гаме
Йөрәгенә аның сыенды.**

**Ул хан булды монда, тәхет тотты,
Һәм кол булып ятты тупсага.
Тик йөрәге аягүрә калды
Өметләрне упкын упса да.**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962)—*шагыйрь, прозаик, публицист; "Ил", "Мәгарә", "Ташка ордым башны" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Ул сәхнәдә ат уйнатты безгә,
Хыялдагы гаярь аргамак
Түшәмнәрне алып күккә ашты,
Очты йолдызларны аралап.

Ул үзенең күңел нуры белән
Тоташтырды ерак елларны.
Елый-елый көлде тамашачы,
Көлә-көлә аннан елады.

Ул яшәде, ә без уйнаганбыз
Төшенмичә уен серенә.
Баш иде ул, бөкре мәхдүм сыман
Ил сагышын салып иңенә.

Ул сәхнәгә яшәргә дип килде,
Һәм яшьнәгән кебек яшәде.
Яшәячәк!—югалганчы тәмам
Җирдә соңгы татар җәсәде.

## Иске моң

Сыздыра татар гармуны!
Ярсый да, аннан янә
Моңнарын түгеп күңелгә
Сызлана, өзгәләнә.

Тарала гүя далада
Кылганнарның исләре.
Кылыч чыңы. Һәм кайдадыр
Аргамаклар кешнәве
Ишетелә тонык кына.
И, син илаһи мизгел...
Җәл түгел мондый чакларда—
И күңел!
Өзел, өзел.

Түгелә аһәң, сеңдереп
Борынгы үкенечне,
Сабантуй әләме өстә
Һаман җилферди төсле.

Язылa кинәт җилкәләр,
Ут ала җанны ялмап.
Янә иргә менгерә
Иске моң—галиҗәнап...

## Тавышлар

Шәһәр гөрелтесе...
Асфальт исе...
Аждаһадай кран—тәкәббер!
Карап торам менә кичке күздә
Сигезенче каттан шәһәрне.
Таш диварлар...
Бетон...
Машиналар...

Урам фонарьлары утында
Сүрән көлемсерәү күрәм никтер...
Шәһәр гөрелтесе йотыла
Галәм тынлыгында... мәңгелектә.
Беркем сизми ыгы-зыгыда,
Беркем сизми шуны: янәшәдә
Елый-елый йолдыз егыла.

Һәм ишетми беркем күк йөзендә
Көтүченең курай тавышын.
Сыер мөгри...
Ат пошкыра монда...
Тургай сайрый күккә ябышып.

Сукыр тәрәзәләр каш сикертә.
Подъезд төбе... табут капкачы.
Ярсый-ярсый өзгәләнә гармун.
Күршедә туй: ачы да ачы!
Һәм бүртенә шәһәр каләш кебек.
Ишетәмсең әнә, күрәмсең—
Янәшәдә сабый сыман үксеп
Ертылганын яшел чирәмнең...

## Караим

Йөзен аның җыерчыклар баскан—
әйтерсең лә җәтмә эчендә.
Хәтерендә диңгез дулкыннары,
бетмәс-төкәнмәс юл—исендә.
"Сабыр бул!"—дип, җилдә-давылларда
күккә ашкан нәсел агачы...
Тамыр җибәрмәгән яңабаштан
бер куак та...
Ачы туфрагы...
Тозлы-кара тирдән, күз яшеннән...
Үзгә тупракларда башлана,
төгәлләнә тәкъдир.
Дан-шөһрәтең
бүтәннәргә була ашлама.

Күптән түгел генә таныштык без:
мөлаем да сыман, кырыс та...
"Хатыным, ди, татар, чәчрәп тора!
Һәм, әлбәттә, балам—урыста".
Күзләрендә—хазар газаплары
яһүд әрсезлеген томалый—
ятим калган ике әнчек гүя
офыкларны ялап юмалый.

Ефәк юлы...
Кырым базарлары...
Чөфүт-кала...
Торса тезләнеп,
бәгыренә күчә онытылган
каберләрнең тыйнак эзләре.
Кәрван үткән яшел далаларда
җан балкышы—учак кабызып

"Тәңрем!"—диеп эндәшкәнгә мәллә
йөз чөергән яһүд раббысы?

"Көйлик, әйдә, агай, иске җырны,
сезнең яра—безнең яра",—дим.
Сүзләр уртак... моң да...
Ә язмышлар?
Төнге Казан...
Соңгы караим...

## Камалыш

Күрмим сезне һич тә! Сез дә
ишетмисез мине, ишет-
мисез. Ә бит дөнья тишек-
ләрдән тора. Ләкин ишек
эзли һәркем, гүя анда—
теге якта инде, тышта—
ул кемгәдер кирәк! Юкса
безнең язмыш—камалышта...

Заман, диләр... заман... заман...
шул ук заман монда—саңгыр-
ау бу дөнья уяу һаман.
Юеш пәрәвездәй яңгыр
ачык күзләремә сыла-
на да кап-караңгы төндә
мин дә йолдыз эзлим елап.

Елан кабыгын салгандай,
Күңелдәге еллар иша-
рәсен ташлап, йөз чөереп!
Мин, ниһаять, киттем кичә
төнге аулак сукмаклардан
челтер-челтер аккан чишмә-
ләрне эзләп. Һәм эзләрен
таптым ап-ак карда.

Алар бераз җылы сыман
иде... Мин аңладым—анда
сез булгансыз инде, тышка
юнәлгәнсез төнге сукмаклардан,
тик эзегез генә мәңге-
леккә калган камалышта...



Роза
Мулланурова

# ӨРӘҢГЕ ӨРӘГЕ

ХИКӘЯ

Вак яңгырлы моңсу көзнең кыска көне сүнеп бара иде инде.

Тынычланып, йокыга ойый башлаган ирен бимазаламаска тырышып, кузгалырга да кыймый, шым гына утыра иде Кәримә. Шулчак стенага тыштан кусәк белән ордыларммыни, тәрәзә пыялалары дерелдәп зыңгылдады. Утырган җирдән кинәт сискәнеп ул сынын турайтты, ятакка күз төшерде. Сизенүе хак икән: йокламый ире! Хәлсез күз кабакларын кыймылдатырга иренеп ятуы идеме?

Комга сеңгән су кебек көннән-көн көч-куәте кимесә дә элеккечә колакка сак, тавыш-шыгырдауларга үтә сизгер ул. Ә шомлы шыкырдау янә кабатланды. Идрис нидер әйтергә теләгәндәй талпынып куйды. Янак сенерләре тартышты. Каны качкан, көл төсенә кергән хәлсез иреннәре арасыннан өзек-төтек ике сүз сөзелеп чыкты:

—Ки-л-е-еп... жит-кә-ән мени?...

Ишетмәмешкә салышып колак яныннан үткәрмәкче иде дә, яхшысынмады. “Кем?” дип тә сорашмады. Китмәскә килгән чир белән көрәшә-көрәшә талчыккан ир генәме, хәтта ни сабыр хатын үзе дә бу тигезсез алышта арый башлады бугай. Түземлеге төкәнмәс анысы, чыдам бит ул. Тик ялгышып кайчактагы гажизләнүе тышка бәреп чыга күрмәсен. Бу юлы да: “Тузга язмаганны сөйләмәсәнә!”—дип кырт кисмәкче иде дә, туктап калды. Мәңгелекнең чигендә—бер аягы җирдә, икенчесе гүрдә асылынып торган кешенең нинди хисләр кичерүен, алай гынамы, күзенә ни-нәрсә күренүен аңлап-белеп була димени?!

—Жил генә ул, жил генә! Йокла!—Бала юаткандай көйләп, юрган астыннан сизелер-сизелмәс кенә беленеп торган, юкарган-кипкән кулын табып, үзенең җылы учына алды, иркәләп сөйде.

Идрис, үзсүзле бала сыман үҗәтләнеп, баш калкытырга азаплана иде:

—Әж-жәл ул! Үзе!—диде өзеп-өзеп.

—Чынлыкта, өрәңге!—дип карышты хатын, ваемсыз-уенчак күренергә тырышып.

—Өрәңге өрәгемени?

—Өрәк ди! Булмаганны! Чаган, алайса.

—Чаган... да чага.

—Кисеп ташлыйк шуны, дип ничә әйттем. Тыңламадың ич. Үҗәт күрше җинде, биреште. Кеше сүзенә карап тыелгач соң... Әнә, йорт ышыгында иркенләп үсә торгач, муртайган өрәңгең безнең балконга авышып-ятып беткән. Ботагы тәрәзәгә тия. Шул шыкырдата! Иртән Исмәгыйльгә әйтеп кистерәм.

---

Роза МУЛЛАНУРОВА (КАМАЛЕТДИНОВА)—*язучы, журналист; «Чишмә күзе», «Ялгыз каеннан да ялгыз» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

—Ан-арчы... яш-әп булса...

—Әйттен сүз! Яшибез әле!

Хатын, артык сүз озайтуның файдасыз икәнен чамалап, тынды. Юрган читен төзәткәләде. Ир күзләрен йомып, янә йокымсырагандай итте. Гөнаһ шомлыгына, жил көчәйде, ахрысы. Шүрәле бармакларыдай тырпайган, тармаклы үҗәт өрәңге ботагы балкон тәрәзәсен каккандай, бәреләсугыла.

"Тук-тук... Тук-тук!.."

Әйтерсең, нидер даулап, какшаган балкон аратасын шыкырдата. Эчкә, жылы бүлмәгә кертүләрен таләп итеп үҗәтләнә сыман.

—Үч ала... ул шу-лай...—Кысылган иреннәр арасыннан саркып чыккан сүзнең мәгънәсенә баштарак төшенми торган хатын, аңлап алгач, кырт кисте:

—Сөйләмә юкны!

—Юк димә! Теге чакны... тамырын корытырга... Кизәнгәнне онытмый ул.

—Агач-куаклар—үч саклый белми. Табигать хәзинәсе лә. Жимешсез агач үссә бигрәк тә саваплы икән. Аллага зекер әйтеп утыра ди алары. Имеш.

—Менә... Әйттен!

—Кеше генә үчле, мәкерле... Агач андый түгел.

Өч катлы иске йорт түрендә жәелеп үскән карт өрәңге берәүнең дә кадерлесе түгел югыйсә. Аны беркем утыртмаган. Жил орлыгын каяндыр очыртып китереп ташлаган да дымлы туфракта шыткан ул. Тамырланган. Йолкып та ташлаганнар аны, чабып та караганнар... Муртаеп, башын аска игән өрәңгене жил дә йолыккалый, айкый-чайкый. Әмма ул талымсыз. Үсә.

Идрис ничәмә-ничә еллар шәһәрдә яшәп тә чын кала кешесенә әйләнә алмады инде. Кендеге авылга береккәндәй туган ягын сагынып йөдәде. Баштарак, аспирантурада укыган елларында, тулай торак кысанлыгына күнә алмыйча, ир жаны иркенлеккә тартыладыр дип, үз-үзен юата иде Кәримә.

Калада—Яңа Бистәдә туып үскән Кәримә өчен ирнең бу гамәле ят иде: Ходайның һәр бирмеш якшәмбесендә, бердәнбер ял көнендә, таңнан торып, тәмле йокыны бүлеп, яп-яшь хатынын ялгыз калдырып, аркага биштәр асып ничек авылга кайтып китмәк кирәк?! Адәм рәтле юлы булса бер хәер! Язын-көзен тездән былчырак ерып, тузан-туфракка батып, мең мәшәкать чигеп авыл юлын таптауны... аңлый алмый йөдәде ул! Карт анасы, әлбәттә, бердәнбер улын көтә, сагына. Монысы белән килешеп була. Улын ялгыз башы күтәргән, укыткан, кеше иткән. Ана хакы бар—бусын да санламый булмый. Әмма япа-ялгыз түгел ич анасы, өч-дүрт чакрымдагы күрше авылда кызы—Идриснең апасы яши, ләбаса! Оныклары килеп-китеп йөри! Юк, аңлый алмады Кәримә авыл дип женләнгән ир холкын! Бәлки сөйгән яры, беренче мәхәббәте шунда калгандыр, аны сагынып авылга ашкынадыр дигән шик-шөбһә жанын әз талкымады. Көнләшү-үртәлүен күрсәтеп тормышларын ямьсезләмәслек акыл бар иде анарда. Түзде. Чөнки ярата иде ул Идрисне. Чөнки аны яратмау мөмкин түгел иде. Сөйкемле сөяге бармы, әллә нинди сихерле тарту көче биргән аңа Ходай. Тыштан кырыс, олпат ир-егетнең күңеле нечкә-нәзберек... Моны да белә Кәримә. Әгәр нахак сүз әйтеп рәнжетсәң, күңеле кителәчәк. Аркан белән бәйләп тә тота алмассың аны ул чакта. Теш кысып булса да килешкән иде авыл белән кала арасында киләп-сарып йөрүенә. Кысан тулай торактан котылып, искерәк кенә өч катлы йортта ике бүлмәле фатир алып күченгәч, тормышлары үзгәрер сыман тоелган иде. Тик берни үзгәрмәде. Идрис һаман шул! Атна ахырына таба кыбырсый, юлга әзерләнә.

Бакча артындагы чишмә, томан астында жәйрәп яткан ужым басуы, чәчәкле тугайлары төшенә кереп йөдәткән бер ул гынамы?! Тора-бара дөнья баса. Идрис тә авыл юлын таптаудан туяр, ял көннәрендә икәү култыклашып кино-театрларга, кунакка йөрербез дип күпме көтте Кәримә. Тик өмете акланмады.

—Юлларына бал сылаганнардыр шул авылының?—дип ирештереп тә карады.

—Тәлгәш-тәлгәш ак чәчәк аткан баланлыкны бер кайтып күрсәң иде! Чыннан да бал сөрткәндәй!—дип куанып, хыялый елмая Идрис.—Әти утырткан бит аларны! Гүя кул жылысын саклый тупылларга кадәр!—Монысын моңсуланып өсти. Һәм бәләкәй якка—эш бүлмәсенә кереп бикләнә. Икегә бүленгәндәй талкынып яшәвенә

кайчак үзе дә аптырый: коеп яуган янгыр, җил-давыл, кар-буран дип тормый, ә менә кайтмый калса, бик кадерле нәрсәсен җуяр кебек. Югыйсә мавыктыргыч фәнни эше көтә, буш вакыты да юк кебек.

—Синнән кайтышлар инде күптән академик та хакыйкый әгъза!

Хәер, җавап эзләп кесәгә керми, шагыйрь сүзе белән хатынының авызын бик тиз каплый ир:

—Йә, бармы арада берәр даһи, Нәкый йә бер Бакый, бер Исхакый?!

—Син бар бит, син! Ходай биргән талантың бар. Сирәгәйтергә кирәк бу кайту-китүләрне! Барысын онытып фәнгә генә җигелергә кирәк!

Әнисе! Улы сыйган җиргә әни-карчык сыймас идеме?! Ташлап китә алмый шул авылын. Мал-туар да тотмый инде. Кыен дип бетерде. Миләш-шомырт дисәң... Яшь үсентеләрен төбе-тамыры белән казып алып килеп, ишегалдына күчереп утыртырга була түгелме? Әнә, кычыткан, тигәнәк баскан, буш яткан җирләр никадәр? Чишмәне, ужым басуын монда күчереп булмый анысы. Әрәмә байлыгы—гөлҗимеш, балан куаклары тамырдан үрчи. Өй тирәсендә чия, сирень чәчкә атып утырса? Бала-чага куаныр иде.

Хатыны белеп тәкрарлый, үзенә дә төпләнергә, утырырга күптән вакыт.

Идриснең ниятен хуплады гынамы, очынып йөрде Кәримә. Торф ташып, чокыр казыдылар, Идрис авылдан яшь үсентеләр алып килде. Күрәк тотып, өмә ясыйбыз дип бөтен гаилә җыелып чыкканнар иде дә... Адәм көйләр, Тәнре көләр, диләрме? Хәтта хыялны күпсенүчеләр була икән дөньяда.

Табылды андый адәм дә..

Беренче катта, тәрәзәләре ишегалдына караган фатирда Әхияр агай яши иде. Моның белән борчак пешереп булмасын элегрәк тә сизенә идеме Идрис?! Болай да каранго чырайлы агайның теле чәнечкеле, күз карашы ук янаулы-авыр иде ул көнне. Элегрәк тә күршеләрнең һәр сүзеннән, эш-гамәленнән гаеп эзләп, калын каш астыннан сынап, сөзеп карарга күнеккән Әхияр агай тышкы ишекне дөбердәтеп, каты ябасыз дип үткән-сүткәнгә бәйләнеп калуны изге бурычы саный иде, ахрысы. Идрискә дә эләкте. Ашыга иде, сүз озайтып тормады. Агай, ахрысы, чын-чынлап үпкәләде. Янәсе, "интеллигент кисәге" гафу үтенү түгел, хәтта аның белән сөйләшеп торырга да гарьләнә. Шик-шөбһәсе генә идеме бу, ачыклап маташмадылар. Әмма шул вакыйгадан соң өске каттагы күршесе артыннан: "Килмешәк" дип төкереп калуны гадәткә кертте агай. Сәламенә җавап кайтармас булды.

Канны уйната торган зәмзәм суын "нык" кына төшереп, ашап-эчеп, кызып-кайнарланып чыкканмы, шадра бите тирләгән иде агайның. Без кебек очлы-үткен күзләрен хәтәр елтыратып, чыгуга өмәчеләргә җикеренергә тотынды:

—Син нәрсә, буш җир күрдем дип, күз тондырып, хуҗа булырга йөрисеңме әллә?

Ә Идрис шат, кәефе күтәренке, агайның усаллануын аңламады. Күршенең чираттагы йомры юморы—шаяртуы дип кабул итте.

—Гөлбакча итәбез ишегалдын, агай! Бергәләп! Менә күрерсез!—Ак тешләрен күрсәтеп дустанә елмайды гына. Игелекле эш башлап йөрүенә чын күңелдән инанган, кемнеңдер каршы төшеп, мәсхәрәләп көләсен уена да кертми иде ул.—Менә, шомырт, балан, гөлҗимеш алып килдем әле авылдан. Тамырлары нинди тармаклы, китә, күрерсез! Кошлар сайрап уятыр, чәчкәсе куандырыр. Кирәк кешегә җимеше дә өлгерер. Балан кан басымыннан дәва...

—Нәрсә? Гөлҗимеш сатып баергамыни исәп?

—Юк ла!—Идрис йөз пар күз текәлгән аудиториядә һәр көн лекция укый, каушау, югалып калуны белми. Ә монда тотлыкты. Шикчел, явыз күз карашы, агайның ирен читенә эләнгән мыскыллы елмаюы каушатты. Балачактан китек күңел, яралы җан гаделсезлек белән очрашканда сыкрый-әрни иде шул.

—Агач утырта! Имеш!—дип каһкаһәле көлде агай.—Ә монысын—мин утыртып куйганын ни эшләтәсең?—Чүп үләне арасыннан моңарчы күренмичәрәк торган, талгын җилдә саз каены сыман сыгылып утырган зәгыйфь үсентегә калын-сары тырнаклы бармагы белән төртеп күрсәтте:—Сездәй имансызларга ышансаң, үсеп утырган агачны күрәк белән кисеп ташларга да күп сорамассыз. Ә син, иптәш

интеллигент, беләсенме, Ходай биргән үсемлекнең җанын кыю гөнаһ! Кулың корыр!

Ирек куйсаң, яна утырткан агачларына көн күрсәтмичә, бар дөньяңны басып алырга әзер әрсез америка өрәңгесен—сыек буынлы үсентене Идрис абайламаган да икән. Гаҗәп, ник зурлап, хөрмәтләп маташа әле агай чүп арасында, үзе дә чүп мисалында йөргән өрәңгене? Ышанамы сүзе хаклыкка, юри Идрисне ирештерүдән тәм табамы, белмәссең!

—Балаң сатып баючы сәүдәгәр!—дип көлде күршесе.—Ә син беләсеңме суң, спекулянтларга закуннар каты бит безнең илдә.

Була шундый кешеләр, сүзен сүз итәр өчен башын кисмәгә бирергә риза. Тик екмасыннар гына аның сүзен—үрдә булсын. Ә үзенең урыны түрдә. Кемдер үзеннән уздыра, әллә кем булган дип шикләнсә, йокысы кача. Зыялы, укымышлы милләттәшеннән үлеп көнләшә торган кара эчле адәм бер Әхияр генә түгелдер. Идриснең чыгышын, халык дошманы улы дигән нахак исем күтәреп, үртәлеп яшәгәнен белә ул! Бер яктан ич алар, якташлар! Җәелеп сөйләшеп утырырга вакыты булмаса да чамалаган иде Идрис: Сәхипгәрәй улы дигәнне ишетүгә карт йөзеннән кұләгә йөгереп үтүе тиккә түгел, сере бар!

Йөз-кыяфәте атасына тарткан Идрисне йортта күрүгә үк төсмерләп алды Әхияр. Булса да булыр, нәселләре белән мактанчык, борынлы, тәкәббер. Шәрекътәшеннән көнләшеп шикаять сырлаганда ул, әлбәттә, әләк адәм үтерер дигәнне уйлап тормады. Куштан булганга куштылар—үтәде. Суга төшкәндәй юкка чыкканына да аптырап тормады: заманы шул булгач. Әнә, улы кем булган. Әле ярый танымый. Институтта укыта, имештер. Көнчелек корты әллә кайсы куәнәкләрен ертып үтте.

Идрис ачу белән көрәген җиргә атты. Ташка тидеме, сабы шартлап сынды. Кәримә үгетләп-җайлап караса да кабат көрәк сабына тотынмады Идрис. Ишегалдын гөлбакча итү хыялыннан биздерде аны күршесе.

Ә өрәңге—әрсез агач. Мине сөймиләр дип үпкәләп тормый. Җәелеп, тармакланып үсүен белә. Ел саен өскәрәк үрмәли.

Әхиярнең хәйләсен төшенде Кәримә. Сирень, чия утыртсалар, беренче кат тәрәзәсенә күләгә төшәр иде. Өскә үрләгән өрәңге ботагы өченче катка үрелеп, әнә, тәрәзә кага.

Йоклап кына китсен, белермен мин сине нишләтергә! Кәримәнең сукранганына карап кына өрәңге балконга орылып-сугылып, шыкырдаудан туктамады, әлбәттә. Әмма хатын үзе тынычлангандай булды.

Гарьчел-рәнҗүчән димәктән...

Гәрчә, язмышы сынауларга бай булса да, тәкъдирнең бормалы сукмаклары монарчы Идрисне адаштырмаган иде әле. Дөрес, әткәсен—укымышлы мулла, аннан мөгаллим булган Сәхипгәрәйне—балаларын кан-яшь елатып алып чыгып китүләре истән чыкмады... Биш кенә яшь иде аңа. Гамьсез балачакка нокта куелды. Сабый зиһене бу фаҗиганең һәр мизгелен мәңгелеккә сеңдереп калгандыр, гүрнәчәдәй үз йортларыннан бер ярлы көнлекченең җир идәнле, карындык тәрәзле куышына куып чыгарулары да хәтердән җуелмаган. Әнкәсенең мөлдерәмә сагыш тулы яшьле күзләре, әтисенең әрнү катыш ачыргаланып: "Мин—гаепсез. Кайтырмын. Көтегез!" диюе... Ел арты ел узды, бәгырьдәге сызлавык, рәнҗеш-үпкә кара кан булып укмашып шешкә әйләнде.

Өрәңге ботагы тәрәз шыкырдатканга шомланып ята торган егет идемени ул? Авызында кош сайрата иде! Җеп өзәрлек хәле булмый, кымшанмый ятсын әле?

Идрисне күпләр язмыш иркәсе, бәхетле зат дип кенә белә. Янәсе, егет солтаны дан-дәрәҗәгә җиңел ирешә. Студентлар, яшь галимнәр арасында абруй казанган күренекле шәхесне җае чыкканда тешләп алырга теләүчеләр дә табыла. Тешләләрне сөендерерлек форсат гел чыгып тора: Язмыш галиҗәнабләре бу юлы да зурдан кубып эш йөртте, корбан тәкәсе итеп аны сайлады. Ана каныкты...

* * *

Әйе, шәп, фырт егетләрне көнләштерерлек Артист булып туган ул дөньяга.

Килеш-килбәт, буй-сын, төс-кыяфәт дисеңме, һәр сүзен җанына үткәзеп сөйли

белү сәләтеме—һәммәсе гаҗәеп килешле, затлы, мөкәммәл. Әзләнүчән, тырыш, сәләтле икәнен таныган хәлдә дә көнләшми мөмкин түгел! Әмма... дан-шөһрәт, абруй, дәрәҗә ана үзеннән-үзе, җинел килә дип исәпләүчеләр ялгыша. Бик нәзберек нәрсә ул дан-шөһрәт. Бүген бар, иртәгә юк. Тир түктерми генә бераүгә дә нурлы йөзен күрсәтергә ашыкмый. Ачышка тиң фәнни хезмәтенә никадәр көч салганын, һәр карышын үҗәтлек-тырышлык белән, үр арты үрне ничек яулаганны ул үзе белә дә, хатыны Кәримә сизенә. Мәһабәт, текә-горур рәвеш-кыяфәтенә сокланып, сөйләү манерасына, осталыгына хәйран калып авызына гына карап торган студентлары да аның төн йокысын калдырып һәр дәрескә бөртекләп, җентекле әзерләнүен, тузан йотып китапханәнең сирәк китаплар бүлегеннән чыкмыйча, баш күтәрми утыруын күрмиләр. Хыялланып аңа гыйшык тотучы, очрашу-күрешү өмет итеп йөрүче хыялый-җилбәзәк студент кызлар бихисап анысы. Сабыр-тыйнак Кәримәне егет солтаны Идрискә тиң түгел дип исәпләүчеләр бар. Ялгышалар. Коеп куйган, бер кимчелексез идеаль кеше булмый. Талантның җайсыз-көйсез булып яралуы да сер түгел.

Кәримә кала кызы. Әнкәсе һөнәрчеләр бистәсендә туып үскән, ә әтисе Гамир абзый чабатасын аркасына асып авылдан яланаяк чыгып киткән, үҗәтлеге чамасыз булганга гына, тырышып-тырмашып укып, прокурор дәрәҗәсенә ирешкән. Намусы чиста, күңеле саф кеше генә гаделлек сагында торырга тиеш дип чын йөрәктән инанган прокурор алдында эш-гамәлләре һәм куллары бигүк чиста булмаган күп кенә түрәләр кан калтырап торды. Бердәнбер кызларын институт тәмамлагач үзләре янында—калада калдыру өчен әти кеше ягыннан бер ишарә, ым кагу да житкән булыр иде, бәлки. Әмма Гамир әфәнде карчыгының ялваруын ишетмәмешкә салышты: "Тормышта һәркем үз сукмагын үзе салсын. Шома юлдан барса, яшәү тәмен, ямен табуы икеле", дип котылды.

Август башында, мәктәпкә укытырга билгеләнүе хакында юллама тотып, Кәримә авылга килеп төште. Биология укытучысының сәгатьләре күп түгел, әмма дәрес бирүдән тыш ул, укучылары белән бергәләп, куян, сыер фермасына шефлык ярдәме күрсәтергә, мәктәп яны участогын тәртиптә тотарга тиеш икән. Эш-мәшәкать—муеннан. Житмәсә, директорның йорт куяннары үрчетү белән җенләнеп йөргән көннәре. Куян асрауга тоткан чыгымнарны каплау бер хәер, зур керем алу турында хыялланып йөри. "Куян малын симертүне тәэмин итү, азык әзерләү биологның изге бурычы!" дип анлатты. Ял көне иде. Иртәдән шыбыр-шыбыр янгыр явып тора. Мондый янгырда куян читлекләре янына бала-чага якын да бармый. Авыл кешесенең үз хуҗалыгында да эш-мәшәкать баштан ашкан. Озын брезент плащ киеп, чаштыр-чоштыр шул мәхлүкләргә үлән чабып маташа иде Кәримә. Үтеп барышлый гына янында туктап сәлам бирүчегә күтәрелеп карасa—дертләп китте. Каш астыннан сынап-сөзеп кызны күзәткән дингезче егет чибәр иде. Ул иплэп кенә кыз кулыннан чалгыны алды, аякларын аерыбрак, җайлап басты, киерелеп, чаж-чож китереп печән чаба башлады. Рәхәт, җинел эшли иде ул. Янгыр астында юеш үлән чабу михнәт икәнен әле генә үз җилкәсендә татыган Кәримә исә аның эш мәне белүенә сокланып карап торды.

Егет Идрис исемле, мәктәптә тарих укытачак икән.

Килгән көненнән мәктәпне авызына каратты егет. Менә ул класска керә. Бәргәләшеп алырга өлгергән, тирләгән-пешкән малайлар утырышып беткәнче сүзсез генә һәркайсын күздән кичерә. Секундлар уза. Класс шым була. Үткен күз карашы, кинаяле, төртмә сүзләре белән тәртипсез, классны дер селкетеп торткан теләсә нинди атаманны урынына утырта ала. Ә сөйли башласа, сыгылмалы бәрхет тавышы сихерле. Әле генә гамьсез, үзишләре белән әвәрә килеп кайнашкан класс дөньясын онытып башка яссылыкка күчә. Борынгы заман каһарманнары, аларның риваять-моннары бар икән. Бәрәнге белән ипигә туяр-туймас тормышны онытып, шулар язмышы өчен ут йота. Яуда җинсәләр, шатлана, җинелсә... Мөгаллим абый һәммәсен үзенә гашыйк итте. Атна-ун көн уздымы-юкмы, эленке-салынкы йөргән малай-шалайлар үзгәрде. Ә кыз-кыркынны гүя алыштырып куйдылар, һәркайсы хәл кадәренчә киенеп-ясанып, сизелер-сизелмәс бизәнеп, курчак кебек матур, чибәр туташларга әйләнде. Күз карашлары, атлап йөрешләренә кадәр икенчә. Әйтерсең,

уку бәйрәмгә әйләнде.

Тугызынчы-унынчы класс укучыларыннан алып яшь укытучыларга кадәр һәммәсенен яна укытучыга гыйшык тотуын Кәримә сизми калмады, әлбәттә.

Югыйсә анын тарих укытучысы күренүгә баш югалтыр сәбәбе юк иде. Әнисе аны тизрәк Казанга кайтарту уе белән яна. Ниятен тормышка ашырмый туктамаячак, бик үзсүзле хатын ул. Хәер, кызын яхшы гаиләгә урнаштыру, башлы-күзле итү хакында кем хыялланмас? Әминә ханым да чарасына керешкән, кияү буласы егет белән Кәримәне дә таныштырды. Баш югалтып гашыйк ук булмады булуын, шулай да кирәге чыкмый калмас дип, нәфис кульъяулыкны түш кесәсенә салып куйгандай исемен күнеленә бикләп куйган иде инде. Үзен канаты бәйләнгән—ярәшелгән кәләш итеп тоюы гамьсезләнеп унга-сулга күз атарга ирек тә бирми. Тарих укытучысына гашыйк булып шашынучылар аны гаҗәпкә калдырды. Артист, җырчы—сәхнә йолдызы саналган асыл зат синеке була димени? Кыз-хатын гомерлек яр сайлаганда ялгышмаска тиеш: бөтен хатын-кыз ярата торган ир белән ул беркайчан да тыныч яшәмәячәк, бүтән хатын-кызлар яратмый торган ир белән дә бәхетле була алмаячак.

Ни гаҗәп, очрашуга сәбәп эзләп, үзен эзәрлекләп, янып-көеп яратам дип йөргән кыз-кыркынга Идриснен исе китмәде. Тыштан һавалы күренсә дә салкын тәкәбберлек егетнең тышкы калыбы гына иде, күрәсең.

Кәримәне шул елны ук уку-укыту эшләре мөдире итеп куйганнар иде. РОНОдан килгән вәкил белән Идриснен бер дәресенә кереп утырырга туры килде ана. Егет педагогия институтында читтән торып укый, училище белеме белән укыткан тарихчы институтны кызыл дипломга тәмамлаган Кәримәгә яналык булырлык нидер әйтә алмас дип ышанып керде. Чыннан да Идрис аңа күптән таныш вакыйгалар хакында сөйли башлады. Әмма ничек сөйли! Инспектор да, Кәримә үзе дә авыз ачып, шаккатып тынладылар. «Ходай оратор сәләтен дә кызганмаган!»—дип куйды вәкил ана таба иелебрәк. Ягымлы, йомшак бәрхет тавыш күнелләргә хуҗа, ә бөркетнекедәй үткен күз карашы гүя сихерле. Яшь йөрәкләрне күренмәс җепләр белән тоташтырырдай әллә ни дә булмады сыман. Ә йөрәкләр бергә кушылып типте.

Институт тәмамлауга Идрисне аспирантурада калдырдылар. Кәримә укытуын ташламады. Кызлары, аннан уллары туды. Укытучы акчасы белән стипендиягә яшәп тормышның очын-очка ялгау җиңел булмады. Дөрес, булганына шөкер дип кул кушырып утыра торган ир түгел ул. Табигать ана мәһабәт кыяфәт, чичәнлек кенә түгел, тырышлык, дәрт-дәрман дигәнен дә кызганмаган. Яшь аспирант студентларга дәрес бирә башлады. Студент кызлар аның артыннан өерелешеп йөри. Ул—канәгать. Ә вакыт уза, үкчәгә баса-баса фәнгә яшьләр килә! "Синен генә авыл дип исен китә. Кандидатлык диссертациянне якларга, доктор булырга кирәк!" Кәримәнен тыкырдатуларын гүя ишетми дә, җомга җитте исә, биштәрен барлый Идрис. Беркатлы, түзем-сабыр татар җанлы авыл тарта аны! Эчкерсез әңгәмәләр яшәртә, яшәтә, һавасы килешә...

Йокы... Татлы да сон йокы... Рәхәт-ләззәтле йокыдан мәхрүм шул Идрис. Хәер, Кәримәнен үзенә дә житми ул. Их, бер онытылырга иде, изрәп, сәгадәтле йокы кочагында эреп, бар борчу-михнәтләрдән котылып туйганчы йокларга иде! Ихтимал, көч-гайрәте кире кайтыр иде. Атна-айлар буе йокысызлыктан интеккән кеше генә анласа анлый йокы дигән сихәтле һәм дә татлы-ләззәтле халәтнең тылсым икәнен, никадәр көч-кодрәткә ия булуын.

Таңда җил дә тына, кошлар чыр-чуы бер мәлгә басыла, бишегендә бала, сөйгәне куенында газиз яр оеый, һәр күзәнәк, җан-тән ял итә. Йокы кочагында карун—байлыгын, гашыйк җан—мәгъшукасын, көчле үчен оныта. Җир өстенә талгын гына канат кагып төн хуҗа булып ала. Йокы... Татлы йокы... Идрис онытылып, рәхәтләнеп йокы кочагында оеп көч җыйсын өчен ул... Йә, ни-нәрсәсен бирер иде икән? Саулыгын, байлыгын, ярты гомеренме?

Җил әллә исү юнәлешен үзгәрткән инде—азмы-күпме тынып торды да өрәңге

янә балконны шыкырдатырга тотынды.

Кәримә, керфекләренә эленгән хәлсезлекне кулы белән сыпырып ташларга теләгәндәй күзләрен уып торып басты. Бүлмә бөркү кебек тоелды. Ул сак кына балкон ишеген ачты. Жинелчә халат бөркәнгән, йомшак башмак кигән килеш әкрен генә тышка атлады.

Йолдызлар да, ай да күренми. Күкне, жирне аксыл томан сарган. Тиздән таң атар, яңа көн башланыр. Нинди булыр ул яна көн? Йә Раббым, таң атканын күрү, яңа көнне каршылауның нинди бәхет икәнен сырхау гына аңлыйдыр шул.

Шулчак өрәңге чайкалды, тармакланган юан ботак балкон киштәсенә бәрелде. Кәримә, комарланып аны эләктерде дә усалланып үзенә таба тартырга тотынды. Ботак көчле-нык иде, һич бирешергә теләмәде. Хатын жан көче белән киерелеп аны үзенә таба тартып китермәкче, көче житсә-житмәсә каерып-сындырып ташламакчы иде. Әмма көчләр тигез түгел иде шул, ручка тотып дәфтәр тикшерүдән бушамаган нәзек беләкле укытучыга агач та карыша икән! Бирешмәскә теләп тартышуына Кәриманең жен ачулары чыкты, тәрәзәгә бәрелеп ирнен тынычлыгын бозган таза ботакны жинмичә тынычлана алмаячак иде ул. Менә кулы белән тотынган чи ботак шартлап сынды, кәүсәсеннән аерылды, «Әһә, була бу!»—дип хатын сөенергә өлгермәде, икенче кулы белән ябышкан ботак та кулдан ычкынды—сынган жире халат жиңен эләктереп өлгерде. Кәримә аягы шуып идәннән аерылуын, һәм коточкыч карангылык өстендә һавада эленеп калуын тойды.

"Өрәнге өрәге!"

Иренең сүзе кылт итеп искә төште: үч ала. Чаган дисәң чага. Өрәнге дисән, өрәге бик яман. Нинди ахмак балалык бу, йә Ходай! Коткарсан, бер син генә коткара аласың!

Жан ачысы белән кычкырмакчы булды, тавышы чыкмады. Керфекләренә яшь бөялде. Ярабби, ире тиккә шомланмагандыр?! Курку, әрнү, шөбһә, һәммәсе бергә укмашып бер мизгелдә аның зиһенен томалап куйды.

«Бетүем шушы икән!» дигән уй башыннан яшен тизлегендә йөгереп узды. Икенче мизгелдә ире күз алдына килде. Хатынын дүрт күз белән көтеп торган ир, бер таянычсыз калса, ни эшләр? Кызгану хисе йөрәгеп өтте. Һәм бу хис—ире өчен хәвефләнү өрәктән куркуга караганда көчлерәк иде. Бик якын ул—әнә ишекнең теге ягында гына, кычкырса, бәлки торырга тырышыр. Әмма хатынының чарасызлыгын күреп соңгы өмете дә өзелсә? Ул чакта ни эшләргә? Алар икесе дә әле һаман могжизага ышана, ирнең аякка басачагына өметләнә түгелме? Бу чыннан да шулай. Иң соңгы булып өмет сүнә.

Очып төшү халәте күз алдына килеп тетрәндерсә дә аягының балкон аратасына кысылып калуын тою, авырту аны айнытып жибәргәндәй булды.

Әлегә бу аның жире, аның биләмәсе, монда бисмиллалы гомер еллары. Иртәләрен таң атканда йокыдан уянып еш кына балконга чыгып баса иде ул. Кызарып таң атканны карап торырга ярата иде. Шул тылсымлы мизгел күңелне һәрчак жылыта, уйландыра. Әбисеннән отып алган догалар хәтердә янарды. Биш вакыт намазга басмаса да ул динле нәсел баласы икәнен онытмый. Күңеле сизә, бу такталар аның догаларын, уй-хисләрен сеңдергән. Тиз һәм жинел генә ычкындырмаячак, язмыш сынавы—сынап астан күз текәп торган куркыныч караңгылык кочагына атарга ашыкмаячак.

Ул гомере буе язмыш белән көрәште түгелме?!

Горур, мәһабәт Идриснең аны, күрер күзгә әллә ни чибәрлеге, табаныннан ут чыгарырдай житезлеге, уңганлыгы белән башкалардан аерылып тормаган, гади кызны яр итеп сайлавын күпсенүчеләр булмадымы әллә? Читләтеп-төрттереп, кинаяләп, хәтта турыдан ярып та бу хакта искәртүчеләр житәрлек иде. Хәтта ирнең туган-тумачасы да авыл эшен изеп эшли торган нык, таза хатын алмавына пошынуларын сиздерми калмады. Беришесе, кияү зур урында утыра торган бабайга аркалана, дип йөз ертудан да оялмады. Барысы да үтте. Сынаулар узды. Чөнки яратам дип кычкырып йөрмәсәләр дә араларында аңлашу бар иде. Әгәр өйләнешү коры исәп-хисапка гына корылса, тормыш сынавын үтүләре, ай-һай четерекле бит. Хәер, килешеп-аңлашып бергә яшәгән еллар да гел шома эздән, уйнап кына

тәгәрәде, дисә, ялганчы булыр иде.

Жор телле, янып торган остазга гыйшык тотучы студент туташлар гынамы, купшы, кәттә ханымнар да Кәримәнең кытыгын китерүне дәрәҗә саный. Көнче күбәләкләр очкалап, Кәримә көнелсезләнеп йөргән чакларда, Идриснең шаярып әйтә торган сүзе бар иде: «Менә берзаман күзләр чибәрләргә төшми башлар, тешләр коелып бетәр. Синең кулына карап, манный боткасы пешереп биргәненне көтеп өйдә генә утырырмын, яме! Шулчакта икебез дә бик бәхетле булырбызмы икән?» Икесе дә көлеп җибәрәләр, киеренкелек шунын белән юыла.

Юраган юш килә икән. Кәримәнең кулына карап, манный боткасы пешереп биргәнен көтеп ята Идрис. Картайганын, тешләре коелып беткәнен күтәргә дә сабырлыгы җитмәгәч...

Монысы да сынаудыр ла. Чираттагысы... Һәм иң мәгънәсезедер, бәлки! Хәер, асыл мәгънәсен, бәлки, Кәримә аңлап-төшенеп бетмидер әлегә. Өрәңге ботагы кулыннан ычкынып китсә, атылган таш сыман аска ыргылыр. Өченче кат кына булса да балконнан егылып төшеп исән калулары... икеле. Ычкындырмаска иде дә, өрәк аны аяусыз рәвештә тарта-йолка, аска сөйри. Ачы җил исә. Ботаклар хәвефле пышылдашып, бәрелеп-сугылып шом тарата.

Кәримә икенче кулы белән тазарак-ныграк ботакка ябышырга тырышып җан тартыша. Шөкер, аягы такталар арасына нык кысылган. Гүя шул арата саклый, ычкындырмый әлегә. Иркенләп сулыш алсын да балконга тартылырлык көч җыйсын. Табар җаен. Җан биргәнгә җүн бирер, дип юкка гына әйтмиләр ич. Иң авыр мизгелдә газиз ирен, сөйгән ярын ташлап калдырып аска очса... Юк, күтәрә алмас ул мондый сынауны! Ә упкын күзеннән—томанлы кара җирдән аңа Өмет карап тора!

Соңгы көчен җыеп, ничек кенә булса да рәшәткә читенә тотынып калырга өметләнеп, каурый кебек җиңел гәүдәсен бер йомарлам итеп җыеп—эчкәрәк, балконга ташларга кирәк ич аңа!..

Аягының чыдамаслык булып авыртуын тойды. Бер мизгелгә хәтта аңын җуйгандай булды. Әмма үзенең кара җирдә түгел, идәндә ятуын абайлап, шатлыгыннан тыелып кына көлеп җибәрде.

Ул исән! Өрәк, әгәр була калса, артка чигенде. Чигенми чарасы юк иде.

Өрәкле түгелдер лә! Өрәңге шатлык-кайгыларга битараф агач лабаса! Каен кайгыларны җиңеләйтә, имән кешегә ныклык бирә, нарат тынычландыру сәләтенә ия, ә өрәнге—битараф!

Ишекне сак кына ачып, сайгакларны шыгырдатмаска тырышып өйгә керде. Аякның сызлавына чыдар хәл юк. Сынмаган булса да, ул һичшиксез имгәнгән, биртелгәндер.

Ләкин бу мизгелдә боларның берсенең дә әһәмияте юк иде инде.

Ул йоклап киткән!

Йокы—тылсым бит ул. Тынычландыра, бәлзәм кебек тәэсир итә, савыктыра. Моны атналар буе йоклый алмый иза чиккәннәр генә аңлый, белә. Ятуга йоклап китә торган берәү дә аның нинди зур хикмәткә ия, олы бәхет булуы хакында хәтта уйлап та бирми. Йоклыймы—йоклый. Һәм вәссәләм!

Кәримә, тынычлап йоклап киткән ирнең сак йокысын бүлдерүдән куркып, кымшанмый да утырырга риза иде дә... Чираттагы уколны кадар вакыт узып киткән шул... Нинди хикмәт соң бу? Тынлык. Шундый җиңел тынлык. Ниһаять, өрәңге дә шыңгырдаудан туктар икән! Укол өчен кирәк-яракны хәстәрли башлау хәерле.

Карасана, аягы гөбе кебек шешкән. Каймыктырган гынамы, әллә...

Ул ирнең зәгъфран сарылары иңгән текә маңгаена кулын тидерде. Һәм корт чаккандай куркынып, кулын тартып алды.

Биек маңгай сап-салкын иде.



Әхмәт
Гадел

# ТОРМЫШ ДИГӘН ЯПАН КЫРДА...

***

Кыл өстеннән йөри кеше,
Йомры булса да Җир...
Кыл өстеннән йөри кеше:
Йөртә аны тәкъдир.

Кисә аның аякларын
Шул кыл, җанга үтә...
Сызлый да өзелә бәгырь,
Якты көннәр көтә.

Күреп аның тилмерүен,
Оран салам:—Әй, син!
Нигә болай тилмерәсең,
Син—бөркеткә ич тиң!

Моңсу бага адәм углы:
—Тиңдер, каршы дәшмим.
Гаиләмне тоту өчен
Көне-төне эшлим...

Әмма тормыш дигән кырда
Куркынычы башка:
Күпләр төшәдер корт булып
Минем хәләл ашка.

—Кыл өстендә гомер, әмма
Аллаһ көдрәте киң.
Әй, зат! Кил бире, дус итим!

...Баксам, үз-үземә шулай
Дәшәм икән бит мин...

Әхмәт ГАДЕЛ (1942)—*шагыйрь, прозаик; "Чал", "Яшьлек урамы", "Йөрәк бәйрәме" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Вакыт көтми

Бу дөньядан туеп булмый,
(Аңлап булмаган кебек...)
Нидер ачам һаман, табам,—
Тапканым гүя кубек.

Аһ, гомер нигә бик кыска,
Нигә аз икән вакыт?!
"Йорт"тан чыгар көннәр җитә,
Тораммы ишек шакып?!—
Мин торам нәни бала кук...
Нигә болай оялам?!
Чү! Кояш та таң күзендә
Миндәй—алга буянган!

Бул кыю, дигән сыман ул,
Йөрәкле бул и, егет!
Син бит кояштай кызусың,
Торма шәм кебек эреп!

Кыюлык кирәк—җәсүрлек,
Дөнья буйлап барганда.
Тәкъвалык макталыр, әмма
Бул кыю—юл ярганда!

Вакыт бит ул көтеп тормый,
Эше күп, ул ашыга.
Дөнья онытмасын дисәң,
Тиң бул язгы ташуга!

Тиң бул яшен-елдырымга,
Ашык, шул хакны хакла:
Бакыйлыкка киткәндә дә
Милләт абруен сакла!

## Изге юл

Тормышның төп фәлсәфәсе, кешем, будыр:
Гөлчәчәкле көзендә дә җимешеңне булдыр.

Зарланма җәй айларында яңгыр аз булганга,
Сан була тик пешкәнгә һәм өлгергән, уңганга.

Әгәр шәрәф-фазыйләтне теләсәң күрергә,
Ашыкма син, гөлчәчәгем, сулырга—үлергә.

Яшәүнең рәхәтен тоеп, чәчәктә данлан син:
Күңелләрне, күз нурларын балкытып, яула син.

Аллаһ бүләге бу гомер—җылы да матур да,
Биргәненнән артыгын тик көтеп син утырма.

Фәкать үзең тырыш, эшлә, тап, үрчет, иренмә,
Ирме, хатынмы... былбылмы—син кирәк илеңә!

Үз халкыңа-кавемеңә тугрылык ит: шулдыр—
Аллаһка укталган нурың... Һәм бердәнбер юлдыр!

***

Алышкан—сугышкан бабайлар,
Ил өчен башларын салганнар.
Төзәлде төзәлмәс яралар,
Тугрылык калдымы, оланнар?

Арыслан егетләр торыны
Үткәнне тотамы исендә?
Әзерме куарга золымны,
Батырлык калдымы җисемдә?

Нигәдер төннәрен җан әрни,
Әти кайта еш—төшемдә:
"Онытым татарча гел белми,
Сөйләшә "знакум" күршедәй!..

Мин сине өйрәттем, син, улым,
Сеңдер шул сабыйга бер дога.
Җуймасын саташып зур юлын,
Синең дә киләсең бар монда!

Җан әрни сезләрне күргәндә.
Бу кадәр кылану ник кирәк?!
Дөньяның мәгънәсен үргәндә
Бирелгән бит сезгә чын шәригать!
Шул сиңа—иң олуг шигърият!"

## Алда

Һәй, Әхмәт, куан, бәйрәм ит,
Яшәвеңә шөкер кыл.
Мең елга тора бер гомер:
Бел, шагыйрь гомере ул!

Гакыл биргән сиңа Тәңре,
Аң биргән, каләм биргән.
Дөнья малы—инеш талы...—
Елкыдай бәдән биргән.

Ләкин сөй, санла халкыңны,
Булмаслык эш бу, димә!
Җәй—киез итек, кыш җиткәч—
Иләк чабата кимә!

Мин генә, дип уйла, һәрчак
Халкыма хадим даим!
Милләтеңә хөррияте
Хактан сора көн саен.

Яз, көрәш, сиңа каләмне
Аллаһ шуңа тоттырган.
Милләтне җылыту өчен,
Кояш нурын йоттырган.

**Алтмыш—гомер соңы түгел,**
**Әле егетләр яше:**
**Алда әле, алда, Әхмәт,**
**Алышлары, көрәше!**

## Шагыйрь гаме

**Яздым. Сыздым. Ташладым.**
**Янә яза башладым.**
**Уй-гамьнәрдән сызлый йөрәк,**
**Онытыла ашларым!**

**Безме икән дөньяда**
**Алдан әйдәп баручы?!**
**Әллә без—тик алдан килеп,**
**Сузган ашны алучы?!**

**Аллаһыма мең шөкер,**
**Иңсен безгә рәхмәте:**
**Шәһри ярлар булып илдә**
**Яшәү—дөнья рәхәте!**

**Таркаулыкны куй, халык.**
**Коллык хисен җуй, халык!**
**Дәрья дулкыныдай бул да**
**Азатлыкка туй, халык!**

**Башыңны һич тә имә,**
**Җан изүчеңне сөймә,—**
**Үзеңне ярат, халык!**
**...Шул—барлыгыңа ярлык!**

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.



Рәмзис Кадыйров

# СУГЫШ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК

1941 нче елның 22 июнь иртәсе күпләрне тетрәтте. Кешеләр, атлар, техника—барысы да мобилизацияләнде. Әхәткә повестка 28 декабрьдә килеп төште. Казанга таба бер эшелон булып кузгалган халык арасында кемнәр генә юк иде: яшьләре яңа тулган җилкенчәкләр дә, дөньяда күпне күргән ирләр дә, сугышка барырга теләгән элеккеге тоткыннар да шунда, кешеләрнең күзләрендә борчу, билгесезлек алдында каушау.

Рузаевка станциясенә җиткәч, кем ничек булдыра, Казанга баручы эшелонга эләгергә тырыштылар. Әхәт тышта 50 градус суык булганын перронда басып торучы әбине күргәч аңлады, мескен карчык акка каткан кулларын күтәргән дә үтүчеләргә ялвара иде. Кая, аны күрүче дә юк, мәхшәр эчендә кеше кешене белми, үз кайгылары кайгы.

Казанга барып төшкәч, хәлләр тагын да мөшкелрәк икәне билгеле булды, этә-төртә вокзал бинасының икенче башына барып чыккач, Әхәтләрне Татвоенкоматка илтеп тә тутырдылар. Военкоматта киендереп халыкны фронтка җибәреп торалар иде өлгермәгәннәрне исә Суслонгер лагерена юлладылар. Вагонның кая туры килсә шул җиренә ябышып, 40-50 градуслы салкында җилләп бер тукталышка кадәр баргач, солдатлар унбер чакрымны җәяүләп киттеләр.

Суслонгерга өч-дүрт чакрым калгач, Әхәтләргә лагерьдагы солдатлар очрады: барысы да үлек чырайлы, сап-сары киемнәре теткәләнеп беткән. Боларның тормышы тора-торгач аңлашыла башлады. Занятиядә урман тулы солдат, ашарга көненә дүрт йөз грамм ипи белән өшегән бәрәңге шулпасы, җитмәсә анысы да тозсыз. Ике йөз кешелек землянкаларда мич юк, түшәмнән тамчылар тамып тора иде. Ике көн эчендә яңа килүчеләрне дә бет басты, аны киемнәрне учак өстендә тотып бераз койдылар да яңадан киеп чыктылар. Көндез алты чакрым тактик занятиеләргә йөртәләр иде, төнлә тревога ясап, ун чакрым бот төбеннән кар ердырып чаптыралар да, кайтканда илле сантиметр диаметрлы, ике метр озынлыктагы чыршы бүрәнәләрне каешлар белән бәйләп, тагып кайтаралар иде. Шул наратларны подразделение янында командир үлчәп тора, агачлар утыз сантиметр диаметрлы гына булса, яңадан урманга җибәрәләр иде. Берәр җирем авырта дип санчастька берәрсе барса, ун-унбиш кешене җыеп, тагын урманга җибәрделәр.



Рәмзис КАДЫЙРОВ (1946) – *техник фәннәр кандидаты; «Татнефть» ААЖ*

Әхәтнең көче бетте тәнендә ите-мае калмады. Бер көнне алты чакрым ераклыкка мунчага дип алып киттеләр. Мунча дисән, хәтере калыр, эчендә боз баганалар, яна гына еккан чи усак агачын турап ягып яталар иде, ике кешегә бер тас жылымса су бирделәр дә, әштер-өштер юынганчы куып чыгара да башладылар. Шул мунчадан кайтырга чыккач Әхәтнең бөтенләй хәле китте, ул кардан сөрлегә-сөрлегә стройдан артта калды. Усак әрәмәсе астына егылып ук калгач, Әхәт ни хәтле озак ятканын хәтерләмәде, уянып киткәндә кайту юлын кар каплаган иде. "Үлүем шушы, ахрысы",—дип уйлады Әхәт. Көчсез гәүдәсен калкытып, як-ягына каранырга тотынды, шунда күзенә землянкалар чагылды, бар хәлен жыеп Әхәт шунда үрмәләде. Бу 42 нче полк тупланган землянкалар булып чыкты. Әлеге полкта Әхәт үзенең якташы Насыйров Гыйният торганын белә иде, шуна, барып житү белән, анын кайдалыгын сорады. Гыйният ашханәдә икән, Әхәтне баштанаяк күзеннән кичереп чыкты да, кесәсеннән талон алып, аңа аш алып килде. Кеше өлешенә кергәнгә, Әхәтнең ризыгы бугазыннан көчкә үтте, алай да итле аш белән ботка аңа кайтып житәрлек көч бирделәр.

Шул рәвешчә бер ай интектергәннән сон хөкүмәт әлеге кешеләрне сугышка барырлык дәрәжәгә килделәр дип тапты һәм Әхәтләрне туры Мәскәүгә жибәрде.

## Мәскәү өчен сугыш

Кышнын иң салкын январь аенда Әхәтләрне киендереп Мәскәүгә жибәрделәр. Аларга жылы бишмәт, сырган чалбар, киез итек, бүрек, подшлемник, жылы тире бияләй, бер атналык коры паек бирделәр. Мәскәү солдатларны үзәккә үтәрлек суыгы, караңгы тәрәзәләре белән каршы алды. Барлык йортлар да маскировка өчен ала-кола төсләргә буялган, тротуарлар казылып, орудиеләр куелган, урамда кеше юк. Солдатларны грампластинка заводына урнаштырдылар. Заводның бер исән тәрәзәсе дә юк, эчендә суык жил ыжгыра, немецлар бик якын булып, тәрәзәдән берәрсенең башы күренсә, шунда ут ачалар иде. Пулялар сызгырып кереп стенадан штукатурканы коя. Солдатлар арыдылар, аларның атналар буе кайнар аш, йокы күргәннәре булмады. Берәр атнадан соң безнең командование һөжүм башлады, кырык биш минут артиллерия утыннан сон, Әхәтләр немецларны Мало-Ярославскийга таба куып киттеләр. Юлда зур тимер юл күпере шартлатылган иде, Әхәтнең исе китте, шундый зур көч—тимер балкаларны тимерчыбыкны боргалаган төсле бөкләп, өзгәләп аткан, олы карга оясын туздырган төсле бозга тараткан. Немец нык чигенгән булган, шуна күрә Әхәтләрнең частен йөк вагоннарына төяп, Мало-Ярославскийга озаттылар. Барганда болар күрә: тимер юлның ике ягында да бик күп немец солдатлары катып үлгән, баскан килеш тә, яткан килеш тә. Командир сөйләве буенча, суык 54 градуска кадәр житкән булган, ә немецлар жәйге формадан, пилоткалардан, ботинкалардан булганнар, шулай итеп, барлыгы биш мең фриц катып үлгән.

Әхәтләр немецларны Калугадан куып чыгарып, йөз илле чакрым ераклыкта булган Юхминга юнәлеп Гороховка авылында тукталдылар. Салкын бер көнне Әхәтләрне берәм-берәм пыялалары булмау сәбәпле, тәрәзәсенә салам тыгылган йортка сөйләшергә чакырдылар. Аларның частьлары наступление көтеп ята, күктә бертуктаусыз немец самолетлары оча, ә һөжүмгә боерык юк иде. Менә бер яшь лейтенант килеп, теге сөйләшергә чакырылганнар арасыннан егерме кешене сайлап алып, бер сафка тезде дә, урман ягына алып китте. Анда ул солдатларны ике рәткә тезеп, нидер аңлатты. Суык жил аркасында Әхәтнең шинель якасы

күтәрелгән булып, бүрек колакчыннары нygытып бәйләнгәнгә күрә, ул бу лейтенантның нәрсә аңлатканын ишетмәде. Бу командир солдатларны нарат урманы эченә, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган блиндажларга алып килде. Тимер торбалардан куе төтен туры багана булып күккә күтәрелә, еракта музыка тавышы ишетелә. Әхәтнең эченә жылы керде, ул жылы тимер мич янында йоклавын күз алдына китерде. Лейтенант артыннан чәнечкеле чыбыкның өстенә икешәр калын сайгак жәйгән жирдән эчкә үттеләр, блиндажларга якынлаштылар. Монда аларны немец автоматчиклары көтеп тора иде, теге командир аларны бер сугышсыз фашистларга китереп биргән! Әхәтнең башыннан берсеннән-берсе куркыныч уйлар үтте, ачлык та, суык та онытылды. Ул заманда Сталинның каты законын игълан иткәннәр иде инде, кем немецларга сатыла, шуларның гаиләләрен атарга дигән. Әхәт хатыны белән кызын уйлый-уйлый, куе агачлыкка кереп карга сенде. Караңгы төшкәч ул шуыша-шуыша кергән жирне эзләп тапты, такталар өстеннән дә шуышып чыкты, урманга чыккач, үз якларына чапты. Күп адашып, иртән генә ул янган авылга килеп керде, үзләренең командирын эзләп табып, булган хәлне сөйләп бирде. Командир моны берсүзсез генә тыңлап торды да, сержантны чакырып, Әхәтне өч көнгә авыл читенә каравылга куярга кушты. Авыл читендә салкында өч көн ач, йокысыз торды солдат. Башкаларны алыштырдылар посттан, моны юк. Өченче көнне Аксубай районы Дума авылы егете Сәләхов Сәхәб килеп, ярты котелок тозсыз пешерелгән арыш китереп китте:

—Әхәт абый, мин постта торганда комбатның сержант белән сөйләшкәнен ишеттем, "Теге нацменны иртәгә үк расходка чыгарырга кирәк",—диделәр. Монда нацмен син дә, мин генә калдык, калганын үзең уйла, дип, кире частька чапты. (Нацмен—представитель национальных меньшинств, чуаш, татар һ. б.).

Бу хәлләр 1942 елның февраль урталарында булды, һаман да үзәккә үтәрлек суык. Ниһаять, Әхәтне ят бер разводящий кызганып, алыштырды, үзләренең землянкаларына алып кайтып, сыек кына аш, ике телем ипи, илле грамм аракы бирде. Тимер мич янында күзен йому белән изрәп киткән Әхәтне, ярты сәгатьтән соң тревога белән күтәрделәр. Караңгыда тиз генә мылтыгын күтәреп, ул йөгереп чыкты тик ничә көн йокламыйча эренләп чыккан күзләре генә ябышып каткан булып, ачылмадылар. Ул күзләрен уа-уа иптәшләре артыннан абына-сөртенә чаба иде, кинәт артыннан комбатның калын тавышы ишетелде: "Разве так бегают во время тревоги!" диде дә, Әхәтнең башына наганы белән китереп тә сукты. Бу комбат моны ахыргача кыйный-кыйный часть артыннан чаптырды, ә соңыннан артта калган жиде солдат белән кардан ясалган буш окопларда оборонада калдырды. Ерак түгел күрше авылның чиркәве күренеп тора, шуннан немец снайперлары безнең солдатларны атып торалар икән. Әхәт иптәшләре белән караса, тирә-якта кар асты тулы үлгән солдат. Бер кыю гына урыс солдаты боларны урман читенәрәк алып китте, ә анда тагын бер авыл бар икән, йортлары да исән, яндырылмаган. Ни булса шул булыр дип, бу сигез солдат мылтыклардан атып, ура кычкырып, авылга бәреп керделәр. Немецлар авылга төрле яктан ут төртеп чыгып качтылар. Әхәтләр яна туналган сыер тиресе таптылар, шуны яна торган өйнең күмерендә өтеп, бүлгәләп ашадылар, тагын бер жирдә янган әтәч табып бүлештеләр. Немецлар киткәч, авыл халкы безнең солдатларны каршыларга чыкты, шатланалар бичаралар, үзләре ачлар, киемнәре сәләмә. Бер балалы марҗаны Әхәт бигрәк тә хәтерендә калдырды, мескен өч яшьләрдәге малае бик сөйкемле булып, аңа үлгән улы Марсны исенә төшерде. Бу малай салкын карга сәләмәләрдән чыгып баскан, ә аягының баш бармагына чүпрәк житмәгән, карга тиеп тора. Шушы хәлләрне

күргәч, Әхәтнең йөрәге кысылды, үзләренең авыр газаплары онытылды.

Солдатлар тешләрен кысып, немецлар артыннан куа киттеләр, тагын бер авыл очрады бөтенләй яндырылган мич торбалары гына серәеп калган. Немецлар авыл халкыннан читтә блиндажлар казыткан булганнар, һөҗүм башлангач, шунда кереп бикләнгәннәр дә пулеметларын төбәп боларны көтәләр. Әхәтләр үзләренең гарип-гораба кораллары белән кая барсыннар, авылда калып, ашарга эзләнә башладылар. Бер солдат ярты мичкә тозлаган кәбестә тапты, тик ул бик тун булып, тамакны туйдырмады.

Күп тә үтмәде, арттан безнең зур часть килеп, ялга туктады. Әхәтләр шатланып алар ягына чаптылар. Сакчылар бу солдатларны командирлары янына алып килделәр.

—Кто вы такие? Далеко еще до передовой?—дип сорады арыган кыяфәтле полковник.

Солдатлар булдыра алганча үзләренең кем булуларын аңлаттылар, ә алда бер-ике километрда немецлар булуын, арада безнең частьларның булмавын әйттеләр.

—Как так никого нет?—дип акырып җибәрде полковник,—по моим данным должна быть артиллерия, танки, пехота и автоматчики!

—Никого нет!—диде Әхәт башын чайкап.

—Товарищ полковник, это же власовцы, они специально вводят нас в заблуждение,—дип кычкырды бер яшь кенә лейтенант.

Китте тавыш: "Атарга боларны, атарга сатлык җаннарны",—дип, мылтыкларын күтәрә башладылар. Әхәтләрнең дә ачулары чыкты, гарип мылтыкларын тегеләргә төзәделәр:

—Без ике авылны немецтан азат иттек, ә сез әзергә килеп, безне атасызмы?—дип кычкырыштылар.

Полковник ике якны да көчкә тынычландырды, Әхәтләрнең документларын карый башлады. Ул да булмады, якыннан гына немец снаряды очып, арттагы урманга төшеп шартлады. Тегеләр шым булдылар, тәмәке утларына кадәр яшерделәр, кунарга җайлырак урын эзли башладылар. Бу полкның кыр кухнясы да булып, мескен сигез солдатны туйганчы кайнар аш ашаттылар. Икенче көнне Әхәтләр киредән үз роталарын эзләп табып, тагын сакка бастылар. Сугыш тынган арада Әхәтләрнең роталарын тулыландырдылар, аларга яңа комиссар бирделәр. Бер көнне авыл кырыена пулемет нокталары куяр өчен солдатлардан кар өйдерттеләр. Суык көнне тимер көрәк белән карны көрәп булмады: коелды да төште, коелды да төште. Әхәт, якындагы колхозның ындыр табагына барып, фанера табып, агач көрәкләр ясамакчы булды. Шунда Әхәтне постка билгеләп куйган исерек сержант очрап, самоволкага киткән өчен дип, тезләндереп аңа мылтыгын төбәде. Арттан Шәйдуллин дигән солдат килеп чыкты, сержант аны да тезләндерде. Сержант затворын тартып патронны патронникка кертеп азапланганда егылып китте. Әхәт иптәше белән кире ротага йөгерде. Алар иптәшләренә барысын да сөйләп бирделәр. Кыю гына урыс солдатлары комиссарны чакырып китерделәр, ротада булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Комбатның ничек итеп безнең солдатларны сатканын әйттеләр. Комиссар баштан ышанмыйча торды. Әхәт үзенең немецларда булып, егерме кешедән берүзе котылуын сөйләп бирде. Башкалар аның сүзен җөпләгәч комиссар уйланып торды да ныклы фикергә килде: өч иң таза солдатны комбатны кулга алып коралсызландырырга җибәрде, биш кешене урамның бер ягына, биш кешене урамның икенче ягына ярдәмгә куйды. Ярты сәгатьтән соң комбатның кулларын боггычлап алып килделәр. Комиссар сорау алырга тотынды. Комбат богаланды, гаебен танымады, әмма комиссарның карары катгый булды: атарга. Солдатлар тезелеп,

комбатка таба өч тапкыр аттылар. Болар берәү генә булырга тиеш түгел дип сөйләп торганда, комбатның ярдәмчесе сержант бинибаһая исерек килеш килеп чыкты да, сүтелгән обмоткасына абынып егылды, мылтыгын төшереп җибәрде. Комиссар аның мылтыгын алып: "Иди к фрицам",—диде дә, өч мәртәбә атты. Икенче көнне иртәнгә сатлык комбатны солдатлар ачудан таптап, җәймә ясаганнар иде.

Шул көннән башлап ротада хәлләр унай якка таба үзгәрде. Яна солдатлар килде, кыр кухнясында өч тапкыр ашата башладылар, солдатларны ашыгыч рәвештә һөҗүмгә әзерләделәр. 1942 елның март башында иртән куе урман эчендә солдатларны җыеп, кыска гына митинг ясап, алдагы бурычларны аңлаттылар.

—Без атакага барырга барыбыз да риза, тик менә миндә бер сорау бар,—диде олы яшьтәге яңа килгән солдат.—Безгә корал кайчан биреләчәк соң?

Чыннан да, яңа килгән солдатларда сыңар мылтык та юк, ә Әхәтнең үзендә дә прикладый ярчык белән җәрәхәтләнгән иске карабин иде.

Командирның авырткан җиренә тиде бу сорау, әмма аның кесәсендә, бу коралсыз солдатларны дошманга каршы күтәрергә, алдагы авылны алырга дигән боерык бар.

—Ватандашлар! Туганнар!—диде ул.—Ил өчен көрәш бик киеренке хәлдә, корал заводлары көне-төне эшләсәләр дә, корал җитешми, ә дошман баштанаяк коралланган, әмма безнең йомшаклык күрсәтергә хакыбыз юк. Сугыш барышында үзегезгә коралны җиңелгән дошманнан, яисә һәлак булган иптәшегездән алырсыз!

Шулай булып чыкты да, солдат кая барсын, алда немец ата, артта, ялгыш куркып кире борылсаң, үзебезнекеләрнең пулеметына юлыгасың. Солдатлар таралып, кыр тутырып, кар өстеннән чаптылар. Әхәтнең уң ягыннан наганыннан күккә ата-ата "Алга!" дип бар көченә акырып командир чаба. "Бу мине ялгыш атмасын тагын",—дип, Әхәт тирән карны ярып чапты да чапты, бераздан аның колагына үзенең гыжлаган тавышы гына ишетелә башлады, башка тавышлар тынды. Солдат бу тынлыкка гаҗәпләнеп, бер мизгелгә генә артына борылып карады, ап-ак кар өсте тапталган, бөтен җирдә хәрәкәтсез соры шинельле солдатлар ята, тирә-якта беркем юк. Тырышып чаба торгач, Әхәт иң алга чыккан, ә иптәшләре үлеп беткәннәр икән. Солдат тиз генә аңга килеп, юан каен артына сузылып ятты, ул үзенең немец өчен иң кулай мишень икәнен аңлаган иде. Сугышчы кич җитеп күз бәйләнгәч кенә, шуышып кирегә, үз ротасы калдыкларын эзләргә китте. Әхәт караңгы төшкәч, урысча сөйләшкән тавышлар ягына атлады, элеккеге урман каравылчысы йортында берничә командир фонарь яктысында сөйләшеп утыралар икән.

—Молодец, живой остался солдат!—дип, үз командиры торып аркасыннан какты.—Сходи с другими за дровами, тут очень холодно.

Әхәт үзе шикелле исән калган иптәшләре белән әрдәнәдән түмәрләр ташып, балта белән шуларны ярып, йортның миченә якты. Булган корысары белән тамак туйдыргач, бер солдатны дежурга куеп, җылыда мылтыкларын кочаклаган килеш сугышчылар бертын йоклап алдылар. Таң белән дежур солдат белән бер таныш түгел сержантның каты сөйләшүенә бар солдат та сикереп торды. Шул арада якында гына ату тавышы яңгырады, чыгып карасалар, бер командир наганын тыгып маташа, сержант үлеп ята. Ул сержант кичә үк алгы сызыкка егерме литр аракы китерергә тиеш булып, шуны китермичә, качып яткан булган икән. Трунов фамилияле карт солдат белән Әхәтне күзәтү пунктына җибәрделәр. Алар пункттан бер километрдагы ераклыктагы авылны күзәтеп, андагы немецларга өстәмә көчләр килүен

үзебезнекеләргә хәбәр итәргә тиешләр иде. Бу авылдан ерак түгел икенче авылны безнекеләр немецлардан азат иткән булганнар, әмма дошманнар барлык йортларны кара күмер ясап киткәннәр. Командирлары бер йортның подвалында тимер мичкә утын ягып, яшәп яталар иде. Көндез күзәтү пунктыннан кайткан солдатларны, төнгә шушы ике авыл арасында күзәтче итеп җибәрделәр. Янган авылга Әхәтләр "идән асты" командирларына ике авыл арасында яналыклар булмавын хәбәр иттеләр. Солдатларга җылынырга да вакыт бирмичә: "Барыгыз, юлны каравыллагыз"—дип, кире җибәрделәр. Кайтканда да немецлар ягыннан йөрүчеләр күренмәде. Үз командирлары да бу икәүне кире дозорга җибәрде. Көч-хәл белән тиешле урынга барып җиткәндә, кинәт күк яктырып китте, чож итеп яктырткыч ракеталар алларына ук төшә башлады. Ике солдат бу күренешне тизрәк ышыграк урынга, урман арасына кереп күзәтергә тотындылар. Ул да түгел, тау астыннан актан киенгән озын-озын дүрт кеше килеп чыкты. Әхәтләр карны казып ятарга урын әзерләп куйганнар иде, баштан-аяк коралланган дошман солдатларыннан качып, шул урыннарына кереп күмелеп яттылар. Үз телләрендә нәрсәдер пыш-пыш сөйләнеп, немецлар ике кар өеменең уртасыннан үтеп тә киттеләр. Ике солдат әле тагын озак кына бер-берсенә сүз әйтергә куркып яттылар.

Икенче көнне Әхәтне баягы карт солдат белән, икенче, немец гаскәренә тагын да якынрак җиргә дозорга билгеләделәр. Янадан кар куышы ясап, бинокльдан карап ятканда командир килеп чыкты. Ул кәгазьгә каләм белән сызып, немецларның урнашу тәртибен күрсәтте.

—Син монда кар өстенә чыгып йөрмә, снайперларның зәһәрләре утыра, үзеңне көпшәгә ала күрмәсеннәр дип әйтергә дә өлгермәде, Әхәтнең кулындагы бинокль кар өстенә төшеп тә китте. Шунда кар өстенә кып-кызыл тап җәелде. Карасалар, Әхәтнең җиненнән кан саркып тама икән. Трунов Әхәтнең ярасын бәйләде, беләзек турыннан пуля сөякләрне икегә ярып чыккан булган. Гимнастеркасын бөтенләй салдырып карасалар, Әхәтнең кулбашы да яраланган! Трунов карт ничек кирәк шулай яраны бәйләгәч, Әхәтне санчастька озатып җибәрде.

Госпиталь зур мәктәп бинасында урнашкан иде, фронттан килгән яралыларны бәйләп, операцияләр ясап, тылга таба эшелоннарга төяп җибәрделәр. Әхәт тә Мәскәү ягына кайта торган эшелонга эләкте. Берәр сәгать барырга өлгерделәрме-юкмы, немец истребительләре поездны бомбага тоттылар. Аяксыз-кулсыз яралылар төрле якка сибелде. Әрәмәләр арасында яткан Әхәт тизрәк бу мәхшәрдән качу ягын карады. Берзаман немецлар ягыннан пулеметлар телгә килде, миналар шартлады, ә яралыларда корал юк, кайсы ничек булдыра ала, шулай качып ята. Поездан чыга алмаган авыр яралылар бомба астында калдылар. Атышлар тынгач, Әхәт, Зайцев фамилияле яралы солдат белән бергә, бу урыннан еракkарак китте. Тирә-якта куе Мәскәү яны урманнары, солдатлар адашып йөри торгач, немецларның тылына килеп чыктылар, унга да борылдылар, сулга да, файдасыз—һәр җирдә дошман. Төн җиткәнче качып кына утырдылар да, чамалап үзебезнекеләр ягына киттеләр. Шикләнеп кенә барсалар да, бәхетләренә күрә, бер кечкенә авылда совет солдатларына очрадылар. Шыгрым тулы бер йортта кем утырып, кем басып, төнне уздырдылар. Иртән солдатларның кайсын кая чакырып алып бетерделәр, йортта Әхәт белән Зайцев кына калдылар. Кесә төпләрен кырып, бер-ике шакмак шикәр табып, кайнар су белән тамак ялгадылар. Алар ястык урынына салам түшәп, әзрәк ял итәргә ятканнар иде, иртән чыгып киткән солдатлар әлсерәп, йончып кайтып җиттеләр. Бик каты бәрелеш булып, күп иптәшләрен югалтканнар, гармунчылары үлгән. Сугышчылар исән калганнарына

сөенешеп, әзрәк ятып ял итеп алдылар да берәр кыр кухнясы эзләп киттеләр. Алдагы окопларга барып житүгә, немецлар Әхәтләргә көчле ут ачтылар. Безнен солдатлар да югалып калмадылар, трофейный мылтыклардан ничек кирәк шулай атып, сугыштылар, әмма көчләр тигез булмагач, Әхәтләр кырык кешедән бары сигез генә калды. Кыр кухнясын эзләп тапкач та, боларга ашарга бирмичә маташтылар, янәсе, алар бу подразделениедән түгел. Бик каты шаулашып, армия штабы белән куркыткач кына боларга өч көнлек коры паек бирделәр. Теге йортка кайтып, ботка пешереп, тамак ялгагач, тимер юлга чыгып санитар поездга утырдылар һәм Мәскәү ягына кузгалдылар. Мәскәүгә бу юлы хәвеф-хәтәрсез барып керделәр. Салкын вокзалга кергән һәр солдатка йөз грамм ипи белән егерме грамм май биреп, зур машиналарга төяп, ярты тәүлек госпитальгә илттеләр. Госпитальдә өч көн буе яралыларны тикшереп, авыр яралыларны ерак тылга, жиңелләрне якын-тирәгә жибәрделәр. Әхәт Иваново өлкәсенең Киржач госпиталендә бер ай дәваланды. Яралары жөйләнә башлагач та, Әхәт фронтка сорады, аны Смоленск ягына жибәрделәр. Можайскида икенче эшелонга төягәндә, Әхәт зур-зур кирпеч торбаларда иләк төсле снаряд тишекләре күреп шаккатты, монда сугыш бик каты булган. Эшелоннан төшкәч, солдатларга өч көнлек паек бирделәр дә, житмеш биш чакрым жирне урман арасыннан жәяү атлаттылар. Бу тирәдә урманнар бик сазлыклы булып, чебен-черки солдатларның жанына тиде. Юлда килгәндә бирелгән паек бик тиз бетте, ә килү белән довольствиега кертелмәгән булгач, аларга кайнар аш бирелмәде, арган ач солдатлар зур гына землянкага урнаштылар. Немецлар бик якын, ярты чакрым ераклыкта гына, ә безнең солдатларның тагын кораллары бик ярлы, кайсында автомат, кайсында мылтык. Бу 1942 елның апрель айлары, төннәр жылынып кына килә. Иртән иртүк сәгать өчтә тревога белән сугышчыларны торгызып, ике рәткә тезделәр дә, бер чакрым ераклыктагы авылга һөжүм ясарга куштылар. Арыган, йончыган солдатлар арасында сугышта күпне күргән усал сугышчылар да бар иде, алар ашамыйча беркая да бармаячакларын әйттеләр.

—Вы знаете, что будет за невыполнение приказа?!—дип жикерде лейтенант.

—Знаем, девять граммов свинца,—дип тыныч кына жавап бирде зур гәүдәле урыс егете.—Покормите нас, споров не будет.

—Сначала возьмете Киселевку, потом напоим чаем.

Солдатлар киреләнделәр, лейтенант акырды-бакырды, тик берни дә кыра алмады. Ярты сәгатьтән комбат килеп шулай ук жикеренеп наганын болгап торды, әмма солдатлар бирешмәделәр. Бераздан соң атка атланып, ординарецын ияртеп, кып-кызыл битле полковник килеп житте:

—Строиться!—дип кычкырды ул. Солдатлар тиз генә тезелделәр.

—Здравствуйте, товарищи солдаты!

—Здорово,—дип жавап бирде бер солдат, калганнар эндәшмәде...

Полковник наганын чыгарып һавага атты:

—Боерыкны үтәмәгән өчен барыгызны да аттырам!

Тиз генә арткы рәттән алыптай гәүдәле, күкрәгенә медаль таккан солдат чыкты да автоматын полковникка юнәлтте, алан тып-тын калды.

—Куркытма, иптәш полковник, безнең курка торган чаклар узган инде. Нигә ач солдатны һөжүмгә куасыз, житмеш биш чакрым жәяү атлап, безнең ашарга хакыбыз юкмыни? Безнең автомат та кысыр патрон белән корылмаган, житмеш бер патроны бар.

Полковник пырх-пырх килде, тотлыкты, аннан соң кулын селтәп, атын борып, кирегә чапты. Ординарец та анардан калмады.

Солдатларның кайсылары: "Хәзер килеп атарлар инде",—дип куркып,

полковник артыннан карап калды. "Курыкмагыз, бездән башка кем һөҗүмгә барсын, алар безне берни эшләтә алмыйлар",—дип тынычландырды икенчеләре. Чыннан да, төшкә таба старшина ат белән кухня алып килеп, солдат саен колбаса, ипи, махорка, йөз илле грамм аракы таратты да, тиз генә китеп барды. Сугышчылар утырып тамак туйдырдылар һәм атакага чакыру көттеләр, тик болар ягына килүче булмады. Әхәт дневальный булып, мылтык белән землянка ишеге төбенә чыгып басты. Немецлар якын, арада нибары кырык метр чиста кыр. Ике немец коралсыз килеш землянкалары өстенә чыгып басканнар да, кулларын болгап нидер кычкыралар. "Бу ни тагын?"—дип аптырады Әхәт. Немецлар тимер көрәккә таш бәрә башладылар: "Рус, на папирос, иди прикури",—дип мыскыллап кычкыра башладылар. Шырпы булмаганда безнен сугышчылар шулай чакма ясап, тәмәке кабызалар иде. Әхәт тиз генә землянкага кереп, иптәшләрен чакырды. Солдатлар кызган баштан йөгереп землянка өстенә чыктылар, гармунчы бию көе уйнап җибәрде: китте такмак әйтү, китте бию. Шушы пәри туенын ин кызган мәлендә бер немец: "Рус, на гостинец!"—диеп, агач саплы гранатаны солдатлар өстенә ыргытты. Граната землянка янәшәсендәге куш каенга бәрелеп шартлады. Алыптай солдат тиз генә танкка каршы ыргыта торган гранатаны дошманнын траншеясына томырды: "Получай, фриц!" Граната фашистларнын өерелешеп, көлешеп торган җирләренә килеп төште, күп немец солдатлары үлде. Уңышка канатланып, сугышчылар урманны чыгып, берәр авылны немецлардан азат итәргә җыенганнар иде, боларны бер командир тотып, дивизиягә беркетте. Сугышчыларнын барлык хыяллары юкка чыкты. Яңа командир боларны постларга дежурга таратып чыкты. Шул көнне кичкә таба Әхәт безнен зур самолетнын гүләп очып килгәнен ишетте. Кинәт самолетнын тавышы үзгәрде, моторы каты гүләргә тотынды, әллә инде яшен сукты, тик бу вакытта нинди яшен булсын. Нәрсә булгандыр, самолет Әхәтләр постка чыгып киткән каравыл сараена борыны белән килеп төртелеп шартлады, күккә кара төтен күтәрелде. Самолетта ничә кеше булгандыр, ә каравыл сараенда утызлап сугышчы бар иде. Бу бүрәнәдән салынган йорт урынында тирән чокыр хасил булды. Икенче көнне дивизия командиры килеп берничә табут ясатты. Бу табутларга бәрәнге бакчасыннан җыелган куллар, аяклар, башларны салып, шомлы музыка белән күмделәр.

## Сугыш вакытындагы укулар

Көннәрнен берсендә Әхәт белән тагын бер солдатны ике айга әзерлек батальонына җибәрергә булдылар. Барганнын беренче көнендә ял итсәләр, икенче көнне укулар башлана дип хәбәр иттеләр аларга. Әхәт белән килгән иптәш малаенын мондый батальонда укып караганы булганга күрә, штаб начальнигына үзенен мондый укуларга сәламәтлеге рөхсәт итмәгәнлеген анлатып: "Күз начар күрә, колагым начар ишетә",—дигән булып, бармый калды.

Әхәт исә монда укыганга күрә сугышка кертмәсләр, землянкада классларда гына укытырлар дигән уйлар белән килде. Әмма мондагы катгый таләпләрне ул күз алдына да китермәгән иде.

Менә укулар да башлана: һәр көн иртәнге сәгать дүрттән 30 градус салкында тревога буенча торгызып, аларны эчке күлмәкләрдән чыгарып бастыралар, бу вакытка аяк киемен киеп өлгермәгән булсан, махсус җәза бирелә, ә инде аякка киеп өлгергәннәрне кыр буйлап өч чакрым йөгертәләр, өлгермәсән, янадан йөгертәләр. Вакытында кайткан солдатларны лом тоттырып, су буена төшереп җибәрәләр, алардан бәке тиштереп, бозлы

суда юынганнарын карап торалар. Юыну сыйфаты ошамаса, юынырга кире боралар. Землянкага кайткач, бет тикшерү, противогаз, мылтык тикшерү китә, барысы да тәртиптә булса, солдатлар ашханәгә юнәлә. Анда барганда кычкырып күмәк җыр җырлыйлар, җырның сыйфаты офицерга ошамаса, аш бирдерми кире бора иде. Аш дигәненен дә инде исеме генә бар: ике кешегә ярты котелок өшегән бәрәнге, тозсыз пешкән сыек шулпа, өчәр сохари. Сохарине берьюлы ашап бетерергә кушмыйча, көне буена җиткертәләр иде. Шулпаны чүмереп бетерүгә, солдатларны, билдән кар ерып, алты чакрым ераклыкка мылтык, миномет күтәреп практик һәм тактик занятиега чаптырдылар. Туң җирне чокып, егерме секундта минометны утыртырга, тиешле җиргә атып тидерергә кирәк. Шулай кичкә кадәр изалангач, кайтып, тышта миномет, мылтык тазарту башлана. Караңгы төшкәч, солдатлар җырлый-җырлый барып, ашханәдән сыек шулпаны иписез генә эчеп кайтып, сугышта һөҗүм итәргә өйрәнделәр. Хәлләре бетеп, землянкага кайткач, җылымса су белән иртән бирелгән сохарины, бер шакмак шикәр кимереп, утырып ял итәргә өлгермиләр, аларны унбиш чакрым ераклыкка чаңгыда чаптыралар. Салкында солдатлар кулларын яисә колакларын өшетсәләр, андыйларны саф алдында аттылар, кайтып җиткәч тиз генә коры утын табып, үзләренең һәм офицерларның землянкаларын җылытырга тиеш иде алар. Утын әзерләгәч, ике сәгатькә постка бастылар, ял иткән арада бөек Сталин приказларын ятладылар, яки учебный тревога булып чыгып йөгерделәр. Төнге сәгать унбердә офицер кичке тикшерүгә тезә, аннан соң солдатлар чиләктән ясалган тимер мич янында киез итекләр, чолгаулар киптерергә чиратка тезеләләр. Сугышчылар арып-талып, кысылышып, бер ян-яклары белән генә ятып, күз йомуга, штаб башлыгы керә, яка-каешлар ычкынганмы икәнен тикшереп китә, таң атканчы тагын ике сәгатькә постка бастыралар. Шушы мәхшәр ике ай дәвам итте, Әхәтнең ите-мае шушы учебкада суырылып калды. Ахырдан, аңа кече сержант чины биреп, кире үз частена кайтарып җибәрделәр, әле аның бәхетенә һөҗүм булмады, анда иң беренче чиратта учебный батальонны җибәрә торган булганнар. Үз частенда аны, рәхәтләнеп, сугышмыйча җылыда укып ятты диеп, постка куярга, эшкә җигәргә көтеп торалар иде.

## Сталинград фронтында

1942 елның 18 ноябренә немецлар Сталинград шәһәренә бөтенләй якын килеп, аны җимереп-яндырып бетерделәр. Әхәт хезмәт итә торган частьларны да әкренләп шул якка күчерә башладылар. Кая гына барма, кайда гына торма, суык солдатларның үзәкләренә үтте, чөнки еш күченүләр, яңадан-яңа землянкалар ясау, тимер мичләрнең җитешмәве, ачлык сугышчыларны нык йончытты. Салкында шакыраеп катып посттан кайткан Әхәт бер көнне түзмәде, землянканың ян стенасын көрәк белән чокый башлады. "Бу татар юләрләнгән, ахры",—дип, старшинаны чакырдылар. Старшина акырды-бакырды да, туфракны тышка чыгарырга кушты. Иптәшләре, Әхәтне сүгеп, патрон әрҗәсенә туфрак тутырып, читкә түгә башладылар. Әхәт стенаны эт оясы кадәр чокып кергәч, землянка өстеннән зур гына агач кагып, чокыр турысына тишек ясады. Керә-керешкә үк коры чыбыклар алып кереп, ул мичне кабызып җибәрде, бу суыкта мич бик күнелле генә дөрләп яна башлады, землянка эчендәге тәмәке төтеннәрен суырып алып чыгып китте, дөньялар җылынып, яктырып китте. Әхәт тиз генә кружкасына кар тутырып, чәй кайнатты, бөтен иптәшләрен көнләштереп, сохарины кайнар чәйгә тыгып алып, шикәр комына манып, тәмле итеп чәй эчте. "Вот хитрый татарин, нашел себе удовольствие",—дип, калган солдатлар да аның янына

жыелып тәмәке тарттылар, коры-сары алып кереп, мичкә яктылар. Кырык кеше кырык тапкыр яккач, землянка иртәнгә нык жылынды, солдатлар шинельләрен салып йоклый башладылар, хатлар яздылар, төймәләрен тактылар. Алар мәш килеп ятканда землянкага политрук килеп керде: "Карале, сездә нинди жылы!"—дип тел шартлатты ул. "Моны безнең профессор Кадыйров уйлап тапты, ышанмыйча башта көлеп йөргән идек тә, ә ул бик шәп нәрсә булып чыкты. Бернинди чыгымы юк, торбалар, мичләр сөйрәп йөрисе юк, ясарга да жайлы",—диделәр солдатлар. Хәзер кайда күченсәләр дә, алар землянка казып, тиз генә мичен дә чыгарып куйдылар. Әхәткә командир рәхмәт белдерде.

Күченә-күченә Әхәтләр һаман көньякка таба бардылар, кайда атналап, кайда берәр ай көтеп яттылар. Күченгәндә аркаларында кырык килолы йөк сөйрәп йөрделәр: миномет көпшәсе егерме биш кило, прицелы ике кило, противогаз, мылтык, биштәр эчендә гайкалар, ике йөз илле данә патрон. Беркөнне Әхәт, постта торганда чана ясарга кирәк дип уйлады һәм посттан бушагач, чананың сызымын сызып, рота командирына илтеп, аңлатып бирде Бу гади генә сызым барысына да ошаган, дивизия командиры Әхәтне эзләп, үзе частька килгән. "Солдат, син моны тиз генә ясап та бир инде",—ди бу. Сталинград якларында шундый начар кәрлә бөкре каеннар гына үсә икән, алары да аз. Дала буйлап материалга яраклы агач эзләгәндә, Татарстан якларының төз озын каеннарын күз алдына китерде Әхәт. Үзенә ярдәмгә бер солдат алып, яраклы агачны үтмәс балта, үтмәс пычкы белән урталай ярып, бөтен кеше йоклаганда Әхәт килештереп чана ясап куйды. Иртән минометны утыртып командирлар белән ул кырга сынауга китте. Әхәт чанадагы миномет янына басып, минаны салып атып жибәрүе булды, чана артка таба шуып китте, тагын ике-өч кат аттылар, чана бирешмәде. Командиры аңарга рәхмәтләр белдереп, кире частька жибәрде. Көч-хәл белән сөйрәлеп кайтып житсә, анда минометчикларны тезеп, приказ укып яталар: "Бөтен минометларны да чаналарга урнаштырырга, чанадан атарга",—диелгән. Ә чаналарны ясау тагын шул ук "уйлап табучы" Кадыйров өстенә йөкләтелгән. "Ник ясап күрсәттем!" көнәнә төште Әхәт. Көннәр суык, жүнле каен юк, балта, пычкы үтмәс. Ул көчкә роталарына алты зур чана ясады. Хәзер тиз генә жыенып күченә башлагач, солдатлар бөтен әйберләрен чанага төйиләр дә, кайда тартып, тау төшкәндә өстенә утырып шуып төшәләр. Барлык иптәшләре дә Әхәтне мактадылар, өстебездән тау төшерден, диделәр.

1943 елның январь ахырлары, Сталинград ягында сугышлар кызганнан-кыза бара. Әхәтләрне төнлә торгызып, житмеш биш чакрым еракльктагы станциягә жәяүләтеп жибәрделәр. Төн суык, ашыгып жәяү атлаганда солдатларның кәжә майлары чыкты. "Әле Кадыйровка рәхмәт әйтегез, минометлар күтәреп бармыйсыз",—дип шелтәләде аларны политрук. Станциягә килеп житкәч, поездның кайчан киләсе билгесез булып чыкты, солдатларны коры яланда бастырып көттереп тордылар. Сугышчылар якындагы урманнан кәкре каеннар кисеп, учак яктылар, каеннар чи, бер жылы бирмичә төтенләп кенә утыралар. Әхәт биш иптәшен котыртты да, минометлар япкан плащларга төренеп, чанага яттылар. Бу плащлар бик жылы булып, тыштагы суыкны да үткәрмәде, үз жылыларын да чыгармады. Солдатлар рәхәтләнеп ял иттеләр: "Баш та бар инде синдә, Кадыйров, бөтен уйлап тапкан әйберең безгә файдага",—дип рәхмәт укыдылар.

Бер тәүлектән соң гына товар поезды килде. Буш, салкын вагоннарга әллә кайлардан такталар эзләп таптылар һәм сәкеләр ясадылар. Кешеләр күп булды бу вагонда. Утырырга түгел, басып торырга да урын юк иде. Станцияләрнең берсендә егетләр каяндыр торбасыз чуен мич, күршедәге

составның түбәсеннән өч табак калай табып алып килделәр. Әхәт үзе белән гел игәү йөртте, кирәк чагында балта, пычкы үткерләде, бик үзәге өзелеп ачыкканда пешекчеләрнең пычакларын кайрады. Алар ни булса да биреп, Әхәтне ач калдырмадылар. Шулай ук Әхәт үзе белән тимер кайчысы, паяльник һәм эш кораллары да йөртте. Күтәреп барырга мөмкинлеге булмаганда, аларны калдырып китте, тик андый чакта бу коралларны иптәшләре күтәреп бара иде. Әхәт иптәшләренең күбесенә котелок ясап, йә төпләп бирде. Йөк вагонында чуеннан коелган торба ясап, аны вагон түшәменнән чыгарып җибәрде. Солдатлар ташкүмер, утын ягып җылынып бардылар. Беренче станциядә үк төшеп, Әхәт ике такта табып алып менде дә, такта башларын ике сәндерәгә куеп, чишенеп менеп ятты. Бу урында аңа бик тә җылы булды.

Икенче көнне тимер юл буеннан кар җыеп, Әхәт үзенә чәй кайнатты. Тик бу чәйне ул тынычлап эчә дә алмады, йә берсе, йә икенчесе кружкаларын күтәреп килеп, анардан ярты гына стакан чәй сорап йөдәттеләр. Әхәт исә берсен дә буш җибәрмәде, биреп барды. Шуңа күрә янадан чәйне ул башкалар яткач кына кайнатырга булды. Шулай бер вакыт кар тутырып чәй кайнатып эчим генә дигәндә, Әхәт янына кече лейтенант һәм аның иптәше килеп басты: "Кадыров, налейка мне полкружки чая",—диделәр. Әхәтнең бөтен булган чәе дә шул бер стакан иде, кайнатырга су табулары бер әҗәл: чөнки поезд әкренәюен саклап сикереп төшеп кар алыйм дисә, станциядә чиста ак кар булмады, паровоз машинистлары да күп вакыт су бирмәделәр, ашханә иң ахыргы вагонда булып, шуннан чәй бөртекләре дә теләнергә кирәк иде. Барысы да булса, мичне болгатып кыздырып җибәрмичә кружкада тиз генә су кайнап чыкмый. Әле су эзләнеп чыккач, ялгыш вагонга керә алмасаң, беттең, дезертир дип ата торган заман. Шуңа күрә аның бу кадерле чәйне беркем белән дә бүлешәсе килмәде: "Чәй кирәк булса, үзегез кайнатыгыз!"—диде ул вагондашларына.

Әхәтләр Воронеж өлкәсенең Грязный станциясендә төшеп, көньякка таба җәяү киттеләр, күпме барырга—беркем бернәрсә әйтмәде. Сугышчылар көне-төне бардылар, ялга да ун минутка гына туктап, ике йөз чакрымны үттеләр, нык алҗыдылар: киез итек төпләре ашалып бетте, привал саен чолгауларның исән җирен табып, аякларына чорнадылар. Бер солдат олтаны төшеп калган киез итек балтырларын салып томырды, икенчесе: "Бара алмыйм",—диеп, карга сузылып ятты, икесен дә шунда ук аттылар.

Таң атканда солдатларны Старобильский авылына биш көнгә урнаштырдылар. Бу авылга бер эшелон корал китереп бушатып киткәннәр, Әхәтләрне шул коралларны сакларга куйдылар. Әхәт постта торганда өелеп торган тартмалардагы коралларны карап йөрде: нинди генә төрдә автоматлар, пистолетлар юк, төрле ящикларда дары, кыскасы, гарип мылтыклар белән сугышкан солдат өчен күргәзмә төсле. Көн саен дошман бомбардировщиклары килеп, авыл өстенә бомба ташлап киталәр. Беркөнне бомбардировкадан соң пистолетлар салынган ящик ватылып, кораллар карга чәчелгәч, Әхәт кесәләренә, итек балтырларына күп итеп ун зарядлы пистолетларны тутырды да, рота командирына кереп, тиешенчә сәламләгәч, сорады: "Наводчик булгач, миңа пистолет бирелергә тиеш бит, ни өчен ул бирелми?" "Пистолетлар житешми, иптәш Кадыйров, трофейга эләктерә алсаң, пистолет йөртергә рөхсәт бар",—диде командир арыган кыяфәт белән, сүз беткәнне аңлатып. Әхәт ашыкмыйча гына яшергән җирләреннән чыгарып, командир алдына уналты данә шәп пистолет тезеп куйды. Командирның арыганлыгы шундук онытылды, ул бер пистолетны Әхәткә биреп, калганнарын командирларга таратты. Әхәттән күреп, башка сугышчылар да каешларына пистолет тагып йөри башлаганнар иде,

командирлары каршы төште, чөнки сүзе күп иде.

Авылда тору озаккарак китте. Әхәтне шлагбаум янындагы постка билгеләделәр. Көн коры салкын, кар инде күптән яумаган. Старобильский ягыннан Әхәт баскан постка таба бер кеше килә. Якынлашкач, моның зур чана тартып килүче олы гәүдәле хатын икәнлеге ачыкланды. Хатын Әхәткә үзенең ире фронтта, балалары күп икәнлеген, күрше авылга туганнарына кием-салым алыштырырга барганлыгын аңлатты. Хатынның чанасында олы гына капчык, аның өстенә иләк-чиләкләр бәйләнгән, иске-москы өелгән иде. Елап торган хатынны кызганып, пропускасы да булмауга карамастан, Әхәт аны шлагбаумны ачып чыгарып җибәрмәкче булды. Хатын, рәхмәтләр укып, юлын дәвам итәргә дип чанасына борылуы булды, тик торган чанадан шырт иткән тавыш ишетелде. Салкын һавада бу тавыш мылтык аткан төсле яңгырады. Әхәт каушавыннан ун патронын да һавага атты, хатын чүгәләп, колакларын томалады. Аткан тавышка солдатлар белән разводящий йөгереп килделәр. Чанадагы иске-москыны ыргытып, капчыкны чишеп җибәрсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр—анда зәп-зәңгәр күзле немец офицеры ята. Хатынны да, офицерны да штабка алып киттеләр, нишләткәннәрдер, Әхәт анысын белмәде. Сизгерлеге өчен аның үзен ике көнгә барлык эштән азат иттеләр, строй алдында рәхмәт белдерделәр.

Сталинград өчен барган сугышларның кызган чагы. Чатнама суыкта Әхәтләрне таң белән торгызып, тагын көньякка алып киттеләр. Бу юлы өч йөз чакрым җәяү бардылар. Юлда бер авылда ялга туктадылар. Хуҗа кортка зур чуенда әрчемичә пешерелгән бәрәңгене төеп маташа иде. Шушы бәрәңгегә онмы, көрпәме бутап, чуены белән тышка чыгарып куйды. Ач солдатлар хуҗалар йоклагач, чуенны алып арт бакчалар янына чыгып, тозсыз, майсыз болгауны бүлешеп ашап бетерделәр. Хуҗалар күзенә күренергә оялып, сугышчылар кире өйгә кермичә, төнне шакыраешып урамда уздырдылар да, иртән юлларын дәвам иттеләр. Сугышчылар Сталинградка ук барып җитмәделәр, бер зур елга ярында тукталдылар. 10 минут кына ял иттеләр дә алар боз өстеннән елганы чыктылар, әрәмәлек арасыннан ярга күтәрелделәр. Монда ярны немец минометчиклары күзәтеп утыралар икән, сугышчылар күренү белән мина яңгыры яудырырга тотындылар, бөтен әрәмәлек кара төтенгә чумды. Күп сугышчы шунда ятып калды. Политрук килеп, елганың теге ярына чигенергә кушты, югыйсә барысы да үлеп каласы иде. Икенче көнне Әхәтләрне 96 нчы полкка куштылар, немецлар бик каты аттылар, бу полк та нык кимеде. Ике як та бер-берсенә бирешмәде. Ике көн сугыш тынып торды, Әхәтләр янына янадан-яна частьлар килде, чаналы атлар күп иде. Өченче көнне күп атлар чана тартып боз өстенә кереп тулдылар, икенче ярга чыга башладылар. Боз өсте сугышчылар белән тулды, барысы да ашыга. Шул вакыт немец боз өстенә авыр снаряд белән ата башлады: һавага су фонтаннары күтәрелде, чаналар суга төшеп, атларны, кешеләрне үзләре белән сөйрәделәр. Атлар шундый кызганыч итеп кешнәделәр, алгы аяклары белән бозга басып чыгарга тырыштылар, моны ишеткән кешеләр бу мәхшәрне гомер буе оныта алмадылар. Әхәтнең фашистларга шул хәтле ачуы чыкты, гомерендә тавык та суймаган адәм, кеше үтергәненә куркып йөри иде, хәзер йөрәге катты, немецларны пленга да алмыйча барысын да атып барды. Елганың ярына урнашып, Әхәтләр немецларга минометтан ут яудырдылар, каты сугыштан соң яр буеннан фашистларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Шулай яр буеннан күп авылларны азат итеп, Сталинградка шактый якын килделәр. Немецлар бу якка күп гаскәрләр, техника, корал җибәргән, шуңа күрә сугышлар бик авыр булды. Авыл өстенә ерактан гына фашистлар снаряд җибәрәләр иде, снаряд ярыла, эченнән чыккан бер метрлы дарылы торбаларга ут кабынып, авыл өстенә ут яңгыры булып явалар

иде. Сталинград шәһәре өстендә төнлә ерактан гел ут янгыры күренеп торды. Шәһәрне бомбага тотарга килгән самолетларга безнекеләр танкка каршы ата торган пулялар яудыралар иде. Кайда кем кемгә атканын, адәм баласы үзенең кайда йөргәнен, кайда басып торганын белмәслек каты сугыш булды. Ниһаять, февраль башында генерал Паулюсның армиясен Совет гаскәрләре урап алдылар, ул көнне беркемгә дә атарга рөхсәт ителмәде. Төшкә таба жинел машинаның капотының бер ягына кызыл, бер ягына ак флаг беркетеп Сталинград ягына җибәрделәр. Соныннан политрук солдатларны җыеп анлатты: "Шәһәр эчендә һәм кырыенда немецларның кырык дивизиясе чолганышта калды. Аларга бер җирдән бернинди ярдәм килерлек түгел. Генералга бөтен армиясе белән бирелергә кушылды. Немецлар, Гитлер белән сөйләшмичә, бернинди дә җавап бирмәделәр, соңгы патрон, соңгы солдатка хәтле сугышырга булдылар". Әхәтләргә яңа частьлар, техника күп килде, сугышчыларның күнелләре күтәрелде. Ә Гитлер Германиядә өч кайгы көне белдерде. Чолганыштагы фашистларны ныгытып дөмбәсли башлагач, немецлар меңәрләп әсирлеккә бирелә башладылар. Җимерелгән шәһәр эченә кертмичә, Әхәтләрнең дивизиясен Өченче Украина фронтына кушып, Ворошиловград ягына җибәрделәр. Немецлар һәр чакрымда ныгытып каршылык күрсәттеләр. Әхәтләр хәзер генә аттылар, шул арада окоплар казыдылар, яисә һөҗүмгә күтәрелеп, немецларны кудылар. Авыллар янган, шуна күрә кунарга тиз генә землянка казып кирәргә туры килде. Зур авырлык белән сугышчылар алга бардылар, Красный Лиман шәһәрен азат итеп, шунда бер айлап тордылар. Немецлар шәһәрне калдыру белән бер дә килешмәделәр, авыр артиллериядән гел атып тордылар, күп йортларны җимерделәр, кешеләрне кырдылар. Совет солдатлары да нык тордылар, шәһәрне кире бирмәделәр.

## Кавказда

Госпитальдән соң Әхәтне Ереваннан үз частена кайтардылар, Шулавери шәһәренә. Монда электән үк хәрби көчләр урнашкан булган. Әлегә монда тыныч, сугыш канонадасы ишетелми. Кече лейтенант Әхәтне чакырып алды да:

—Иптәш Кадыйров! Ачык һавада күргәзмә класс ясарга кирәк. Кайсы частьның классы шәбрәк, шуна бүләк булачак. Бу эшкә синнән дә кулай солдат юк, күпме ярдәмче кирәк шулкадәр ал, төзе. Төзү материалы аяк астында, менә җир, әнә таулар, әнә елга. Сиңа өч көн срок, безнең класс иң әйбәте булырга тиеш,—диде.

Әхәт частьлар буйлап башкаларның эшләрен карап чыкты: бер подразделениедә таудан ташлар ташып, дүрт почмакка дүрт тумбочка өйгәннәр, уртага командир өчен, аннан һәр солдат өчен тагын тумбочкалар ясалган. Бик күп көч куелган, солдатны кызганмаганнар, Әхәткә ошамады. Икенче частьта ташлы җирне чокып, таудан таш ташып тумбочкалар өйгәннәр, ифрат күп көч түккәннәр. Болары да ошамады. Карангалап йөри торгач, Әхәт кешедән биегрәк ике "үгез борыны" үсә торган кечкенә генә чокырсу урын сайлады, ярдәмгә биш солдат сорап алды. Әхәт башта уртага командир утырырга кырык сантиметр тирәнлектә чокыр казытты, аннан соң солдатлар утырсын өчен утыз сантиметр тирәнлектә канаулар ясатты. Солдатлар тирә-якка түтәлләр ясап, ак гравий түзделәр, арасына солы чәчеп, лозунг яздылар. Су сибеп торгач, солы өч көн дигәндә тишелеп чыкты. Хәрефләр куерак булып күренсен өчен Әхәт солыны кыркып чыкты. Утырырга йомшак булсын дип, командир һәм солдатлар утыргычларына ярдәмчеләр кипкән печән салдылар. Комиссия аларга дүрт-биш көнсез килеп җитә

алмады. Әхәт классны себереп, яшеллеккә су сибеп, карап торды. Тәрбияләгәч, агачларда кызыл роза чәчәкләре күбәйде, солы яшелләнеп, хәрефләр ачыкланып китте, класс алдына сугышчылар флагчыклар кадап куйдылар. Менә унике командирдан торган комиссия килде, аптырап торалар инде, кая икән монда класс дип. Кече лейтенант әйтә:

—Әйдәгез, рәхим итегез безнен класска,—ди. Ул баштан полковникны командир урынына, калган офицерларны солдатлар өчен эшләнгән дугалы чокырларга аякларын салындыртып утыртты. Комиссия членнары утырып беткәч солыдан язылган лозунгларны күрделәр дә, барысы да кычкырып көлделәр. "Утырырга йомшак, аяк салындырырга урын иркен, лозунглары үзенчәлекле, эшләсәләр ике сәгать көч түккәннәрдер инде, кемнен башы житте мона?"—дип сорадылар лейтенанттан.

Лейтенант болай дип жавап бирде:

—Безнең частьта бер бик йомры башлы нацмен бар—татар баласы, шунын кулы бөтен эшне белә, шул эшләде. Күптән түгел сугышчыларга зур гильзалардан мең ярым котелок та ясады.

Комиссия бик канәгать булып, мактап китте. Әхәтләргә якындагы ял йортына өч күлмәк юллама бирделәр, рәхмәт белдерделәр. Сугыш вакытында иркенләп чишенеп, юынып ял итүдән дә кыйммәтле әйбер юк солдат өчен. Частьтагы барлык сугышчылар да Әхәткә рәхмәт әйттеләр.

***

Беркөнне Әхәтләрне таудан агач кисеп кайтырга жибәрделәр. Бу якларнын агачлары шундый чырыш, ни киселми, ни ярылмый. Әхәт, барасы килмәгәнлектән, политруктан лозунг язарга сорап калды. Кызыл почмакта матурлап-сырлап әрмәнчә лозунг күчереп утырганда, казармаларны тикшереп йөрүче комиссия килеп керде. "Матур язасын, әллә әрмәнчә дә беләсең инде",—дип, Әхәтне мактап чыгып барганда бер лейтенант: "Каян әрмәнчә белсен, ул бит хәрефләрне күчереп кенә ясый",—диде.—Әле ул Сталиннын сонгы приказын да ятламагандыр",—дип өстәп куйды. Комиссия членнары кире борылып керделәр, Әхәттән сонгы приказны сорадылар. Әхәт бу приказны бөтенләй ятламаган иде. Төш узгач, жыелыш жыеп, Әхәтне алга чыгарып нык оялттылар инде, каты сүктеләр. Үзенчә яхшы эш эшләп макталырга жыенган солдатка шулай итеп тиргәү әләкте.

***

Әхәткә дежур чираты иде. Төшке ашка сигнал бирер өчен бер кабинетның ишеген ачып сәгатьне карамакчы булды. Бу бүлмәдә ниндидер командирларнын укулары икән, ул шуны күрү белән ачкан ишекне кире япты. Шул арада ишектән атылып кызарынган-бөртенгән комбат чыкты:

—Стой! Кто тебе лычки пришил (звание дал)?—дип кычкырды.

Ишекне ачкач, Әхәт честь биреп, командирга тиешенчә эндәшмәгәнгә котыра икән бу тыл күсесе.

—Званиене мина фронтта бирделәр. Лычкалар кирәк икән, мә алыгыз,—дип Әхәт лычкаларны комбат каршында ук ертып ыргытты.

Ике көн погонсыз йөргәч, төнге унберд䙙 Әхәтне старшина уятты да, погоннарына ашыгыч төстә лычка тагып куярга кушты. Йокысыннан уятканга ризасызлык белдереп, Әхәт икенче ягына әйләнеп ятты, чөнки мендәр астында анын әйбәт калайдан ясалган лычкалы өр-яна погоннары икенче гимнастеркасына тагылган иде. Тагын ярты сәгатьтән сон старшина үзенә чакыртып Әхәтне: "Сине өч көнгә гаупт-вахтага",—дип белдерде. "Нәрсә өчен мина шундый каты жәза?"—дип сорады Әхәт. "Син нигә телләшеп торасын? Командир боерыгын үтәмәгән өчен. Нигә лычка

такмадың?" Әхәт старшинаны шаккаттырып, үзенең ялтырап торган погоннарын күрсәтте. "Бар, йокла",—диде аның хәйләкәрлегенә шаккаткан старшина. Икенче көнне аның яңа погоннарына полковникның да күзе төште, барлык сугышчыларга да шундый матур лычкалар тагарга кушты.

***

1943 елның җәй айлары Кавказ артында сугыш бармаган жирләрдә узса да, ашау ягы, махорка монда да такы-токы була. Күрше авылларда тәмәке плантацияләре булса да, урлаган-талаган өчен армиядә каты җәза бирәләр иде. Әхәт жаен табып бер әрмәнгә ат сатарга сөйләште. Үз гомерендә бер кешедән ялгыш бер шырпы да алмаган Әхәт ат хәтле ат урларга булды. Ул бик үткер бер әрмән Тригорян һәм урыс Долгопавлов фамилияле солдатлар белән сөйләшеп, егерме мең сумга бер полк атын төнлә белән уйсулыкка төшерергә булды. Төнге сәгать унберда карт әрмән акча белән шунда көтеп торырга тиеш иде. Долгопавлов ул кичне очып кына йөрде, барып чыкса, акчаның яртысын авылга аналарына җибәрергә жыенды, заем түләргә, ә калганына туйганчы ашарга, тартырга алырга хыялланды. Кичке занятиеләр беткәч болар шыпырт кына барып, ат абзарындагы кизү белән сөйләштеләр дә бер олы бияне алып чыгып, икәү атланып чаптылар. Уйсулыкта бурка, папаха кигән әрмән трубка кабып йөренеп тора, боларны көтә. Инде атны сатып акча кулга керә дип, солдатлар шатланып бетә алмадылар. Икәүләшеп аттан сикереп төшеп, әрмәнгә якынырак килсәләр, әрмән дигәннәре юри шулай киенгән батальон командиры икән. Тезгенне җибәреп, ике солдат ике якка яшен тизлегендә качтылар. Казармага кереп яткан Әхәтнең йөрәге дөпелдәп тибә: "Трибуналга биреп торырлар микән мине, бүген үк судсыз-нисез атарлар микән?" Танга хәтле ул йокламыйча көтеп ятса да, артыннан килүче булмады, иртән зарядка, укулар узды, чакыручы булмады. Төштән соң сержантларны штабка чакырдылар да: "Ат сатарга жыенган өчен Кадыйровны фронтка җибәрергә"—дигән боерык укыдылар. Аңа жыенырга сәгать ярым вакыт бирделәр. Судка бирмичә болай гына котылуына Әхәт жинел сулап куйды. Урлашу бит ул килешкән кешегә генә килешә, гомер буе тир түккән кешегә урлашу килешми, шундук тотыла.

***

Әхәт хезмәт иткән батальоннан утыз кешене фронт ягына алып киттеләр. Гори шәһәрендә боларны кече лейтенантка тапшырып, мунчага китереп тезеп куйдылар. Көтәләр болар строй белән басып, көтәләр, мунча өлгермәгән. Лейтенантларының каядыр китеп юк булуыннан файдаланып, Әхәтнең иптәшләре тиз генә гимнастеркаларын, каешларын сатып килделәр. Аларга яраган миңа ярамыймыни дип, Әхәт тә тиз генә каешы белән гимнастеркасын, аннан соң курткасы белән чалбарын сатып килде, үзе башкалар кебек иске-москы киемнәр киеп куйды. Менә лейтенант килде. Ул солдатларының ертык иске әйберләр кигәнен күрсә дә, сүз озайтып тормады, санады да мунчага кертеп җибәрде. Әхәт мунчада акчасын кулъяулыкка төреп кулына тотып йөрде, душта тиз генә чупырдады да чыгу ягына борылды. Кечкенә генә тәрәзәдән сугышчыларга яңа киемнәр биреп, баштанаяк киендереп чыгардылар. Яңа бер тиен кебек ялтырап торган солдатларны казармаларга урнаштырып, ишек төбенә сакчы куйдылар. Шәһәргә чыгарга мөмкинлек калдырмаганнар, тирә-якны чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алганнар икән. Шулай да Әхәт бер татар—кече лейтенант белән танышып, шәһәргә чыгып фляжкасына тутырып шәраб алып кайтты, лейтенантка да шәраб сатып алып бирде. Икенче көнне иртәнге аштан соң митинг ясап, концерт күрсәтеп, тынлы оркестр уйнатып,

солдатларны сугышка озаттылар. Командирлары болар тагын киемнәрен сатмасыннар дип, ашыктырып, вокзалга барып вагонга утырганчы карап бардылар. Әмма дә ләкин бу дөнья гизгән солдатлар шул хәтле шомарып беткәннәр ки, 25 км китүкәч разъездда озакка туктагач, кирегә шәһәргә барып, яна киемнәрен сатып, иске-москы киенеп килделәр. Разъездда тору бер тәүлеккә сузылганын белгәч, Әхәт тә иптәшләре кебек әйберләрен сатып, сәләмәләр киеп куйды. Тбилисига килгәч, поезд фронтка китә торган башка эшелоннар янына туктады. Солдатларга чыгып тезелергә приказ булды. Бу сафка караган кеше көлми түзә алмады: солдатларнын кайсыберсе ертык туннан, икенчеләренең бер аягында ак итек, икенчесендә кара итек, кайсылары эчке күлмәкләрдән бөрешеп тора. Командир, гаҗиз булып, стройга күз йөртеп чыкты да, тыл начальнигына приказ бирде:

—Бу партизаннарны шушы кыяфәттә Польшага кертеп булмый бит инде. Өч сәгать эчендә шәһәр мунчасында юындырып, яна киемнәр бирегез!

Шулай итеп, Тбилисида аларны яңадан киендерделәр дә поездга төяп, Махачкалага озаттылар. Махачкала вокзалы янына якын җирдә бай базар булып, Әхәт шуннан тиз генә җаны теләгән ашамлыкларны алып капчыгына тутырды. Анын тагын бераз акчасы калган иде, шуна бераз тәмәке алмакчы булып, кире базарга килсә, шаккатты: барлык прилавкаларны солдатлар талап бетергәннәр, хәтта тактадан ясалган ларекларны да аударып, эчендә берни калдырмаганнар.

Бу хәлләрне алдагы станцияләргә дә хәбәр итеп куйгач, фронтка китүче эшелоннар узып киткәндә сатучылар вокзал тирәсендә бар нәрсәне яшереп куя торган булдылар. Шулай да Польшада тоз кыйммәт дигән хәбәр таралгач, барлык солдатлар да капчыкларына тоз тутырып алдылар. Белоруссия, Украина җирләрен күп михнәт, ачлыклар белән үттеләр, Польша җирләренә кергәч, шул тозны солдатлар самогонга, тәмәкегә алыштырдылар. Бер солдат кыйммәткәрәк сатарга җыенып, тозын озак саклап барган иде, алгы сызыкка кергәч, капчыгын куак төбенә бушатып китәргә мәҗбүр булды.

## Илебез чикләрен узгач

Немецлар безнең сугышчылар бара торган юллардагы барлык тимер юлларны, күперләрне шартлатып, ватып чигенгәннәр, миналар тезеп киткәннәр. Командование шуна күрә сугышчыларнын бөтен подразделениеләрен бергә җыеп, колонна белән җәяү җибәрде. Февраль аенын җилсез көне. Сугышчылар өстенә ябалак-ябалак кар ява, тирә-якта мәһабәт нарат урманы. Әхәтләр әкияттәге кебек көн бардылар, төн бардылар, бернинди привал, ял юк, өсләренә яуган карны хайваннар төсле селкенеп кенә төшерделәр дә, туктамыйча тагын бардылар. Сугышчылар арыдылар, аягүрә йоклап бара башладылар, йоклап басып калып булмый, арттан килүче төртеп җибәрә иде. Өч көн һәм төн бертуктамый баргач, сугышчылар ниндидер фермалар янына ялга туктадылар. Монда бик озын ике йөз ат сыярлык зур аран, сыер, сарык дуңгыз абзарлары, тавык кетәклекләре бар иде. Сарайлар уртасындагы калкулыкка сугышчылар килеп утырулары булды, немец самолеты парашют белән дүрт "лампа" элеп китте. Солдатлар кайсы-кая яшеренергә тотындылар. Әхәтләр түбәнгә, таш келәт эченә кереп качтылар. Мәхшәр башланды. Авыр артиллериянен снарядлары ат аранына һәм башка абзарлар өстенә төшә башлады. Мескен атлар арт аякларына басып, үзәк өзгеч итеп кешнәделәр, тавыклар котлары очып, кирелән ут эченә очып керделәр, дунгызлар чинады, сыерлар, сарыклар бакырды. Бөтен яктан пулеметлар атты, тирә-як тетенгә, утка күмелде. Кинәт атыш

тынды, Әхәт тәрәзәдән караса, фермага таба строй белән озын-озын немец автоматчылары килә. Болар яшеренеп торган келәттә бер командир да юк иде, бер бәләкәй буйлы өлкән сержант белән Әхәт солдатларны торгыза башладылар, әмма пулеметчылар да, минометчылар да йөзтүбән ятканнар, гырлап йоклыйлар, һичничек уятып булмады. Вакыт уздырып тормастан бу икәү, ике тәрәзәгә ике миномет корып, немецлар өстенә мина җибәрделәр. Көтелмәгән каршылыктан фашистлар югалып калдылар, бик күп солдатларын югалттылар, аннан соң чигенә башладылар. Сугышчылар бу кечкенә җиңүгә шатланырга өлгермәделәр, каршыларында танклар пәйда булды. Миналар чинавына яткан солдатлар да уянып, автоматларын көйли башлаганнар иде инде. Менә бер яшь кенә солдат, гранаталар бәйләме алып, шуышып, танкларга каршы китте. Ул танкны да шартлатты, үзе дә үлде. Теге танк кысрык җирдә өзек гусеницасы белән бөтерелеп алды да, юлны бикләп, туктап яна башлады. Башка танклар ферманы урап башка якка киттеләр, әмма монда тагын немец автоматчыларының икенче чылбыры күренде. Әхәт тагын минага үрелсә, миналар бетеп бара. Бар булганын кече сержант янына этеп куеп, Әхәт келәттән чыкты, караса, таш сарай янында җигүле ат пошкырып, колакларын шомартып, дилбегәсенә уралып тора, ездовое үлгән, җирдә ята. Арба артына бер сыер бәйләнгән, ә арба тулы сугышчыларга бу минутта бик кирәк булган миналар. Солдат йөгереп барып, атның дилбегәсен кисеп атты да, йөгәненнән тотып келәт ишеге төбенә алып килеп, миналарын бушатты. Ике миномет алыш-тилеш таң атканчы аттылар. Яктыра башлап, күрше подразделениедан пулеметлар, минометлар атарга тотынгач, немецлар ниһаять тындылар. Күрше частьның командирлары килеп: "Әле дә сезнең минометчикларыгыз булды, алайса немецлар безне ике яклап чолгап алалар иде",—дип, мактап китте. Әмма үзләренең командирлары аларның бары икесенең генә җиде арбаның миналарын атып бетереп, шундый зур көчләрне төне буе тоткарлап торуларына әһәмият бирмәде.

Каты сугышлардан соң Әхәтләр тагын алга киттеләр, әмма бу юлы аларның колоннасы бик нык сирәгәйгән иде. Юлда бер-ике тапкыр тагын немецлар белән чәкәләшеп алдылар. Үз өенә якынлашкан саен фашист ныграк усаллана, һәрбер авыл, һәрбер йорт өчен каты сугыш алып бара иде. Бер көнне немецлар белән атышып туктагач, Әхәт янына өлкән лейтенант килде:

—Иптәш Кадыйров, бу юлы частьта зур югалтулар булды, кешеләр бетте, хәтта штаб сакларга да юк. Менә бу урман артында хутор бар. Анда немецлар бик каты ныгытма корып, безгә каршылык күрсәтергә җыеналар. Иртәгә аларга өстәмә көчләр килеп кушылса, безне чолгап алып бетерәчәкләр, шуна күрә үлсәң үләсең, ун солдатны алып барып, төнлә шул хуторны туздырып кайтасың. Приказны үтәмәсәң сиңа да, миңа да—тугыз грамм кургаш!!

Әхәт илле мина, бер миномет алып, ун солдат белән урманга юнәлде. Урман эчендә калын кар ята, бассаң, аста су. Киез итекләр эченә карлы су кереп солдатларның аякларын чылатты, киптерергә бер җай да чыгарга охшамаган. Урман читенәрәк чыгып, хуторны карасалар, ике катлы йортның барлык тәрәзәләреннән пулеметлар, миномет көпшәләре чыгып тора. Әхәт алты солдатны, миналарны бушаткач, кире урман арьягына җибәрде һәм үзләренең чыкканын көтәргә кушты. Немецлар нидер сизенеп, утыз солдатны разведкага җибәрде. Әхәткә күп уйланып торырга вакыт калмады, тиз генә минометны көйләп, хуторга табан бер-бер артлы илле минаны яудырдылар да, тиз генә урманга качу ягына чаптылар. Тик миналардан башка ничек җиңел булмасын, калын карга бата-чума бик тиз йөгерү барып чыкмады. Немецлар тиз генә исләренә килеп, кызыл ракета

аттылар. Кызыл ракета—барлык кораллардан дошманга атарга дигән сүз. Безнен сугышчылар кар эченә чумдылар. Тын да алмыйча шушы юеш кар эчендә күп сәгатьләр утырдылар. Кар гына аларны саклап кала алмаган булыр иде инде, немецларнын артык якын булулары коткарды. Снарядлар боларнын артында, урман эчендә ярылдылар, жир өсте пружиналы матрас кебек селкенеп торды. Тан атты, сугышчылар кузгалмыйча ятуларын дәвам иттеләр. Әхәтнең аяклары әллә кайчан юешләнгән иде инде, кар эчендә ята торгач шинеле дә бер яктан лычма булып юешләнде. Алар ачыктылар, бигрәк тә тәмәке тартырга тилмерделәр, чөнки әз генә селкенеп үзенне белдерсән, немец снайперлары хәзер ата башлый иде. Кичке эңгерне сугышчылар шулкадәр көтеп алдылар ки, бөтен сугыш дәвамында да шундый куркыныч озын көн булганы юк иде кебек. Карангы төшкәч, бер йөгереп, бер карга чумып, сугышчылар урманга кереп, сул яктагы ачыклыкка юнәлделәр. Хутордан аларнын кыймылдаганын сизгән немецлар минометтан, пулеметтан ата башладылар, әмма, бәхеткә каршы, алар безнен солдатлардан бераз сулгарак аттылар. Болардан котылып, сулга, урман читенә килеп житсәләр, анда бер кечкенә бистә булып, эче тулы немец техникасы, солдаты икән. Карангыда аларнын сөйләшкәннәренә кадәр безнен сугышчыларга ишетелеп торды. Әхәтләр кире урманга керсәләр, анда төрле яклап фашистлар кереп тулган, кыскасы—дүрт якта да дошман. Сугышчылар берәр метрлы утын әрдәнәсен очратып шуны ишеп, астына миномегларын яшерделәр. Әхәтнен өчпочмаклы немец плащын дүртәүләшеп бөркәнделәр дә, бер нарат төбенә чүмкәеп туйганчы тәмәке тартып алдылар. Яшь кенә яна солдат кулындагы сәгатен Әхәткә күрсәтеп: “ Иптәш кече сержант! Хәзер сәгать 6 тула, яктырганчы берәр котылу юлын эзлик. Көндез безне бу фашистлар эләктерәчәкләр бит. Алар хәзер әсирлеккә алмый, Германиягә жибәрми, күзләрне чокып жәзалап үтерә”,—диде. Әхәт иптәшләренә карады. Алар барысы да арыганнар, манма су, янаклары эчкә баткан, әмма өчәүләшеп өмет белән ана карыйлар, ни кушса, шуны эшләргә әзерләр. Сугышчылар башта плащ-палаткага барлык коралларын жәеп салдылар: ике Ф1 гранатасы, дүрт автомат, ике запас автомат дискысы бар икән. Әхәт гранаталарны үзенә алды, патроннарны тигезләп дүрткә бүлде. “Хәзер,—диде ул пышылдап,—минем команданы тынлагыз. Сигезәр метр ара калдырып, карга сузылып ятыгыз. Немецлар якынлашканчы, тавыш чыгармагыз, мин ата башлагач, баш күтәрмичә генә кыска чират белән атыгыз. Мин граната ыргыткач, бар көчегезгә “ур-ра” кычкырып, өсләренә чабыгыз. Исән калунын башка юлы юк”.

Немецларнын зур бер төркеме коралларын бер жиргә өеп тәмәке тартырга, ял итәргә туктаганны гына көткән Әхәт автоматтан ата башлады, ана иптәшләре кушылды. Урман эчендә ату тавышлары янгырап, зур отряд һөҗүм иткән тавыш чыкты. Шул арада Әхәт, жаен туры китереп, гранатасын ыргытты, тик авыр юеш кием унайсызлаганга күрә, граната якында ярылып анын үзенен ботын яралады. “Урра!” кычкырып чапкан иптәшләренә карап, Әхәт ботын пешереп аккан канга да карамастан, кызулык белән ата-ата немецларга таба йөгерде, икенче гранатасын баскан килеш турырак ыргытты. Менә бер заман алда, урман читендә немецлар кулларын күтәреп тора башладылар. Болары ниндидер өшәнгән, сакал-мыек баскан, ябык карачкылар иде. Бу немецлар башларына шакмаклы юрганнар ураганнар, барсынын да зәнгәр күзләре “шыелдап” тора иде. Безнен дүрт сугышчы боларны колоннага тезеп, кулларын күтәртеп, үзебезнен якка алып киттеләр. Үзебезнен гаскәрләр торган хуторга якынлашып килгәндә, боларга үзебезнекеләр ата башлап, бер солдатны яраладылар, берсен үтерделәр. Әхәт тиз генә ятарга команда бирде дә, татарчалап: “Нурсиев

(анда шундый фамилияле казах бар иде), күзен чыкканмы әллә, тукта, атма. Мин бит Кадыйров",—дип, бар көченә кычкырып җибәрде. Теге казах каушап калды: "Мин танымадым. Киленнәр, атмыйбыз",—дип кычкырды. Ягалы сугышчыны бәйләп, үлгәнен плащ-палатка белән сөйрәп, сугышчылар басып үзебезнен якка киттеләр. Хуторга ниндидер утыз метр калгач, карасалар, яңа килгән пополнениенын дары да иснәмәгән яшь солдатлары, ике катлы йортнын чардак тәрәзәсен ватып, пулеметны аларга каршы көйләп азапланалар. Нурсиев болардан алда чабып: "Болар безнекеләр, атмагыз",—дип, кулларын бутады. Теге уңны-сулны анламаган нәрсәләр янына менеп, "максим"нарын кирегә бормыйча булмады. Әхәт хуторга кергәч, иптәшләренә әсирләрне сакларга кушып, рота командиры янына китте. Рота командирын ул бер таш йортта тапты. Командир өстәл артында башын иеп утыра иде, Әхәтнен кергәнен сизмәде дә. "Товарищ старший лейтенант! Сезгә мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез! Заданиегез үтәлде, тагын унике немецны әсир иттек",—диде. Лейтенантнын реакциясе көтелмәгәнчә булды. Ул әкрен генә Әхәткә таба борылды да, каптырмасын ычкындырып наганын чыгарып сугышчынын мангаена төзәде: "Сезгә,— диде ул дәһшәтле пышылдап, унике сәгатьтән кайтырга кушылган иде. Сез анда ике тәүлек нишләп яттыгыз? Мин сине боерыкны үтәмәгән өчен үз кулларым белән атып үтерәм." Монын ише җүләрләрне күп күргән Әхәт каушап калмады, автоматын тегенен башына төбәде дә: "Без анда ике тәүлек ашамыйча-эчмичә чолганышта яттык, сугыштык, унике фрицны әсирлеккә алып кайттык, ә сез шунын өчен мине атарга җыендыгызмы? Менә миндә магазин тулы житмеш бер патрон, чакмага бассам, нәрсә буласын беләсезме?"—дип, әшәке тавыш белән аңа каршы акырды. Командир автомат күргәч, айнып китте, Кадыйровны сөзеп карады да наганын кире кобурасына тыгып куйды. "Әйдә,—диде ул—күрсәт пленныйларынны! Әгәр дә мәгәр алдаган булсаң, шундук үзенне атам". Чыксалар, ни күрсеннәр, сугышчылар теге немецларны чишендергәннәр, коры аяк киемнәрен үзләре киеп яталар, әсирләр яланаяк карда басып торалар. Рота командиры Әхәтне батальон командиры янына алып китте. Сугышчы анда үзләренен ничек сугышып, чолганыштан чыгуларын сөйләп бирде. Комбат писарьны чакырып, Әхәткә Кызыл Йолдыз орденына боерык язарга кушты. Тагын бер айдан штабка чакыртып, орденны Әхәткә тагып җибәрделәр.

Әхәтләр авыр сугышлардан соң Көнчыгыш Пруссиягә барып җиттеләр. Рота командиры яна кеше иде, ул Әхәтне син олы кеше, яшьләр белән җәяү баруы авыр булыр дип, үлгән ездовой урынына куйды. Сугышта үзүзенне каравы да авыр, ничек атны карармын дип, Әхәт бик кайгырды, әмма командир боерыгына буйсынмыйча булмый, сугышнын кануннары каты. Аты әйбәт, тынлаучан булса да, арбасы бик иске, йөз кат ямалган. Шул арбада ни генә юк: ломнар, тимер мичләр, сабыннар, гранаталар һәм башкалар. Ул әйберләр таулы-чокырлы юлда коелалар, аларны Әхәткә җыярга кирәк. Юлда өч көн ат эчерергә су булмады, ашатуны әйткән дә юк. Әз генә тукталып җыелып торсалар немецлар шундук ата башладылар. Бер урман янына тукталгач, сугышчыларга окоп казырга боерык булды, ә Әхәтнен вакыты юк, ул ниндидер коелган арыш көшеленнән шинель итәгенә тутырып атына ашарга алып килде. Ат, мескен, ашлыкны минут эчендә суырып кына алды. Атны туарып ашлыкны туйганчы ашаткач, Әхәт су табып малкаена эчерде. Атнын корсагы тулды, күбенә күрмәсен дип, солдатнын коты очты. (Тик ат сыер түгел, күбенгәнче ашамый икән). Икенче көнне минометчылар белән болар алга киттеләр, юлнын кырыенда чокырлы су һәм чәнечкеле тимерчыбык. Әхәтнен аты нигәдер бик әкрен бара башлады, барган саен дугасы тарайды, ат авыр сулады. Әхәт арбадан бөтен кирәкмәгән

тимерләрне ташлады, атка жинеллек килмәде, дуга сынардай булып тарайды. Ул арбадан төшеп караса, аста арба кендегенә дүрткырлы тимерчыбык эләккән дә, әллә кайдан ук сөйрәлеп тартылып бара икән. Көчкә тимерчыбыкны ычкындыргач, атның дугасы җәелеп, арба жинеләеп китте. Әхәт ашыгып үз ротасын куарга тотынды. Минометчыларны, пушкаларны уза торгач, үзләренең батальонын мең җәфалар белән эзләп тапты. Хәзер болар бара торган юл урман эченә борылды. Урманны немец бертуктаусыз утка тотты, керсәң, исән чыгуың икеле иде. Берзаман снарядлар юл өстендә ярыла башладылар. Барлык сугышчылар да юл кырыендагы сулы каналга сыендылар. Әхәтнең атыннан ерак түгел снаряд төшеп ярылды. Ат снарядтан күтәрелгән балчыклы тәтенгә пырхылдап карап торды да хуҗасына борылды: "Мина котылырга җай юк, син ярый ла качтың",—дигән төсле булды. Атны җәлләүдән Әхәтнең йөрәккәйләре өзелеп төшә язды. Ул сикереп торды да атны бар көченә куалап, урман аша бер бистәгә алып килде. Ике катлы таш бина янында күп кеше җыелып тора иде. Әхәтнең аты дулап чапканга, хуҗасы аны туктата алмады. Илле метрлап чабып баргач, авыр снаряд артка, җыелып торган теге кешеләр өстенә төште, бер атны урталай өзде. Ат әле басып тора алгы аякларында, арт саны юк, аннан соң башын һавага күтәреп сулыш алды да егылып үлде. Әхәт янындагы старшинаның бер күзен немец снаряды кыйпылчыгы стенага чәпәде, бу күренешне ул картайганчы оныта алмады. Атны тынычрак җиргә куярга тырышып, хуҗасы берәр сарай эзләде, бер сарайга снаряд төшеп чокыр ясаган, икенчесендә яралы солдатлар канга батып яталар иде. Әхәт яралыларның капчыкларыннан бинтлар алып, сугышчыларның яраларын бәйләде. Аларның кайберләре, бинт биргәч, яраларын үзләре дә бәйләде. Тагын алга бара торгач, ул шәп кенә таш сарай тапты, печәне дә, суы да бар. Тик монда да озак юанырга туры килмәде, якында гына немецлар дип, бер солдат кычкырып узды. Ике телефонист тиз генә чыбык сузарга керештеләр. Әхәт боларның телефоннарын алып, үзенең ротасына шалтыратты. Теге баштан старшина трубканы алып: "Кадыйров, тиз генә кил монда, азык-төлеккә барырга кирәк,—дип кычкырды.—Без передовойда",—дип өстәде.

—Алгы сызык монда, тиз генә немецларны куарга кирәк!—дип Әхәт прицелны, угломерны әйтеп торып, фашистларга мина яудыртты. Алты миномет немецларны кырып чыкты. Сугыш тынган арада Әхәт ротасына барып, старшинаны алып, азык-төлеккә китте. Немец шулхәтле көчле атты ки, старшина куркуыннан сикереп төшеп, траншеяга качты. Арбалы ат алга карап чапты. Әхәт караңгыда юлны ялгышып, немецлар ягына барып чыкты. Иртәнге эңгердә бер кибәнгә якынлашса, өч немец солдаты атларына печән йолкыйлар икән. "Пан, там Гитлер,"—дип, алар Әхәтне кире бордылар. "Гитлер плех, Чталин плех, пух-пух ни-ни,"—дип, тавыш чыгармаска куштылар. Болар мине кайчан атып үтерерләр икән дип көтте Әхәт. Бу ябык, кырынмаган солдатлар ишарәләр белән тартырга тәмәке сорадылар: "Дома такой, киндер такой,"—дип балаларының биеклекләрен күрсәттеләр. Алар бармаклары белән Әхәткә төртеп: "Киндер есть?"—дип сорадылар. Әхәт аларга бер бармагын күрсәтте дә, атын борып, иплэп кенә кирегә китте, немецлар атмадылар. Озак буталып йөргәч, ул полк кухнясыннан ашарга алып килеп, сугышчыларны сыйлады. Күп айлар шушы ат белән йөргәч, Әхәт ана нык ияләште, сугыш беткәч үзе белән Бөгелмәгә алып кайтырга җыенды, әмма бер сугышта атның муен тирәсенә пуля тиеп, аяк ягыннан чыкты, ярасы үләрлек тә түгел, әмма тиз генә төзәлерлек түгел. Яраларын кысып бәйләп, ашарына салып, хуҗасы аны бай гына ат абзарында калдырды. Су анда торбадан килә иде, бу ат шуны белеп эчергечкә борынын төртеп калды.

***

Каты сугышлардан соң Әхәт хезмәт итә торган батальонны башка подразделениеларга кушып бетерделәр. Карт солдат булганга, аны телефонист-элемтәче итеп билгеләделәр. Бу да бик авыр эш булып чыкты: аркага катушка, телефон асып, линиянең өзек урынын ялгарга пуля астына керергә кирәк. Ачыграк урын булса, немец элемтәчеләрне чүпләп кенә торды. Башка сугышчылар ялга туктаганда, алар авыр катушкаларын асып, алгы сызык белән элемтә урнаштырдылар, анда телефон корып калдырдылар да башка роталар белән элемтә ялгый башладылар. Бөтен җиргә элемтә сузып кую белән ул кайдадыр өзелә дә, ял да итмичә, связист тагын чыбык буйлап китә. Шулай ялсыз-йокысыз элемтә урнаштырып йөргәндә, аның күпме яна иптәшләрен немец снайперының пулялары үтерде, Әхәт үзе дә шунда яраланды.

***

Госпитальдә дәваланып терелгәч, сугышчыларга ныгырга бер атна ял бирделәр. Сугыш вакытында ял итеп буламыни, Әхәт сулар, утыннар ташып, авыр яралыларны ашатып йөрде. Лазарет ишек алдында бер клубта яралыларга концерт куйдылар. Клубка бер яраланып гарипләнеп калган майор җитәкчелек итә иде. Әхәт карый: клуб эчендә бер плакат, лозунг юк. Ул майорга үзенең ярдәмен тәкъдим итте. Майор бик шатланды, тиз генә барып, госпиталь башлыгыннан Әхәтне өч көнгә клубка җибәрергә дигән боерык алып кайтты. Әхәткә кызыл материал, буяу, пумалалар кайтардылар, ул бик матур итеп ясады, язды. Майор тагын өч көнгә сугышчыны калдырырга бик нык ялынгач, госпиталь начальнигы теләмичә генә риза булды. Солдат лозунглар язып бетергәч, зур бер фанерага Европа картасы ясап, кечкенә флагчыклар белән Совет гаскәрләре азат иткән шәһәрләрне билгеләмәкче булган иде, вакыты бетте. Майор бу картаны бик ошатты, госпитальдән Әхәтне тагын өч көнгә калдырырга көчкә ризалык алып кайтты. Ике көндә сугышчы картаның эшен бетерде дә, Сталинның трубкасын кабып басып торган сурәтен ясый башлады. Тагын көн бетте, бернигә дә карамыйча, Әхәтне фронтка җибәрделәр, әмма унбиш километрлап узгач, артыннан килеп кире бордылар да, Сталинны ясап бетергәч кенә кире озаттылар. Майор солдатка күп рәхмәтләр укып калды.

***

Савыккач утызлап сугышчыны Гдыня шәһәренә җибәрделәр. Бик усал, бер колаксыз урысны өлкән итеп билгеләделәр дә, барлык документларны сугышчылар ана бирделәр. Барасы унбиш кенә чакрым булса да, бандитка охшаган колаксыз белән алар бу юлны ике атна үттеләр. Башта ук колаксыз каршыга килүче машинаны туктатып, үзләрен кире яктагы шәһәргә илттерде. Анда барып төшү белән шәһәр комендантурасына кереп, үзләренә кунарга бүлмәләр һәм ашау-эчү таптырды. Комендант боларны мосафирханәгә урнаштырып поляклардан ашарга ташытып, юлламаларына мөһер сугып, көчкә котылды. Аннан соң башка көннәрдә дә, бүтән шәһәрләрдә, яисә авылларда шул ук хәл кабатланды. Шулай килеп сарып, үз башларына мажаралар эзләп, унбиш чакрымны унбиш көн уздылар. Үзләренең частьларын эзләп тапкач, икенче көнне үк Гдыняны немецлардан чистарта башладылар, бик каты сугыш булды. Ике көн дигәндә фашистларның 5000 солдаты әсир ителде. Балтыйк дингезе янында утырган шәһәр бирелде. Дингез эчендә чалгыга охшаган Косагон дигән утрауда немецларның еракка атучы туплары булып, аларны бомбага тотарга егерме биш самолет очып

килде. Һәр биш минут саен бер самолет очып барып, бомба ташлады, утрау су астында калды. Шунда ук дингез эчендә яртылаш баткан немец корабы бар иде. Әхәтне бер солдат белән шул корабка тирә-якны күзәтергә постка куйдылар. Бер кеше постта торганда, икенчесе корабны яхшылап карап чыкты. Бөтен жиренә су тулган, ишекләре ачылмый, шулай да Әхәт бик әйбәт материалдан тегелгән ике байрак табып чыкты. Беренче эш итеп байракларны кисеп, сугышчылар үзләренә чолгаулар ясап, аякларына чорнап та куйдылар, аннан соң алмаш-тилмәш постта тордылар. Төннең бер вакытында Балтыйк дингезе ягыннан көймәләргә утырып килгән ике йөзләп солдат күренде. Нишләргә? Ике мылтык белән бу кадәр кешегә каршы тору мәгънәсез бер үлем! Әхәт такталар өстеннән ярга, телефонистлар янына чапты. Тиз генә тревога күтәреп, бөтен орудиелардан дингезгә аттылар. Прожекторлар яктысында Әхәт су өстенә караган иде, дингез өсте кып-кызыл кан, теге немецларны кырып салганнар. Иртәнгә кадәр сугыш тынмады. Иртән политрук барлык сугышчыларны тезеп, соңгы хәбәрләрне укыды: Совет гаскәрләре Берлин өчен сугышалар, немец каты каршылык күрсәтсә дә, безнекеләр жинеп баралар. Барлык сугышчылар да шатландылар, кулларында нинди корал бар, шулардан күккә аттылар. Боларның атыш тавышына Гдыня халкы: "Немецлар килделәр, русларга һөҗүм иттеләр",—дип куркып, балконнарыннан ак флаглар чыгарып элделәр.

Сугыш тынгач, сугышчылар шәһәр карап йөрделәр: бар нәрсә ватык, жимерек, паровозларны бер жиргә эттереп өйгәннәр, Украинадан ук шпалларны кармак шикелле тимер белән эләктереп, сабан сөргән төсле итеп ваттырып килгәннәр, паровоз артына ике кеше бастырып бронебойный пулялар белән рельсларны атып, ваклатканнар. Фашистларның явызлыкларын сөйләп, аңлатып бетерешле түгел: торбалары гына калган янган авыллар, концлагерьларда җәзалап үтерелгән солдатлар, жимерелгән күперләр, шәһәрләр—болар барысы да Әхәтнең күз алдыннан гомер буе китмәде.

### Берлин

Гаскәр соңгы юл итеп Берлинга әзерләнде. Сугышта снаряд тиеп тишкәләнгән машиналарны рәтләделәр, кузовка эскәмияләр тезделәр; солдатлар, киемнәрен юып, ямап, төймәләрен тактылар. Автоколонна юлга кузгалды, машиналарны алга кудылар да кудылар.

Шыплап тулган кузовларның бортлары көймәнеке төсле як-якка бөгелеп чыкты. Әхәт борт буена утырган иде, сыгылып торган такталар менә шартлап сынам, менә сынам дип бара башлагач, куркудан нишләргә белмәде. Янында утырган тыңкыш Бычков бераз булса да эчкәрәк чигенергә теләмәде:

—Нигә кайгырасың, иртәгәме-бүгенме барыбер барыбызга да үләсе,—диде. Әхәт берничә тапкыр әйтеп караса да, Бычков кирегә катып тик утырды. Бу солдатларның кыбырсып утыруларын кече лейтенант күреп барган икән. Ул Бычковны Әхәт урынына утыртты. Шулай бераз барганнан соң Бычков:

—Туктатыгыз машинаны, монда бик куркыныч,—дип шаулый башлады.

—Сиңа барыбер түгелмени, йә иртәгә, йә бүген барыбызга да үләсе,—диде Әхәт.

Бу сүзләрдән солдатлар дәррәү көлешеп алдылар. Бычков ачуыннан кызарды.

—Синнән Кадыйров дүрт тапкыр күчүеңне сорады, нигә син күчмәдең,—

дип кече лейтенант аның авызын япты.

Бара торгач, "Берлинга кадәр кырык чакрым" дигән табличка күренде, шартлау тавышлары ишетелде. Колоннаның алдагы машиналары унга, урманга таба борылдылар, алар артыннан калган машиналар да урман эченә юнәлделәр. "Бер кашык аш ашар өчен нигә шул хәтле урманнарга кереп торырга инде,"—дип уйлады Әхәт, ялга туктыйбыз дип белеп. Әмма бер дә ул уйлаганча булып чыкмады. Тиз арада коры-сары гына капкаладылар да, сугышчыларны кайсын кая постка бастырдылар, коралларны, минометларны көйли башладылар. Әхәтне урман читенә юл буена постка куйдылар. Көн кояшлы аяз, юл читенә утыртылган груша, алмагачлар шау чәчәктә. Әхәтнең колагына ерактан килгән поезд тавышы ишетелде, ана ул туган якка кайтып бара төсле тоелды. Күңеле тулып солдат елап җибәрде:

—Менә Берлинга барабыз, анда немецлар тагын нинди хәйләләр корып яталар инде, әллә исән калабыз, әллә юк. Ник сугышның башында ук үлмәгәнмен, хәзер үлүләре шундый үкенечле,—дип, такмаклый-такмаклый үкседе Әхәт.

Якында гына бер чуаш солдаты тора икән. Әхәт аның янына килде дә: "Сез кайсы частьтан, машиналарыгыз бигрәк күп?"—дип сорады.

—Әүвәл бу часть штрафной батальон иде, хәзер техника өстәделәр дә мото-механизм хәрби частена әверелде. Бу частьта озак йөри алмыйсың, болар фронтны өзеп кереп китәләр дә, яртысы гына исән кала, пополнение алып тагын фронт өзәргә кереп китәләр,—диде чуаш.

Бу сүзләрдән соң Әхәт тагын да курка калды. Шулай үз уйларына чумып утырганда телефонист кычкыра башлады:

—Кемгә лагерь турында әйтим икән?—диде.

Әхәт шыпырт кына телефонист янына килде дә:

—Нишләп сугыш вакытында лагерь дип бар дөньяга кычкырасың?—диде ул, усал итеп.

Теге телефонист эчтән дә, тыштан да көлеп Әхәткә шыпырт кына:

—Югары командование беләсеңме нәрсә хәбәр итте? Нинди подразделение кайда урнашса, шунда лагерь төзеп, землянкалар казырга диделәр. Сугыш бетә торгандыр.

Ул да түгел, телефонистның сүзләрен раслап, халыкны землянка чокырга куштылар. Солдатлар күтәренке рух белән эшкә керештеләр, озын колаклар чыш-пыш кына сугыш беткәнен хәбәр итә башладылар. Шунда Әхәт сикереп торды да дүрт ел начар землянкаларда яшәп интеккәннәрен исенә алып, үзенчә яхшы землянка проектлаштырырга уйлады. Кәгазь кисәгенә сызым ясады да рота командирына илтеп күрсәтте.

—Командир, ишексез тишекләрдән йөрү туйдырды. Бу землянканы менә шулай ясыйк әле,—диде Әхәт.

—Бик яхшы бу. Бар, үлчәп күрсәтеп бир, прораб булырсың,—дип, командир Әхәтне мактап җибәрде.

Солдатлар көне буе казыдылар. Кайберәүләр агач ташып, баганалар утырттылар. Землянканың яртысын ясап бетергәч, комсостав тикшереп йөри башлады. Кайбер землянкалар кар базы кебек, кайберләре печән кибәне төсле итеп ясалганнар. Бу комиссия Әхәтләр турына килеп җиткәч, землянканың ясалыш проекты белән кызыксынды. Солдатлар, моны безнең баш инженерыбыз ясады дип, горурланып әйттеләр. Бер атнадан Әхәтләрнең роталарына дивизия командиры үзе килеп, анарга бөтен дивизиянең землянкаларын бертөсле итеп проектлап, карап торып ясатырга кушты. Комрота карышып караган иде дә, анардан сорап та тормадылар. Әхәт әйбәтләп бау белән тигезләп, бер рәткә тездереп, кечкенә шәһәрчек кебек итеп, землянкаларны төзетте. Сугыш вакытында мондый

иркен, якты жирдә яшәмәгән солдатлар кырынып, мунчалар кереп, кеше төсенә керделәр. 9 май көнне иртәнге аштан соң сугышчыларны аланга тезеп, бер шадра майор сугыш беткәнне әйтте. Солдатларның шатлыгы эчләренә сыймады, алар урра кычкырдылар, коралларында булган барлык патроннарны һавага аттылар, кочаклаштылар, жылаштылар. Әхәт сугыш бетеп үзенең исән калуына ышанмыйча торды: күпме михнәтләр, үлем белән күзгә-күз очрашырга туры килде ана! Ул инде берәр заман кайтып туган ягын, гаиләсен күрермен дип уйламый да башлаган иде. Үз өенендә фашист бигрәк зәһәрләнеп каршылык күрсәтте шул. Жиңү!! Бу бәхетле көнне дә күрер көннәр бар икән! Әхәт тыныч кына иптәшләренең кыланышларын карап утырды. Менә сугышчылар немецлардан калган бер вагон яктырткыч ракета таптылар да, шуны әрҗәләп ташып, төне буе атып чыктылар. Тик уеннан уймак чыгаручылар да очрады, ракета ялгыш төшеп, йоклаганда янып үлүчеләр дә булды.

Сугыш бетте дип боларны тиз генә кайтарырга уйламадылар әле, шуңа күрә землянка шәһәрчеген тагын да матурлап бизәп куйдылар. Әхәт үз землянкалары каршысына даһи Сталинның басып төшкән рәсемен бер журналдан күчереп ясап куйды. Сугышчылар карап, тел шартлатып: “Бар икән дөньяда оста куллы кешеләр”,—дип киттеләр. Бер көнне, машинада узып барышлый бер генерал туктап, рәсемне кем ясавы белән кызыксынды. Компрота бу сорауның жүнлегә бирелмәгәнен белеп: “Бер солдат ясаган иде, Берлин өчен сугышларда үлеп калды”,—дип котылмакчы иде, булмады. “Бу рәсем әле яңа ясалган, ялганламагыз! Кая, китерегез рәссамны! Курыкмагыз, мин аны вакытлыча гына алып китәм”,—дип Әхәтне үзе белән бер бай хуторга алып китте.

Бай хутор гел кирпечтән салынган сарайлардан тора иде. Хужалар яшәп торган өй ике катлы, кызыл кирпечтән салынган, түбәсенә кызыл чирәп ябылган. Әхәтне сөт эшкәртә торган сарайларның берсенә урнаштырдылар. Ул бүлмәне себереп чистартып, рәсем ясарга өстәлләр кертеп куйды. Икенче көнне комсостав утырган машинада ул да кырык чакрым ераклыктагы Берлинга буяулар, пумалалар алырга китте. Юл буйларында кыргый алмагачлар, грушалар үсеп утыра. Сугыш үткән булуга карамастан, Берлин бик чиста шәһәр иде: йортлары кызыл кирпечтән, түбәләре кызыл балчыктан ясалган кечкенә чирәпләр белән ябылган, өйләр каршындагы вак агачларны кыркый-кыркый лампочка төсле формага кerткәннәр. Йортларның диварларын вак яфраклы үрмә гөлләр каплаган. Әхәт немец хәрефләрен латин алфавитына охшатып, таныш түгел вывескалар укый-укый, берәр остаханә эзләп китте. Хәрефләре таныш булса да, сүзләренең берсе дә аңлашылмый иде. Әхәт көртлекләр ясалган ишектән кереп, бик бай остаханәгә туры килде. Хужасы да, кибетчесе дә булмаган бу урыннан Әхәт үзенә кирәк хәтле буяулар, пумалалар алып, кире үзе килгән якка, машина янына китте. Командирлар жиңү хөрмәтенә бәйрәм ясап, солдатларга да зур, ике йөз литрлы мичкә белән спирт алып кайтып киттеләр. Сугыш бетсә дә, шәһәрдә сирәк кенә ату тавышлары ишетелә иде әле. Әхәт хуторда төрле лозунглар, командующийларның портретларын, Сталин рәсемнәрен ясады.

Сугыш беткәч, аларны Германиядә бик озак тотмадылар, Белоруссиягә кайтардылар. Анда биш ай торгач, демобилизация башланды, беренче чиратта олы яшьтәге солдатларны кайтарып жибәрделәр, аннан соң Әхәтләргә чират житте. Дүрт ел да алты ай хезмәт итеп, бөтен Европаны солдат итеге белән таптап, ул исән-сау туган ягына кайтып китте.

Фирдания
Гыйлфан

# АККОШТАЙ КАГЫНЫП...

## Кемдер айга менә...

Өметләрем, саф хисләрем белән
Кайгыларны таптап үтәмен.
Салам ишкәк, кәгазь көймә белән
Сагыш диңгезендә йөзмәмен...

## Тибрәтәмен каләм

Шигырь язу—мавыктыргыч шөгыль,
Төгәл хаклык, тәнкыйть, изге хис.
Чын сөюсез шигырь—зәвыксыз ул,
Айсыз булган кебек язгы кич.

Таһир-Зөһрәләрдәй сөям дисәм,
Яратырга юк бит ярларым.
Сагышларын сөйли бәхетсезләр,
Шигыремдә мәгънә өсти сыман
Киләчәгем, үткән таңнарым.

Хыял белән өмет гел янәшә...
Яшәү көчен бирә өметем.
Канатланып, чын бер шагыйрьдәй
Каләм тибрәтәмен көн вә төн.

## Гомер юлы

Хак дөньяга бер килгәнбез икән,
Ә нигә соң ташлап китәргә?
Мәңгелеккә иркен юллар табып,
Мин телимен гомер итәргә.

Аңлый белсәң, дөнья нинди иркен,
Иксез-чиксез галәм-дәрьялар!
Океаннарның саны-хисабы юк,
Тайга, чүлләр һәм тау-кыялар...

---

Фирдания ГЫЙЛФАН—*шагыйрә; "Гомер юлы" исемле китап авторы. Казанда яши.*

Ләкин һаман нидер бүлешәбез,
Сәбәп табып, сугыш ачабыз...
Хак газраил килеп баскач алга,
Булдыра алсак, аннан качабыз.

Котылсак та үлем тырнагыннан,
Күңелләрдән китми кырыслык...
Бу дөньяда озак яшәүләрнең
Төп сәбәбе—хаклык, тынычлык.

Күңелемне гел бер сорау били:
Гомер юлын ничек үтәргә?
...Мәңгелеккә иркен юллар ярып
Мин телимен гомер итәргә.

## Төшләр хакында

Мин берәүгә шулай сорау бирдем:
"Нигә, димен, төшләр күрәбез?"
—Баш миендә уйлар тоткарлана,
Шул уйларны төштә күрәбез.

"Үлгән җаннар нигә төшкә керә?"
—Җаннар үлми—күккә ашалар...
Бар галәмне, үткән, киләчәкне
Читтән күреп алар качалар.

"Фәрештәләр нигә төшкә керә,
Юлыкмагыз,—диеп,—ялгышка?"
—Киләчәкне алдан күрә торып,
Каршы килмәгез, дип язмышка.

"Мин төшемдә ак күгәрчен күрдем,
Бу төшемне ничек юрарга?"
—Киләчәгең бәхетледер,—диде,
Бәхет эзләп чык син юлларга.

## Әрсез кычыткан

Кычыткан әрсез һәм чорсыз,
Кая тели шунда үсә.
Орлыкларын чәчә-чәчә
Бакчалардан кырга күчә.

Гаскәр кебек тезелешеп,
Каплап ала кырны, юлны.
Үрелдеңме, өзим, диеп,
Керпе кебек чәнчи кулны.

Шифалы һәм зифа буйлы,
Тылсымлы да, мәкерле дә.
Өтеп ала аяк-кулны,
Калдыра шул хәтерне дә.

Өлгер үзе, сизгер үзе—
Иналәре саклый аны.
Әллә, дуслар, кычытканның
Кеше сыман микән җаны?



Данил
Салихов

# ТАШ САНДЫК

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ САТИРИК КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**
Мөстәкыйм
Йосыф Исхакович.
Суфия—Йосыфның хатыны.
Нуркасыйм
Миңлениса—Нуркасыймның хатыны.
Касыйм Сабирханович
Вил Вилданович
Сан Санович
Гали Вәлиевич
Вәли Галиевич
Сәли Садриевич
1нче милиционер
2нче милиционер
1нче санэпидстанция кешесе
2нче санэпидстанция кешесе
Биюче кызлар...

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*Пәрдә ачылганда Мөстәкыйм фатирының ярлы гына җиһазландырылган бүлмәсе. Гадәттәгечә, уртада өстәл, берничә урындык, кыршылган диван һәм дә ки башкалар.*

*Мөстәкыйм диванда гырлап йоклап ята. Бүлмәгә ашыгып Касыйм Сабирханович, аның артыннан Вил Вилданович, ак халатлы туташ, ике милиционер керәләр.*

Касыйм Сабирханович *(сәгатенә карый).* Сезгә унбиш минут вакыт. *(Мөстәкыймгә төртеп.)* Бу имгәкне тиз арада рәткә китерегез. Кырындырыгыз, юындырыгыз, киендерегез, бу дуңгыз абзарын рәткә кертегез!

1нче милиционер, 2нче милиционер *(үрә катып).* Есть! Иптәш Касыйм Сабирханович! *(Мөстәкыймне ике яктан эләктереп алалар да ванна бүлмәсенә өстерәп алып кереп китәләр. Алар артыннан ак халатлы ханым да кереп китә.)*

Вил Вилданович. Органнарда егерме биш ел эшләп, һич кенә дә башыма сыймый. Гарәп илчеләре ни өчен

Данил САЛИХОВ (1958) — *драматург; төрле театрларда куелган купсанлы пьесалар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

бу фатирда очрашуны кулайрак күрделәр икән?

Касыйм Сабирханович. Үзем дә аптырыйм. Ныклабырак кара әле, Вил Вилданович, адресны бутамадыгызмы ?

Вил Вилданович *(папкасыннан кәгазь чыгарып).* Менә, минем күзләремә ышанмасагыз, үзегез укып карагыз. *(Кәгазьне Касыйм Сабирхановичка суза.)*

Касыйм Сабирханович *(укый).* Шулай шул. Казан каласы. Яна бистә, "Татарлар шатлыгы" урамы, жиденче фатир, Мөстәкыйм әфәнде, Исхак улы фатиры. Гарәбстаннан, диелгән.

Вил Вилданович. Шаихка бу сасы көзән нигә кирәк булган.

Касыйм Сабирханович. Йоклыйсыз, иптәш Вил Вилданович, йоклыйсыз. Ярты сәгатьтән гарәп самолёты Казан аэропортына килеп төшә. Ә сез гарәп илчеләренең ни өчен килгәннәрен дә белмисез. Сагынам тегे заманнарны, ай, сагынам. *(Кесә телефоныннан номер жыя.)* Әй сез, кая олактыгыз? Тизрәк булыгыз! Вакыт кыса. Нәрсә!? Ишек төбендә пычак калганмени сезгә. Бирегә кирәгез! Нәрсә...? Кертмиләр....? Кемнәр...? Мәскәүләр...? Бишенче отдел..? *(Вил Вилдановичка.)* Нәрсә, Мәскәүләр килеп тә життеләрмени?

Вил Вилданович. Һич нишләп булмый. Без Мәскәү контролендә.

Касыйм Сабирханович *(телефонын Вил Вилдановичка суза).* Мә, имгәк. Мәскәүләргә әйт. Минем кешеләремне кертсеннәр.

Вил Вилданович *(телефоннан.)* Алло, алло... Трубканы Мәскәүләргә бир! Нәрсә, нәрсә?!. Мингерәү дим! Трубканы Мәскәүләргә бир, ангыра! Алло... Алло, пятыймы? Пятый отделмы, дим?.. Нәрсә?.. Что?! Кто?! Телевидениенең беренче каналы журналисты Василий Николаевич?.. *(Трубканы ала.)* Василий Николаевич, ди.

Касыйм Сабирханович. Төкерәм мин синең Василий Николаевичына. Тизрәк минекеләр керсеннәр!

Вил Вилданович *(трубкага).* Төкерәм мин аның!.. *(Аңына килеп.)* Ни тебе, ни тебе... *(Трубкасын колагыннан алып.)* Үтерәләр болар мине. *(Трубканы уч төбе белән каплап, пышылдап.)* Мәскәү телевидениесенең беренче каналы, ди.

Касыйм Сабирханович. Мина синең беренче каналың кирәкми! Мина менә шушы эт оясын рәткә салыр өчен, санэпидстанция хезмәткәрләре кирәк. Күземә күренмә! Бер аягың бирердә, икенче аягың беренче катта булсын.

Вил Вилданович *(үрә катып).* Есть! *(Чыгып чаба.)*

Касыйм Сабирханович *(бүлмә буйлап йөренә).* Ни өчен!? Кемгә-кемгә, гарәп иленә нигә кирәк булган бу фатир? Бу сәрхуш Мөстәкыйм белән гарәп иле арасында нәрсә ята?..

*Бүлмәгә защитный костюмнардан сиптерә торган аппаратлар күтәреп, авызларына респираторлар кигән ике кеше керәләр дә, бүлмәдәге һәрнәрсәгә пар сиптерәләр. Берсе Касыйм Сабирханович янына килә дә, аңа да пар сиптерә.*

Касыйм Сабирханович. Нишлисен, имгәк?

Санэпидстанция кешесе. Сезне стерилизовать итәм.

Касыйм Сабирханович. Итәрмен мин сина, имгәк! Ычкын яныннан. *(Үз-үзенә мыгырданып.)* Каян башларына килә.

1нче санэпидстанция кешесе. Сарымсак төнәтмәсе сибүме? Безнен башка каян килсен инде. Хужа, хужа башлы безнен.

2нче санэпидстанция кешесе. Беренче кварталда химикатларны сатып бетерә дә...

1нче санэпидстанция кешесе. Калган өч кварталга сарымсак суы гына кала.

2нче санэпидстанция кешесе. Сез әле бәхетле. Сезгә чистотел төнәтмәсе эләкмәде.

1нче санэпидстанция кешесе. Анысын атна буе мунча кереп тә тәннән юып бетереп булмый.

Касыйм Сабирханович. Хужагызга кайтып әйтегез. Касыйм Сабирханович өчегезне дә мунчага алып кереп стерилизовать итәм, диде, диегез. Гарәпләр генә китсен әле...

1нче санэпидстанция кешесе, 2нче санэпидстанция кешесе: *(икесе бергә).* Яхшы. *(Чыгып китәләр. Бүлмәгә эт талаган кыяфәттә Йосыф Исхакович һәм чалма-чапаннан Нуркасыйм Исхакович керәләр.)*

Нуркасыйм. Бу татарга бер жирдә

дә рәт юк. Үз туганына да керер хәл юк. Прямо өзгәлиләр. *(Үзенең тышкы кыяфәтенә карап.)* Кара инде. Кара, адәм мәсхәрәсе.

Касыйм Сабирханович. Нәрсә булды? Гарәп илчеләре янына бу кыяфәттә разве киләләр.

Йосыф Исхакович *(кулын сузып)*. О... Исәнмесез, Касыйм Сабирханович. Исән калу шатлыгыннан сезне күрми дә торам. Өзгәлиләр прямо. Журналистлар ишек төбен камап алганнар, бер алга, бер артка төшәләр. Бер төймәмне дә калдырмадылар.

Касыйм Сабирханович. Кемгә, кемгә, сезгә Иосиф Исакович, мондый кыяфәттә йөрү килешми. *(Булмәгә күрсәтеп.)* Энегезнең яшәү рәвешен карагыз. Дуңгыз абзарында яшәтәсез түгелме?!

Йосыф Исхакович. Әйтмәгез инде, Касыйм Сабирханович, әйтмәгез. Үзе дә дуңгыз, яшәеше дә дуңгыз. Аттан ала да туа, кола да туа икән. Югыйсә, бер ата, бер ана балалары инде. Бер авызына хужа була алмады. Юк, юньгә килми.

Касыйм Сабирханович. Димәк, тәрбия житми. Димәк, тәрбияләү системагыз дөрес түгел.

Йосыф Исхакович. Ничә тапкыр эшкә урнаштырып карадык. Өч көн эшкә чыга да, дөреслек эзли башлый. Дүртенче көнне куалар.

Касыйм Сабирханович. Дөреслек эзли дисең инде...

Йосыф Исхакович. Һәр нәрсәдән кер эзли..

Нуркасыйм. Өйләндермәкче булып тә карадык. Бай, унган, булган гаиләдән кыз да димләп карадык. Бай булса—ничек баеган, ди, хәерче булса—нишләп хәерче, ди.

Касыйм Сабирханович. Ярый. Мин сезнең зарларыгызны тыңларга килмәдем. Үз кайгым да хәттин ашкан. Менә моннан! Нигә сонга каласыз?! Нигә көттерәсез?!

Йосыф Исхакович. Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, безнең килгәнгә ике сәгатьтән артты инде. Кертмиләр бит. Кертмиләр.

Нуркасыйм. Прямо өзгәлиләр.

Касыйм Сабирханович. Нигә чакыртканымны беләсезме?!

Нуркасыйм, Йосыф Исхакович: *(икесе бергә)*. Юк, белмибез.

Касыйм Сабирханович. Белмисез шул. Менә мин дә белмим. Дөреслек эзләргә ярата дисез инде...

Йосыф Исхакович. Не то слово...

Нуркасыйм. Киребеткән, үжәт!

Касыйм Сабирханович. Анын янына хәзер биш минуттан гарәп илчеләре килә.

Нуркасыйм. Гарәп илчеләре?..

Йосыф Исхакович. Гарәп илчеләренә Мөстәкыймнең нигә кирәге чыккан ?

Касыйм Сабирханович. Менә анысын сездән сорарга кирәк инде.

Вил Вилданович *(килеп керә)*. Касыйм Сабирханович, төрле каналлар буенча аралашкан кешеләрен тикшереп чыктык, Гарәбстаннан бер кеше белән дә аралашмаган.

Касыйм Сабирханович. Менә шулай, Иосиф Исакович, сезнең эшләр харап.

Вил Вилданович. Сезнең нәселегез белән Мәскәүнең бишенче отделы кызыксына. Төрле илләрдән журналистлар, репортёрлар килгән.

Касыйм Сабирханович. Шулай, Иосиф Исакович, жиденче бабагызны исегезгә төшерә башласагыз да була.

Вил Вилданович. Кем сез?.. Атагыз кем булган?.. Бабагыз?.. Уйлагыз, уйла! Вакыт бик аз.

Касыйм Сабирханович. Өч катлы коттеджыгызны ничек салдыгыз?!

Вил Вилданович. Мерседесыгызны, хатыныгызның БМВсын ничек алдыгыз. Башка жирдәге байлыкларыгызны искә төшерегез.

Касыйм Сабирханович. Чит илләрдәге связьларыгызны....

Вил Вилданович. Бигрәк тә гарәп илләрендәге элемтәләрегезне...

Касыйм Сабирханович. Сезнең чын исемегез ничек әле, Йосыфмы?

Йосыф Исхакович. Туган илемне, хөкүмәтемне, тынычлыгымны, илемдәге тәртипне саклаучы милиция органнары аша кабат-кабат тикшерелеп бирелгән төп документымда—паспортымда мин Йосыф түгел, ә киресенчә Иосиф. Телисез икән, Осип дип дәшә

аласыз, телегезгә жинел дип саныйсыз икән,—Хосе дия аласыз. Әмма ләкин мин Россия гражданины буларак горурланып, чын исемемне—Иосиф дип кабатлап әйтәм. Отчествома килгәндә, Исхак түгел, Исак. Минем Исхак улы Мөстәкыйм атлы кеше белән бернинди дә туганлык жебем юк.

Вил Вилданович. Бәлки сез үз-үзегезгә уйлап тапкан исем-отчествогыз ширмадыр. Бәлки гарәп иле белән сезнең күперне Мөстәкыйм атлы энегез тоташтырып торадыр?!

Йосыф Исхакович. Кабатлап әйтәм. Минем Мөстәкыйм атлы энем юк. Минем гарәп илләренә чыкканым юк. *(Нуркасыймга төртеп күрсәтеп.)* Менә бу чалма-чапаннан киенгән иптәштән сорагыз. Ул хажны бик ярата. Исеме дә Нуркасыйм, атасы да Исхак бугай. Ул гарәп илләрен бик ярата.

Нуркасыйм. Бу жөмләне мина адреслап бик ялгышасын, кем, энем Йосыф. Аталар өчен балалар жавап бирми. Татарда Исхаклар күп. Аннары күреп торасын, Мөстәкыйм белән минем арада охшашлык юк. Ул чандыр, мин... Ул—хәмер ярата, ә мин терпеть не могу.

*Урамда сирена тавышлары ишетелә.*

Касыйм Сабирханович. Булды. Булды, життте! Хватит! Разберёмся! Килеп життеләр бугай. Үз- үзегезне тәртипкә китерегез! (Юыну бүлмәсенә карап кычкыра.) Әй сез, кая олактыгыз! Жәһәтрәк булыгыз! Тизрәк чыгыгыз! Килеп життеләр.

*Юыну бүлмәсеннән ике размер зурырак костюм, күлмәк, муенына олы галстук таккан, олы туфлидән Мөстәкыйм, аның артыннан уң кулына сөлге аскан, сул кулына сиптерә торган грушалы одеколон тоткан ак халатлы туташ, ике милиция чыгалар.*

Ак халатлы туташ. Касыйм Сабирханович, объект әзер! Трусигына кадәр алыштырдык. Носки алып килергә генә онытканбыз. *(Мөстәкыймнен бөтен жиренә одеколон сиптерә).*

Мөстәкыйм. Носки булмаса да зыян юк. Чалбар озын, носки барыбыр күренми.

Касыйм Сабирханович. Нәрсә бу?!

Мөстәкыйм. Нәрсә түгел, иптәш. Мин бу, мин—Мөстәкыйм!

Касыйм Сабирханович. Нәрсә сон бу?! Нинди чучело, бакча карачкысы?!

Мөстәкыйм. Гаепләмә инде. Бар булганым шушы. Әткәй белән әнкәй ат чырайлы итеп яраткач, нишлим. Матурлыкны сорап алып булмый. Бар булганыма шөкер кылып яшим.

Касыйм Сабирханович. Хикмәт синең ат чырайлы булуында түгел, хикмәт син кигән киемдә.

Ак халатлы туташ. Гафу итегез Касыйм Сабирханович, сезнең ярдәмчеләрегез биргән размер буенча киендердек. Монда минем гаебем юк.

Касыйм Сабирханович *(Вил Вилдановичка).* Син нәрсә карадын?!

Вил Вилданович. Сез жибәргән карточка буенча, компьютер аша киендереп карап, размерын билгеләдек.

Касыйм Сабирханович. Размерын... Күзен чыкканмени. Дүрт размер зурырак костюм кидергәнсез!

Вил Вилданович. Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, менә сезнен безгә жибәргән анын сурәте, ягъни карточкасы.

Касыйм Сабирханович. Сезнен—безгә, безнен—сезгә *(Карточканы карап.)* Бу бит бу кеше түгел. *(Карточканы Йосыф Исхаковичка сузып.)*

Йосыф Исхакович *(карточканы карап).* Юк, юк, ул түгел, Касыйм Сабирханович.

Нуркасыйм. Кая, карыйм әле? *(Карточканы карый.)* Юк, ул түгел, Касыйм Сабирханович.

Мөстәкыйм *(фотоны ала).* Кая, үзем карыйм әле. Мин бу, мин булмый кем булсын. Шешенелгән, шешенгән килеш төшкәнмен. Но мин үзем тормышта болай ук түгел, вак сөякле мин.

Касыйм Сабирханович. *(Кесә телефоны шалтырый. Телефонны колагына куя.)* Әйе. Тынлыйм. Күтәреләләр?.. Яхшы. *(Телефонын кесәсенә тыга. Вил Вилдановичка.)* Бар. Каршы ал. Күтәреләләр.

Вил Вилданович *(честь бирә дә чыгып китәргә жыена).* Тукта әле, ашыкма. *(Нуркасыйм белән Йосыфка.)* Сезнең хатыннарыгыз кайда?

Нуркасыйм, Йосыф. Урамда.

Безне кѳтәләр.

Касыйм Сабирханович. Урамда? Алар биредә булырга тиеш! *(Вил Вилдановичка.)* Тизрәк хатыннарын тап та, бирегә кертеп җибәр.

Вил Вилданович. Икесенекен дәме?

Касыйм Сабирханович. Юк, өчесенекен дә. Ангыра.

Вил Вилданович. Яхшы.

Касыйм Сабирханович. Өч минуттан алып кермәсәң, погоннарыңны кертеп минем өстәлгә сал!

Вил Вилданович *(үрә катып)*. Есть! *(Чыгып китә.)*

Касыйм Сабирханович. *(Нуркасыйм белән Йосыфка.)* Сез үзегезне тәртипкә китерегез дә, тизелеп басыгыз! Ә бу карачкының җиннәрен, чалбар балакларын бераз сызгандырыгыз!

Мөстәкыйм. Кирәкми, иптәш, кирәкми. Борчылмагыз. Ике сәгатькә генә түзәм. Ике сәгатьтән барыбер сез аны миннән салдырып аласыз.

Касыйм Сабирханович. Илчеләр китеп, исән генә калыйм, костюмыңны гына түгел, бер кат тиреңне салдырам әле мин синең. Барыгыз да әзерме?!

Йосыф Исхакович. Әзер.

Нуркасыйм. Әзер, Касыйм Сабирханович. *(Бүлмәгә зәвык белән киенгән Йосыфның хатыны Суфия һәм алтмышның теге ягындагы Нуркасыйм хатыны Миңлениса килеп керәләр.)*

Касыйм Сабирханович. Сез кайда йөрисез?!

Миңлениса. Урам чатында.

Касыйм Сабирханович. Алтмышка житкәч, тапкансың урам чаты.

Суфия *(арт санын уйнатып, Касыйм Сабирханович янына килә дә, үбәргә кулын суза.)* Исәнмесез, Касыйм Сабирханович. Хәлләрегез ничек?

Касыйм Сабирханович *(дорфа)*. Ару. Сафка бас!

*Барысы да тизелеп сул порталга басалар. Салих Сәйдәшевнең Совет армиясе маршы яңгырый. Ишек ачыла. Бүлмәгә гарәп киеменнән өч илче килеп керәләр. Аларның берсенең кулында таш сандык, икенчесенең кулында йомарлап төрелгән васыятьнамә. Алар уртасында озын гәүдәле, ап-ак сакаллы өченче илче. Керәләр дә сул порталга басалар. Гарәбстан гимны башкарыла. Илчеләрнең башлары югары күтәрелә. Гарәбстан гимны тәмамлануга, ана Татарстан гимны кушыла. Уң порталдагыларның башлары күтәрелә. Гимн тәмамлануга илчеләр кулларын күкрәкләренә куеп, башларын түбән ияләр.*

1, 2, 3нче илче: Әссәламүгаләйкүм.

Уң порталдагылар: *(иелә төшеп).* Вәгаләйкүмвәссәлам.

Ак сакаллы илче: Биредә Исхакның улы Мөстәкыйм яшиме?

Уң партaлдагылар: Биредә яши, биредә. Менә ул.

*Ак сакаллы илче васыятьнамәне сораган рәвеш ясап уң кулын суза.*

2нче илче *(васыятьнамәне аның кулына бирә).* Рәхим итегез. *(Уң кулын күкрәгенә куйган килеш иелә төшеп, артка чигә.)*

Ак сакаллы илче. Хөрмәтле Исхакытдин углы Мөстәкыйм галиҗәнап.

Мөстәкыйм. Галиҗәнап үк булмасак та, атам Исхак кушкан Мөстәкыйм исемем бар анысы.

Ак сакаллы илче *(васыятьнамәне укый башлый)*: Исәнме, минем нәсел җебемне, нәсел шәҗәрәмне дәвам итүче, ерак, ерак туганым, төпчек углым. Гасыр-еллардан соң син минем телемдә, шушы таш сандыкны ачып, минем әманәтемне укып, сандык эчендәге "Мирасыйм"ны кабул итәрлек хәлдә булырсыңмы? Әгәр булсаң, кем син? Татармы, әллә... әллә үзенә башка исем алдыңмы? Борынгы бабаңның юлын дәвам итәсеңме?.. Дәүләтлеме син? Әллә дәүләтсезме? Миннән калган шушы нәсел сандыгын кабул итеп алып, мине куандырырлык хәлдәме син? Мин бу таш сандыкны син яшәгән чордан мең ел элек, буш җиргә килеп, сез яшәргә хаклы булган, борынгы бабаларның җиренә казан асар өчен казык каккан көннең шул ук айлы төнендә, ай яктысында ташка уеп, үз мирасымны, нәсел мирасын калдырам. Мин синең исемеңне дә, кем атлы икәнеңне дә белмим. Шуңа күрә дә бу сандыкны нәселемне дәвам итүче ир-ат затыннан булган төпчек торыным ягъни сиңа калдырам. Синнән гайре бу

сандыкка һичкемнен дә орынырга хакы юк! Бу сандыкны ачарга син генә хаклы. Әгәр бу сандык ачылганчы синен белән ул-бу хәл булса, сандык эчендәге "Мирас" үз көчен югалтачак. Мин, ягъни Казан каласына беренче казык каккан хан бабаң, Казан каласына мең ел тулганнан соң, бу сандык сезнең кулга килеп эләккән жәйнен соңгы көннәрендә, халкым бәйрәм иткән айлы төндә, ай яктысында, ай мин каккан казыкның очына эленгәч кенә син бу сандыкны ача аласын. Әгәр ки син сандыкны ачканда ай казыкка чәнти бармакның бер буыны кадәр генә килеп житешмәсә, йә узып китсә, сандык эчендәге "Мирас" үз көчен югалта.

2нче илче. Көчен югалтачак.

1нче илче. Чәнти бармакның бер буыны кадәр генә...

2нче илче. Килеп житмәсә...

1нче илче. Йә, узып китсә...

2нче илче. Ай казыкка эленгәч кенә...

Ак сакаллы илче. Бары тик син генә.

1нче илче. Ханнын ир токымыннан булган иң соңгы буыны гына.

Йосыф Исхакович *(пышылдап, күршеләреннән)*. Ир токымыннан булган иң соңгы буын гына диме?..

2нче илче. Сандык синең кулга килеп эләккән елның утызынчы августында айлы төндә генә.

Ак сакаллы илче. Бары тик син генә, төпчек оныгы гына.

Йосыф Исхакович. Төпчек оныгы дисез инде...

Ак сакаллы илче *(илчедән сандыкны ала да, Мөстәкыймгә суза)*. Рәхим итегез. Борынгы хан бабагызның мирас сандыгын кабул итеп алыгыз!

Мөстәкыйм *(кулларын суза)*. Рәхмәт сезгә.

Йосыф Исхакович. Чү, кагылма! Калтыраган кулларын белән хан бабабызның нәсел мирасын харап итәсең. Үзем алам.

Нуркасыйм. Сабыр. Сабыр, Иосиф энем.

Мөстәкыйм *(Сандыкны кулына ала. Сандыктан күзен ала алмыйча.)*. Таш сандык... Баш сандык... Хан сандыгы... Нәсел сандыгы!.. Бабам сандыгы!..

*Көй яңгырый. Ут сүнә.*

## Икенче күренеш

*Ут янганда Нуркасыйм, Йосыф, Суфия, Миңлениса, Касыйм Сабирханович пыр тузып сугышалар. Нуркасыйм өстенә Йосыф Исхакович менеп атланган, Суфия өстендә Миңлениса, Касыйм Сабирханович диван арасына кысылган, ике аягы гына күренеп тора.*

Касыйм Сабирханович *(аякларын болгый-болгый)*. Коткарыгыз, коткарыгыз, үләм... Муеным кысылып калды.

Миңлениса *(Суфияга)*. Беттенме, себерке! Чәйнәп өзимме үзенне!

Суфия. Төш, төш өстән, убырлы карчык. Юкса күрмәгәненне күрсәтәм.

Нуркасыйм *(өстендә утырган Йосыф Исхаковичка)*. Беттенме, беттенме. Шул кирәк сиңа, гәвнә!

Миңлениса. Нуркасыйм, Нуркасыйм, чалып ташлыйммы бу үләксәне.

Нуркасыйм. Кирәген бир. Күрмәгәнен күрсәт.

Касыйм Сабирханович. Коткарыгыз, коткарыгыз, тыным бетте.

Миңлениса *(Суфия өстеннән тора да, Касыйм Сабирхановичның аягыннан сөйрәп чыгара)*. Тор, үләксә. Диван ярыгыннан чыгалмый. Корсак үстергән булган. *(Касыймның изүеннән сөйрәп торгыза да янагына сугып жибәрә. Касыйм диванга ава.)* Бар, корсаклы ата чыпчык. Иркенләп диванда жан бир.

Йосыф Исхакович *(Нуркасыймга)*. Хәзер борыныңны кысып жаныңны чыгарыйммы?!

Миңлениса *(кулларын бөеренә куйган хәлдә Йосыфка)*. Әле син шулай... *(Күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстыра да, кулларына төкереп.)* Мин синеме, мин сине хәзер бастырыклыйм. *(Нуркасыйм өстеннән Йосыфны өстерәп ала да, өстенә менеп атлана. Нуркасыймга Суфияны төртеп күрсәтеп.)* Бар, теге

чебешнең өстенә менеп кунакла. Аңа синең көчең җитә. Жаны чыксын, тыны бетсен, ике күзе борынына килсен.

Суфия *(яткан урыныннан сикереп тора да)*. Ах сез шулай... *(Нуркасыймга ямап җибәрә.)* Мә, получай, гад! *(Нуркасыйм ишек белән бергә коридорга чыгып оча.)* Буталып йөрмә.

*Ишек катында ике милиционер пәйда була. 1нче милиционер сыбызгы кычкырта.*

2 нче милиционер. Прекратите!

Касыйм Сабирханович *(елыйелый үрмәләп милиционерлар янына килә дә)*. Кайда йөрисез сез?! Иртәгә үк икегезне дә уволю. Хуҗагыз капкынга кысылган тычкан кебек диван арасында җан бирә, сезгә хет бе хны. Хәзер үк барысын да камерага озатыгыз!

1нче милиционер, 2нче милиционер: *(икесе бергә)*. Есть, Касыйм Сабирханович! *(Икесе ике яктан килеп Миңленисаны элдктереп алалар.)*

Минлениса. Ах, сез шулаймы?.. *(Ике милиционерны чәкештерә. Милиционерлар идәнгә егылалар.)*

Касыйм Сабирханович. Бетерде, бетерде милиционерларымны, үтерде.

1нче милиционер *(яткан килеш)*. Борчылмагыз, Касыйм Сабирханович, борчылмагыз. Тиз генә безне бетерә алмый әле ул.

2нче милиционер. Бераз гына хәл алабыз да, Касыйм Сабирханович, аннары тәртипкә салабыз!

Касыйм Сабирханович *(Миңлениса өстенә килә башлый)*. Мин синеме, мин сине... Мин сине под суд җибәрәм!

Минлениса *(Касыйм Сабирхановичның борын астына йодрыгын куя.)*. Тик кенә тор. Маңгаеңа тартырмын, җилегең атылып чыгар. Кара моны. Өстәл сугып өйрәнгән.

Касыйм Сабирханович. Молчу. Теләсә нәрсә эшләгез, бүтән арагызга керсәмме. Тик шуны белегез. Хан сандыгы, хан мирасы сезнең генә гаиләнеке түгел. Дәүләт байлыгы, татар мирасы! *(Милиционерлар аңгыраеп урыннарыннан торалар да Касыйм Сабирханович каршысына киләләр.)*

1нче милиционер. Касыйм Сабирханович, барысын да илтеп ябыйкмы?

Касыйм Сабирханович. Исән калуыгызга шатланып, тыныч кына торыгыз.

1нче милиционер. Балаларыбыз бәхетеннән инде, балаларыбыз бәхетеннән, Касыйм Сабирханович.

Йосыф Исхакович. Менә шул. Бабам сандыгындагы мирас минеке. Буш сандыгы синеке, Нуркасыйм туганым, дәү абый!

Нуркасыйм. Тоттырган диярләр.

Суфия. Дөрес, безнеке! Әткәй белән әнкәйне без җирләдек. Әнкәй белән әткәйгә чардуганны, кабер ташын без куйдык. Нәсел турында гел без кайгырттык.

Йосыф Исхакович. Шулай булгач, нәсел мирасы безгә.

Касыйм Сабирханович. Туктагыз әле, туктагыз. Мирас сезнеке дә түгел, Нуркасыйм Исхаковичныкы да түгел. Мирас милләтнеке!

Нуркасыйм. Дөрес! Мин килешәм. Мирас милләтнеке! Ә безнең Йосыф—маңкорт. Ул үзе теләп Иосифка әйләнде. Паспортын карагыз.

Йосыф Исхакович. Паспорт! Паспорт нәрсә ул. Паспорт ул кәгазь. Минем татарлык менә монда! Душада!

Касыйм Сабирханович. Туктагыз әле, җәмәгать, туктагыз. Сез бит бер ата, бер ана балалары.

Нуркасыйм. Сез нәрсә сөйлисез. Нинди бер ана, бер ата. Аның атасы—Исак, минем атам—Исхак.

Касыйм Сабирханович. Тынычланыгыз, иптәшләр, тынычланыгыз. Бүгенге көндә безнең милләтне бөтен дөнья халкы күзәтә. Күрмисезмени. Шәһәребезне бөтен дөнья журналистлары, репортёрлар камап алган. Безгә бүген татарларга аеруча бердәм булырга кирәк. Ә сез үзара бер фикергә килә алмыйсыз. Безгә төп мәсьәләгә кучәргә кирәк. Төптәнерәк уйлыйк. Ярар. Хан сандыгын ышанып Мөстәкыймгә калдырыйк ди. Кая гарантия.

Суфия. Анысы хак. Сатып эчә ул аны.

Касыйм Сабирханович. Эш аңа үк барып җитмәс җитүен. Сандык

жиде кат сак астына куелды.

Йосыф Исхакович. Сатып эчмәсә, вакытыннан алда ачып, сандык эчендәге мирасны юкка чыгарачак.

Касыйм Сабирханович. Тирәнрәк уйлап карыйк әле, иптәшләр, тирәнрәк. Милләт язмышы безнең кулда. Нәселегездә иң төпчек ир бала Мөстәкыйм микән? Бәлки, мирас сандыгының төп хуҗасы башка кешедер.

Нуркасыйм. Ягъни мәсәлән?

Касыйм Сабирханович. Ягъни мәсәлән... Тормыштагы кайбер ялгышларыбыз киресенчә милләтебез өчен яхшылык булып кайтмый микән. Соңгы халык санын алуны гына искә төшерик.

Йосыф Исхакович. Постой, постой... Уйланырлык фикер бар монда. Чыннан да, тирәнрәк уйласаң, бәлки хан мирасы, бабайның мирасы минем читтә адашып йөргән берәр улымныкыдыр...

Суфия. Нәрсә?! Берәр улымныкы, дисеңме?! Ах син, бабник, сволочь! Читтә әле син уйнаш итеп йөрдеңмени?! *(Өстенә килә башлый.)*

Йосыф Исхакович. Чү, чү, Софочка, нишләвең бу. Мин бит уйнап кына. Аллам сакласын. Юк, Мөстәкыймнән гайре нәселебездә хан мирасына ия булырдай ир-ат затыннан башка туганыбыз юк.

Суфия. Шулай дип котыл.

Нуркасыйм. Ашыкмагыз әле. Минем өчен дә җавап бирмәгез. Бәлки минем яктан бардыр.

Минленисa. Дөрес, әтисе. Уйлап кара әле, синең яктан юк микән.

Нуркасыйм. Мин соңгы вакытларда кай якларда булдым әле әнисе?

Минленисa. Син, әтисе, соңгы вакытларда кай якларда булгансыңдыр, анысын хәтерләмим, но шунысын яхшы хәтерлим, мина өйләнеп бер ай торгач, Волков урамындагы урологический больницада операция ясатканыңны гомер буе сизеп яшәдем.

Нуркасыйм. Юк, юк. Безнең нәселдә Мөстәкыйм энекәштән гайре хан сандыгына хуҗа булырдай бүтән туганыбыз юк.

Касыйм Сабирханович. Нык-лап уйладыгызмы?

Суфия. Безнең яктан, хатын-кыз ягыннан булса ярамыймы?

Йосыф Исхакович. Юк, ярамый. Хатын-кыз ягыннан ярамый. Сез хан нәселеннән түгел.

Касыйм Сабирханович. Димәк, сандыкның төп хуҗасы Мөстәкыйм.

Йосыф Исхакович. Туктагыз. Башка бер уй килде. Бу бәладән сезне без генә коткара алабыз. Шулай бит, әнисе, Софочка?

Суфия. Ничек?

Йосыф Исхакович. Малай алып кайтабыз.

Минленисa. Ике ай эчендәме?

Йосыф Исхакович. Нигә ике ай эчендә...

Нуркасыйм. Сандыкны ачарга ике ай калып бара.

Йосыф Исхакович. Булмады. Бер татар арттырмакчы идек, барып чыкмады.

Касыйм Сабирханович. Иптәшләр! Әгәр без милләтебез язмышы турында уйлыйбыз икән, Мөстәкыйм әфәндене күз карасы урынына сакларга тиешбез!

Йосыф Исхакович. Нәрсә? Мин хәзер бетен эшемне ташлап, исерек баш Мөстәкыймне саклап утырырга тиеш буламмени?

Нуркасыйм. Юк инде җәмәгать, миннән булмый. Намазлык җәярлек тә чиста урыны булмаган шакшы сәрхүш Мөстәкыйм фатирында биш вакыт намазымны өзеп, Ходай алдында үземә гөнаһ җыеп, вакытымны әрәм итәсем юк. Минем көн дә мәчеткә барасым бар.

Вил Вилданович. Сакларсыз! Сакларсыз! Сез сакламасагыз, үзем саклармын!

Касыйм Сабирханович. Мөстәкыйм кебек асыл татар егетләре теләсә кайда аунап ятмый. Мөстәкыйм әфәндегә без чебен дә кундырмаска тиешбез. Мөстәкыйм әфәндегә сабый җиле дә тияргә тиеш түгел.

Суфия. Дөрес, Касыйм Сабирханович. Үзем, үзем саклармын. Төннәрендә янынннан бер секундка да китмәм. Шулай бит, әтисе.

Минленисa. Хыялларың тормышка ашмас. Йокы бүсәргә яратасың. Үзем саклармын. Мин инде төннәрен мәет сакларга күнеккән.

Йосыф Исхакович. Тукта әле. Нишләп әле син минем бертуган

энем Мөстәкыймне мәет белән тыңлисең. Нәрсә, синеңчә ханның нәселе өзелгән, соңгы буынын мәет димәкче буласыңмы?! Касыйм Сабирханович, ишеттегезме? Нәрсә ди? Мәет ди. Бу бит зур хата.

Суфия. Политическая хата.

Нуркасыйм. Ярый, ярый, житте. Күпертмәгез. Сүзне икенчегә бормагыз.

Йосыф Исхакович. Ишетәсезме? Алар бердәм эшлиләр. Алар татар милләтенең тамырын балта белән чабалар. *(Күкрәгенә сугып.)* Бабам хакына, нәселебез хакына, милләтебез хакына барысын да эшлим. Кирәк икән, үземне дә, кирәк булса, хәләл хатынымны да корбан итәм!

Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович: *(икесе бергә).* Дөрес, Иосиф Исакович! Дөрес!

Йосыф Исхакович *(елаган кыяфәттә).* Белә идем бит, сизә идем бит, тоя идем затлы кан, хан каны акканын белә идем бит.

*Ут сүнә. Музыка.*

## Өченче күренеш

*Ут янганда иркен зур зал. Бүлмәләргә чыга торган берничә ишек. Зал уртасында тумбочкада, пыяла аквариум эчендә таш сандык. Ул дүрт яктан прожектор белән яктыртылган. Залның стенасы тирәли урындыклар тезелгән. Сандыкның бер ягында Нуркасыйм, икенче ягында, йокымсырап, мылтык тотып, урындыкта Йосыф Исхакович утыра.*

Йосыф Исхакович *(авызын олы итеп ачып).* Төне озын булды.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк.

Йосыф Исхакович. Бу мәет саклаган әбиләргә Ходай ярдәм бирсен.

Нуркасыйм. Аның бер нәрсәсе дә юк. Алар бит гайбәт сатып утыра.

Йосыф Исхакович. Анысын син беләсең инде. Ни әйтсәң дә егерме ел дин юлында йөрисең.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Егерме ел намазлык өстендә утырып, исерекбаш Мөстәкыймне саклап утыр инде.

Йосыф Исхакович. Тәһарәтсез намазлыкка менмиләр аны.

Нуркасыйм. Менә анысын синнән сорамыйлар, кем энем Осип.

Йосыф Исхакович. Мин Осип түгел. Аңлыйсыңмы, Осип түгел. Минем атам кушкан исемем бар. Мин—Йосыф!

Нуркасыйм. Нигә? Син бит үз теләгең белән паспортыңны алыштырдың. Элек Йосыф идең, хәзер Иосиф. Элек Йосыф Исхакович идең. Хәзер Иосиф Исакович.

Йосыф Исхакович. Кабатлап әйтәм. Мин Осип та, Иосиф та түгел, мин—Йосыф!

Нуркасыйм. Әйттем икән кайттым. Әле бер ай элек кенә Йосыф дисәң чырайга ябыша идең.

Йосыф Исхакович. Заманасы үзгә иде.

Нуркасыйм *(кашынып алганнан соң).* Их, бер мунча кирәсе иде ул.

Йосыф Исхакович. Сөйлисе юк.

Нуркасыйм. Айдан артык утырабызмы?

Йосыф Исхакович. Бүген ай да унжиде көн була. Бетләп бетмәсәк ярый.

Нуркасыйм. Августның утызына кадәр күп калдымы әле?

Йосыф Исхакович. Кул бармаклары гына түгел, аяк бармаклары да житми.

Нуркасыйм. Айдан артык намазлыкка басканым юк.

Йосыф Исхакович. Басып та азапланма. Укыганнарың барыбер Ходайга барып ирешми.

Нуркасыйм. Нигә алай дип уйлыйсың?

Йосыф Исхакович. Уйламыйм. Беләм.

Нуркасыйм. Каян беләсең?!

Йосыф Исхакович. Әнә, Мөстәкыйм укымады да, аңа Ходай йомшак түшәк бирде. Ә сиңа—каты урындык.

Нуркасыйм. Шулай дисеңме?

Йосыф Исхакович. Шулай димен.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Хатыныңны аяк очына салып гомер кичерә. Ә бит нинди заманалар бар иде.

Йосыф Исхакович. Ничего.

Бер айлык уразаның баребер гаете була.

Н у р к а с ы й м. Ярый да бит мирастан өлеш чыгарса.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Өч югары белемле дипломың була торып, шул исерекбашны саклап утыр инде. Адәм көлкесе.

Н у р к а с ы й м. Шатыр-шатыр кашынып диген.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Ничего. Утызы гына житсен.

Н у р к а с ы й м. Нишләмәкче буласың?

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Үз өлешемне генә алыйм. Икегезнең берегезгә дә әйләнеп карамыйм.

Н у р к а с ы й м. Әле син өлеш өмет итәсеңмени?!

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Нигә итмәскә. Мин дә бит ул ханның оныгы.

Н у р к а с ы й м. Осип Исаковичмы?

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Осип түгел мин. Аңлыйсыңмы, ангыра. Осип түгел — Йосыф мин. Алла тарафыннан өстәлгән дигән төшенчәне аңлата. Күркәмлек, гүзәллек иясе. Легендар Йосыф.

Н у р к а с ы й м. Белмим шул. Әткәй белән әнкәй ризалыгыннан башка Иосифка әйләнгән кешегә хан бабабыз сандык эченә бирәр генә карамил булса да салды микән.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Анысы өчен борчылма. Син үзең турында уйла. Үзең турында.

Н у р к а с ы й м. Минем уйлыйсым юк. Мин Ходай юлында. Ходай барысын да күрә.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Шулайдыр шул. Әйтәм жирле төннәр буе агач мылтыгыңны кочаклап, прожектор яктысында, исерек сәрхуш Мөстәкыймне саклап утырасың.

Н у р к а с ы й м. Шулай, энем. Джузеппеме әле син? Ә, әйе, Хосе, то есть Осип Исакович, мин Мөстәкыймне саклап утырмыйм. Мөстәкыймне син сакла. Мин таш сандык саклыйм. Мирас саклыйм. Ә инде ул таш сандык эчендәге Хан бабабызның мирасыннан сиңа — ноль. Мирасның яртысы Мөстәкыймнеке, яртысы үзебезнеке дип торабыз.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Бик жирный булмасмы? Үтләрсең. Әткәй белән әнкәйнең кер бавына кадәр даулап алган бәндә бит син.

Н у р к а с ы й м. Кем? Минме?!

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Нигә... Кер каптырмасын сорап өйгә ничә тапкыр килдең?

Н у р к а с ы й м. Әкиятеңне кайтып хатыныңа сөйлә. Син аларның башына життең. Син, син, Осип энем. Шәһәрдән зуррак фатир алыр өчен әткәй белән әнкәйнең йортларын саттырып Казанга алып киттең дә, аннары үзләренә вокзалдан, урамнардан буш шешә жыйдырдың.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Син сүзеңне чамалап сөйлә. Дәү абый дип тормам, ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорамам.

Н у р к а с ы й м *(утырган жиреннән сикереп тора)*. Мендергән диярләр. Менәрсең син минем ипи шүрлегенә. Ничек төшкәнеңне дә сизми калырсың. Мин сиңа Мөстәкыйм түгел. Эчеңне тишеп агызырга да күп сорамам.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч *(әтәчләнеп Нуркасыйм өстенә килә)*. Попробуй! Әтәчке! Коерыксыз әтәч. Тәһарәтсез мулла калдыгы! Сине белмиләр ди. Кеше алдап, байлык туплап, шул акчага ел саен диңгез буена барып, яшь кызлар сатып алып, яшь кызларны бозып йөргәнеңне.

Н у р к а с ы й м. Докажи?!

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Кирәк булса, докажем!

Н у р к а с ы й м. Нәрсә?! Ялган диплом сатып алып түрә булдыңмени? Мин синең белемеңне беләм. Әлепне таяктан аера алмаган аңгыра сарык, дуңдук бит син!

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Ах, син шулаймы... *(Нуркасыймны якасыннан эләктереп ала.)* Мә, получай, гад! Мә, паразит! Мә, фиргавен токымы! Ал үзеңә тиешлесен. *(Сугыша башлыйлар.)*

Н у р к а с ы й м. Барыбер мирасның яртысы минеке, яртысы Мөстәкыймнеке.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Шулаймы? *(Башы белән Нуркасыймның йөзенә тарта.)* Мә мирасның яртысын! *(Тагы башы белән тарта.)* Мә мирасның тиешле өлешен! *(Тагы сугып жибәрә.)* Мә мирасны бөтен килеш. Күңелең булдымы.! *(Тагын суга.)* Мә, получай, гад!

Н у р к а с ы й м. Үтерәләр! Коткарыгыз! Каравыл!

*Югарыдан тавыш ишетелә.*

Микрофоннан. Әй сез, фиргавен токымнары! *(Йосыф Исхакович белән Нуркасыйм тынып калалар.)* Молчать! *(Нуркасыйм белән Йосыф Исхакович үрә каталар.)* Хуҗага йокларга ирек бирмисез! Быдло.

Нуркасыйм *(пышылдап Йосыф Исхаковичка).* Нәрсә ди?

Йосыф Исхакович. Бетле ди!

Нуркасыйм. Бардыр инде, ике айга якын мунча кергән юк бит.

Микрофоннан тавыш. Разговорчики!

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм *(честь бирәләр).* Есть!

Микрофоннан тавыш. Иртәгә үк икегезне дә уволю!

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. *(Икесе ике якка югарыга, почмакка карап тезләнәләр. Кулларын ияк астына куеп.)* Не надо!. Не надо. Мы больше так не будем...

Микрофоннан тавыш. Вольно!

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. *(Тезләнгән килеш честь бирәләр.)* Есть!

Микрофоннан тавыш. По местам.

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. *(Сикереп торалар да, үрә катып честь бирәләр.)* Есть!

Йосыф Исхакович *(үз-үзенә мыгырданып).* Шушы почмактагы глазокны уйлап тапкан инженерның күзләрен чокып алыр идем!

Нуркасыйм. Ярый әле аннан күзәтеп торалар. Юкса үтерәсең син мине. Валлаһи, үтерәсең. Иртәгә үк аппарат житәкчеләренә жалоба язам.

Йосыф Исхакович *(үз-үзенә сөйләнеп).* Тырный тагын. Биткә сикерә. Чалып ташланган көзге әтәчмени. *(Нуркасыймга.)* Яз! Син гомер буе жалоба язган кеше, анонимчик!

Нуркасыйм. Үзенне бел. Ангыра баш. Жалоба язарга да грамота кирәк. Кояш дигән сүздә биш хата ясап, жалоба язып булмый ул.

Йосыф Исхакович. Кем?! Минме? Әллә саташа башладыңмы, тинтәк?

Нуркасыйм. К, ы, й, я, а, ш. Мягкий знак! Син язганча кояш.

Микрофоннан тавыш. Життеме сезгә, юкмы? Иртәгә үк икегезне дә уволю. Почётлы каравылга куйганга рәхмәт юк, сугышалар тагын. Шатланыгыз! Халык, милләт мирасын саклыйсыз. Сөенегез!

Нуркасыйм *(ялагайланып).* Ай рәхмәт, ай рәхмәт. Сәламәт булыгыз!

Йосыф Исхакович. Бетерәм мин бу почмактагы глазокларны. Шартлатам, матери! *(Мылтыгын почмакка төзи.)*

Нуркасыйм *(аның аяк астына тезләнеп, кулларын ана суза).* Чү, энекәш, кирәкми... Икебезне дә харап итәсен... Мирассыз калдырасын. Акылына кил.

Йосыф Исхакович *(мылтыгын төшерә).* Өелеп торган байлыгым була торып, шушы каһәр суккан таш сандык янында айлар буе йокысыз төннәр уздыр инде.

Нуркасыйм. Уздырма. Кем сине мәжбүр итә. Кайт та йокла!

Йосыф Исхакович *(Нуркасыйм булып).* Кем сине мәжбүр итә... *(Паузадан сон. Ишеккә бармагы белән төртеп.)* Син һәм ул. Юк инде. Еллар буе утырсам утырам, китмим. Икегез генә бүлер идегез бугай. *(Эчке бүлмәдән Суфиянын чыркылдаган тавышы ишетелә.)*

Нуркасыйм *(авызын зур итеп ачып, иснәп).* Уяндылар бугай.

Йосыф Исхакович *(авызын зур итеп ачып, иснәп).* Ниһаять тагын тан атты. *(Янә чыркылдашу ишетелә. Йосыф Исхакович сискәнеп.)* Бар әле, бар, кара. Нишлиләр анда?..

Нуркасыйм. Үзең кара. Сиңа кирәк. Ни әйтсәң дә синең хәләл хатының—Софочкаң түгелме сон анда.

Йосыф Исхакович. Кызлар сорады бит.

Нуркасыйм. Сораса. Артык юмартланмаска иде. Хатын тикле хатыныңны бирмиләр аны. Хотя, энекәшкә, Мөстәкыймгә жәл түгел дигәнсендер инде.

Йосыф Исхакович. Көлмә. Кая барасын. Яшь кызлар сорады бит. Кертеп кара син аның янына чит кызлар. Беләм мин ул хәзерге яшь кызларны. Аларга Мөстәкыйм кирәкми, аларга хан сандыгы, таш сандык, мирас сандыгы кирәк. Төн чыкканчы ун тапкыр кияүгә чыгып, ун тапкыр ЗАГСка алып баралар алар. Аннары көтеп утыр хан

сандыгыннан мина да өлеш чыгар дип. Болай ичмаса ышанычлы.

Нуркасыйм. Үз хатыным дисен инде.

Йосыф Исхакович. Кая барасын. Түзәсен. *(Чыркылдашкан аваз янә кабатлана. Йосыф Исхакович түзми, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлый. Нуркасыймга.)* Бау бир. Асылынам. Бар инде, кара, нишлиләр?

Нуркасыйм *(иплэп кенә тавыш килгән бүлмәнен ишеген бераз гына ачып, ишек ярыгыннан карый).* Булдыра Мөстәкыйм энекәш.

Йосыф Исхакович. Нишли?

Нуркасыйм. Нишли, нишли!?. Бар да кара!

Йосыф Исхакович. Йә, әйт инде, нишлиләр?..

Нуркасыйм. Нишләсеннәр... Мөстәкыйм аркасына массаж ясата.

Йосыф Исхакович. Ходай бар икән. Ныклап карадынмы, массаж гынамы?

Нуркасыйм. Массаж гына булмый... Син, энекәш, бигрәк. Как будто син Мөстәкыймне белмисен.

Йосыф Исхакович. Ышан. Абый хатыны, жинги дип тормас.

Нуркасыйм. Мин Мөстәкыйм энекәшкә ышанам. Менә синен хатынын Софочкага гына шигем зур.

Йосыф Исхакович. Ул Софочка түгел, ул Суфия. Анлыйсынмы—Суфия.

Нуркасыйм. Анлыйм, анлыйм, энекәш. Бүген ул Суфия, иртәгә Софочка, берсекөнгә—Сонечка. *(Бүлмәгә таушалган кыяфәттә Суфия килеп чыга.)*

Суфия *(дорфа).* Житте, хватит миннән. Башка булдыра алмыйм!

Йосыф Исхакович *(Суфия янына килә дә шикләнеп пышылдый).* Нәрсә? Издеваться итте, да?

Суфия. Сорыйсын тагын. Төне буе йоклатмады.

Йосыф Исхакович. Сволочь! Түз, үз өлешебезне генә алыйк. Күрмәгәнен күрсәтәм әле мин анын. Төне буе азаплады дисен инде.

Суфия. Төне буе... Атна буе диген!

Йосыф Исхакович. Нишлисен бит. Түзәргә туры килә, жаным. Хан байлыгыннан баш тартып булмый.

Суфия. Юк. Башка түзә алмыйм. Хет ас, хет суй, башка түзә алмыйм. Адәм баласы бер сутка, ике сутка, конца да концов өч сутка йокламый түзә ала. Ә мин...

Йосыф Исхакович. Түз, жаным, түз. Озак калмады. Озакламый ханбикә буласын.

Суфия. Ханбикә булганчы үтерә әле ул мине.

Йосыф Исхакович. Вот маньяк!

Суфия. Маньяк кынамы, зверь! Юкса бит аяк очына гына ятам. Тибә дә төшерә, тибә дә төшерә. Йокыга гына төнәләм, тибә дә төшерә.

Йосыф Исхакович. Тибә дә төшерә?..

Суфия. Әйе. "Син нәрсә, мине кемгә санйсын. Абый хатыны белән йоклап ятарга син мине кем дип уйлыйсын. Хан нәселенен оныгы Йосыфнын хатыны булуынны онытма. Безгә, хан нәселенә тап төшерергә ничек жөрьәт итәсен", ди. Булды житте, хватит! Бүген үк өйгә кайтып китәм. Әнә, сменага Нуркасыйм хатыны Минлениса калсын. *(Пыр тузып чыгып китә).*

Йосыф Исхакович *(артыннан кычкырып кала).* Суфия, Суфия, Софочка, нишләвен бу.

Нуркасыйм *(шаркылдап көлеп).* Нәрсә, капитуляцияме?

Йосыф Исхакович. Авызынны жәеп ыржайма, ангыра. Авызынны ябарга да өлгермәссен, хан бабанның мирасыннан колак какканынны сизми дә калырсын. Әнә, сменага остабикәнне чакыр. *(Бүлмәгә Мөстәкыйм килеп чыга.)* Нихәл, энем?

Мөстәкыйм. Әбиеннеке кебек!

Нуркасыйм. Нәрсә булды, энекәш?

Мөстәкыйм. Нәрсә булды, нәрсә булды. Белмисен инде как будто. Әгәр бүген төнлә тагын берәрегезнен хатыны минем бүлмәгә, мине сакларга керсә, белеп торыгыз. Йә—асылынам, йә—тәрәзәдән сикерәм. Йокыга гына төнәләсен, мәче кебек куенга керергә генә торалар. Настоящий ханга әверелсән, нишләмәсләр.

Йосыф Исхакович. Сон бит, энекәш, өстән шулай куштылар. Төнлә синен белән берәр хал булса, күз-колак булырга кирәк, диделәр.

Мөстәкыйм. Дисәләр. Без бит өч бертуган. Менә шушында сабый чактагы кебек идәнгә сузылышып ятып, өчәүләп йокласак ни булган.

Нуркасыйм. Без бит сандык саклыйбыз.

Мөстәкыйм. Ә хатыннарыгыз мине саклыймы?

Йосыф Исхакович. Нишлисен, өстән килгән положения шундый.

Мөстәкыйм. Төкерәм мин аларның положенияләренә.

Нуркасым, Йосыф Исхакович *(икесе бергә пышылдап)*. Чү, энекәш... *(Түшәм почмагындагы глазокка ымлап.)* Тыңлап һәм күреп торалар.

Мөстәкыйм. Сез бәхетле, сезгә мешать итүче юк.

Нуркасыйм. Алай дип әйтмә әле, энекәш. Йокысыз төннәр уздыру бик рәхәт түгел ул.

Йосыф Исхакович. Минем үземә ошый.

Нуркасыйм. Ошагангамени йокымсырап өч тапкыр урындыгыннан егылып төштен. Микрофоннан кычкырып кына уяттылар.

Мөстәкыйм. Төне буе Осип абыйны кызганып чыктым.

Йосыф Исхакович. Осип түгел мин, энекәш, Осип түгел...

Мөстәкыйм. Ә, әйе бит әле, Иосиф абыйны.

Йосыф Исхакович. Мин Иосиф та түгел.

Нуркасыйм. Ярар инде, кем энекәш, Мөстәкыйм... Джузеппе абыенны үртәп утырма.

Йосыф Исхакович. Каян ул исемнәрне табасың да, каян башыгызга килә.

Нуркасыйм. Нигә? Үзең бит, үзең мактанып йөрден. Минем сигез исемем бар, дип.

Йосыф Исхакович. Кайчан?

Нуркасыйм. Әткәй кушкан исеменнән ваз кичеп, паспорт алмаштырып йөргән чагында. Атам кушкан исемем—Йосыф, русларда—Иосиф, Осип, инглизләрдә—Джозеф, французларда—Жозеф, испаннарда—Хосе, итальяннарда—Джузеппе, полякларда—Юзев дип. Мин алдасам, әнә, Мөстәкыйм энекәш үлмәгән. Ул дөресләр.

Йосыф Исхакович. Ну бу татар, ну бу татар... Шул кадәр тар күңелле булырга кирәк бит, ә?! Үз туганыннан көнләшә.

Нуркасыйм. Хатын кадәр хатынынны сатып та ярап булмый.

Йосыф Исхакович. Сатмадым. Нәселебез турында кайгырттым. Нәселебезне мин дә кайгыртмасам, син дә кайгыртмасан, ул да кайгыртмаса, кем кайгыртыр. Әйт, энекәш, нишлибез?! Нәсел сандыгы белән нәрсә эшлибез?!

Мөстәкыйм. Нәрсә эшләргә кушасыз, шуны эшлим.

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. Сандыктан баш тарт.

Мөстәкыйм. Мирастан?!

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. Әйе, мирастан.

Мөстәкыйм. Ничек итеп?

Йосыф Исхакович. Васыятнамәдә борынгы бабабыз доверенность турында бер сүз дә әйтмәгән. Минем исемгә доверенность яз!

Нуркасыйм. Юк инде. Минем исемгә яз!

Мөстәкыйм. Була ул. Кая кәгазегез, кая каләмегез?

*Музыка. Ут сүнә.*

*Пәрдә.*

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## Дүртенче күренеш

*Пәрдә ачылганда Мөстәкыйм белән Нуркасыйм идәндә, Йосыф Исхакович өстәл алдына кәгазь куйганнар да язарга җыеналар.*

Мөстәкыйм. Башлыйбызмы?

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. Башлыйбыз!

Йосыф Исхакович *(Мөстәкыймгә)*. Нәрсә, энекәш, әллә үз-үзеңә доверенность язасынмы?

Мөстәкыйм. Әйе. Нигә, әллә ярамыймы?

Йосыф Исхакович. Ярый. Нигә ярамасын. *(Тамашачыга.)* Дуракларны чәчеп үстермиләр.

Нуркасыйм. Ну баш бар да инде үзеңдә, Мөстәкыйм энекәш.

Йосыф Исхакович. Сөйлисе юк инде, сөйлисе юк. Шушы яшемә җитеп үз-үзенә доверенность язган кешене беренче тапкыр күрәм.

Мөстәкыйм. Нигә алай дисен?

Сезнен халыкны, начальство халкын әйтәм, бер үзләренә ике оешма ачып, ике печәт ясатып, үз-үзләренә доверенность язып утыралар түгелме соң?

Йосыф Исхакович. Син, энем, тирәнгә кермә. Чыга алмый азапланырсын.

Мөстәкыйм. Ходайга тапшырып, башлыйм.

Йосыф Исхакович. Башла.

Мөстәкыйм. Әйтеп торыгыз. Минем грамыт бәләкәй. Мин доверенность яза белмим.

Йосыф Исхакович. Мин әйтеп торам.

Нуркасыйм. Ни өчен син?!

Йосыф Исхакович. Мин югары белемле. Мин өч институт бетердем.

Нуркасыйм. Мин риза. Кояш кебек елмаеп әйтеп тор әле.

Йосыф Исхакович. Көлмә, ангыра! Сез әзерме?

Мөстәкыйм, Нуркасыйм. Әзер!

Йосыф Исхакович. Мин, дип язып куй Мөстәкыйм энекәш.

Мөстәкыйм. Яздым, абзыкай.

Йосыф Исхакович. Молодец! Булдыргансын Хәзер мин язам. *(Ижекләп яза.)* Ми-н. Булды бу. Икенче сүзне язабыз. Мөстәкыйм, яз. Үз исемеңне яз. Мөс-тә-кыйм, дип яз.

Мөстәкыйм. Аңлашылды, абый. Димәк, үз исемнәребезне язабыз. Мин кыскартып кына үз исемемне "Мин", дип яздым.

Нуркасыйм *(Мөстәкыймгә)*. Нәрсә минем кәгазьгә карыйсың. Үзен яз. Күчермә миннән.

Мөстәкыйм. Исемемне дөрес язасың микән дип карыйм.

Нуркасыйм. Син мине ул кадәр аңгырага санама инде. Үз исемемне дә яза белмәскә. Менә, кара. Нур-ка-сыйм. Шәпме?

Йосыф Исхакович. Изумительно! Өченче сүзне язабыз. Үземнен, дип языгыз.

Мөстәкыйм. Яздым, абый.

Йосыф Исхакович *(Нуркасыймга)*. Син яздыңмы?

Нуркасыйм. Яздым инде, яздым. Колакка акырма. Чукрак түгел.

Йосыф Исхакович. Хәзер үзем язам. *(Яза.)* Ү-зем-нен. Булды бу. Хәзер, борыңгы,—дип языгыз.

Нуркасыйм. Нигә борыңгы?

Йосыф Исхакович. Борыңгы булганга борыңгы! Беренче булмаганга борыңгы. Как бу кадәр аңгыра син.

Нуркасыйм. Ярар теленә салынма. Яздым. Синенчә булсын. Борыңгы дип яздым. Хан булгач, дураку ясно, борыңгы була инде ул. Язмыйча да аңлашыла.

Йосыф Исхакович. Хан, дип языгыз!

Нуркасыйм *(ижекләп яза)*. Ха-н...

Йосыф Исхакович *(Нуркасыймга)*. Өч хәрефле җөмләне ижекләп язмасаң булмыйдыр. Син яздыңмы, Мөстәкыйм энекәш?

Нуркасыйм. Җөмлә түгел, сүз. Ангыра кояш.

Мөстәкыйм. Яздым. Мин әллә кайчан яздым инде, абзыкай.

Йосыф Исхакович. Молодец! Үзем дип язып куйыйм әле. *(Яза.)* Хан! Олы хәреф белән яздыгызмы?

Нуркасыйм. Нигә олы хәреф белән язарга?

Йосыф Исхакович. Хан булганга олы хәреф белән язарга. Ангыракаем, тәти баш, өстәвенә надан!

Нуркасыйм. Нигә акырасың, акырма! Төзәтеп була бит аны. *(Төзәтә.)* Менә төзәттем. Сизелми дә.

Мөстәкыйм. Мин төзәтмим. Мин надан. Миңа, ангырага, ничек тә ярый.

Йосыф Исхакович. Дальше киттек.

Нуркасыйм. Кая?

Йосыф Исхакович. Бөгелмәгә!

Нуркасыйм. Нигә?

Йосыф Исхакович. Әйттерерсең әллә ни.

Нуркасыйм. Әйт. Эчеңдә калмасын.

Йосыф Исхакович. Башка бер сүз дә әйтмим. Мыскыл итеп утыра. Үзе әйтсен.

Мөстәкыйм. Ярар инде, кечкенә абый, үпкәләмә. Арабызда иң грамотные син бит.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Үпкәләмә инде. Мин бит карт. Зиһен тарала.

Йосыф Исхакович. Зиһенең таралгач, ни пычагыма сиңа хан сандыгы. Кәфенлек алырлык кына акчаң бардыр бит. Булмаса, үзем биреп торам.

Нуркасыйм. Ашыксан, үзең бара тор. Синнән әҗәткә акча алып торсаң, каберемә төшеп азапларсың.

Йосыф Исхакович. Дүртенче җөмләгә киттек.

Нуркасыйм. Дүртенче җөмләне язабыз, диген. Тапкан сүз: киттек!

Йосыф Исхакович. Ба-бам-ның.

Мөстәкыйм. Ба-бам-ның.

Йосыф Исхакович. Үземә, дип языгыз.

Мөстәкыйм. Ү-зе-мә. Булды бу.

Нуркасыйм. Атап,—дип языгыз.

Нуркасыйм, Мөстәкыйм. *(Иҗекләп.)* А-тап.

Йосыф Исхакович. Җи-бә-рел-гән.

Нуркасыйм. Кем җибәрелгән?

Йосыф Исхакович. Син!

Мөстәкыйм. Сандык... Сандык җибәрелгән, дәү абый.

Йосыф Исхакович. Үтерә бу мине.

Нуркасыйм. Үзең бит әллә нинди сүзләр эзләп табасың. Җибәрелгән, дигәч башка әллә нинди уйлар килә.

Нуркасыйм, Мөстәкыйм: Җи-бә-рел-гән.

Йосыф Исхакович. Ашыкмагыз. Хәзер үзем дә язып куям. Җи-бә-рел-гән. Точка.

Нуркасыйм. Беттемени?

Йосыф Исхакович. Нигә?

Нуркасыйм. Точка, дисең бит.

Йосыф Исхакович. Ни эшләп бетсен инде, аңгыра. Яз!

Нуркасыйм *(яза).* Яздым, точка, дип.

Йосыф Исхакович. Нәрсә язасың син?! Нигә точка дип язасың?!

Нуркасыйм. Үзе точка дип яз, ди. Үзе җенләнә.

Йосыф Исхакович. Мирас,— дип яз! Мирасны дөрес языгыз. *(Нуркасыймга.)* Бигрәк тә сиңа әйтәм. Ми-и-и-рас дип өч "и" белән язма. Бу сиңа "аять" түгел.

Нуркасыйм. Өйрәтмә! Башың яшь! Ничек язарга кирәген белермен.

Йосыф Исхакович. Кемгә тапшыра?

Нуркасыйм. Миңа!

Йосыф Исхакович *(Нуркасыйм булып).* Миңа... Сиңа гына түгел шул, безгә тапшыра.

Нуркасыйм. Аңладым инде, аңладым. Безгә тапшыра. *(Яза.)* Без-гә. Булды.

Йосыф Исхакович. Ашыкмагыз. Хәзер мин язам. *(Яза.)* Менә шулай.

Мөстәкыйм. Хәзер исемнәребезне куябыз, әйе бит, дәү абый. *(Иҗекләп яза.)* Мөс-тә-кыйм-гә.

Нуркасыйм *(ана ияреп).* Мөс-тә-кыйм-гә. Булды бу.

Мөстәкыйм. Дәү абый, минем кәгазьгә кара әле, исемемне дөрес язганмынмы?

Нуркасыйм. Эчемне пошырып, секунд саен сорап утырма инде. Тот та миннән күчереп яз.

Йосыф Исхакович. Тап-шы-рам,—дип языгыз.

Нуркасыйм, Мөстәкыйм. Тап-шы-рам.

Йосыф Исхакович. Бүгенге числоны, айны куярга онытмагыз.

Нуркасыйм. Өйрәтмә. Аңа гына башыбыз җитәр.

Мөстәкыйм *(Нуркасыймның кәгазенә күз ташлый).* Дөрес икән.

Нуркасыйм. Нәрсә дөрес икән?!

Мөстәкыйм. Исемеңне дөрес язгансың икән.

Нуркасыйм. Мин бит, энекәш, армиядә писарь булган кеше. Йосыф Исхакович шикелле өч диплом сатып алмасак та, төшеп калганнардан түгел. Аллага шөкер. Кояш дигән сүздә биш хата җибәрмибез. *(Йосыф Исхаковичка.)* Нәрсә сырлаган буласың инде. Кайсы исемеңне язарга белмисеңме әллә? Кыскарагын яз. Хатасы азрак булыр. Хосе, йә булмаса Осип дип куй. Юзев дип яза күрмә. "Е" белән "и"не бутарсың. Менә мин атам кушкан исемемне Нуркасыйм дип, тутырып язып куйыйм әле. *(Яза.)* Нур-ка-сыйм! Булды бу. Менә хәзер настоящий точканы куйсаң да була. Точка!

Йосыф Исхакович. Өйрәтмә аңгыра башың белән. *(Язган кәгазенә карап.)* Булды бу. Мөстәкыйм энекәшнең кулы гына кирәк. *(Кәгазьне Мөстәкыймгә суза.)* Ал, энем.

Нуркасыйм. Ашыкма энем. Чиратсыз кермә. Атаң урынына калган дәү абыеңның барлыгын онытма. *(Мөстәкыймгә кәгазен суза.)* Мә, энем. Башта үзеңә—үзең кул куй да, аннары миңа

куярсың.

Мөстәкыйм. Китер. (Нуркасыймнең кәгазенә кул куя.)

Нуркасыйм *(кәгазен алып).* Ниһаять, булды бу.

Мөстәкыйм. Кая, кечкенә абый, сина да куйыйм.

Йосыф Исхакович. Мә. Ал, энекәш.

Мөстәкыйм *(кәгазьне алып кул куя).* Булды бу.

Нуркасыйм. Димәк, Мөстәкыйм—беренче, мин—икенче, син Хосе—өченче!

Йосыф Исхакович. Хикмәт беренчедәмени...

Мөстәкыйм. Зато өчебездә дә доверенность бар. Әйдә, дәү абый, укып җибәр үзеннән доверенностенне.

Нуркасыйм. Була ул, энекәш. *(Укый.)* Мин, Нуркасыйм, үземнән борынгы хан бабамнын үземә атап җибәргән мирасын безгә Мөстәкыймгә тапшырам. Беренче число, ай, ел. Нуркасыйм.

Йосыф Исхакович. Фамилияңне дә куй инде. Нуркасыйм Февральский дип.

Нуркасыйм. Нәрсә?

Йосыф Исхакович. Ангыракаем! Син бит үз-үзенә доверенность язгансың. Менә тынла. Доверенностьны ничек язалар аны. Мин Мөстәкыйм, үземнән борынгы хан бабамның үземә атап җибәрелгән мирасын Йосыф Исхаковичка тапшырам. Беренче число, ай, ел.

Йосыф Исхакович *(Аптырап озак кына кәгазьгә карап торганнан соң.)* Тукта әле. Нишләп болай килеп чыкты соң әле бу. Үземә... Йосыф Исхаковичка... Йосыф Исхаковичка дип язганмын. Мөстәкыйм кул куйган.

*Музыка, ут сүнә.*

## Бишенче күренеш

*Ут янганда бүлмәдә Мөстәкыйм, Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович, Нуркасыйм, Минлениса, Йосыф, Суфия.*

Вил Вилданович. Хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде!

Мөстәкыйм *(тамашачыларга).* Кызык бу дөнья. Кичә генә адәм калдыгы идем, ә хәзер... *(Вил Вилдановичка.)* Мөстәкыйм генә диегез. Әфәндесе миңа килешеп бетми.

Касыйм Сабирханович. Алай димәгез Мөстәкыйм иптәш. Сез милләтебезнең йөзе!

Вил Вилданович. Иптәшләр. Мин сезгә важный яналык ачам. Кичә безнең егетләр кабаттан ханның васыятьнамәсен тикшергәннән соң, шундый мөһим җөмләгә тап булдылар.

Нуркасыйм. Ягъни мәсәлән?

Вил Вилданович. Ягъни мәсәлән... Тынлагыз. Васыятьнамәдә шундый юллар бар. Исәнме минем нәсел җебемне, нәсел шәҗәрәмне дәвам итүче ерак-ерак туганым, төпчек углым.

Касыйм Сабирханович. Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз?

Вил Вилданович. Васыятьнамәнең ахырына ихтибар итегез. Мин синең исемеңне, кем атлы икәнеңне белмим. Шуна күрә бу сандыгымны нәселемне дәвам итүче, ишетәсезме, дәвам итүче, ихтибарлы булыгыз, ир-ат затыннан булган төпчек торыным, ягъни оныгым, сина калдырам диелгән.

Касыйм Сабирханович. Нәселебезне дәвам итүче... Вил Вилданович, кабатлап шул җирен укыгыз әле.

Вил Вилданович. Нәселне дәвам итүче ир-ат затыннан булган...

Касыйм Сабирханович. Мин сезгә тик торганда гына васыятьнамәнең өтеренә кадәр өйрәнегез дип бюджеттан акча бирдермәдем. Күрәсез, васыятьнамә төбендә нинди фикерләр ята.

Йосыф Исхакович. Һич ни анламыйм.

Нуркасыйм. Мин дә.

Суфия. Йөз сиксән тапкыр укыган җөмлә.

Минлениса. Алай димәгез. Монда бик мөһим мәсьәлә ята.

Йосыф Исхакович. Ха, ха, ха... Мөһим мәсьәлә ди...

Мөстәкыйм. Юк инде, туганнар, уйларыгыз барып чыкмас. Мин өйләнмим. Үз тамагымны туйдыра алмаган килеш, кеше баласын алып, бәхетсез итеп, хәерче тудырасым юк.

Вил Вилданович. Ялгышма-

гыз, Мөстәкыйм әфәнде, Мөстәкыйм Исхакович.

Касыйм Сабирханович. Хан бабагыз сезне хөрмәт итеп, мең еллар элек сезнең бу якты дөньяга киләсегезне сизеп, сезгә шундый дәүләт калдырган икән, сез инде борынгы бабагызның йөзенә кызыллык китермәгез.

Вил Вилданович. Бабабыз диегез, Касыйм Сабирханович.

Касыйм Сабирханович. Сез инде хан нәселен дәвам итәргә алынгансыз икән, давай, өйләнегез. Күреп торасыз, нәселемне дәвам итүче, дигән. *(Мөстәкыймгә.)* Ә сез дәвам итәсезме? Юк. Бүгенгә кадәр өйләнмәгәнсез. Үзегезгә шактый яшь.

Йосыф Исхакович *(пышылдап, Суфияга)*. Син авырлы. Син авырлы.

Суфия *(пышылдап, Йосыфка)*. Ничек авырлы?

Йосыф Исхакович. Син корсаклы!

Суфия. Ничек корсаклы?

Йосыф Исхакович *(пышылдап)*. Ангыра! Син корсаклы. Мин нәрсә әйтсәм шуны җөпләп бар. Иптәшләр, гафу итегез. Ул өйләнде!

Касыйм Сабирханович *(аптырап)*. Ничек өйләнде?

Вил Вилданович. Өйләнде?

Йосыф Исхакович. Әйе, өйләнде.

Нуркасыйм, Минлениса. Кайчан өйләнде?

Йосыф Исхакович *(Нуркасыйм белән Минленисага пышылдап)*. Тик торыгыз, ангыралар. Сизмисезмени, хан мирасын кулдан тартып алмакчы булалар. Мин нәрсә әйтсәм, әйе, дип торыгыз. Җәмәгать, Мөстәкыйм өйлән-де!

Касыйм Сабирханович. Кемгә?

Йосыф Исхакович. Суфияга!

Вил Вилданович. Ничек Суфияга?

Касыйм Сабирханович. Суфия бит синең хатының.

Йосыф Исхакович. Элек минем хатын иде, хәзер энекәш хатыны.

Касыйм Сабирханович *(Мөстәкыймнән)*. Җиңгәнә өйләндеңмени?

Мөстәкыйм. Белмим шул. Күптәннән эчкәнем дә юк инде...

Вил Вилданович. Үзенең җиңгәсенә өйләндеме?

Йосыф Исхакович. Әйе. Үз җиңгәсенә.

Касыйм Сабирханович. Ә син Суфия белән кайчан аерылыштың?

Вил Вилданович. Әйе. Судыгыз кайчан булды?

Йосыф Исхакович. Ә без суд белән аерылышмадык, шулай бит дәү абый, Нуркасыйм.

Нуркасыйм. Нәрсә дип әйтергә дә белмим шул.

Йосыф Исхакович. Без хәзер шәригать законнары белән яшибез. Без хан нәселе. Борынгы бабабыз законы белән яшибез. Суфия белән Мөстәкыйм төнлә икәүдән икәү генә калгач, мин Суфияга өч тапкыр талак, талак, талак дидем. Шулай бит, җиңги, Минлениса?

Минлениса. Әйе, әйе, өч тапкыр талак диден.

Йосыф Исхакович. Әйттем бит, Нуркасыйм абый.

Нуркасыйм. Әйттең, әйттең, энекәш, әйттең. Әле өстәвенә үзенә әйттем, хатын кадәр хатыныңны да җәлләмисең инде, юмарт булсаң да булырсың икән, дидем.

Касыйм Сабирханович *(Суфияга)*. Ә син аның талак дигәнен ишеттеңме?

Суфия. Ишеттем, ишетмичә.

Вил Вилданович. Ябык ишек аркылымы?

Суфия. Ул кычкырганда мин ишекне тибеп ачтым.

Вил Вилданович. Нигә?

Нуркасыйм, Минлениса, Йосыф Исхакович. Шатлыктан.

Касыйм Сабирханович. Аерылышу шатлыгыннанмы?

Нуркасыйм, Минлениса, Йосыф Исхакович. Кавышу шатлыгыннан.

Касыйм Сабирханович. Һични аңламыйм. *(Вил Вилдановичка.)* Син берәр нәрсә аңлыйсыңма, юкмы?

Вил Вилданович. Юк.

Нуркасыйм. Аның нәрсәсен аңлыйсың. Энекәш Йосыф өч тапкыр талак әйтүгә, мин указлы мулла буларак, Мөстәкыйм белән Суфия киленгә никах укыдым. Шулай бит?

Минлениса. Шулай, шулай.

Вил Вилданович. Ә син, Мөстәкыйм, ризалыгыңны бирдеңме?

М ө с т ә к ы й м. Сез бигрәк. Нишләп мин ризалыгымны бирим. Абый хатынына өйләнергә сез мине кемгә саныйсыз.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч. Син, энекәш, давай не паникуй. Сүзеннән кире кайтма. Хан оныгы икәненне онытма.

К а с ы й м  С а б и р х а н о в и ч. Дөрес, Мөстәкыйм әфәнде! Хан оныгы буларак үз сүзегездә нык торыгыз! Иртәгә үзенә хатынлыкка кандидатлар конкурсы оештырабыз. Шәһәребезнен иң гүзәл, иң затлы кызлары сезнен алдыгызда, сезнен йөрәгегезне яулап алыр өчен көч сынаячаклар. Әзер булып торыгыз.

М ө с т ә к ы й м. Карагыз аны, күбрәк чакырыгыз. Мин үзем төскә-биткә, буй-сынга алама булсам да, хатын-кыз мәсьәләсендә бик нәзберек.

К а с ы й м  С а б и р х а н о в и ч *(тамашачыларга).* Сасы көзән! Татар баеса хатын ала, урыс баеса чиркәү салдыра. Хак икән.

*Музыка. Ут сүнә.*

## Алтынчы күренеш

*Ут янганда сәхнәдә шул ук бүлмә. Әмма ул бик матурлап бизәлгән. Бәйрәм төсе алган. Сул порталда тәбәнәк кенә үзбәкләр чәйханәсенә охшаган, келәм капланган сәке. Сәкедә аш-су. Уртада аякларын бөкләп Мөстәкыйм, анын уң ягында Нуркасыйм һәм Йосыф Исхакович, ә сул ягында Касыйм Сабирханович, Вил Виллановичлар. Каршыларында затлы, ялтыравыклы чалма-чапаннан яшь чибәр егет курай уйнап утыра. Анын алдында зур бизәкле кувшин. Егет уйнавыннан туктала.*

Е г е т. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде, хөрмәтле шәһәребез кунаклары. Кувшиннан елан чыгарып булмады. Бүгенге бәйрәмнең шарты елан чыгару түгел. Бүгенге мәҗлесебезнең максаты, күңел ачу белән генә чикләнмичә, борын-борыннан килгән мирасыбызның, милләтебезнең асыл кызларын барлау, хан нәселен дәвам итүче, хан оныгы Мөстәкыйм әфәнде Исхакетдин улына яр эзләү. *(Егет уң кулын сузып.)* Хан оныгы, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде галиҗәнабләре беренче номерлы чибәр, яшь сылу кызны бирегә чакыра. Музыка. *(Шәрык музыкасы көчәя. Бүлмәгә ярым шәрә шәрык кызларына хас киенгән, уң кулына беренче номер таккан кыз чыга да бии башлый. Ара-тирә, килеп, Мөстәкыймгә сырыша.)*

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч *(Нуркасыймга пышылдап).* Ничек тә сайлатмаска тырыш. Хан мирасын үзләренә калдырыр өчен уйлап табылган хәйләләре.

Н у р к а с ы й м *(кул чаба).* Булды, булды, хватит! *(Музыка кими, кыз биюеннән туктый да, матур кыяфәт ясап, бүлмәдән чыгып китә.)*

М ө с т ә к ы й м. Нәрсә булды. Нигә туктаттыгыз? Дөньямны онытып карап утырган җирдән, шапы-шыпы кул чабып матурлыкны, гүзәллекне туктаттыгыз.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч *(Мөстәкыймнең колагына пышылдап).* Исең китмәсен. Күрмисеңмени, аяклары кәкре.

М ө с т ә к ы й м. Булса соң. Сиңа кыз сайлыйбызмы, әллә миңамы?!

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч *(Нуркасыймга).* Әйт әле шуна берәр сүз.

Н у р к а с ы й м. Күзең чыкмагандыр бит, энекәш. Кендегенә кара.

Й о с ы ф  И с х а к о в и ч, М ө с т ә к ы й м. Кендегенә нәрсә булган?

Н у р к а с ы й м. Нәрсә булган, нәрсә булган? Борчак кадәрле генә калган.

К а с ы й м  С а б и р х а н о в и ч *(Мөстәкыймнең колагына).* Абыең хаклы. Борчылма. Алда әле аның затлылары.

Е г е т. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде, хөрмәтле кунаклар! Сезнең алда чыгыш ясаган беренче номерлы асыл зат турында кыска гына мәгълүмат. Исеме—Декабрина! Алдагы гасырда туган, нәселе затлы. Кичә үзен урыс милләтеннән санаса, бүгенгесе минутта татар милләтеннән саный. Буе бер метр да кырык тугыз сантиметр. Чәче сары, кашы кара, күзе яшел. Пони нәселеннән. *(Уң кулын сузып.)* Хәзер икенче номерны чакырабыз. Рәхим итегез икенче номер! Маэстро, музыка. *(Музыка көчәя.)*

К а с ы й м  С а б и р х а н о в и ч *(Мөстәкыймгә).* Минем үземә иң ошаганы менә шушы икенче номер. *(Бии-бии икенче номер чыга. Мөстәкыйм шар-*

*кылдап көлеп җибәрә.)* Нигә көләсез?

Мөстәкыйм. Кызык бит.

Касыйм Сабирханович. Нәрсәсе кызык?

Мөстәкыйм. Көйгә баса белми.

Касыйм Сабирханович. Көйгә басу нәрсә ул. Йөрәккә баса. Кара син аның фигурасына. Фигурасы шәп бит, ә?

Мөстәкыйм. Тяжеловес!

Касыйм Сабирханович. Чебеш түгел инде.

Мөстәкыйм. Ялгыш салып кайтып моның йодрыгына эләксән, бер сугуда накаут ясый бу.

Касыйм Сабирханович *(Вил Вилдановичка).* Сиңа ошыймы?

Вил Вилданович. Шәп бу. Аркалыгын чамадан тыш күтәргән ат шикелле.

Касыйм Сабирханович. Синнән сораган мин дивана. Хатын-кыз аерган кеше сыман сөйләшеп торган буласың. Мөстәкыйм туган, тукта шушы кызга, алдатмассың. Минем бу мәсьәләдә опыт зур. Мин җиде хатын алып аерган кеше буларак, хатын-кызны мичкә керсә дә арт саныннан таныйм.

Мөстәкыйм *(кул чабып туктата).* Житте, булды. Азапламагыз баланы. Бар, сеңлем, бар, кер. Бии белмәгән кешегә биюдән дә авыр әйбер юк.

Касыйм Сабирханович. Нәрсә, сиңа бу кызның бер җире дә ошамадымени?

Мөстәкыйм. Бер җире дә дип инде... Күкрәкләре ошады да соң, но бит күкрәккә генә карап яшәп булмый бит әле. Тормыш булгач, бераз гына муены да, арт саны да, бил дигән нәрсәсе дә булырга тиештер бит.

Егет. Хөрмәтле туганнар. Хәзер сезнең рөхсәт белән икенче номер хакында кыскача гына мәгълүмат. Исеме—Нуркасимә... Буе ике метр да...

Нуркасыйм. Булды, булды, мәгълүмат кирәкми. Өченче номерны чакыр.

Егет. Хөрмәтле әфәнделәр, хөрмәтле галиҗәнап Мөстәкыйм әфәнде. Хәзер сезнең ихтибарыгызга күп милләтле илебезнең иң гүзәл затларыннан берсе, өченче номерлы илаһи затыбыз, татар һәм урыс тырышлыгы белән дөньяга туган, ике милләтне дә уртак күреп, үзенә Элеонора исеме алган чибәркәйне чакырабыз. *(Бүлмәгә бии-бии өченче номер чыга.)*

Вил Вилданович *(кул чаба).* Браво, браво! Афәрин! *(Мөстәкыймгә.)* Менә бу ичмаса асыл. Кара син аның аякларына. Аяклары колактан төшкән. Ә ул муен, ул күкрәкләре.... Сезнең урында, Мөсткыйм әфәнде, үзем булсам, ике дә уйламыйча шушы асыл затка тукталыр идем.

Мөстәкыйм. Да.. Дөрес әйтәсең. Миңа да ошый бу гүзәл.

Касыйм Сабирханович. Браво, браво! Афәрин! *(Кул чабып туктата.)* Рәхмәт, сеңлем. Сез Мөстәкыйм әфәндегә ошагансыздырмы, юктырмы, анысын белмим, но әтиегез Вил Вилдановичка искитмәле ошадыгыз. Рәхмәт сезгә. *(Өченче номер бии-бии чыгып китә.)*

Егет. Хөрмәтле дуслар, хөрмәтле әфәнделәр. Хәзер бирегә дүртенче номерны чакырабыз.

Касыйм Сабирханович. Постой, постой, энем. Өченче номер турында мәгълүматны ишетмәдек.

Егет. Гафу итегез, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде. Извините, господа. Әле генә сезне каршыгызда булып, сезне таң калдырган өченче номерлы гүзәл зат, Элеонора Вилевна егерменче гасырның азагында туып, егерме беренче гасырның башында күпләрне таң калдыручы Элеонора, урыс һәм татар милләтенең гүзәл өлгеләреннән берсе.

Касыйм Сабирханович. Рәхмәт. Безгә башкасы кирәкми.

Вил Вилданович. Нигә бүлдерәсез. Сөйләсен, сөйләсен.

Нуркасыйм. Сөйләмәсен. Безгә саф татар кызы кирәк. Шулай бит, Мөстәкыйм энем?

Мөстәкыйм. Шулай, абый.

Йосыф Исхакович. Дүртенче номерны чакырсыннар. Дүртенче номерны.

Егет. Хөрмәтле кунаклар. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде. Хәзер сезнең соравыгыз буенча шәрык музыкасына коенып, шәрык музыкасында йөзеп, бүгенге мәҗлесебезгә тагын да якты нур өстәп, дүртенче номерлы Мәгъруфкамалны алкышларга күмеп бирегә чакырабыз. *(Музыка көчәя, бүлмәгә, бии-бии, ярым шәрә Суфия чыга.)*

Нуркасыйм *(шаркылдап көлә).* Охшаса да, охшар икән. Ка...а...ра әле,

ка...ра. Монысы гел безнең Суфия киленгә охшаган.

Йосыф Исхакович. Кая ошасын инде. Суфия янында бу курчак. Аннары Суфия янында бу бит әле сабый гына.

Нуркасыйм. Ха... ха... ха... Кара инде, кара. Сикереп, сикереп куямы? Әй бичара. Байлык адәм баласын ниләр генә эшләтми. Ха... ха... ха... Иелеп аягыңны дә күтәреп күрсәт инде.

Мөстәкыйм. Ха... ха... ха... Афәрин, афәрин! Молодец, булдырасың.

Йосыф Исхакович *(Мөстәкыймгә)*. Әллә ошыймы, энекәш?

Мөстәкыйм. Класс! Во, абый. Вот это номер! Браво! Браво! Бис!

Йосыф Исхакович. Афәрин! Афәрин! *(Онытылып китеп.)* Әйдә, әйдә, Суфия.

Нуркасыйм. Кем дисең?! Суфия дисеңме?

Йосыф Исхакович. Син үзең Суфия. Колагыңны чистарт. Мәгъруфкамал димен!

Мөстәкыйм. Уф, үтерә бу мине. Әйдүк, әйдүк әйтергенәсе, сыгылмасмы идәне! *(Барысы көлә-көлә кул чаба башлыйлар. Суфия бии-бии кереп китә.)* Рәхмәт абый. *(Йосыф Исхаковичка кулын суза.)* Молодец абый. Синең башка гына мондый юмор килә ала. Менә ичмасам бу номер. Алайса скучно була башлаган иде. Җәмәгать! Мин болай хатын сайлый алмыйм.

Касыйм Сабирханович. Нигә?

Мөстәкыйм. Нигә, нигә. Беренче чыккан кызның йөзен онытып та өлгердем инде мин. Сез каршы килмәсәгез, барсын да бергә чакырыйк. Сез каршы түгелме?

Вил Вилданович. Мин каршы түгел.

Касыйм Сабирханович. Мин дә каршы түгел.

Йосыф Исхакович. Мин каршы.

Касыйм Сабирханович. Нигә каршы?

Йосыф Исхакович. Потому что энекәш Мөстәкыйм арыды. Ялгышып үзенә охшамаган хәләл, ягъни кәләш, хатын сайлавы бар. Ни генә әйтсәгез дә без ханбикә сайлыйбыз.

Нуркасыйм. Мин дә каршы.

Мөстәкыйм. Юк инде. Көн дә хатын сайлап утырып булмый. Бүген эшне бетерәбез.

Касыйм Сабирханович *(егеткә)*. Барысын да бергә чакыр.

Егет. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде. Хәзер сезнең йөрәгегезгә матур чәчәк булып кадалырга ут йотып торган хур кызларын чыгарам. Музыка! Хөрмәтле мөхтәрәм туганнар. Хан оныгы сезне көтә. *(Булмәгә җиде кыз чыгып бии башлыйлар. Алар янына Мөстәкыйм дә чыгып кушыла.)*

Мөстәкыйм *(биеп бетергәч)*. Хөрмәтле туганнар. Сезнең рөхсәт белән мин сезгә шуны җиткерәм. Шушы минуттан бу җиде асыл затларның барысын да минем кәләшләрем дип уйлый аласыз.

Нуркасыйм, Касыйм Сабирханович, Йосыф, Вил Вилданович. Барысы дамы?

Мөстәкыйм. Әйе барысы да!

Нуркасыйм, Касыйм Сабирханович, Йосыф, Вил Вилданович. Берүзеңәме?

Мөстәкыйм. Әйе, берүземә. Борынгы бабайлар көтүе белән хатыннар тотканнар, ә мин алардан киммени. Җиде хәләл, җиде хатын, җитмеш бала, җитмеш татар!

*Музыка. Ут сүнә.*

## Җиденче күренеш

*Ишектә звонок тавышы.*

Мөстәкыйм. Очтым. Хәзер ачам. Сабыр итегез. *(Ишеккә юнәлә. Ишекне ачып җибәрүгә булмәгә өч галим: Гали Вәлиевич, Вәли Галиевич, Сәли Салриевич, Александр Александрович һәм Нуркасыйм килеп керәләр.)*

Гали В., Сәли С., Вәли Г. Исәнмесез?

Александр Александрович. Здравствуйте?

Йосыф. Саумысыз.

Гали В., Сәли С., Вәли Г. О... Иосиф Исакович. *(Күрешәләр.)*

Александр Александрович. Здравствуйте, Осип Исакович.

Йосыф Исхакович. Сан Са-

ныч, извините пожалуйста. Я не Осип, Иосиф та түгел. Минем атам кушкан исемем бар. Мин Йосыф, отчеством да Исхакович. Исем, отчествомны бозмавыгызны үтенәм.

Александр Александрович. Извините, пожалуйста. Вы всегда представлялись Осипом Исаковичом.

Йосыф Исхакович. Ну и что. Хәзер Йосыф.

Александр Александрович. Извините.

Вәли Галиевич. Нигә сез паспортыгызда Иосиф Исакович түгелме соң?

Йосыф Исхакович. Паспорт нәрсә ул. Паспорт кемдер язып биргән кәгазь ведь ул. Сез минем туу турындагы таныклыгымны карагыз.

Нуркасыйм. Әйе. Әйе, җәмәгать. Мин аның атасы урынына калган иң зур дядясы буларак шуны әйтә алам. Аның митрәкәсенә Йосыф дип язылган. Алла тарафыннан арттырылган, өстәлгән дигән төшенчәне аңлата.

Йосыф. Күркәмлек, гүзәллек иясе. Легендар Йосыф пәйгамбәр исеме.

Сәли Садриевич. Иптәшләр. Без бирегә исем тикшерергә килмәдек. Төлкегә күпме генә бүре дисәң дә, төлке булып кала. Хикмәт исемдә түгел. Хикмәт Казан каласының беренче казыгын табуда. Мин "Казык" фәнни тикшерену үзәге булып формалашкан "Казык" тикшерену институтының комиссия рәисе Сәли Садриевич. Бу югары дәрәҗәле урынны мин үзем сорап алмадым. Үзегезгә мәгълүм ки, бу югары постны миңа хөкүмәтебез ышанып тапшырды. Комиссиянең сәркәтибе итеп археология фәннәре докторы, профессор, академик Гали Вәлиевичны билгеләргә дигән тәгъдим белән чыгам. Кем дә кем мин әйткән, мин күрсәткән кандидатура белән килешә, Гали Вәлиевичны, "Казык" фәнни тикшерену институтының баш сәркәтибе итеп сайларга дип тавыш бирүләре сорала.

Гали Вәлиевич *(кулын күтәреп)*. Мин риза!

Вәли Гәлиевич *(кулын күтәрә)*. Риза булырга мәҗбүрмен.

Александр Александрович. Мин тоткарланам.

Сәли Садриевич. Мин рәис буларак ике тавышка ия. Мин риза. *(Кулын күтәрә.)* Каршылар юкмы?

Нуркасыйм. Мин каршы.

Йосыф Исхакович. Мин риза.

Сәли Садриевич. Ә сез коллегия әгъзалары түгел. Димәк, күпчелек тавыш белән иптәш Гали Вәлиевичны институтыбызның баш сәркәтибе итеп билгеләргә дигән карарга килдек. Протоколга язып куегыз.

Вәли Гәлиевич. Протоколны кем яза?

Сәли Садриевич. Билгеле инде, сәркәтиб Гали Валиевич. *(Өстәлгә олы ап-ак кәгазь җәеп сала.)* Барыбыз да белгәнебезчә, сандыкны ачарга санаулы көннәр калып килә. Хөкүмәтебез безнең өскә зур җаваплылык тапшырды. Тиз арада сандыкны ачканчы, Казанның беренче казыгын табу мәсьәләсен. Кемнәрдә нинди фикерләр барын. *(Гали Вәлиевич кулын күтәрә.)* Рәхим итегез, Гали Вәлиевич.

Гали Вәлиевич. Сүз башы итеп, барыгызга да рәхмәтемне белдерәм. *(Күңеле тулып.)* Миңа ышанып шушындый зур пост—"Казык" институтының баш сәркатибе итеп сайлавыгыз белән барыгызга да рәхмәтлемен. *(Дымланган күз төбен кулъяулыгы белән сөртеп ала.)* Кичә министрлар кабинетында бу эшкә лаеклы галим дип минем исемемне фәнни тикшерену институтына керткәч, мин шул ук минутта эшкә керештем.

Вәли Галиевич. Йә, йә...

Сәли Садриевич. Нинди фикерегез бар? Иптәшләр, бүлдермәгез.

Гали Вәлиевич. Казык юк!

Мөстәкыйм. Юк?

Йосыф Исхакович. Ничек юк?

Мөстәкыйм *(дисбе тартуыннан туктап)*. Казык бар!

Гали Вәлиевич *(Мөстәкыймгә)*. Гафу итегез, казык юк!

Мөстәкыйм. Казык бар!

Сәли Садриевич. Мөстәкыйм әфәнде, гафу итегез, авыр булса да әйтим, сез әле бу мәсьәләдә бик надан.

Александр Александрович. Сезгә безнең арага керү өчен бер пот тоз ашарга кирәк.

Мөстәкыйм. Казык бар!

Гали Вәлиевич. Казык юк!

Сәли Садриевич. Нинди источникка таянып казык юклыгын фаразлый аласыз?

Гали Вәлиевич. Ягъни мәсәлән, казык мең ел элек хан тарафыннан Казан каласын төзергә дип шушы жиргә, шушы төбәккә кагылган дип фаразлыйк.

Нуркасыйм. Әйе. Мең елдан артык.

Гали Валиевич. Мең ел элек кагылган казык нинди материалдан булган дип уйлыйсыз.

Вәли Гәлиевич. Билгеле, казык тимердән булган.

Александр Александрович. Әлбәттә, тимердән.

Гали Вәлиевич. Билгеле, казык агачтан булган. Мең ел элек безнең халык тимер эшкәртмәгән. Хан Казансу елгасы янына килгән. Биленнән үткен тимер балтасын алган да, яр буенда үсеп утырган талны кисеп алып очлаган да, Казан төзеләсе урынга казык каккан.

Вәли Гәлиевич. Юк инде. Безнең бабайлар Болгарда сарай салганда ук тимер эшкәртә башлаган. Казык тимердән булган.

Гали Валиевич. Юк, агачтан!

Александр Александрович. Дөрес. Мең ел элек сезнең халыкның тимер төшенә дә кермәгән. Казан каласы сез уйлаганча мең ел элек түгел, примерно жиде йөз илле ел элек төзелә башланган. Жиде йөз илле ел элек урыслар тарафыннан тимер, чуен эшкәртү табылган. Казан каласына хан казыкны тимердән каккан.

Мөстәкыйм. Нәрсә? Мина сандыкны ачар өчен тагы ике йөз дә илле ел көтәргә мени?

Александр Александрович. Ни эшлисең, тарихка каршы килеп булмый.

Нуркасыйм. Сезнең фикер йөртүегез буенча, нәрсә, сандыкны китергән илчеләр ялгышканмени?

Александр Александрович. Күрәсең, ялгышканнар. Иптәшләр, сез сандыкка ихтибар итегез. Сандыкта берәр тимер кисәге бармы? Питлә, бикләвеч, йозак ише әйберләр юк. Акылыгызга килегез. Мең ел элек сезнең халыкта тимер булмаган. Димәк, Казан сез уйлаганча мең ел элек түгел, тик жиде йөз илле ел элек төзелгән.

Сәли Садриевич. Яхшы. Сез уйлаганча Казан каласына хан, тимер казык каккач, мина шуны әйтегез: ни өчен хан сандыкны тимер йозак белән бикләмәгән?

Александр Александрович. Бөтен хикмәт тә шунда. Сорау туа. Ни өчен хан таш сандыкны тимер йозак белән бикләмәгән?

Мөстәкыйм. Хан үзенең киләчәгенә, үз халкына, халкының иманлы, намуслы булуына ышанган. Хан сандыкны бикләүне кирәк дип санамаган.

Йосыф Исхакович. Хан сандыкка тимер кертүне кирәк дип санамаган икән, димәк казыкның тимер булуы да ана мөһим булмаган.

Сәли Салриевич. Яхшы. Казыкны агачтан булган дип фаразлыйк. Казык урыны кайда?!

Александр Александрович. Әйе. Казык агач ди. Казанга мең ел ди. Казык кая соң? Казык юк. Агач мең ел эчендә череп туфрак була.

Йосыф Исхакович. Мең ел өчендә тимер казык та череп жир була.

Нуркасыйм. Димәк, ай казыкка эленеп калмаячак. Димәк, без сандыкны ача алмаячакбыз. Димәк, безнең милләтнең мирасы, киләчәге юкка чыгачак.

Александр Александрович. Хөрмәтле галимнәр, Сезгә безнең галимнәргә таянырга кирәк. Казанга нибары иң күбендә жиде йөз илле ел. Ышаныгыз мина. Сезгә, Казан казыгын табу өчен, дәүләтле булыр өчен, тагын ике йөз дә илле ел көтәргә кирәк. Шул чагында гына сез дәүләтле булаласыз!

Вәли Галиевич. Юк инде, Александр Александрович. Гафу итегез. Жәмагать, мин сезне тыңлап-тыңлап тордым да, сынап карамак булдым. Һәм сезнең наданлыкка тагын бер кат инандым. Казык бит агач та, тимер дә булмаган. Казык, сандык кебек үк, таштан булган. Казан каласы—баш кала, баш калаларга таш кала!

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. Менә галим! Афәрин! *(Кул чабалар.)*

Нуркасыйм. Галимнәрнең галиме сез, Вәли Галиевич.

Йосыф Исхакович. Сезгә бу хезмәтегез өчен Нобель премиясе бирергә кирәк.

Александр Александрович. Туктагыз, туктагыз әле. Кул чабарга ашыкмагыз. Нобель премиясен алай тиз генә алып булмый ул. *(Вали Галиевичка.)* Тирәнрәк аңлатуыгызны көтәм. Нинди

версиягә таянып, нигезләнеп, бу фикергә килдегез?

Вәли Гәлиевич. Минем версиям шул. Моннан мең ел элек Казан каласына хан казык какканда тимер булгандырмы, юктырмы, анысын беребез дә әйтә алмыйбыз. Беребез дә барып күрмәгән. Тик шунысын беләм, мең ел эчендә агач та, тимер дә череп юкка чыга. Ә таш?! Таш мәңгелек!

Йосыф, Нуркасыйм. Афәрин, афәрин Вәли Гәлиевич.

Нуркасыйм. Болай булгач, сандык ачыла!

Йосыф. Болай булгач, милләт яши!

Йосыф, Нуркасыйм. Браво, афәрин, Вәли Гәлиевич! *(Кул чабалар.)*

Гали Вәлиевич. Яхшы. Сезнеңчә казык таш булган ди. Миңа шуны аңлатып бирегез. Сезнең әйтүегезгә караганда тимер булмаган. Булмагач, таш казыкны ничек эшкәрткәннәр?!

Александр Александрович. Әйе. Ничек очлаганнар?

Вәли Галиевич. Кем, кем сез, Александр Александрович, мондый сорау бирерсез дип һич кенә дә башыма китермәгән идем. Гали Вәлиевичка ярый инде. Ни әйтсәң дә ул мылтыксыз кырда куян аткан кеше. Казык кагарга тимере булмаган хан, елга буеннан билендәге үткен тимер балтасы белән тал кисеп ала да, казык итеп җиргә кага. Ә син... Син бит зур галим. Сиңа мондый сорау бирү килешми. Очларга, шомартырга өйрәнгән халык очлау мәсьәләсен күршесеннән кереп сорамый.

Сәли Садриевич. Яхшы. Казык таш булсын ди. Алга китик.

Мөстәкыйм. Юк инде. Казык таш та, агач та, тимер дә түгел. *(Барысы ды шаркылдап көләләр.)*

Йосыф Исхакович, Нуркасыйм. *(Мөстәкыйм янына киләләр дә, пышылдап.)* Тик кенә утыр инде.

Йосыф Исхакович *(пышылдап)*. Намазлык өстендә утыра-утыра саташа башлагансың.

Нуркасыйм *(Мөстәкыймгә пышылдап)*. Көтүләре белән эшләрен калдырып безнең өчен, синең өчен казык эзләп утыралар. Ә син?

Мөстәкыйм. Ә мин нәрсә?! Үзләре өчен, милләт өчен. Казыкны бүген эзлисе түгел иде. Алданрак эзлисе иде. Казык таш та түгел, тимер дә түгел, агач та түгел. *(Барысы да кычкырып көләләр.)*

Сәли Садриевич. *(Йосыф белән Нуркасыймнан.)* Бу энегезнең тамагына ашаганы бармы? Врачка күрсәткәнегез бармы?

Нуркасыйм, Йосыф Исхакович. *(Мөстәкыйм янына киләләр. Пышылдап.)* Төш, төш намазлыктан. Саташа башладың.

Нуркасыйм. Йосыф, энекәштән хан оныгы ясыйбыз дип, үзеннән җүләр ясыйбыз лабаса. *(Мөстәкыймгә.)* Төш, төш энем, намазлыктан, төш. Харап буласың.

Мөстәкыйм. Төшмим! Тәмам жәлегемә төштегез. Жиде тапкыр намазымны бүлдердегез. Колагымда агач та таш, тимер дә агач, агач та таш! Шул казык белән үземне бастырыклап куйдыгыз. Життеме сезгә, юкмы?!

Сәли Садриевич. Алайса әйтегез. Сезнеңчә казык нинди материалдан?

Мөстәкыйм. Агач та түгел, тимер дә түгел, таш та түгел. Вакыты житкәч, күрсәтермен.

Гали Вәлиевич. Ә син безгә хәзер күрсәт.

Вәли Галиевич. Безнең тотып карыйсыбыз килә.

Мөстәкыйм. Кызыкмыни?

Александр Александрович. Әйе, кызык.

Мөстәкыйм. Вакыты житкәч, тотарсыз!

Гали Вәлиевич. Юк. Безнең хәзер тотып карыйсыбыз килә.

Мөстәкыйм. Ашыкмагыз. Күп калмады. Озакламый тотарсыз. Татар тотып карамый ышанмас.

Йосыф. Иптәшләр, ана игътибар итмәгез.

Сәли Садриевич. Күрәсез, егетнең таш сандык күргәч зиһене таралган. Алмашына ук башлаган.

Гали Вәлиевич. Байлык харап итә ул.

Мөстәкыйм. Миңа сезнең казыгыгыз кирәкми. Кадалып китегез.

Барысы бергә *(жайлап кына, әкрен генә)*. Сиңа нәрсә кирәк соң?

Мөстәкыйм *(түшәмгә төртеп күрсәтеп)*. Ай!

Барысы бергә *(түшәмгә карыйлар)*. Ай?

Мөстәкыйм. Әйе. Ай!

Сәли Садриевич *(Гали Вәлиевичтан).* Нәрсә ди?

Гали Вәлиевич. Ай, ди.

Вәли Галиевич *(Сан Санычтан).* Ай диме?

Александр Александрович. Ай, ди.

Нуркасыйм *(Йосыфка).* Харап иттек энекәшне.

Мөстәкыйм *(намазлыкта тезләнгән килеш түшәмгә карап ике кулын югарыга күтәреп).* Мина ай кирәк. *(Барысы да жайлап кына Мөстәкыйм янына киләләр дә, аны тотып бастыралар.)*

Нуркасыйм. Булыр. Булыр энем, ае да, кояшы да булыр.

Йосыф Исхакович. Мөстәкыйм энем, әйдә, диванга ятып тор.

Мөстәкыйм. Мина ай кирәк.

Сәли Садриевич. Булыр. Булыр, ае да булыр.

Вәли Галиевич. Син ятып тор.

Мөстәкыйм. Әгәр ул көнне айны болыт капласа?

Александр Александрович. Капламас. Капламас, борчылма.

Мөстәкыйм. Ай бабам казыгына эленеп калмаса...

Йосыф Исхакович. Эленер. Эленер, энем.

Мөстәкыйм. Милләт нишләр? Таш сандык эчендәге халкым мирасы нишләр?

Александр Александрович. Борчылма, энем, борчылма.

Гали Вәлиевич. Без барда барысы да тәртиптә булыр.

Мөстәкыйм (Гали Вәлиевичка). Рәхмәт, агач галим абзый. Рәхмәт!

*Диванга илтеп салалар. Өстенә юрган каплыйлар.*

Сәли Садриевич. Җәмәгать, өстәл янына килегез. Безгә хәзер казыкның урынын табарга кирәк.

Гали Вәлиевич. Нигә?

Сәли Садриевич. Нигә, нигә?! Казыкның урынын эзләп табып, казыкның ташмы, агачмы, тимерме икәнен белү өчен!

Сәли Садриевич. Кемдә нинди фикерләр бар? Казыкны каян эзли башлыйбыз?

Александр Александрович. Миндә бер фикер бар.

Сәли Садриевич. Йә, әйтеп карагыз, Сан Саныч.

Александр Александрович. Минем фикер йөртүем буенча, казыкны Яна бистәдән эзләргә кирәк. Татар халкы Яна бистәдә генә калды.

Мөстәкыйм *(юрган арасыннан башын чыгарып).* Фикерегез ялгыш! *(Юрганын бөркәнә.)*

Вәли Галиевич. Юк инде. Казыкны Кремльдән эзлибез. Казан каласы шуннан төзелә башланган.

Сали Садриевич, Гали Вәлиевич, Нуркасыйм, Йосыф. Дөрес! Казан Кремльдән төзелә башланган.

Сали Садриевич. Ә ничек эзлибез?

Александр Александрович. Минем бер фикерем бар.

Сали Садриевич, Гали Вәлиевич, Вәли Гәлиевич. Йә, йә нинди фикер?

Александр Александрович. Кремльнең почмакларыннан капмакаршы бау сузабыз.

Вәли Галиевич. Шуннан...

Александр Александрович. Бау, кайда кисешә. Казык шунда була.

Барысы бергә. Дөрес!

Мөстәкыйм. *(Юрганнан башын чыгара).* Кремльнең коймасы мең ел эчендә туксан тугыз тапкыр үзгәртелгән. Койма бабам төзегән чактагы халәтен югалткан. Бау, җеп киселеше дөрес түгел! *(Юрганын бөркәнә.)*

Сали Садриевич. Башына зәгыйфьлек килсә дә, аның сүзендә дөреслек бар.

Александр Александрович. Ә без бау кисешкән урының кинерәк итеп казыйбыз.

Йосыф. Анысы дөрес. Ә җепне ничек тартабыз?

Нуркасыйм. Җеп тартырга бит Кремль эчендәге йортлар мешать итәчәк! Ягъни мәсьәлән Сөембикә манарасы...

Александр Александрович. Сүтү мәсәләсен күтәреп, түрәләргә хат язабыз.

Сали Садриевич. Риза булмаслар...

Гали Вәлиевич. Ни әйтсәң дә үткәнебезнең тарихы, борынгы мирасыбыз.

Александр Александрович. Бу мәсьәләне үз өстемә алам.

Мөстәкыйм *(юрганнан башын чыгарып)*. Ул булдыра. Олы абыйлардан зур акча сорап ала да, иске Казанны сүттергән кебек, башында торып Кремльне сүттерә. Ә сез авызыгызны ачып, шатланып үзегезгә яңа йорт салырга урын көтеп торырсыз. Юк инде. *(Урыныннан сикереп тора да диванга баса.)* Минем борынгы бабам зиһенле һәм зирәк булган. Казан казыгы нәкъ менә шушы җирдә. Тереклек, үсемлек, яшәеш кояшка тартылган кебек, минем борынгы хан бабам да бирегә, менә шушы урынга тартылган. Яшәешнең казаны нәкъ менә шушы урында. Кояшның иң уңдырышлы нуры нәкъ менә шушы җирдә. Кояшның җылысы, назы ком сәхрәләрендә, йә булмаса Себер котыпларында түгел. Моны борынгы бабам бик яхшы белгән. Тереклеккә ял итәргә йокы кирәк булган кебек безне тудырган җир анабызга да ял кирәк. Ямьле җәйдән соң, таянып торырга көз кирәк, йоклап алырга кыш, сулыш алыр өчен яз кирәк. Кояшның төп ноктасы биредә. Ямьле җәе дә, җир анаңы ял иттерүче карлы, буранлы ап-ак юрганлы кышы да булган уңдырышлы җир кирәк. Минем борынгы хан бабам үз-үзенә сорау биргән.—Тереклеккә, адәм баласына яшәр өчен ни кирәк?

Барысы бергә. Һава.

Мөстәкыйм. Адәм баласына тереклек итәр өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Су!

Мөстәкыйм. Адәм баласына тереклек итәр өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Ризык!

Мөстәкыйм. Ризык табар өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Уңдырышлы җир, кояш кирәк!

Мөстәкыйм. Ул ризыкны пешерер өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Казан!

Мөстәкыйм. Ул казанны асар өчен нәрсә кирәк? Вакытында җил дә исеп, яңгыры да ява торган, карлы, буранлы кышы да, кояшлы җылы җәе дә, ямле язы да булган—борынгы бабам казык каккан, җир кирәк.

Нуркасыйм. Син боларны каян беләсең?

Мөстәкыйм. Намазлыкка менеп, күзем кыйблага төшкәч, мәрхүм атам сүзе искә төште. Бер кешегә күршесе кергән ди. Хуҗа өстәлгә ботка куйган ди. Ботканың уртасына кашык йөзе белән чокыр ясап май салган ди. Комсыз күрше телгә килгән:—Минем туган авылда елга менә шушылай үргә ага иде,—дип, боткадагы майны кашыгы белән ерып үзенә агызган ди. Казан аскан хуҗа, янәшәсендә күзләрен мөлдерәтеп боткага карап утырган ач балаларына күз сирпеп алган да, ә менә мин үскән авылда елга менә шушылай борылып-борылып, болганып ага иде дип, ботканы болгатып куйган,—ди. Минем хан бабам, казык кагарга, казан асарга урынны дөрес тапкан. Ботксы да, мае да булган җирне сайлаган. Ботканы болгатырга гына өлгермәгән. Киләчәк буынга калдырган. Киләчәк буын йоклаган. Ботка мае елга булып күршегә аккан. Борынгы бабамның оныклары ач калган. Алар май елгасы буйлап бәхет эзләп чәчелгәннәр, сибелгәннәр. Тилмереп, диннәрен, гореф-гадәтләрен, татар булуларын онытканнар. Майлы боткадан мәхрүм калганнар.

*Музыка. Ут сүнә.*

## Сигезенче күренеш

*Ут янганда сәхнәдә—зур мәйдан. Балкып Колшәриф мәчете күренеп тора. Шәһәр халкы, килгән кунаклар Казанның меңьеллыгын бәйрәм итәләр. Уен-көлке, җырбию, төрле уеннар уйныйлар. Әкренләп уен-көлке, җыр-бию тына. Сәхнә караңгылана. Сәхнәдәгеләр барысы да намазлыкка утыралар. Бар белгәннәрен укыйлар. Күктә кызарып тулы ай калка. Айның яктысы багана булып халык өстенә төшә. Халык аптырашта калып, гөр килеп шаулаша:—Казык, казык! Хан казыгы!—дигән сүзләр яңгырый. Халык уртасында Мөстәкыйм. Кулында таш сандык. Янәшәсендә Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович басып торалар. Айдан килгән яктылыкның очы Вил Вилдановичның аяк астына төшә.*

Вил Вилданович *(Мөстәкыймгә)*. Ач, ач инде сандыкны. Казык үзенең урынын тапты. Күрәсеңме, минем аяк астында. *(Ай яктысы аның аяк астыннан*

*кучеп, Касыйм Сабирхановичка килә башлый.)*

Касыйм Сабирханович. Күрәсезме, сизәсезме, казыкның төбе минем аяк астымда. Мөстәкыйм туган, әзерлән, әзерлән сандыкны ачарга. *(Якты Касыйм Сабирхановичтан узып китә.)*

Вил Вилданович. Аңлашылды. Син жинден, Мөстәкыйм. Казык синең кулда. Казык синең аяк астында. *(Яктылык Мөстәкыймне дә узып, Колшәриф мәчетенең аена килеп куна.)*

Вил Вилданович, Касыйм Сабирханович, һәм башкалар. Сандыкны ач! Ач инде, таш сандыкны ач! Ай казыкка эленде!

*Сәхнәдә бар халык гөр килеп ала.*

Бар халык бергә. *(Колшәриф мәчетенең аена карап).* Хан казыгы! Казан казыгы! Ач инде, ач!

Мөстәкыйм. Мина сандыкны ачуның кирәге бетте. Сандык эчендәге серне мин болай да беләм.

Бар халык бергә. Нәрсә? Таш сандыкта нәрсә?

Мөстәкыйм. Өмет!!!

Бар халык. Өмет!!!

*Музыка. Ут сүнә.*

*ПӘРДӘ*

---

## *Алхәбәр*

2008 елның соңгы саннарында журнал үзенең укучыларына күпсанлы чәчмә һәм шигъри әсәрләр, кайнар публицистик язмалар, әдәбият һәм сәнгатьнең байтак тармакларын колачлаган тәнкыйть мәкаләләре тәкъдим итәргә җыена.

Чәчмә әсәрләр арасында **Ринат Мөхәммәдиевнең** “Кош булып очар идем” романы, **Туфан Миңнуллинның** “Дивана” пьесасы, **Радик Фәизовның** “Ат карагы”, **Илсөяр Иксанованың** “Житкән кыз” хикәяләре бар.

Шигърият сөючеләрне **Шәүкәт Галиев, Салисә Гәрәева, Гәрәй Рәхим, Ленар Шәех, Габделхак Шәмсетдинов, Гөлзадә Әхтәмова** h. б. әсәрләре белән очрашу көтә.

Публицистика бүлегендә **Тәфкил Вафинның** татарларны чукындыру хакындагы “Мәкруһлар” исемле күләмле язмасы, **Дамир Асыловның** “Без дә нефть чыгарыштык” исемле истәлекләре урын алган.

Киләсе саннарда шулай ук **Гомәр Бәширов** көндәлекләре, **Нурихан Фәттах, Әхмәт Рәшит** истәлекләренең дәвамы, **Ф. Батталның** “Мәгариф” гел сөендерә” исемле мәкаләсе, **Ф. Гариповаың** “Авылларыбыз тарихы”, “Татар энциклопедиясе битләреннән” h.б. кызыклы язмалары белән танышырга мөмкин булачак.



Лениза Вәлиева

# БЕЗНЕҢ СЕРНЕ САКЛАР КҮКЛӘР

* * *

**Сәер халәт:**
**Бар дөньяны айкыйм уйларымда—**
**Менә чите...**
**Алларымда—ап-ак кәгазь бите.**
**Җанда—кояш.**
**Утта дөрләп яна һәр күзәнәк.**
**Җитми түзем.**
**Тик кәгазьгә сыя—агыла сүзем.**
**Бушый күңел.**
**Әмма һаман яңа күкрәү көтеп**
**Иңрәү кала:**
**Нарасый җан-шигырь аваз сала...**

* * *

**Тирән тынлык һәр тарафта—тоташ.**
**Ярдан ярга йөзә-йөзә бата кояш.**
**Тыелып кына күңлем моңлы бер көй көйли.**
**Аһ-зарымны сизгер җанлы скрипкам сөйли.**
**Ташкын булып урап ала моң дәрьясы**
**Һәм тирбәлә шул дулкында бар дөньясы!**
**Сихерләнеп басып торам, хәйран калып.**
**Их, бу аһәң! Булса иде сүзгә салып.**
**Татлы төер күтәрелә, җанны өтеп,**
**Күзләремнән яшь пәрдәсен сүтеп.**
**Бер чарасыз көйнең колы булып калам.**
**Эреп бетеп, җырга әйләнеп агам.**
**Белмим инде—ләхетемме, тәхетемме?..—**
**Суга салып китеп барам бәхетемне...**

Лениза ВӘЛИЕВА—*шагыйрә; Алабуга педагогия институты студенты. "Диңгездә йолдыз коена" исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

* * *

Өмет тулы күзләр һаман күккә бага,
Нәтиҗәсез әмма бар да—вакыт ага.
Бер-бер артлы үтә тора соры көннәр,
Саташтырып, алга әйди серле өннәр.
Йә упкынга, йә күкләргә—юк урталык!
Бер тайпылсаң көтеп тора әзер калып—
Моңсыз көннәр, төссез яшәү, эзсез гомер,
Вак мәшәкать, юк-бар сорау, түбән гозер...
Болай яшәү—тере килеш үлем.
...Шәм яндырып, якты эзли нәүмиз күңлем.

* * *

Аһ, бу киңлек—
Хәтфә үлән, зәп-зәңгәр күк!
Уртада—җан. Бәргәләнә
Гүя яраланган киек:
Кан саркыган җәрәхәтнең
Төзәлүен көтә кебек,
Дәва эзли һәр тарафтан.
Үрсәләнеп яши өмет.
Ә тирә-юнь—тоташ тынлык.
Боза бары җан сулкылдау.
Һични, берни кирәк түгел.
Мохтаҗ нәрсәм—ихлас аңлау.

* * *

Язмышларда бердәнбер нур, якты балкыш,
Әллә инде төзәлмәслек ачы ялгыш,
Бар киртәне җимерерлек ярсу ташкын,
Ә кем белә, бәлки әле тиле шашкын—
Ни дип атыйм? Нәрсә диим—тәмам гаҗиз.
Көчсез каләм: сүз табалмый—буйсынмый хис.
Хәер, ансы мөһим түгел, кирәкми һич.
Атсыз җайдак оча җанда һәр иртә-кич.
...Аңламаслар, гаҗәпләнеп карар күпләр.
Тик икебез белгән серне саклар Күкләр...

* * *

Ай тулган көн. Йокы керми күзгә.
Саклык белән торам урынымнан.
Әкрен генә тәрәзәне ачам,
Колач җәеп, күккә ургылам:
Төн пәрдәсен ерта ак күлмәгем—
Бер тап булып оча һавада.
Ярым уяу, ярым шашкан аңым.
Таныш та бу халәт, яңа да.
Төнне ерып йөрим таңга кадәр.
Аяк астым—йолдыз, ут кына.
Кайнарлыгы табанымны өтә,
Бирешмичә атлыйм ялкынга.

Өзелә юл. Бары бер җан калка
Төн йокымнан мине калдырган,
Күнегелгән дөньям, бар Галәмнән
Аерганда үзенә чакырган.

* * *

Өн ишетелә (минем тавыш, ахры):
«Ирек бирәм. Газапламам. Җитәр.
Һәм уйламам башка беркайчан да.
Син дә оныт. Тотма җанны! Җибәр!»

* * *

Хөкем итсә сине берчак Күкләр,
Мөһер сукса «Җан кыючы» дигән,
Бар җәзадан шундук коткаручы
Аклау булып яннарыңа киләм!
Сиңа диеп әзерләнгән учак—
Ялкыннарын учларыма алам.
Гаепсез ул! Ишетегез, Күкләр!
Җанны утка үзем теләп салам.

* * *

Асылыма кайтам. Үз-үземә...
Бик арылган чит калыпта яшәп,
Ирек сөйгән җанны, хыялларны
Чама дигән богау белән чикләп.
Үз-үземә кайтам. Асылыма.
Юллар озын—ерак кителгәндер...
Күп урында, хисне учка кысып,
Хәрабәләр ясап үтелгәндер...
Моннан миллион еллар элек, ахры,
Мин су кызы булып туганмындыр,
Яр буенда алтын тарак белән
Чәчләремне тарап юганмындыр.
Юкса дәрья тартмас иде болай,
Саташтырмас иде диңгез шавы:
Төшләремә керә биек ярлар,
Хыялымда күрәм дулкын тавы.
Керим әле суга, колач җәеп,
Чәчләремне иңгә таратыйм да.
Иркен киңлек куенында калыйм—
Үзем булып, иң саф асылымда.

Фәүзия
Бәйрәмова

# СЕБЕР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

## Тара буендагы татар авыллары

Омск өлкәсенең төньяк-көнчыгышына таба, Иртыш елгасы буенда Муромцево дип аталган бер район урнашкан, аны табигый матурлыгы өчен Себернең Швейцариясе дип йөртәләр. Бирелдәге кеше кулы кагылмаган мең еллык урманнар, шифасы белән бөтен дөньяга дан алган серле күлләр, мул сулы һәм балыклы Тара, Бергамак, Тунгус елгалары Россиядән генә түгел, чит илләрдән дә күп сәяхәтчеләрне үзенә тарта. Дөрес, монда хикмәт эзләп, ырым-шырым артыннан йөрүчеләр дә шактый, чөнки кайберәүләр бу тирәләрне дөньяның кендеге, энергетик үзәге дип том-том китаплар язып чыктылар, шунлыктан хәзер биредә, бигрәк тә Окунево авылы тирәсендә төрле сектантлар кайнаша. Югыйсә Окунево



авылы үзе XVII гасыр ахырында Бергамак дип аталган татар авылыннан аерылып чыккан, башта Резино, ягъни Рәҗин дип аталган татар авылы булган бит! Шулай ук хәзерге район үзәге Муромцево, Сеткул авыллары да шул заманда шул ук Бергамактан аерылып чыккан булганнар, ягъни бу бүленеш бер өлеш татарларны көчләп чукындырганнан соң булган булырга тиеш.

Без менә хәзер Омскидан "Умырзая" ансамбле белән шул Муромцево районына барабыз, әмма хикмәт эзләп түгел, татарларны эзләп. Биредә 3 саф татар авылы бар икән, район үзәгендә, башка зуррак урыс авылларында да татарлар яши, әмма аларның саны күп түгел. Районда 27 мең кеше яши, шуның меңнән артыгы—татарлар. Әле моннан утыз ел элек кенә Муромцево районында 126 авыл булса, хәзер алар нибары 55кә генә калган, урыс авыллары сазга баткандай юкка чыга, яшәүдән туктый икән. Сәбәбе—эшсезлек, эчкечелек, үтерешләр. Татар җирләрен кан түгеп басып алып, халкын көчләп чукындырып кына бәхетле булып та, сакланып калып та булмый икән шул, дүрт гасырдан соң булса да моның өчен барыбер җәзасы килә. Минем шундый закончалыкны да күзәткәнем бар—чукынган татарларның нәселе әкренләп юкка чыга, бетүгә таба бара, князь Йосыповлар, Шереметьевлар шуның ачык мисалы, ә түбәнрәк торганнарны исәпкә алучы да юк.

*Ахыры. Башы 8,9 саннарда.*

Муромцево районы Новосибирск өлкәсе белән чикләшә, анда да татар авыллары шактый икән. Без башта чикне үтеп, Новосибирск өлкәсенә барырга һәм андагы Тарлар авылында халык белән очрашырга булдык. Бу татар авылы Новосибирскидан—600, Омскидан 300 чакрым ераклыкта булгангамы, әллә юллар булмагангамы, әллә башка сәбәптәнме, бирегә татарча концерт белән дә, очрашу өчен дә килүче юк икән. Дөрес, узган ел шул "Умырзая" ансамбле менә шулай кереп чыккан, хәзер дә алар сәфәрне онытылган Тарлар авылыннан башларга булдылар. Бу авыл урыс карталарында Альменево дип күрсәтелгән, дөресен әйткәндә, бу яклардагы татар авыллары һәрберсе икешәр исемле. Омск өлкәсенең Тазлар һәм Новосибирск өлкәсенең Тарлар авылы арасында 12-13 чакрым гына булса да, без аны ике сәгатькә якын үттек, чөнки кар көртләре арасында юл юк диярлек була иде. Омск эшмәкәре Тамир әфәнде Алимбаев биргән "Паз" автобусын этә-төртә, карны көрәкләр белән көрәп, машинаны арканнар белән сөйрәп азаплана торгач, икендегә таба Тарлар авылына да килеп җиттек.

Безне клуб янына китереп бушаттылар, клуб дигәннәре агач бер йорт булып чыкты, элек ул мәктәп булып торган. Уч төбе хәтле генә сәхнәсе бар икән, киенүчишенү бүлмәсенә "Умырзая"ның егермәләп артисты кереп тулды, мин чиста итеп юылган авыл клубының бер башында ялгызым гына намазларымны укып алдым. Аннан урамга чыгып, концертка кадәр авыл белән таныштым. Авыл шактый кечкенә булып чыкты, анда йөзләп кенә кеше яши икән, мәктәп тә, мәчет тә юк. Балалар мәктәпкә күрше урыс авылына йөриләр, ә кеше үлсә җеназа укырга мулланы Омск өлкәсенең Тазлар авылыннан алып киләләр икән. Әлбәттә, авылда газ да юк, юл да юк, эш тә юк. Ә бит заманында Тарларда мәчет тә, мулла да булган, тарихи белешмәләрдән күренгәнчә, 1882 елларда биредә Абдулкаюм Абдрафиков имам булып торганлыгы билгеле. Ул заманнарда Тарлар авылы Тубыл губернасының Аялы волостына кергән һәм анда 1903 елны 90 ир-ат, 78 хатын-кыз яшәгәнлеге билгеле. *(Ю. У. Сафаралиева. Культура и просвещение татар Прииртышья /конец XIX—начало XX в /.—Нефтеюганск-Москва, 2004, с. 83.)* Йөз ел эчендә халык артуга түгел, кимүгә таба бара түгелме соң?



*Тарлар авылы клубы*

Халык белән аралаша торгач, моның да сәбәпләре ачыкланды—татарларны эчкечелек кыра икән, милләттә өмет бетеп бара, дин бик зәгыйфь, шул сәбәпле, әхлак түбән. Шуңадырмы, халык, бигрәк тә хатын-кызлар бер авыздан авылга мулла сорый. "Үзегездән Омскига яки Новосибирскига җибәреп муллалыкка укытырлык егетләр юкмы соң?"—дим. "Кая ул!"—дип, ишек төбендә тәрткәләшкән кызмача егетләргә күрсәтәләр. Шуңа күрә мин дә чыгышымда үзәк мәсьәлә итеп әхлак темасын алдым, читтән беркем килеп аларның тормышын төзәтмәячәген әйттем, иманга килеп менә диген итеп яшәп яткан татар авылларын мисалга китердем. Чөнки бу авылда да урман дисәң—урманы, су дисәң—янәшәдәге Тара елгасы, күлләре, болынлыклары бар, мал тотарга да, аучылык, балыкчылык белән шөгыльләнергә дә була. Әмма башын эчүгә салган кешегә боларның берсе дә кирәкми шул, ул шушы бәхетсезлегенә сәбәп эзли-эзли һаман эчә, аңа карап тормышы яхшырмый, начарая гына бара. Урман эчендә яшәп, агачтан бер мәчет тә салып куярга була иде, ул авылның үзенә кирәк бит, күршеләргә түгел! Безнең белән Омскидан килгән милли хәрәкәт җитәкчеләре Гафия Алиева, Сания Мирхалиева бу авыл турында Омск, Новосибирск эшмәкәрләренә дә сөйләргә, ярдәм итү юлларын эзләргә булдылар.

Халыкның сөйләве буенча, заманында Тарлар авылы да болай төшеп калганнардан булмаган, тарихта үз эзен калдырган. Тарихчы-археологлар бу яклардан да борынгы курганнар тапканнар, ә алардан Алып кешеләрнең сөякләре чыккан. Бу җирләр заманында Күчем ханның биләмәләре булган, аялы татарлары

дип йөртелгән бу татарлар исә аның гаскәрендә иң оста мәргәннәр булганнар. Телче-фольклорчылар, этнографлар өчен дә биредә әле өйрәнәсе материал күп, халык үзенә күрә бер шивәдә сөйләшә, йөз төзелешләре дә башкалардан шактый аерыла. Авыл тирәсендәге елга-күл атамалары исә Тарларның ни дәрәҗә борынгылыгын тагы бер тапкыр күрсәтә—Йир балаган, Тиргәй күл, Лоңгыр күл, Килтебай күл, Пәйвәс күл исемнәре үзләре үк безне Идегәй чорларына алып китә кебек...

"Умырзая" ансамбле чыгышын да халык исе китеп карады, чөнки аларның мондый милли матурлыкны, зәвыкны күптән күргәннәре булмагандыр, мөгаен. Ансамбльнең Казанда һәм Омскида тектергән затлы киемнәре дә, берсеннән-берсе оста, профессиональ дәрәҗәдә башкаручылары да сокланырлык иде шул! Кешегә сазлыктан чыгарга ярдәм итү өчен бәлки менә шулай матурлык үрнәге дә күрсәтергә кирәктер, үзләренең татар дигән бөек милләтнең бер өлеше икәнлекләрен исләренә төшерергә кирәктер. "Умырзая" ансамбленең тәҗрибәле, өлкән яшьтәге башкаручылары да, ут чәчеп торган яшь егетләре һәм берсеннән-берсе гүзәл кызлары да бүген кара урман эчендәге Тарлар авылы халкына матурлык дәресе бирделәр, татарның нинди булырга тиешлеген күрсәттеләр.

Безнең әле бүген тагы бер авылда—Омск өлкәсенең Тазлар авылында чыгыш ясыйсыбыз бар иде, шуңа күрә бераз соңарып булса да, кайтыр юлга кузгала башладык. Ә халыкның җибәрәсе килми, таралмыйлар, рәхмәтләрен әйтәләр, тагы килергә чакыралар. Насыйп булса, тагы килербез Тарларга, иншаллаһ, чөнки милләт Казанда гына түгел, менә шундый Себер урманнарында да яши бит, һәм алар җылы сүзгә, дөрес киңәшкә, милли матурлык үрнәгенә тилмергән! Караңгыда кайтыр юлга кузгалдык, безнең әле теге батып яткан кар көртләрен яңадан ерып чыгасыбыз,үзебезне тилмереп көтеп торган Тазлар авылы халкы каршында чыгыш ясыйсыбыз бар иде...

Ун чакрым араны ун тапкыр батып, атлаган саен көрәк-арканнарга ябышып, этә-төртә автобусыбызны Тазлар авылына китереп җиткергәндә, сәгать кичке унынчы иде инде. Клуб Тарлардан да ике тапкыр кечкенә, сәхнә бөтенләй юк, клубның икенче башында башлангыч мәктәп, ике арада ут кебек кызган мич янып тора иде. Артистлар әзерләнгән арада, мин халык алдында чыгыш ясый тордым, чөнки вакыт төнгә авышып бара иде. Мин биредә дә татар тарихы турында мәгълүмат бирдем, бу якларның тарихына тукталдым, динебез һәм мәдәниятебез турында сөйләдем, алып килгән китапларымны бүләк иттем.

Ул арада ансамбль дә чыгыш ясарга әзерләнеп өлгерде, уч төбе кадәр җирдә могҗизалар күрсәтә башлады. Югыйсә иртәдән бирле юлда булган, әле бер җирдә туктап җылы ризык капмаган, инде бер авылда чыгыш ясаган, салкын автобуста күшеккән, билдән карга батып, аны өстерәп барган халык дип кем әйтер аларны? Югыйсә аларның барысының да төп эш урыннары бар бит, кем табип, кем журналист, кем инженер, кем студент, ә милләт дигәндә җылы өйләрен дә, гаиләләрен дә калдырып торып, ял көннәрендә булса да ерак юлга чыгып китәләр! Мондый фидакарьлек бер татар милләтендә генәдер, валлаһи! Аларга бит моның өчен акча түләмиләр, ә алар мин барам да мин барам дип, халык каршында чыгыш ясарга атлыгып торалар. Афәрин, "Умырзая", афәрин, аның алыштыргысыз җитәкчесе Гафия ханым!

Аларның бирегә инде өченче тапкыр килүләре икән—беренче тапкыр 2005нең кышында концерт биреп киткәннәр, узган ел Тазларга килеп, соңгы вакытта тәүге тапкыр Сабан туе уздырганнар һәм менә хәзер авыл клубында ут уйнаталар. Мичтән җылылык бөркелеп тора, бу хәл миңа балачагымдагы авыл клубларын хәтерләтә, минем илле ел инде мондый клубларны күргәнем юк иде. Инде концертны бер тапкыр караганга, икенче якка чыгып, мәктәп белән таныша торырга булдым, ул бүлем аша гына иде. Бу очрашуны эшләргә җан атып йөргән укытучы Бибисара ханым Абдуллина да биредә иде, аның белән авыл хәлләрен сөйләшеп тордык. Башлангыч мәктәптә 9 бала укый икән, татар теле факультатив буларак укытыла. Шунысын да әйтергә кирәк, Тазлар авылы—районда татар теле укытыла торган бердәнбер мәктәп. Казаннан өр-яңа дәреслекләр дә кайткан, китапка кытлык юк, укысыннар гына.

—Укыйлармы соң?—дип сорыйм.

—Балалар татар телен дә, татар китапларын да бик яраталар,—ди Бибисара ханым.—Авылда, гомумән, халык татарча сөйләшә, татарча яши. Әле моның өстенә балалар догалар да өйрәнәләр, бергәләп өйрәнәбез. Безнең авылда балалар

гаеттә өй саен кереп, котлап йөриләр, кем аларга бүләк бирә, кем—сәдака. Авыл халкы сәдаканы, балалар өчен дип, мәктәпкә дә китерә. Балалар дини бәйрәмнәрнең, татар теленең кадерен кечкенәдән аңлап үсәләр...

Әйе, аерым шәхеснең эшчәнлегеннән дә күп нәрсә тора шул. Балаларга шушы юлдан барырга ярдәм иткәне өчен Бибисара ханымның үзенә дә зур рәхмәтләр әйтәсе килә. Ул тавышланмый гына авыл балаларына миллилекне дә сеңдерә, динилекне дә булдыра алганча бирә. Авыл халкы үзе дә чагыштырмача тыныч, тәртипле, булдыра алганча дин тотарга тырыша, корбан чалдыра, гаетләр уздыра. Авылда мәчетнең булуы да нур өстенә нур булып тора, муллалары Исмәгыйль хәзрәт Әхмәтвәлиев безнең яклардан, Балык Бистәсе районыннан икән, әмма инде Себер кешесе булып беткән. Ул тарих белән кызыксына, халыкка күпьяклы мәгълүмат бирергә тырыша.

—Авылга 650 еллар булырга тиеш,—ди Исмәгыйль хәзрәт, үзе белгән тарихи чыганакларга таянып.—Авыл янында Күчем хан курганы дип йөртелгән урын бар, ул да әле өйрәнүне көтә. Моннан тыш та тирә-юньдә курганнар бар, халык телендә изге зират дип йөрткән урын да бар.

Әйе, Тазлар авылының тарихы борынгы булырга тиеш. Рәсми белешмәләрдә, географик карталарда бу авыл Гузенево дип йөртелә, элеккеге урыс чыганакларында Кузенево дип тә язганнар. Гуз дигәч, Ризаэддин Фәхреддинов язып калдырган риваятьтәге Нух галәйһиссәламнең оныгы Гузз /угыз/ искә төшә, ул бертуганы Төрекне алдап, атасы Яфәснең яңгыр яудыра торган ташын үзләштерә. Моннан ерак булмаган Окуневодагы сәер кешеләр дә ниндидер хикмәтле таш эзлиләр, Миллер да шундыйрак ташны Иртыш буендагы Ташаткан авылында саклана, Ермак шуннан куркып кире борылган, дип язып калдырган. Халык авыз иҗатында Күчем хан һәм Бараба, Аялы татарлары турында сөйләгәндә, бу авыл да телгә алына. Ә Тазлар атамасы исә Геродот язып калдырган "пеләш кешеләр", ягъни Себер скифлары турында уйлануларга этәрә...



*Тазлар авылы урамы*

Ә йөз ел элек Тазлар авылында 23 йорт булган, аларда 65 ир-ат, 68 хатын-кыз яшәгән. Хәзер исә Тазларда 280 кеше яши, күпләрнең эш урыны юк һәм алар үз хуҗалыклары хисабына көн күрә икән. Бирედә мал асрыйлар, кәҗә тоталар, шәл, оекбаш бәйләп саталар, сөт саталар, аучылар, балыкчылар, балта осталары да бар. Әлбәттә, газ да, асфальт юллар да юк, әмма авылда тормыш нык күренә—йортлар матур, төзек, халык фәкыйрь киенмәгән, гел зарланып тормый. Бу авылның тагы бер үзенчәлеге бар—биредә башлангыч мәктәптән соң бик укырга яратмыйлар. Дөрес, укырга теләүчеләр кичен 8 класс белем алырга мөмкин, әмма укырга теләүчеләр аз, диделәр. Шул сәбәпле, "малограмотный" дип, егетләрне армиягә дә алмыйлар икән. Кызык бит, укымау урыс армиясеннән коткара! Шулай ук яшьләрнең авылдан китмәүләре, шушында тормыш алып барырга тырышулары турында да сөйләделәр. Хәтта киткәннәр дә кире кайтып, Тазларда яши башлый икән. Шуңа күрә авыл таралмый, беркемнән ярдәм көтмичә, үзен-үзе оештырып, элеккеге тәртипләр белән яшәп ята булып чыкты.

Халык суны Тара елгасыннан эчә, биредә аны Тар дип йөртәләр. Шулай ук авыл тирәсендә Калтау күле, Чептар күл, Аусак күле бар, 15 чакрымнар ераклыкта шифалы дип даны дөньяга таралган Данилово күле дә бар диделәр. Авылда Шабановлар, Абдуллиннар, Бакаевлар, Агафуровлар фамилияләре киң таралганлыгын әйттеләр. Авыл халкының йөз төзелеше бик себерчә дә түгел, казанлык та алай сизелми, үзләренә бер төрле кыяфәт. Хәер, бер килгәндә генә бөтенесен белеп бетереп буламыни? Узган җәй бирегә Казаннан галимә Дөрия ханым Рамазанова килеп, бу яклардагы авылларның тел үзенчәлекләрен өйрәнеп киткән, аның язмаларында мәгълүмат күбрәк булыр, иншаллаһ! Ә башка бу авылга

килүче язучылар да, артистлар да юк икән.

Төн уртасы җиткәндә, очрашуыбыз тәмамланды, безне йокларга өйләргә бүлеп алдылар. Мине башта ук Фәзидә апа Белалова үзенә алып кайтырга тәгаенләп куйган булган, концерт бетүгә, кайтып та киттек. Тазлар авылын намазлы, тәртипле, хәләл ризыклы җылы өендә, мамык мендәрләргә күмелеп, төнгә кердем. Әйтерсең лә мин бу өйне, бу авылны, бу кешеләрне бик күптән беләм, бик ерак сәфәрдән соң яңадан әйләнеп кайтканмын һәм хатирәләр диңгезенә чумганмын... Минем белән бергә Тазлар авылы да борынгы замандагы Тузлары, скиф-тазлары, Күчем ханнары белән төнгә кереп бара, яңа көн алдыннан көч туплый иде...

Икенче көнне Тазлар авылы халкы безне ашатып-эчертеп, кулыбызга күчтәнәчләр тоттырып, изге теләкләр белән озатып калды. Безне сәфәребезнең соңгы ноктасы—Чуртанлы авылы көтә иде. Бу авылның Күчем хан заманнарында ук булганлыгын мин инде белә идем, Омск археологлары да биредә Себер ханлыгы торак урыннары һәм каберлекләре табып, шуны исбатладылар. 2005 елны Омскида басылып чыккан "Прошлое Омского Прииртышья" китабының 96нчы битендә бу хакта махсус таблица да бирелгән. Әмма урыс телендә Чуртанлы авылын нигәдер Черталы дип йөртәләр, барлык тарихи чыганакларда һәм белешмәләрдә ул шулай язылган. Алардан күренгәнчә, бу якларда яшәүче Аялы татарлары әле XVI гасыр уртасында да өлешчә мәҗүсиләр булып калганнар, каберләргә мәет белән берга эш кораллары һәм бизәнү әйберләре салып калдырганнар: "Раскопки татарских могильников (Бергамак, Чеплярова, Окунево, Черталы) показывают, что богатых погребений не было, обычно в могилу клали производственный инвентарь и украшения... Ислам среди аялынцев распространился позднее, чем в центральных частях Сибирского ханства." *(Средневековая археология Евразийских степей. Том 1.—Казань, 2007, с. 229.)*

Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, Чуртанлы авылы элек-электән тирәюньдә иң зур авыллардан саналган. Әйтик, 1782 елгы ревизия материалларыннан күренгәнчә, Чуртанлыда 78 ир-ат, 75 хатын-кыз яшәгән, бу Аялы волостында иң зур сан. *(Г. Т. Бакиева. Сельская община тоболо-иртышских татар /XVII-начало XX в/. Тюмень-Москва, 2003, с. 208.)* Әмма, ни сәбәпледер, 1816 елга бу сан яртылаш кимегән, ир-атлар 47, хатын-кызлар 30 гына калган. *(Шунда ук, 218 б.)* Бу авыл өстеннән йә көчләп чукындыру, яисә берәр чир-зәхмәт үткәнне аңлата. 1869 елда исә Чуртанлыда 15 йортта 59 ир-ат, 55 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет булган. *(Шунда ук, 242 б.)* 1904 елда исә Чуртанлы халкы берничә тапкыр арткан, ирләр 136га, хатын-кызлар 123кә җиткән. *(Шунда ук, 225 б.)*

Менә без хәзер, кар-бураннарны туздырып, шул Чуртанлыга барабыз. Ул район үзәге Муромцеводан ерак булмаган, Тара елгасының сул як ярына урнашкан уртача зурлыктагы бер авыл булып чыкты. Анда 200ләп кеше яши, башлангыч мәктәп, клуб, мәчет, медпункт бар икән. Авыл шактый нык, төзек күренә, йортлар матур, тәртипле төзелгән, халык та көр күңелле булып чыкты. Безне тагы сәхнәсез, шырпы тартмасы кебек бер бинага керттеләр, клублары шул икән. Халык җыелган, артистлар әзерләнгән арада, мин авыл урамнарын әйләнеп кердем, кешеләр белән очраштым, хәл-әхвәлләрен сораштым. Шунысына игътибар иттем, монда катнаш халык яши, ягъни Себер татарлары һәм казанлылар, теге заманнарда безнең яклардан сөргенгә сөрелгәннәрнең нәселе. Шуңа күрә төс-битләре дә төрлечә, зәңгәр, хәтта яшел күзле татарлар да шактый. Яшел күзләргә мин инде Тарлар белән Тазларда да игътибар иткән идем, бу үзенә күрә бер кавемнең билгеседер, мөгаен.

Хәтта кыш көне дә күренеп тора—авыл бик матур җиргә урнашкан. Авылга терәлеп Тара елгасы ага, капка төпләренә хәтле болынлыклар, әрәмәлекләр килеп җиткән, якында гына Чабаклы, Илətау, Түгәрәк күл, Эчкә күлләре бар. Ә инде карлыганнар үскән, су эчендә утрау кебек бүленеп калган җирләрне биредә бүләкләр дип, яр буендагы уентыкларны нәү дип атыйлар икән. Халык суны Тара һәм Өер елгаларыннан эчә булып чыкты. Әлбәттә, авылда газ да, асфальт юллар да юк, халык үз көнен үзе күрә, эш мәсьәләсен дә үзе кайгырта. Күп кеше мал тота, ит, сөт саталар, балыкчылык, аучылык белән шөгыльләнәләр.

—Биредә халык бик эшчән, килгән кеше дә китми, ябышып яталар,—диде авыл апалары берсен-берсе уздырып.

Авылдагы тарихи урыннар, риваятьләр белән дә кызыксынам. Тараның аргы ягында, урман буенда борынгы зират бар, авыл халкының фикеренчә, анда изгеләр күмелгән. Ул җир "кышлау" дип атала, ягъни элек Чуртанлы халкының анда

кышлау урыннары булган, ә монда—җәйләү җирләре. "Кышлаудагы каберлекләрне кемнәрдер актарган, безнең авылдан барып, сөякләрне күмделәр",—диде олы яшьтәге апалар, рәнҗеп. Әйе, бу Омск археологларының "эше" булырга тиеш, гомумән, аларның Россия буйлап татар каберлекләрен актарып йөрүләре минем үземә дә авыр тәэсир итә, фән өчен дә мин әрвахларның тынычлыкларын бозасым килми.

—Безнең авылга фирештә төшкән, шуңа күрә ул таралмый, безнең авылны фирештәләр саклый,—диде өлкән яшьтәге бер ханым мине гаҗәпләндереп, ул Земфира Тукаева булып чыкты.

Үзе дә сөргенгә сөрелгән мулла нәселеннән булган Наҗия апа Мәүлитова аңа кырыс кына карап куйды, фәрештә төшкән авылның намазлы булырга тиешлеген әйтә иде аның бу карашы. Мин дә авылда милли-мәгариф, дин мәсьәләләренең торышы белән кызыксындым. Башлангыч мәктәптә татар теле бөтенләй укытылмый икән, Муромцеводан урыс кешесен чакыртып, татар балаларын тоташ урысча укыталар булып чыкты. Әле немец телен дә Муромцеводан кеше чакыртып укыталар икән. Гаҗәп бит—саф татар авылы, ә укыту урыс һәм немец телләрендә генә! Ә бит авылда элек укытучы булып эшләгән, бүген дә балаларны татарча укыта алырлык кеше бар, ул—Мәрдәмшина Мотыйга апа. Ул бүгеннән балаларны татарча укытырга әзер, бу хакта минем яныма килеп әйтте дә, әмма район җитәкчеләренә һәм авыл халкына татарча укыту кирәк түгел, ахры, мин шулайрак аңладым. Югыйсә күрше Тазлар авылында Бибисара ханым татар телен укытырга җай тапкан бит, ә нигә Чуртанлыда ул мөмкин түгел? Бу мәсьәләне Омск милли хәркәте җитәкчеләре бергәләп хәл итәргә булдылар.

Дин белән дә шундыйрак хәл—мәчет бар, әмма мулла юк, аны гаетләрдә Муромцеводан алып киләләр. Авыл халкы үзен мөселман дип санаса да, намаз укучылар һәм ураза тотучылар бик аз икән, ә менә хәтемнәрне, ягъни, Коръән ашларын күп һәм яхшы итеп уздыруларын, ниятлекләр суюларын, корбан чалдыруларын әйттеләр. Гаҗәп инде, мәчет бар, әмма анда намаз укылмый, хәтта өйдә дә намаз укучылар юк дәрәҗәсендә диделәр, яшьләрнең аракы эчүеннән зарландылар, хәтта 90 яшьлек картның да эчеп ятуын әйттеләр. Әйе, дин юк җирдә әхлак та юк, эчкечелекне тыя алмыйлар. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Чуртанлы мәчете бу тирәдә сакланып калган бердәнбер иске агач мәчет бит, ул XIX гасыр уртасында ук төзелгән! Бу хакта тарихи белешмәләр менә ни сөйли:



*Чуртанлы авылы мәчете*

"Из сельских культовых зданий неправославных конфессий сохранилась только деревянная мечеть в с. Черталы Муромцевского района, датируемая серединой XIX в. Уточнить дату основания мечети позволило существование ее фонда в Государственном архиве Омской области, это 1832 г. Она построена по типу мечетей "минарет на крыше". В 1782 г. в Черталах проживало 67 сибирских татар, а в конце XIX в.—55 семей: 109 сибирских и 167 поволжских татар. В 1893 г. мечеть была перестроена. Возможно, изменение состава жителей, зафиксированное переписью населения 1897 года, повлияло на облик мечети после ремонта, когда европейские стилистические особенности стали отчетливо прочитываться. Мечети такого типа были в деревнях Байбы и Ташетканы Тевризского района." *(Лебедева Н. И. Храмы и молитвенные дома Омского Прииртышья.—Омск, 2003, с. 64.)*

Шулай итеп, халык әйтүе буенча, бер кадаксыз салынган борынгы мәчет бүген бикле тора, үзен мөселман дип санаган милләт өчен моннан да зур гөнаһ бармы? Саф татар авылы булып та, мәктәптә ана теле укытылмый, үзен татар

дип йөргән милләт өчен моннан да зур кимчелек бармы? Аллаh биргән җәннәттәй җирләрдә эчеп-исереп йөрүдән дә зур хурлык бармы? Мин болар турында авыл халкына озаклап сөйләдем, татар тормышыннан, татар тарихыннан мисаллар китерә-китерә аңлаттым, ана теленә һәм дингә салкын мөнәсәбәт булган очракта, милләтне берниндиi мал-мөлкәт тә, байлык та коткара алмаячагын әйттем. Чуртанлы турында, фәрештәләр төшкән авыл дип түгел, фәрештәләр качкан авыл дип сөйләргә калмасын иде, бу татар авылы чын иманга килеп, аны Аллаhы Тәгалә Үзе сакласын иде!

Тарихчы Миллерның язуы буенча, Аялы татарлары заманында иң күп санлы төркем булган, шуңа күрә дә урыс патшалары Тара шәһәрен башта шушы тирәләрдә төзергә ниятләгәннәр, әмма сазлыклы урын булганга, хәзерге урынына күчерергә мәҗбүр булганнар. Хәзер кайда ул күп санлы Аялы татарлары—анда бер авыл, монда бер авыл һәм бетте! Искәр һәм Ялым-Тора /Тара/ шәһәрләре алынганнан соң, Күчем хан да бу якларга чигенергә мәҗбүр булган, аның артыннан бастырып, Тара елгасы буенча һәм урман-далалардан урыс казаклары килгән, бирередә көчле сугышлар булган, күп татарлар кырылган. XVII гасырда исә бу як татарлары калмыкларның һөҗүменнән газап чиккән, ә соңрак инде көчләп чукындырулар меңләгән милләттәшебездән урыс һәм христиан ясаган.

Хәзер урыс булып йөргән авылларның күпчелегендә, шул исәптән дөнья сихерчеләре җыелып яткан Окуневода да чукындырылганнан соң урыска әйләнеп киткән татарлар яши, моның өчен аларның йөзләренә карау да җитә. Татарларның чукындырудан калган өлеше гасырлар буе җан саклау өчен тырышкан, нинди шартларда да телен, динен, мәдәниятен саклаган, мөселман-татар нәсел калдырган. Татар халкының иң борынгы дастаннары, иң тетрәндергеч тарихи җырлары шушы якларда язып алынган, "Идегәй" дастанының беренче варианты әле 1919 елда ук Нигъмәт Хәким тарафыннан моннан ерак түгел урнашкан Яланкүл авылыннан язып алынган, шулай ук "Мешәк Алып", "Йәстәй Мөңке", "Алыпмәмшән", "Кара Күкел", "Йиртөшлек", "Күр углы", "Бүрихан", "Сәйфелмөлек", "Кузы Көрпә", "Урак белән Мамай", "Таhир белән Зөhрә" һәм башка бик күп дастаннар Омск, Новосибирск, Төмән өлкәләрендә Себер татарларыннан язып алынган бит! һәм шушындый мәгърифәтле, бай тарихлы халык бүген юкка чыксынмы, үзенең кемлеген дә белмәсенме, телен-динен онытсынмы?! Хәзер Россия мәктәпләрендә христиан дине нигезләре укытыла башлаячак, региональ компонент буларак,мәктәп программасыннан милли телләр алып ташланды, бу инде яңача чукындыру, урыслаштыру дигән сүз. Себер урманнарында яшәп яткан татарлар моңа каршы нәрсә куя ала—бу хакта бүгеннән, хәзер уйларга кирәк, аннан инде соң булырга мөмкин! Без, татарлар, яңача чукындыруга һәм урыслаштыруга каршы бары тик ислам динен һәм татар телен, бай мәдәниятле тарихыбызны куярга тиешбез. Без нинди шартларда да, кайда гына яшәсәк тә татар булып, мөселман булып калырга тиешбез!


Мин Себергә шушы сүзләрне әйтер өчен килгән идем, һәм мин аны әйттем, Аллага шөкер! Халык уйлансын, гыйбрәтләнсен һәм тормышын үзгәртергә омтылсын, үзенең асыл тамырларына кайтсын—безнең төп максатыбыз шул."Умырзая" ансамбленең концертыннан соң, кайтыр юлга кузгалдык. Муромцево районындагы өченче татар авылына—Инсәцкә барып җитә алмадык, чөнки ансамбль әгъзаларына иртәгә эшкә һәм укуга, ә миңа Курган якларына кузгалырга кирәк иде. Шулай итеп, мин хәзергә Омск өлкәсендә эшемне туктатып торып, Габдрәшит Ибраһимов эзләре буенча Курган өлкәсенә чыгып китәргә ниятләдем. Ә бу яктагы авылларда эшебезне җәйгә дәвам итәргә булдык, без әле өлкәнең иң ерак почмагында урнашкан Усть-Ишим тирәләренә барып җитмәгән идек, ә анда 900 еллык татар авыллары бар, диделәр. Без Омск шәһәре татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе һәм "Умырзая" ансамбле җитәкчесе Гафия ханым Алиева белән киңәшеп, җәйгә ул якларга тарихи-фольклор экспедициясе оештырырга булдык. Ягъни бөтен ансамбль белән түгел, фольклор төркемен генә алып, мин татар тарихы буенча лекцияләр укып, алар халыкка милли күренешләр күрсәтеп һәм халык авыз иҗаты материаллары җыеп, Тарадан Усть-Ишимга хәтле татар авылларында йөреп кайтырга уйладык. Моның өчен Гафия ханым Омскида яшәүче эшмәкәр милләттәшебез Тамир әфәнде Алимбаевтан ярдәм сорарга булды һәм өлкә хөкүмәтеннән бу эшкә грант алу өчен материалларын әзерләде. Әгәр безнең бу проект барып чыкса, без шундый ук экспедицияне күршедәге Томск, Новосибирск, Төмән өлкәләренә, Кемерово, Курган якларына

да оештырырга булдык, чөнки Себердә шушы эшләрне башкарырлык бер үзәк кирәк иде, Омск шул милли базага әйләнеп китәр, Аллаһ насыйп итсә, бөтен Себер буенча эшләрбез, иншаллаһ!

## Курган якларында Габдрәшит Ибраһимов эзләре

Белгәнебезчә, күренекле мәгърифәтче, дин белгече, милли сәясәтче Габдрәшит Ибраһимов Уыш мәдрәсәсеннән соң укуын Әлмән авылында дәвам итә. Төрек галимнәренең бутавы сәбәпле, бу авылның исеме моңа кадәр аларда Әрмән дип язылды, бездә дә кайберәүләр шулай дип буталдылар. Әмма Габдрәшит Ибраһимов үзе бу хакта бик ачык итеп: "Соңыннан 1867 елның декабрь аенда, әни (Алланың рәхмәтендә булсын) гайрәт итәрәк, мине Оренбург губернасында Чиләбе өлкәсендә Әлмән карьясына укуга җибәрде",—дип яза. *(Габдрәшит Ибраһимов. Дәүре галәм. Тәрҗемәи хәлем. —Казан, 2001, 138 б.)* Чиләбе чигенә урнашкан бу авыл хәзер Курган өлкәсенә керә, район үзәге булып тора, һәм мин хәзер шул тарафка юл тоттым. Ун яшьлек Габдрәшит мең чакрымлы бу юлны башка шәкертләр белән бергә кыш көне бөркәүле чанада, ат белән үтә, юлда бүреге төшеп калып, колаклары өши. Әлбәттә, Тара, Омск, Төмәннәр аша алар бу юлны атналар буе үткәннәрдер, хәзер исә мин тиз йөрешле поездда иртән Омскидан кузгалып киттем, Петропавел, Курганнар аша көн эчендә үтеп, кичен Шадрин шәһәренә килеп җиттем. Шадрин вокзалында мине Йолдыз авылыннан Әхмәдулла әфәнде каршы алды, без төн уртасында Йолдызга кайтып җиттек. Бирегән Әлмәнгә әле 150 чакрымнар иде, бу юлны соңрак, бераз ял иткәч дәвам итәргә булдык.

Минем Курган өлкәсендә инде икенче тапкыр булуым, Казакъстан чигенә урнашып, тын гына яшәп яткан бу яклар миңа бик охшый, үзенә тартып тора иде. Курган өлкәсен мин "Күлләр һәм курганнар иле" дип атыйм, чөнки монда ике меңнән артык күл, меңләгән борынгы курган бар. Татарлар биредә иң борынгы чорлардан—скиф-һун заманнарыннан көн күргән булырга тиешләр, аларның шулай ук Төрки каганатлар, Алтын Урда, Себер ханлыгы дәүләтләрендә дә яшәгәнлеге билгеле. Ул дәвердәге татарлардан җир-су атамалары һәм курган-таулар торып калган. Дөрес, курганнарның бер өлешен инде Петр патша заманында ук актарып, байлыгын талап бетергәннәр, Петербургтагы Эрмитаж кунсткамерасында биредән табылган алтын-көмеш скиф әйберләре саклана. Хәер, бу өлкә үзе дә татар патшаларының курган-кабере исемен йөртә бит, 1782 елга кадәр ул Царев-Курган, Царево Городище дип аталган һәм анда, нигездә, татарлар яшәгән. Әби патша үзенең әмере белән элеккеге татар каласына шәһәр статусы бирә һәм Курган исемен генә калдыра, ә гербка ике көмеш курган сурәте ясала.



*Йолдыз-Эчкен авылы мәчете*

Бүгенге көндә Курган өлкәсендә 22 мең татар яши, алар барлык шәһәрләрдә дә көн күрә, шулай ук Шадрин, Сафакүл, Әлмән, Шатров, Целина районнарында дистәләгән татар авыллары бар. Әмма мин Курган өлкәсендә милли тормыш алай гөрләп тора дип әйтмәс идем. 2 мең татар яшәгән Курган шәһәре нишләптер күтәрелеп китә алмады, һаман мәчет салынып бетмәгән, милли мәктәп-матбугат турында инде әйтеп тә торасы юк. Татар конгрессының үзәге Сафакүл районында дип исәпләнә, ә ул Курганнан ерак, бөтен татарларны туплый алмый. Рәсми булмаган милли үзәк Шадрин районының Йолдыз авылында, биредә татарлык та көчле, өлкәдә беренче булып мәһабәт мәчет тә ачылды, мәктәптә татар теле дә укытыла,

әмма Казан ярымбашкортлашкан Сафакүл белән эшли. Моннан тыш әле 5 татар авылын берләштергән Әлмән районы бар, әмма анда да милли хәлләр әллә ни түгел, диделәр.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу яктагы татар авыллары, бигрәк тә Әлмән ягындагылар барысы да заманында Эчкен авылыннан таралган, дип яза тарихчылар. (Хәзерге Йолдыз авылы элек Эчкен дип аталган.) Рәсми тел белеме фәнендә "Эчкен сөйләше" дип аталган шивә-диалект та аерып чыгарылган. Эчкен сөйләше Чиләбе өлкәсенең Татар Караболагы, Мөслим, Коншак авылларына хәтле таралган, Әлмән, Өчкүл, Бишнәк /Вишняково/, Тузавыл /Тузово/, Аманкүл /Иванково/ авылларында, хәтта кайбер Себер татарларында да бу шивәне очратырга була. Эчкен татарлары сөйләше үзендә Себер, Казан һәм мишәр диалектларын берләштерә, шул ук вакытта "а" авазын "о"лаштыру киң таралган. Эчкен татарларының тышкы кыяфәте дә Себер татарларыннан шактый аерыла, алар аксыл йөзле, зәңгәр күзле, озын буйлы, әмма арада кара чәчле, себерчә кара кысыграк күзле, тәбәнәк буйлылар да очрый. Кыскасы, тарих казанында барысы бергә буталган һәм үзенчәлекле Курган татарлары килеп чыккан.

Без хәзер шул Эчкен татарларының бүгенге көндәге лидеры Әхмәдулла әфәнде Хәбибуллин белән Әлмән авылына барабыз. Әхмәдулла әфәнде моңа кадәр Себердә һәм үз авылларында җитәкче урыннарда эшләгән, хәзер фермер хуҗалыгы тота, үз акчасына туган авылы Йолдыз-Эчкендә мәчет төзеткән, өч тапкыр Хаҗда булган гаять милли җанлы кеше, район советы депутаты. Хәзер ул Эчкен татарлары турында китап өчен материал туплый, архивларда эшли, туган авылында рухи-мәдәни үзәк ачтыру артыннан янып йөри, һәр елны Казаннан артистлар чакыртып, Сабан туйлары уздыра, авылга яңадан тарихи Эчкен исемен кайтару планнары да бар. Әхмәдулла әфәнде бу якларның тарихын, кешеләрен яхшы белә, бу тирәдәге бөтен татар авылларын диярлек милли һәм дини китаплар белән ул тәэмин итеп тора, аларны Казаннан һәм Төмәннән үзе ташый.

—Әлмәнгә безнең Эчкен авылы кешеләре нигез салган,—ди Әхмәдулла әфәнде.—Картлар сөйләве буенча, 1586 елны 12 нәсел Эчкеннән Әлмәнгә күчкән, алар арасында Алферовлар, Тынкачевлар, Барашовлар, Юматовлар, Байбулатовлар һәм башкалар булган. Аларның кайберләре Әлмәнкүл буенда утырып калган, кайберләре Өчкүл, Бишнәк, Тузавыл, Аманкүлгә нигез салган. Без хәзер дә бер төрлерәк сөйләшәбез, каһарман шәхесләребез, гореф-гадәтләребез, җыр-моңнәҗәтләребез дә уртак, тарихыбыз да бер.

Әлмәннән чыккан атаклы кешеләр турында минем инде ишеткәнем дә, язганым да бар иде. Шулар арасында иң танылганнары—аталы-уллы Ибраһим һәм Фазыл Тынкачевлар, татарча әйткәндә—Тенкәчләр токымы. Бу нәсел заманында Эчкендә яшәгән, әле 1700 елны авыл халкының санын исәпләүдән күренгәнчә, биредә Тенкәчевләр булганлыгы билгеле. *(ЦТАДА, ф.214, оп.5, ед.хр.434.)* Ибраһим Тынкачев Эчкен волосте татарлары исеменнән 1767 елда Мәскәүдә, патшабикә Екатерина II оештырган "Уложенная комиссия" эшендә катнаша, Әби патшага Исәт провинциясендә яшәүче милләттәшләренең дәгъва-наказларын җиткерә. Аның улы Фазыл Тынкачев исә үзенең гыйлеме, галимлеге белән бөтен тирә-якта дан тота. Ул Каргалыда һәм Кабулда дини белем ала, гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белә, атасы Ибраһим Тынкачев кебек, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Аның кабер ташына язып калдырган хәбәрдән күренгәнчә, Фазыл Тынкачев урыс патшасы тарафыннан Истанбулга, төрек солтаны янына солых төзү өчен илче итеп җибәрелә, аннан кайтышлый Хаҗ кыла. Хаҗдан кайткач, урыс патшасы аны Бохара әмиренә илче итеп җибәрә, соңыннан бу эшләре өчен Фазыл Тынкачевка шушы биш татар авылы һәм җирләре бүләк итеп бирелә. Бик күп дөньялар гизгән һәм дин-милләт өчен күп изге эшләр башкарган Фазыл Ибраһим улы Тынкачев 1826 елны, 70 яшендә үлә, Әлмән авылы зиратына күмелә.

Тынкачевларга шулай җентекләп тукталуымның сәбәбе бар. Габдрәшит Ибраһимов үзенең югарыда телгә алган китабында: "Икенче як нәселем башкорт булып, Гафифә бинте Ибраһим бине Җәгъфардыр,—дип яза. Ана карендәшләрем һәммәсе Оренбург губернасында Чиләбе өязендә Әлмән карьясендәдер. Әлмәндә туганнарыбыз—бер тарафтан Җәгъфар баба, башка тарафтан мәшһүр Фазыл хаҗилар нәселедер." *(Күрсәтелгән хезмәт, 136 б.)*

Үн яшьлек Габдрәшит Ибраһимовның башкорт сословиесе белән башкорт милләтен бутавы күренеп тора, шуңа күрә ул бер авыз башкортча белмәгән әнисен башкорт дип уйлый, алга таба Әлмән авылын да башкорт дип бутап

яза. Әле моңа алга таба тукталырбыз, иншаллаһ, хәзергә тагы Тынкачевларга өйләнеп кайтыйк. Габдрәшит Ибраһимов "Әлмәндә туганнарыбыз...мәшһүр Фазыл хаҗилар нәселедер", дип яза, безгә калса, бу—Фазыл хаҗи Тынкачев турында сүз бара. Фазыл хаҗиның да әтисе -Ибраһим, Гафифә абыстайның да әтисе—Ибраһим. Ягъни, Габдрәшит Ибраһимовның әнисе Гафифә абыстай һәм Фазыл хаҗи Тынкачев бертуганнар булып чыга. Шуңа күрә дә Гафифә абыстай газиз улын, үзеннән аерып алып, мең чакрымдагы Әлмәнгә җибәрә, үз туганнары янына озата. Чөнки Габдрәшит Ибраһимовның әтисе Гомәр хәзрәт, мулла булса да, кызганычка каршы, салгаларга яраткан, һәм шуңа күрә дә Гафифә абыстай улын туган якларына җибәрергә мәҗбүр булгандыр...

"Минем әниемнең атасы: Ибраһим мулла, асыл Әлмән карьясы кешеләреннән. Соңыннан Тарада мөдәррис булганнан соң Ташкентка барып, анда бер байтак вакыт укытканнан соң вафат итмеш. Мәдрәсәи Шөкерхан янында күмелгән имеш",—дип яза бабасы Ибраһим турында Габдрәшит Ибраһимов. *(Күрсәтелгән хезмәт, 139 бит.)* /Габдрәшит Ибраһимовның атасы ягыннан да бабасы Ибраһим икәнлеген онытмаска һәм бутамаска кирәк./

Габдрәшит Ибраһимов Әлмән авылын бик яраткан, андагы халыкның тәкъвалыгына сокланган, фәкыйрьлегенә гаҗәпләнгән. Ул вакытта Әлмән мәдрәсәсендә 500 шәкерт укыган була, кыш уртасында Тарадан килеп төшкән 7 ир баланы, мәдрәсәдә урын булмагач, күршеләр үзләрендә тотарга алалар, алар алты ай шунда яшәп укый. "Карья соң дәрәҗәдә фәкыйрь, карьяда өй диярлек бер өй күренмәде, бөтен өйләре дә бер хөҗрә яки бүлмәдән гыйбарәт өч йөзләп иде,—дип яза Габдрәшит Ибраһимов бу авыл турында.—Өч йөз ханәдән гыйбарәт булган бер авылда, ике хөҗрә, бүлмәле өй, ниһаять, ун булган иде: моның белән бәрабәр кешеләре гаять мосафирга хөрмәт күрсәтүчеләр иделәр, голямәне сөя, таләбәне сөяләр иде... Вә таләбәгә дә бик хөрмәт вә ригая итәләр иде. Таләбәнең керләрен юып, икмәген пешереп, бөтенесе түләүсез иде, бәлки дә хатыннар бәяненда таләбә хезмәтен күрү бер үзенчә горурлану булгандыр." *(Күрсәтелгән хезмәт, 139 б.)*

Шунысын да әйтергә кирәк, кечкенә Габдрәшиткә бик-бик атаклы кешенең улында белем алырга насыйп була. Ул—Габделәхәт хәзрәт, аның атасы Габделнасыйр әл-Әлмәни-әл-Эчкени турында Ризаэддин Фәхреддинов үзенең "Асар" хезмәтендә язып калдырган. 1750-1845 елларда яшәгән Габделнасыйр Сабит улы Сәфәргалиев дини белемне ерак Дагыстанда ала, гомер буе китап күчереп язу белән шөгыльләнә. 1841 елны күчереп язган соңгы китабының ахырына ул мондый сүзләрне язып калдыра:

"Бу китапны да кушып санасаң, минем тарафтан 223 том китап язылган. Мин егерме яшемнән китап күчереп яза башладым. Хәзер миңа 95 яшь, күзлек кигәнем булмады. Китапларымны чыра яктысында яздым. Хәзер шәм дигән яктырткыч барлыкка килгән диләр, әмма минем бер төнлек шәм алырлык та акчам юк." Соңыннан исә әтисе язып калдырган шушы мантыйк, 'шәригать белеме, грамматика китаплары буенча улы Габделәхәт үзенең мәдрәсәсендә безнең Габдрәшит Ибраһимовны да укыткан. "Бигрәк тә ул арада булган мөдәррис Габделәхәд бине Габделнасыйр хәзрәтне кешеләр бик сөяләр иде вә бик хөрмәт итәләр иде",—дип яза бу хакта Габдрәшит Ибраһимов үзенең югарыда телгә алган хезмәтендә.(139 б.)

Менә без милләтебезгә шушы асыл затларны биргән Әлмән авылына килеп тә җиттек һәм беренче эш итеп мәктәпкә киттек. Исәбебез—балаларга күренекле якташлары турында сөйләү, алып килгән китапларыбызны бүләк итү иде. Әмма директор бүлмәсенә килеп керү белән, безнең өстебезгә бозлы су сипкән кебек булды—мәктәптә татар теле бөтенләй укытылмый икән! Мәктәп директоры, рус милләтеннән булган Александра Ивановна Бабикова моның сәбәбен ата-аналар теләмәүдә дә, укытучылар юклыктан да күрде. Югыйсә мәктәптә укучы 504 баланың яртысыннан күбе—татар һәм башкорт балалары икән бит, алар өчен хәтта ана телендә түгәрәк тә юк! Әлмән авылында яшәүче биш мең ярым кешенең 40 проценты—урыслар, 30 проценты -татарлар, 15е башкортлар икән. Район оештырылгач, бу саф татар авылына урыслар һәм башкортлар күчеп килә башлаган, шулай итеп, бөтен өлкәләргә дә урыс теле үтеп кергән һәм хуҗа булып алган.

Гомерләрендә татарча китап укымаган, татарча белмәгән Әлмән балалары белән очрашу уздырудан мәгънә юк иде, алар Габдрәшит Ибраһимовның кем

икәнлеген дә белмиләр иде. Мәктәп директорыннан христиан дине нигезләрен укыту мәсьәләсе белән кызыксынабыз. Ул бу проблемага шактый сак килде. "Бездә катнаш мәктәп бит, нишләргә дә белгән юк инде",—диде. Без аңа татар-башкорт балаларына христиан динен укыту дөрес булмаганлыгын әйттек, Казанда диннәр тарихы буенча яхшы китап чыкканлыгын, Татарстан мәктәпләрендә шул укытыла башлаячагын сөйләдек. Александра Бабикова да бу китап белән кызыксынды, чөнки мондый катнаш мәктәптә христиан дине нигезләрен генә укыту мөмкин түгел иде. Әхмәдулла әфәнде Әлмән мәктәбенә дә Татарстанда басылган диннәр тарихы китабын алып килергә булды.

Икенче эшебез итеп шушы авыл һәм район тарихы турында "Вехи истории Альменевского района" дип аталган китап язган Фәйрүзә апа Шакирова янына китәбез, бәлки Габдрәшит Ибраһимов турында ул нәрсәдер беләдер дип өметләнәбез. Фәйрүзә апа 85 яшен тутырган мөлаем гына бер татар хатыны булып чыкты. Аның әти-әнисе безнең яклардан, ә үзе исә Әлмәндә туган. Гомере буе мәктәптә, редакциядә, райкомда эшләгән, пенсиягә чыккач, үзе башлап йөреп, район музеен оештырган Фәйрүзә апа архивларда утырып, Әлмәнгә тарих китабы да язып биргән. Әлбәттә, китапның борынгы чорына аның материалы җитеп бетмәгән, ул Курганда яшәүче урыс тарихчыларының карашыннан читкә чыга алмаган, әмма китапта авылның һәм районның совет чоры бик тулы яктыртылган.

—Элек Әлмәндә зур татар мәктәбе бар иде, мин үзем дә шуны тәмамладым,—дип башлады сүзен Фәйрүзә апа.—Аннан параллель классларга калдырдылар, хәзер бөтенләй бетерделәр. 1963 елларда район бетеп торды, шунда татарча укыту да бетте. Ата-аналар үзләре дә балаларын русча укытырга тырыша, татар телен белүче укытучылар да юк хәзер... Алай да, балалар бакчасында татар бүлеге бар, татарлык шунда гына калды инде һәм Сабантуйларда... Элек татар телендә радио тапшырулары бар иде, хәзер юк. Элек бик зур татар фольклор ансамбле бар иде, 3 группа—өлкәннәр, яшьләр, балалар төркемнәре, хәзер ул бик зәгыйфьләнде, чөнки татар телен белүче юк, әйтә алмыйлар җырның сүзләрен. Элек районда татарча-русча газета чыга иде, хәзер русча гына калды. Элек авылда ике мәчет бар иде, Кыйбла як мәчетнең башта манарасын кисеп, клуб ясадылар, аннан ул кибет, ашханә булып торды. Хәзерге музей урынында да мәчет иде, аны да сүттеләр, 1931 елда аен төшергәндә халык бик елады. 1995 елны элеккеге авыл советы бинасын алып, түбәсенә манара куеп, халык мәчет ясады, хәзер шунда җомга намазларына йөри картлар.

Сүз дингә килеп җиткәч, Габдрәшит Ибраһимов турында да сорыйбыз, әмма Фәйрүзә апа аны белми икән, белмәгәч, китабына да кертмәгән. Мин аңа Габдрәшит Ибраһимов турында сөйләдем, аның "Дәүре галәм" китабын бүләк иттем, җай чыгып, башкортлар турында да сорадым.

—Мин үскәндә Әлмәндә бер башкорт та юк иде, читтән килгән 1-2 көтүче генә бар иде,—диде ул.—Урыс та юк иде, алар 1933 елда, авылда МТС оештырылгач килә башладылар. Әлмән саф татар авылы иде, монда хәзер дә Эчкен татарлары яши. Башкортларның Әлмәндә бернәрсәләре юк, корылтайлары гына бар, алар күбрәк башка авылларда яшиләр.

Әлмәндә өлкә татар конгрессы әгъзасы да бар икән, ул—Кәримов Ринат Ришат улы, район хакимият башлыгының социаль мәсьәләр буенча урынбасары. Ринат әфәнде шул ук вакытта башкорт корылтаеның да Әлмәндәге җитәкчесе булып тора икән. Әле Әлмәннең фольклор группасы белән Казанда булып кайткан, анда Эчкен татарларының туй йолаларын, кич утыру күренешләрен күрсәткәннәр. Башкортстанга нәрсә күрсәтергә алып баргандыр, белмим...

Фәйрүзә апа белән саубуллашып, музейга юл тотабыз, Габдрәшит Ибраһимов турында анда нәрсәдер күрергә өметләнәбез. Музей элеккеге мәчет урынында булгач, безне Габдрәшит Ибраһимов белән күзгә күренмәгән җепләр бәйли кебек иде. Музей директоры Юшков Владимир Дмитриевич безне бер катлы агач йортның баскыч төбенә үк чыгып каршы алды, бик тәфсилләп экспонатларны күрсәтеп йөрде. Әлбәттә, Габдрәшит Ибраһимов турында ул да белми иде, әмма музейда ул чор шактый яхшы яктыртылган булып чыкты. Кергәч тә милли татар почмагы каршы ала, ә иң түрдә—Фазыл хәзрәт Тынкачевның кабер ташы тора. Эш шунда ки, элеккеге зират хәзер парк эчендә калган, таш югалмасын өчен, аны музейга китереп куйганнар. Әмма авыл халкы арасында моны ошатмаучылар да бар икән, ягъни кабер ташы музейда түгел, зиратта торырга тиеш, диләр. Миңа

калса, ул бередә дә начар тормый, киресенчә, паркта аяк астында аунаганчы, монда ул кадер-хөрмәттә кебек күренә. Шулай ук киштәләргә кадерләп тезеп куелган борынгы дини китаплар, нәсел шәҗәрәләре, кульязмалар да бередә мәгърифәтле халык яшәгәнлеген сөйләп тора. Шунысын да әйтергә кирәк, XVI гасырда күчереп язылган борынгы кульязма Коръән дә Әлмән авылында табылган. Эчкен татары Әхмәт Уразаев-Кормаши үзенең атаклы "Таһир-Зөһрә" кыйссасын да шушы якларда рухланып язуын әйтеп үтәргә кирәк.

Колшәриф мәчете фонында аякларын бөкләп китап язып утыручы Габделнасыйр хәзрәтнең сыны да музейга керүчеләрне башка дөньяга, башка заманнарга алып китә. Габделнасыйр хәзрәт янына шагыйрь Басыйр Рафыйковның аңа багышланган шигырен язып куйганнар, тик ул нигәдер рус телендә генә. Шунысын да әйтергә кирәк, утызынчы елларда ата-аналары белән Мамадыштан Магнитогорскига сөргенгә сөрелгән Басыйр Рафыйков, Троицкида педагогия училищесын тәмамлагач, 1939-1941 елларда Әлмән мәктәбендә урыс теле һәм әдәбияты укыта.



*Әлмән авылы музеенда китап күчереп язучы Габделнасыйр Сәфәргалиевнең сыны.*

Миңа Әлмән районының гербы да бик охшады— яшел байракка томырылып чабып барган ат рәсеме ясалган, аста исә кояш-икмәктән 12 алтын башак нур булып таралган, бу Эчкеннән Әлмәнгә күчеп килгән 12 нәселне аңлата. Әлбәттә, Габдрәшит Ибраһимовның Төркиядән ниндидер әйберләрен алып кайта алсак, Әлмән музеенда аны һичшиксез куячаклар иде, димәк, моны үзебезгә эшләргә кала. Ягъни Әлмәндә әле Габдрәшит Ибраһимовны өр-яңадан ачарга туры киләчәк, иншаллаһ!

Алланың рәхмәте белән, мин Әлмәндә очраклы рәвештә бер апаны очраттым, хәер, дөньяда бер генә очраклы нәрсә дә юк бит! Яңа танышым Һадиева Гарифә Әхәт кызы 1939 елны Әлмән авылында туган, 40 ел Бишнәк авылында яшәгән, шуның 20 елын мәктәптә татар телен укыткан икән. Гарифә апаның кыз чактагы фамилиясе Тынкачева булып чыкты, һәм ул Фазыл .хаҗиларга барып тоташкан нәсел шәҗәрәсен тикшереп, торгызып йөри икән. Мин, әлбәттә, ачыклап бетермәгән килеш аның Габдрәшит Ибраһимовка да туган булырга тиешлеге турында әйтмәдем, әмма без адреслар алыштык, аралашып торырга килештек. (Чаллыга кайтып, үземдә булган архив материалларын тагы бер тапкыр тикшергәч, минем инде Габдрәшит Ибраһимовның Фазыл хаҗи Тынкачевка туганлыгына шигем калмады, димәк, Бишнәк авылында яшәп ятучы Гарифә апа да аның ерак туганы булып чыга бит! Бу хакта мин шул көнне үк Курган өлкәсенә Әхмәдулла әфәндегә шалтыратып, хәбәр бирдем һәм Гарифә ападан үзендә булган материалларны сораттым.)

Иң соңыннан Әлмән авылының боз кебек салкын мәчетен ачтырып кереп, намаз укыдык, бередә бездән дога өмет итеп яткан әрвахлар рухына, Габдрәшит Ибраһимовның әби-бабалары рухына багышлап дога кылдык. Әлмәндә Габдрәшит Ибраһимов белән бәйле әллә нәрсә тапмасам да, мин монда килергә тиеш идем, ул йөргән эзләрдән йөрергә, ул күргән табигатьне күрергә тиеш идем. Ул монда дүрт ел белем ала, язганнарыннан күренгәнчә, шушы вакыт эчендә мең чакрымда булган туган шәһәренә бер тапкыр да кайта алмаган, һәм 1871 елда ул шушында әнисенең үлгән хәбәрен ала, әтисенең чакыруы буенча, Әлмәнне калдырып, Тарага кайтырга кузгала. Әмма Төмәнгә кайтып җиткәч, ул әтисенең дә үлгән хәбәрен ала, шулай итеп, 14 яшендә дөм ятим кала. Аңа әтисеннән бер тиен мал калмый, киресенчә, 12 яшьлек энесе өчен дә инде ул кайгыртырга тиеш була, чөнки Тарада калган җизнәләре: "Углым, атагыз вафат итте, бер әйбере калмады, кардәшең Исмәгыйльне монда тәрбия кыла торган кеше юк. Син һич килмә, мин бер чара булып, кардәшеңне анда юллармын, ничек булса да икегез бәрабәр яшәрсез",—дип язылыган хат килә.*(Күрсәтелгән хезмәт, 141 б.)* Шулай итеп, ике ятим дөнья буйлап җитәкләшеп чыгып китәләр...

Буранлы юл буенча Әлмәннән Эчкенгә кайтып җиткәнче, мин шушы ятим

балалар турында уйладым. Дөрес, мин аларның авырлыклар каршында югалып калмауларын, бөтен каршылыкларны җиңеп, зур кешеләр булып, милләткә һәм дингә хезмәт иткәннәрен белә идем инде. Тик аңа кадәр күпме газап күргән, күпме кыен ашаган, күпме авыр сүз ишеткән бу ятимнәр, әмма милләттә һәм өммәттә аларга ярдәм кулы сузучылар да булган. Әлмәннән Төмәнгә кайтышлый, Габдрәшит Ибраһимов та Эчкендә туктап, бер атна мосафир була, әнисез калу кайгысын шушындагы татарлар белән бүлешә. "... шул көннәрдә безнең юлыбызга Эчкен карьясыннан килгән бер муллага безне юлдаш итәрәк, ул арадан хәрәкәтебезгә ярдәм итте,—дип яза ул кайгылы көннәре турында Габдрәшит Ибраһимов.—Бу рәвешле без Әлмән карьясын ташлап китәрәк юлга юнәлдек, өч көн тарафында Эчкен карьясына килдек, йөз илле чакрым сәфәр кичтек. Ул арада бер атна кадәр юлчы булдык, нәтиҗәдә төмәнлек Акъяр каласыннан Мөхәммәдколый исемле бер адәм туры килеп, безне Төмәнгә кадәр бәрабәр ияртеп китерде, бу арада тагын бер атна кичте." *(Күрсәтелгән хезмәт, 140 б.)*

... Эчкен мәктәбендә балалар белән очрашканда, мин менә шулар турында әйттем, ата-анасыннан дөм ятим һәм бер тиенсез фәкыйрь калып та, Алла ярдәме белән, үз тырышлыгы, иманлы, тәртипле булуы сәбәпле, якташлары Габдрәшит Ибраһимовның нинди бөеклекләргә ирешүе турында сөйләдем. Мин бу балалар арасыннан да динебезгә, милләтебезгә хезмәт итәрлек асыл затлар чыгасына ышанам, чөнки алар ана телендә укыйлар, динебезгә зур хөрмәт белән карыйлар, кара урман уртасында яшәсәләр дә, Интернет аша бөтен дөнья белән элемтәдә торалар. Аларга да күренекле якташлары Габдрәшит Ибраһимовтагы кебек кызыксынучанлык, белемгә омтылу хас, Эчкен балалары авылны чорнап алган скиф курганнары турында да, татар халкының асыл тамырлары турында да үзләре зур тарих язар әле, иншаллаһ!

Себергә сәфәрем тәмам, алда мине Габдрәшит Ибраһимов эзләре буйлап Төркиягә сәяхәт, Истанбул-Анкара архивлары, аның Төркиядә генә басылып чыккан китаплары, шул бәрәкәтле туфракта яшәп ятучы нәселе-оныклары көтә иде...

*Язмада автор фотолары файдаланылды.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклантан кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# Гаилә елы уңаеннан



*Язучы Әмирхан Еники (1909-2000) гомеренең соңгы дәверендә яшәгән хатыны Нәҗия ханым белән. 1999 ел.*



*Туган илдә нигез корабыз! Сөргеннән Кырымга кайткан яшь гаилә. 90 нчы еллар.*



*Татарстанның халык язучылары Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов хатыннары Нәкыя һәм Шаһидә ханымнар белән. 1992 ел.*



*Сынчы Фәһим Фәсхетдинов кызы Луиза (чигү остасы, Татарстан Рәссамнәр берлеге әгъзасы) белән. 1994 ел.*



*Шагыйрьләр гаиләсе: Әдип Маликов һәм Саҗидә Сөләйманова. 1951 ел.*

## Нурихан Фәттахның тууына 80 ел

*Нурихан агабыз үзенең беренче чор иҗаты—"Сезнеңчә ничек?", "Бала күңеле далада", "Мөдир Саҗидә" кебек роман-повестьлары белән дә әдәбиятыбыз тарихында урынны түрдән алган булыр иде. Ләкин болардан соң аның "Әтил суы ака торур", "Сызгыра торган уклар" дигән тарихи романнары, "Кол Гали" трагедиясе, "Шәҗәрә" дигән тарихи-лингвистик тикшеренүе дә дөнья күрде. Болар әдипкә дан-шөһрәт өстәп кенә калмады, татарның милли аңын уятуда да мөһим роль уйнады.*

*Татарстанның халык язучысы Н. Фәттахның бөтен әсәрләре дә диярлек иң әүвәл "Казан утлары"нда басылды. Һәм бу эш әдипнең вафатыннан соң да (2003) дәвам итә. Былтыр журналда Нурихан аганың "Аклан" дигән хыялый романын биргән идек. Бу санда басыла башлый торган истәлекләре әдипнең балачак елларын бәян итә. Редакциягә хатыны Руфинә ханым китергән бу истәлекнең азагында "26 апрель, 1988 ел" дигән дата тора.*



Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

*Үткән гомер, калган хәтер*
*Сатып алыйм дисәң табылмас.*

### 1. Телеграмма

1984 елның язы бик иртә килде. Башка еллардагыга караганда табигать иртәрәк уянды, кешеләр авыр киемнәрен иртәрәк салып ташладылар. Күк йөзе иртәдән алып кичкә кадәр чалт аяз булды, аяз күктә көне буена кояш балкып торды. Вакытыннан элегрәк килгән яз баштарак сөендерде, соңга таба шулай да күңелләргә шом салды—ни әйтсәң дә гадәттәгечә түгел. Эсселек көннән-көн арта башлагач һәм май уртасында температура утыз градуска җиткәч, кешеләр пошаманга төштеләр, һәркем күктән яңгыр көтте.

Менә шундый баш пешәрлек эссе көннәрнең берсендә Татарстан Язучылар союзының ничәнчедер зур җыелышы булды. Җыелышның төрлесе була—берсенә барасың, берсенә бармыйсың, чөнки файдасы, кызыгы

булмаячагын алдан ук белеп торасын. Бу жыелышта мин иртәдән башлап кичкә кадәр булдым, бер көн генә дә түгел, икеме, өчме көн булдым.

Шулай бер көнне арып-талып соң гына өйгә кайтып керсәм, минем исемгә телеграмма килгән. Ашыгыч хәбәр китерүче телеграмма һәрвакыт күңелдә курку һәм шомлану тойгысы уята. Ашыгыч хәбәрнен, билгеле, күңеллесе дә булырга мөмкин. Һәрбер көтелмәгән хәлдән курку канга сеңгәнгә күрә, теләсә нинди телеграмма мина бары күңелсез хәбәр генә китерәдер сыман тоела.

Телеграмма авылдан килгән иде. Инәннен хәле шәптән түгел, кайт, дигәннәр. Моннан берничә көн элек шундыйрак хат та килгән иде. Чирләп тора, сине көтә, кайтырга тырыш, дигәннәр иде. Мондый хатлар авылдан килгәли тора, шуна күрә әлеге хат та мина әлләни тәэсир итмәгәндер кебек. Бит безнен гадәттә эш күп була, безгә әле вакыт житми, әле акча житми. Аннан соң моннан утыз-утыз биш еллар элек тә, университетнын ничәнчедер курсында укыганда авылдан мина шундыйрак телеграмма килеп төшкән иде. Әниеннен хәле шәптән түгел, тизрәк кайтып жит, диелгән иде. Әле дә хәтердә: кыш башы, яна гына кар яуган чак. Катып-туңып, вагон тоткасына гына тотынып дигәндәй, мен газап белән кичкырын авылга кайтып төштем. Кайтсам, инәкәй тап-таза, көлеп-елмаеп тик утыра. Мин, билгеле, бик ачуландым. Мен газап чигүе бер хәл, анын бит әле укуы да кала, калган уку өчен жавап та бирәсе була. “Ник чакырдыгыз?”—дидем. “Күрәсем килде сине,—диде инәкәй.—Хатына да язгансын, ашау ягы начар, дигәнсен. Бәрәнге булса да алып китәрсен”,—ди. Ул вакытта мин чыннан да бер капчык бәрәнге алып киттем. Тамбурда, вагоннар арасында кача-поса көчкә Казанга килеп егылдым.

1984 елнын маенда телеграмма алгач, әнә шул күптәнге хәлләрне искә төшердем. Ләкин бу юлы мине бәрәнге алып китәр өчен генә чакырмыйлардыр иде, ахрысы, авылга. Мин уйга калдым. Күңелдә ямьсез бер сизенү барлыкка килде. Шулай итеп, ана да вакыт житте микәнни? Ул вакыт, билгеле, һәркемгә житә һәм житәргә тиеш. Ләкин андый котылгысыз “вакыт” никтер синен үзенә дә, синен якыннарына да беркайчан да житмәскә тиеш кебек. Ул “вакыт” бары башка кешеләргә генә житәргә тиеш кебек. Бит хәзерге заманда кешеләр машинага тапталып үлә, агуланып үлә. Ләкин мин бик яхшы белгән, минем өчен иң кадерле булган кеше андый үлем белән үләргә тиеш түгел...

Кечке энгер-менгердә бүлмәгә караңгы тула башлады. Ут яндырдык. Ләкин шом баскан күңелне ут кына яктырта алмады. Өзек-өзек булып үткәннәр искә төште, кайчандыр әйтелгән сүзләр янадан ишетелеп киткәндәй булды. Төне буена йокылы-уяулы килеш уйланып, борчылып чыктым. Авылга иртән иртүк китеп булмады. Авылга бары икенче тәүлек башында, төн урталарында гына кузгалып киттем. Хәзерге заман машиналары әкияттәге кебек сине күз ачып йомганчы бер урыннан икенче урынга илтеп куя ала. Ул син ашыкмаганда гына шулай. Син ашыкканда алар нишләптер әкрен кыймылдыйлар.

Шулай да мин кайтып життем авылга. Кайткач, апа сөйләп бирде: үпкәсенә салкын тигән, диде. Хәле алай куркыныч түгел, диде, кичәгенәк кенә бүлнискә салдык, диде. Больница авылнын үзендә генә, икенче очта. Иртән ашагач-эчкәч, ашыкмыйча гына, тыныч кына, сөйләнә-сөйләнә, ындыр артлап тар сукмактан апа белән больницага киттек.

Авылнын икенче башына барып житәрәк, читтә, елга буенда, куе чыршылык арасында агач өйләр. Искереп беткән, кыйшаеп беткән өйләр. Менә шул “бүлнис” була. “Палата” дигәне—зур гына бүлмә. Түшәме тәбәнәк. Ике яклап тезелгән караватлар. Матрацы-ние юк. Шәп-шәрә

караватлар, тип-тимер. Тәбәнәк тәрәзәдән төрле чүп-чар үләннәре, әрсез куак-ботаклар күренеп тора. Бөтен палатада ике авыру. Берсе—башка авыл хатыны. Икенчесе...

Без килеп керү белән, башка авыл хатыны, кирәгеннән артык кычкырып, шундук аңлатырга тотынды: бүген әйбәт йоклады, диде. Аннан тупас кына итеп миңа кычкырып алды, "нигә кайтмадың?"—диде.

Мин тимер караватчитенә утырып, инәкәйнең мамыктай йомшак коры кулын учыма алдым. Ул да шул ук сорауны бирде: "Нигә кайтмадың?"—диде. Кайттым ич менә, дидем. Беләсең ич, күршегә керү генә түгел, дидем. Беркадәр вакыт без аның хәле турында сөйләшеп утырдык. Ул ятып торды, әледән-әле күзләрен ачып карады. Апа әйтте, янында торырга, төн кунарга, булышырга калыйммы, диде. Ашарына кирәкмиме?—диде. Бернәрсә дә кирәкми, өйгә кайтыгыз, диде инәкәй.

Гомергә ул динле булды, үлгәч терелү булачагына, теге дөньяда оҗмах та, тәмуг та булуына чын күңелдән ышанып яшәде. Шул ук вакытта ул медицинага да ышанды. Больницага салганда яшь кенә врач апа әйткән, сиңа пенициллин кадарга кирәк, ләкин бездә пенициллин юк, дигән. Шулай да соңыннан каяндыр тапканнар һәм кадый башлаганнар. "Укол кадыйлармы?"—диде инәкәй. "Кадыйлар", дидем мин. Шуннан соң ул тынычланып күзләрен йомды. Бу көннәрдә мине көтеп ул рәтләп йокламаган булган, ахрысы. Хәзер инде йокласа да ярый.

Без дә тынычланып кайтып киттек. Кичкә таба безнең арттан күңелсез хәбәр килеп җитте. Мин аптырап калдым. Минем ышанасым килмәде. Бит ул үзе әйтте безгә кайтып китәргә! Белгән булсам, сизгән булсам кайтып китәр идеммени мин аның яныннан?! Һичьюгы бирәр кирәкле, бик кирәкле сүз әйткән булыр идем.

Менә шул. Без аны носилкага салып, өсте ачык машинада өйгә алып кайттык. Күрше-тирәгә хәбәр иттек. Төне буе хатыннар, корткалар аның янында утырып чыктылар. Икенче көнне таң ату белән урамның бер башыннан икенче башына Зәйкәт: "Кабер казырга барыгыз! Кабер казырга барыгыз!" дип кычкырып үтте. Безнең тау башындагы, чыршылыктагы тавык кетәгедәй бәләкәй генә өйгә янадан күрше хатыннары җыелды. Кабер казучылар Пулат яктагы зыяратка киттеләр.

Җир эрү булса да, кабер казу бик авыр булды. Шулай да каберне төшкә өлгерттеләр, өйдәгеләр ул арада мәетне юдылар, йола кушканча соңгы эшләрне башкардылар. Иплән кенә, сак кына күтәреп бераздан аны өйдән алып чыктылар һәм җиләс җилдә монсу гына гүләп утырган чыршылар янына, яшел чирәм өстенә сузып салган кабыкка куйдылар. Заманча мулла, таушалып беткән куен дәфтәренә карый-карый, ясин укыды, хәер таратылды, һәм мондый чакларда гына әйтелә торган изге сүзләр әйтелде.

Мартның унбишендәме, егерме бишендәме аңа 84 тулган иде. Гәүдәгә ул ябык, чандыр иде. Шулай да кабыкка салып күтәргәч, нишләптер ул бик авыр тоелды. Без аны унлап кеше күтәреп бардык. Көн эссе. Аяк астында тузан бөркелә, маңгайлардан тир ага. Зыяратка ирләр генә барды. Аллы-гөлле күлмәкләр кигән, озынча яулык бәйләгән хатын-кызлар калкулыкта, чыршылар янында сүзсез генә озатып калдылар. Мәңгелек юлга озатып калдылар.

Без аны күтәреп алып бардык. Җир куенына салдык, чи, авыр, үзле балчыкны кире үз урынына өеп куйдык та, артка борылып карамаска тырышып, авылга, исәннәр янына кайтып киттек. Менә шул. 1984 елның 25 май көнендә Янтык Нуртдин кызы Сәлиха җирдә яшәүчеләр исемлегеннән сызып ташланды.

Авылда күрше-тирәдә аны чын күңелдән хөрмәт иттеләр. Ул беркайчан күршеләр белән бозылышмады, гайбәт сатмады, кешенең йөзен ертмады. Соңгы елларда ул күбрәк вакытын йорт эшләре белән булашып үткәрде, туктаусыз дип әйтерлек китап укыды. Күрше-тирә, яшенә карап, берсе Сәлихәттәй диде, икенчесе Мулләттәй диде, Әбзаби диде. Үлгән көнне аның турында "изге" дигән сүзләр ишетелде.

Мин кайтканда авылда да Казандагы кебек бик эссе иде. Корылыктан җирләр ярылган, үләннәр саргая башлаган. "Мулләттәй"не күмгәч, төштән соң күктә болыт күренде. Кичкә таба зарыгып көткән яңгыр сибәли башлады. Төнлә яңгыр коеп яуды. Элекке заман булса, мондый хәлне могҗиза дип аңлатырлар иде. Бит аның үлеме дә үзе теләгәнчә булды! Ул атна кич үлде, җомга көн, җомга укылганчы күмелде. Изгелегенә тап төшерәсем килмәсә дә, мондый туры килүнең сәбәбен әйтми кала алмыйм. Бөтен күңеле белән ул мине көткән. Әгәр аның мине күрү өмете беткән булса, ул, ихтимал, иртәрәк тә үлгән булыр иде. Бит кешене өмет яшәтә. Улын күргәч, ул кинәт тынычланып калган. Үлем аның шундый чагын сагалап кына торган да инде.

## 2. Имеш-мимеш

Дөньяга мин Нуртдин кызы Сәлиханың икенче баласы булып туганмын. Беренчесе Тәәүлә дигән бик сәер исемле кыз бала булган. Әллә сәер исемле булганга, әллә башка сәбәптән, тугач Тәәүлә күп тормаган. Миннән соң туган Халисә белән Тәлгать тә үлгән. Мин Халисә сеңлемне бөтенләй хәтерләмим, Тәлгатьне бераз хәтерлим. Мин аны гел тәрәзәдән карап торган итеп күрәм. Кара бөрчекле күлмәге кендек турысыннан гына. Кендектән түбән берни юк, шәп-шәрә. Ул, ахрысы, тифтан үлгән. Тәлгать миннән тазарак булган. Минем чәчтән тота да "ах апбыйны!"—дип әйтә торган булган имеш.

Мин үзем мен дә тугыз йөз егерме җидеме, әллә егерме сигездәме туганмын. Мин туганда көз көне булган, солы суккан чак булган. Паспортта мин егерме сигезенче йөрим. Туган көнем 25 октябрь имеш, ләкин чынлыкта ул октябрьме, ноябрьме—беркем белми. Мин туган заманнарда ел исәбен, көн исәбен төгәл теркәп калдыруга әлләни игътибар итмәгәннәр, ахрысы. Муллада яздыру беткән, янача теркәү әле, күрәсең, ныклап торып урнашмаган булгандыр. 1928 елны да, 25 октябрьне дә миңа паспорт бүлегендә бүләк итеп кенә бирделәр. Соңыннан инәкәйдән төпченеп карасам да, ул миңа ачык кына итеп берни дә аңлата алмады. "Надан булганмын, берни белмәгәнмен"—диде. Ул үзе 1903 елда март аенда туган. Ләкин ничәнче көнендә мартның—анысы да билгесез.

Менә шул—туганбыз шулай да дөньяга без. Мин бик бәләкәй булганмын. "Йодрык кадәр генә", дияр иде инәкәй. Күрше җиргәләре керәләр икән дә, инәкәйне үртәп, "Һи, җиңгәй, шул да кеше булыр дисеңме?!"—диләр икән. "Сездән артыграк булыр әле ул!"—дип әйтә торганыем, дияр иде инәкәй.

Бик кечкенә, зәгыйфь кенә һәм жылак кына булганмын мин. Килен буларак инәкәй юаш һәм йомшак булган. "Синең белән авырлы чакта көн-төн эштә булдым—мал карадым, сыер саудым, эпи пешердем, ашлык суктым. Бар кара эш минем өстә булды",—дип сөйләгәне истә калган. Әткәй дә юаш холыклы булган. Аның урынына әткәйнең инәсе—инәкәйнең каенанасы усал һәм кансыз булган, имеш. "Бидерә тутырып сөт савып керәм, үземә бер кашык сөт алырга курка торганыем" дип сөйли торган иде инәкәй. Иң нык хәтердә калганы шул: минем белән авырлы чагында аның бәрәңге ашыйсы килгән икән. Каенанадан куркып, бәрәңгене җеп

манганда жеп янына салып пешерә икән дә, качып-посып ашый икән.

Мин туар алдыннан ул солы сугуда булган бугай. Мин тугач күп тә тормаган, янадан эшкә тотынган. Имезергә сөте булмаган, вакыты булмаган, күрәсең, эшен ташлап өйгә керергә курыккан. "Мин" дигән йодрык кадәрле бала көне буе җылап, үз йодрыгын үзе имеп яткан. "Бишегең янына беркем килеп әйләнмәсие" ди торган иде инәкәй. "Үлсә изге җан булыр, үлсә котылырсын, җингәй", дигәннәр күрше-күләннәр яшь килен белән мескен баланы кызганып.

- Үлмәсен!—дигән инәкәй ачуланып.

Шулай итеп без исән калганбыз. Ачлыкка, тифка һәм төрле җәбер-золымга бирешмичә без шулай яши биргәнбез. Беренче баласының үлемен яшь ана үзенең "йомшаклыгыннан, аңсызлыгыннан" күргән. Икенче баласы булгач, анда, күрәсең, ихтыяр көче уянган һәм ул мине саклап кала алган. Мин дә алай изге җан булырга атлыгып тормаганмындыр.

Менә шул—үлем белән, җәбер-золым һәм хаксызлык белән көрәш рухы бездә бишектәге заманнарда ук баш калкыткан. Әйтсәм әйтим, минем бөтен гомерем туктаусыз көрәш булды. Мин яшәү хокукын бертуктаусыз кем беләндер сугышып-тартышып алгандай алдым.

Әдәп һәм закон рөхсәт иткәнчә, мин шулар турында сөйләрмен дип уйлыйм. Без ялганны чын дип язарга күнеккән ... Мин мөмкин кадәр дөресен язарга тырышачакмын. Ләкин бик күп серләр үзем белән китәчәк. Кеше күнеле—төпсез кое, кеше күңеле—серле сандык ул. Аннан соң шунсы да бар бит әле: кемгә кирәк синең кайгыларын да, кемгә кирәк синең хәтер калуларың борчулы, мәшәкатьле бу заманда? Синен эч серләрен, синен тормышың чыннан да беркемгә дә кирәк булмас, бәлки. Анысы шулай.

## 3. Тарих һәм география

Дөньяда Кучтәвыл дигән авыл барлыгын Кучтәвыл кешеләреннән башка беркем белми дияр идем, ялган булыр. Күчтәвылны күршеләре, якын-тирә авыл кешеләре беләдер кебек. Элек анда 30-40 йорт булган. Совет власте елларында авыл күзгә күренеп үсте, хәзер анда 50-60 йорт бар, ахрысы. Өйләр "елга" дип аталган тар гына, тирән генә су буена урнашкан. "Су"ның ярлары йомшак—ишелеп-кимерелеп кенә тора, чөнки "елга" тигез җирдән, үзәннән ага. Елга артында тәбәнәк кенә тау калкып утыра. Тау белән елга арасында тигезлек җәелеп ята. Каз, бозау "болыны". Тауҗыкның уң ягында серле булып Бәрдәшә чокыры күренә, чокыр буйлап "урман" сузыла. Сул якта таучык түбәнәя барып, каядыр китеп югала. Аннан да арырак, бик-бик еракта, зәңгәрләнеп, томанланып һәм бик тә серле булып Бүә—аръяк таулары-урманнары күренә. Хәер, Кучтәвылның үзәненнән күренә микән, бик үк ышанып житә алмыйм. Минем күнел күзеннән генә ул шулай серле булып күренә, ахрысы.

Кучтәвыл исемен картлар "Күчте авыл" исеменнән чыгып аңлаталар иде. Кучтәвыл элек, имеш, бик зур авыл булган—әллә жиде мәчетле, өч тегермәнле, әллә өч мәчетле, жиде тегермәнле. Тегермән белән мәчет саннарының нисбәте ничек булгандыр—төгәлен әйтеп булмый. Ләкин шунысын ышанып әйтергә була: бик ерак заманнарда Кучтәвыл Казан ягыннан күченеп килгән. Хәзерге Кучтәвыл элекке Кучтәвылның бер кыйпылчыгы гына, имеш.

Житмешенче елларда авылга кайткач, әткәйнең бер кордашы, сиксән яшьлек Фәлән карт әйткән иде, Бөре ягында тагын бер Кучтәвыл бар, дигән иде. 1983 елда Казанда Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" китабы янадан басылып чыкты. Китапның азагында дастанның халык арасында

табылган төрле кульязма нөсхәләренең тулы исемлеге бирелгән. Шунда Башкортстанның Янавыл районы Кучтәвыл авылында табылган нөсхәсе турында әйтелгән сүзләрне күреп мин балаларча елмаеп җибәрдем. Сөенечемнән хәтта телсез-өнсез калдым. Менә нинди атаклы авылда туганмын икән мин!

Казаннан Сверловскига барганда, ике шәһәр уртасындарак, Янавыл дигән станция бар. Янавыл—район үзәге, Янавыл—минем үсмер чакның данлы башкаласы. Янавылдан өч-дүрт чакрым читтә Буә дигән елга ага. Буәне картада БУЙ дип язалар. Без гадәттә Буә-буй дип, Буә-буйда, ягъни "Буә буенда" дип сөйләшәбез. Моннан фәлән еллар элек карта төзүче урыс иптәш шул Буә-буйны ишетеп калган да елганы да Буй дип язып куйган, күрәсең. Менә шуннан киткән Буй буйдан-буйга.

Буә Көнчыгыштан Көнбатышка таба ага да, Камбаркадан түбәнрәк борынгы Чулманга житеп коела. Янавыл Буә үзәненә—тип-тигез жиргә урнашкан. Буәнең уң ягында—төньягында таулар, урманнар, сул ягында—көньякта шәрә жирләр. Монда инде калкулыклар тәбәнәгрәк, урманнар юк дәрәҗәсендә. Безнең атаклы Кучтәвылыбыз Янавылдан биш-алты чакрым көньяккарак урнашкан. Кучтәвылны күрәсе килгән туристлар юлны ялгыштырмаслар дип уйларга була. Янавылдан чыккач та Әйбүләк ягына таш юл китә. Таш юлдан бер-ике чакрым баргач, сул якка сукмак сыман гына юл китә. Янавылга килгәндә, Янавылдан кайтканда без элек шуннан йөри торган идек. Хәер, теләгән кеше Күник аша да бара ала.

Кучтәвыл—типтәр авылы. Жирсез-сусыз, урмансыз авыл. Утын урынына элек салам ягалар иде. Урманлы як кешеләре, ягъни Буә аръяклары Кучтәвылны гомер-гомергә "хәерче" дип йөрткәннәр. Кучтәвылның бер ягында—Әйбүләк юлы буенда Күник дигән удмурт авылы, икенче якта—Ябалак дигән мари авылы. Авыл халкы удмуртны ар ди, марины чирмеш ди. Болары Кучтәвыл кебек үк үзәнгә, тигез жиргә утырган якын авыллар. Көнчыгышта—тәбәнәк калкулык артында, биш-алты чакрым ераклыкта—Эткенә авылы. Безнең авылныкылар әйтмешли, Эткенәвыл-Көнбатышта, шулай ук тәбәнәк калкулык артында—Байгужа дигән авыл. Байгужа—типтәр, Эткенәвыл башкорт исәпләнелә. Аның жирләре әдәм әйтеп әдәм ышанмаслык—бөтен тирә-якны каплап алган. Эткенә авыл жирләре элек мин белгәндә генә дә Кучтәвылның ындыр артына килеп терәлгән иде. Кучтәвылның каршысында гына калкып утырган тәбәнәк тау да, Бәрдәшә чокыры да, андагы агач-куаклар да Эткенәвылныкы исәпләнелә иде.

Эткенә авыл, билгеле, чи башкорт түгел. Аларның ата-бабалары бу жирләргә шулай ук Казан якларыннан килгәннәр һәм кучтәвылларга караганда алданрак килеп утырганнар, башкорт булып язылганнар һәм шулай итеп күбрәк жирне эләктереп калганнар. Патшага бөтенләй диярлек салым түләмәгәннәр. Алар баемый кем баесын?

Кучтәвылның жирләре уч төбе кадәр генә дисәм, хәтерләре калыр. Шулай булса да, Кучтәвылның жире кара туфраклы, уңдырышлы. Сугыш елларында тирә-якныкылар ачтан шешенгәндә кучтәвыллар авыз тутырып эпи ашадылар. Колхоз булсалар да, авыл халкы үз жиренә трактор-фәлән кертмәде. Бөтенесе ат көче, кул көче белән эшләнде. Халык бердәм, тырыш булды.

Менә шушы бердәм, тырыш һәм уңган халык яши торган Кучтәвылда туганмын да инде мин.

Буәнең таулы-урманлы ягында, Янавылдан турыга сигез-тугыз чакрым чамасы төньяктарак Яңа Уртавыл дигән бер авыл бар. Буә суын Буй дип язган урыс писаре Яңа Уртавылны кәгазьгә Новый Артаул дип язган. Шуннан ул һаман да русча Н. Уртаул дип языла. Хәзер инде русча гына

түгел, татарча да Урта авыл Арт авылга әйләнгән. Язганда да, сөйләшкәндә дә заманыбызның алдынгы укымышлылары Артаул дип кенә җибәрәләр.

Бүә буе җирләрендә иң элек Карман дигән авыл барлыкка килгән. Шуннан соң Карманнан бер егерме чакрым көнчыгышта яңа авыл оешып киткән. Күпмедер вакытлар үткәч, Карман белән Янавыл уртасында өченче авыл үсеп чыккан. Монысын Урта авыл дип атаганнар. 1755 елда колониализмга каршы баш күтәргән мишәр мулласы Батыршаның патшага язган хатында Гәйнә яклары турында сүз бара. Шунда Батырша, "Урал илендә Уртаул" дигән авылны да телгә ала. Бу, күрәсең, безнең яктагы Урта авыл булгандыр инде.

Батырша язганча, моннан ике йөз дә утыз еллар элек Уртаул кешеләре бик оста укчылар булганнар, чаңгыда яхшы йөргәннәр. "Вә һәм чаңгы йөрергә шул кадәр осталар, урман эчендә качкан киек котылмыйдыр. Алдына аркылы яткан ат биеклеге агачларны аша сикереп чыгалар. Йулдан килүче ат кырдан килгән чаңгылы кешеләремезгә йитмәйдер" дип язган Батырша Уртавыл кешеләре турында.

Яңа Уртавыл Иске Уртавылдан бүленеп чыккан. Яңа Уртавылның Янтык дигән исеме да бар. Монысы халык телендә. Иске Уртавыл да, Яңа Уртавыл да башкорт санала. Ләкин чи башкортка аларның берниндиi катнашы юк. Эткенәвыллар кебек алар да Казан ягыннан күченеп килгәннәр. Татарстанның үзәгендә, Лаеш районында Янтык дигән ике авыл бар—берсе татарныкы, берсе руснықы. Шул ук районда Кече Елга, күршедә генә, Балык Бистәсе районында Олы Елга авыллары бар. Безнең якта, Янтык янында гына шулай ук "Елга" дигән авыл бар. Булат Елга дип атала. Халык телендә Пулат кына дип йөртәләр. Пулатка, имеш, Булат дигән кеше килеп утырган. Дөрестерме, юктырмы, ләкин "Елга" исеме ерактан, Казан ягыннан тагылып килгән.

Әткәй минем типтәр ягында, Кучтәвылда, инәкәй—"башкорт" ягында—Янтыкта туган. Әткәйнең туган елы билгеле түгел. Әткәй белән бергә уйнап үскән Рәхимҗан абзый әйткән, имеш, "Садырлиман кырык яшендә үлде", дигән. "Садырлиманның" үлеме тарих сәнә 1934 тә булды. Февраль башы ирде. Күрәсең, ул 1894 елда тугандыр. Хәер, аның кайчан тууы да кайчан үлүе кемгә генә кирәк булыр икән?

## 4. Тарихның дәвамы

Янтык—Яңа Уртавыл халкы Бүә аръягына күченеп утыра башлаганда бу яктагы җирләр кара урман белән капланган булган. Кешеләр озын чыршыларны туп-туры булачак ишек алдыннан гына кисеп алганнар да, шунда ук өй салганнар, каралты-кура салганнар. Әкренләп җир ачканнар, урман яндырганнар. Күрше Мәхмүтҗан бабай сөйли торган иде: көн туу белән олылар урманга китәләр икән, бала-чага җыелышып өйдә кала икән. Урман яндырганда күтәрелгән төтен авылга кадәр килеп җитә торган булган. Төтеннән качып балалар, ягъни Мәхмүтҗан бабайлар өйдә генә ятканнар, имеш.

Мәхмүтҗан бабай хәтерләгән ул урман яндырулар, күрәсең, җир ачу өчен түгел, ачылган җирне киңәйтү өчен кирәк булгандыр. Чөнки җирне элегрәк ача башлаганнар. Ни генә булмасын, Янтык—Яңа Уртавыл халкы монарчы кеше аягы басмаган җиргә килеп утырган, үз тырышлыгы белән яңа җирләр-басулар ачкан. Авыл уртасында кайчандыр кара урман шаулап утыруын хәтерләтеп авылның әле бер төшендә, әле икенче төшендә—ишегалды, ындыр артында, киртә буйларында әле дә юан-юан чыршылар, каеннар моңаеп утыра. Яңа җир ачкач, ишегалды тирәсендә, авыл янында үсеп утырган ялгыз агачлар калдыру, күрәсең, безнең халыкның борынгы бер йоласы булгандыр. Элек

озын кәүсәле агачларга табынганнар һәм аны алла дип белгәннәр. Күчтәвылда, авыл каршындагы тау буенда шулай ук бер ялгыз нарат утыра иде. Мин кечкенә чакта шунда барып нарат төбеннән ниндидер "серле" ташлар жыя торган идек, наратның чатлы-ботлы ботакларына карап, исебез китеп: менә ул алла бабай дип сөйләнә торган идек. Андый сүзләрне инде без үзебез уйлап чыгармаганбыздыр—олылардан отып алганбыздыр.

Янтыкта да безнен тау буенда, лапас артында ялгыз чыршы шаулап утыра иде. Шундый ук йөз яшәр чыршы ишегалдыннан читтә, урам якта да бар иде. Сугыш елында утын югында без аларны утынга кистек. Хәзер рәхәт—агачларны "алла" дип көфер сүз сөйләүче балалар да юк, йөз яшьлек чыршылар да юк.

Инәкәй ягыннан безнен нәсел гомергә игенчеләр булган. Ләкин Янтык жирләр әллә ни ундырышлы түгел. Аннары тау да таш, чокыр-чакыр дигәндәй. Бәлки, шуна күрәдер, кыш көне халык сату-алу белән якындагы базарлы авылларга, шәһәрләргә олау йөргән. Революция алдыннан авылларда таш кибетләр, елгаларда зур-зур тегерменнәр барлыкка килгән. Китапта язылганча, безнен якка капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керә башлаган.

Инәкәйнен инәсе Вайжады кызы булган. Мин анын исемен белмим. Бездә өлкәннәрнен исемен атау, аларга исем белән эндәшү булмаган дип әйтергә була. Бигрәк тә хатын-кыз ягын. Менә шул "исемсез" Вайжалы кызын Яна Уртавылнын Каюм малае сукыр Нуртдингә кияүгә биргәннәр. Безнен Каюм бабай Яна Уртавыл-Янтыкта старшина булып торган. Бер үк авылда бер үк вакытта анын ике хатыны булган. Сукыр Нуртдин андый ук дәрәжәгә ирешә алмаган. Үз кул көче белән иген иккән, мал-туар асраган. Аннан сон " булыста", ягъни волость идарәсеме, канцеляриесеме урнашкан йортта каравылчы булып торган. Ансы шул кыр эшләреннән бушаган чакта гына булгандыр инде. Янтык-Яна Уртавыл волостенә якын-тирәдәге уналты авыл караган.

Сукыр Нуртдин белән Вайжалы кызынын алты баласы: дүрт кызы да ике малае булган. Кызларынын беренчесе Вазифа, икенчесе Салиха, өченчесе Галимә, дүртенчесе Нәгыймә. Уллары Салих белән Фатих. Салихны, ахрысы, бик яшьли армиягә алганнар—әллә аклар, әллә кызыллар. Ул шунда бик яшьләй һәлак булып калган. Инәкәйнен кече энесе Фатих буранда туныш үлгән. Калган дүрт кыз.

1918 елда тиф чиреннән Нуртдин картатай дә үлеп киткән, егерме беренче ачлык елында безнен инәкәйнен инәсе дә дөнья куйган. Ул вакытта Вазифаны уналты яшеннән тотып Шатын авылыннан хатыны-балалары булган бер картка икенче хатынлыкка биргәннәр. Күрәсен, ачлык бабай мәжбүр иткәндер инде. Бөтен авырлык буй житеп килгән япь-яшь кызлар өстенә төшкән. Дөнья көтүдә бернинди тәжрибәләре булмаган кызлар аптырап калганнар. Булган бар азыкларын ашап көн күрештергәннәр дә, юк кына бәягә мал-туарларын, каралты-кураларын сата башлаганнар. Дөресрәге, "акыллы кешеләр", туганнары аларга шулай кинәш иткәннәр, үзләре алучысын да тапканнар. Кызлардан ин кечесе Нәгыймәне күрше Уразы авылына бала караучы итеп алып киткәннәр. Нәгыймә ул вакытта үзе дә әле бала гына булган һәм анын үзен карау өчен бала караучы кирәк булган. Ләкин әлеге дә баягы Нужа карт усалрак, кансызрак булган. Беркем белән икеле-микеле сөйләшеп тормаган.

Менә шундый кыен, бик кыен вакытларда егерме ике яшьлек Салиханы Күчтәвыл Садырлиманга димләгәннәр дә, биргәннәр дә жибәргәннәр. Садырлиман ул көзне Ушия суына салынган Пулат тегерменәнә ашлык тарттырырга килгән булган. Шунда очрашканнар, танышканнар. Егерме ике яшьлек Салиха ни дәрәжәдә матур булгандыр, хәзер инде әйтеп булмый. Мин белгән Салиха шундыйрак иде: урталан калку төз гәүдә, аксыл чырай, кара каш, озын калку борын. Сөйләүләренә караганда, затлары алай төшеп

калганнардан булмаган. Коңгырт күзләре кысыграк, озынча йөз. Яңаклары калку түгел.

Салихага өйләнгән чагында Садырлиман хатынынннан тугыз яшькә зуррак булган. Садырлиманның беренче хатыны Җәннәт үпкә чиреннән үлгән. Җәннәтнең ике кызы торып калган. Егерме ике яшьлек Салиха менә шул үги кызлар һәм явыз каенана янына килен булып төшкән.

Кучтәвылның Хәсән малае Садырлиман әлләни тазалыкка туймаган. Гирман сугышында окопта бик каты салкын тидергән дә, шуннан мантый алмаган. Ничәнчедер елны аты белән кыш көне Урал ягына эшкә җибәргәннәр. Монысы инде Совет чорында. Шунда тагын салкын тидергән һәм бик каты чирләп, үлмә хәлендә өенә кайтып киткән. Аты кемнәргәдер ияреп кайткан, үзе поезд белән кайткан. Шул авырудан соң рәтләнә алмаган, бик каты шешенеп, "прукчирса" белән вафат булган.

Ике кызы һәм усал анасы булган шундый чирлекәш киявен яратты микән Салиха? Бик үк яратмагандыр дип уйлыйм мин. Хәер, ул елларда, алар заманында мәхәббәт дигән нәрсәне хәзергечә бизмәнгә салып, минеке бер грамм артык тарта, синеке бер грамм ким тарта дип сатулашып тора алмаганнар. Мәхәббәтне түгел, язмышны үлчәүгә салганнар ул чакларда. Шуның белән алар исән калган. Алар исән калу белән, очкын безгә күчкән. Барлык матур, дөрес фәлсәфәләрне читкә куеп торганда, яшәү өчен иң кирәге шул түгелмени?!

Яшь кеше буларак, яшь хатын-кыз буларак яратмаган ул Кучтәвылдагы тормышын. "Яратып бардыңмы?"—дип сорагач, туганнарына әйткән: "Күргәч тә аты ошады", дигән. Тегермәнгә килгән Садырлиманның үзе түгел, аңа аның аты матур булып тоелган. Болай дип әйткән чагында бәлки ул бик үк дөресен дә әйтмәгәндер. Хуҗасы бөтенләй ошамаса, ихтимал, аның аты да ошамас иде. Шулай да гомере буена ул яратып, сагынып әткәйнең шул сөйкемле атын сөйләде. Атларга карата аның күңелендә искиткеч бер җылылык хисе бар иде. Кучтәвылдагы тормышын искә төшергәндә генә түгел, Янтыкта үткән бала чаклары турында сөйләгәндә дә аның телендә гел атлар булды. Ул аларның төсен, буй-сынын, кыланышларын үзенчә матур итеп, яратып, сагышланып сөйли белә торган иде.

Әткәй белән ул тугыз ел торган. Әткәй аны бик яраткан һәм юаш булганга үзенчә иркәләп "тешсезем" дия торган булган. Әткәй чирләп урынга егылгач, инәкәй көн-төн аның янында булган. Утыз өч яшендә тол калган. Шуннан соң аны берничә җиргә димләп тә караганнар—риза булмаган. "Нуриханымны ятим итәсем килми"—дигән. Бәлки монысы аның сылтау гына булгандыр? Бит чын мәхәббәтне кешегә сөйләп йөрмиләр. Ни генә булмасын, үзенең Садырлиманына ул мәңге турылыклы булган.

Әткәйнең инәсен мин әнкәй дип атый идем. Безнең Әнкәй Кучтәвылга Уракайдан килен булып төшкән. Әткәйнең беренче хатыны Җәннәт тә шул Уракай кызы булган. Күрәсең, шуна күрәдер, үпкә чиреннән үлгән киленен Әнкәй якынрак күргән. Садырлиманның яшь Салиханы алып кайтуын ул, күрәсең, яратып җиткермәгән. Шуның өстәвенә ятим калган ике кызны да какмый-сукмый карарга, үстереп кеше итәргә кирәк булган. Үги ана ничегрәк булыр аларга карата? Шуларның барысын уйлап, безнең Әнкәй бөтен өйне үз кулында тотмакчы булган. Икенче киленен бик яратмаса да, мине, имеш, бик яраткан. Соңыннан, үләр алдыннан инәкәйгә җылый-җылый сөйләгән: шул явызлар (ягъни үги кызлар) аркасында кыерсыттым сине, киленкәем, дигән. Синнән әйбәт киленем булмады, бәхил бул инде, дигән. Бәхилмен, дигән инәкәй, дөньяныкы дөньялыкта калсын, дигән.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Лирон Хәмидуллин

# ТӘРҖЕМӘНЕ ОНЫТМЫЙК

Һәрдаим күнелгә тынгылык бирмичә, жанны борчып торган мәсьәләләр була. Татар әдәбиятының башка телләргә тәржемә ителешенә караган уйлар да нәкъ шулай, әледән-әле күнелдә борчу тудыра. Чөнки әдәби мирасыбыз бик зур. Еш кына без «мен еллык язма әдәбиятыбыз бар", дип мактанып та куйгалыйбыз. Әмма ләкин ул байлыкны башкаларга таныту юнәлешендә генә бик әкрен кыймылдыйбыз. Тугандаш яки замандаш булган башка халыкларга да ул язма мирасыбызны житкерәсе, ирешелгән уңышлар белән аларны да таныштырасы иде бит. Житешә алмыйбыз, көндәлек ыгы-зыгы белән өстебездә шундый бурычлар торуын онытабыз шул.

Безгә якын дәверда яшәп ижат иткән классик әдип вә шагыйрьләребезнен мирасын һәм исемнәрен дөнья мәйданына чыгару эшебез дә ярыйсы ук сүлпән бара. Бүгенге көнгә хәтле бөек Тукаебызның күп кенә шигырь һәм поэмалары тиешле дәрәҗәдә рус теленә дә тәржемә ителмәганнәр. Дөньяның кин таралышлы башка телләре турында инде әйтеп торасы да түгел. (Дөрес, соңгы елларда берничә китапның, шул исәптән Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасының инглиз телендә чыгуы турында матбугатта хәбәрләр булды. Аларны бастыруга әзерлек эшен Татар ПЕН үзеге үз өстенә алган икән. Уңышлы башлангыч була күрсен.)

Утыз биш еллар элек Дәрдемәнднең шигъри мирасын рус телле укучыга житкерү талпынышы да булып алган иде. 1970 елда нәшер ителгән «Стихи» китабын дөньяга чыгаручылар күренекле шагыйрьләребез Сибгат Хәким белән Ренат Харис булды. Татар жәмәгатьчелеге ул жыентыкны нигездә хуплады. Әмма ләкин, тәжрибәле тәржемәчеләрнең аз катнашуы сәбәпле, анда уңышсыз тәржемә ителгән, шагыйрь фикерен укучысына тулаем ирештерә алмаган тәржемәләр дә житәрлек урын били. Ул китапка кергән уңышлырак тәржемәләрне Р. Харис соңыннан «Агарган кыл» китабына *("Поседевшая струна", "Мәгариф" нәшрияты, 1999 ел)* туплап та бастырды. Ул китапны әзерләшүдә З. Бәширов белән минем дә бераз катнашым булды.)

Шәхси батырлыгы һәм ижаты белән исеме бөтен дөньяга танылган Муса Җәлилебез бу җәһәттән беркадәр бәхетлерәк. Аның шигырь һәм поэмалары рус теленнән тыш башка бик күп телләргә тәржемә ителде. М. Жәлил ижатына багышланган бер мәкаләдә хәбәр ителүенчә, аның әсәрләре бүгенге көндә илле дүрт телдә басылып чыккан. Тәржемәләренең кат-кат эшләнүе һәм илебезнең иң тәжрибәле тәржемәчеләренең җәлеп ителүе нәтиҗәсендә, аларның сыйфаты да канәгатьләнерлек. Мәсәлән, шагыйрьнең байтак әсәрләрен украин теленә тәржемә итүче шагыйрь һәм академик Павло Тычинаның төрки телләрне белүе дә ярдәм иткән. Украинада нәшер ителгән бер җыентыкта: «Павло Тичина знав тюркски мови», дигән сүзләр китерелә.

Элегрәк елларда сыйфатлырак дип саналган әдәби әсәрләрне татарчага тәрҗемә итеп чыгаруда шактый уңышка ирешкән идек. СССР күләмендә югары бәяләнгән, дәүләт бүләкләренә лаек булган әсәрләрне тәрҗемә итү рәсми төс алган, сәясәткә әверелгән чаклар да булды. 1940-1950 елларда югары бәяләнгән андый әсәрләрне тәрҗемә итү мәҗбүри санала иде. Ул мәҗбүрилекнең безнең өчен унай нәтиҗәләре дә булгалады. Нәкъ шул дәвердә өченче дәрәҗә Сталин премиясенә лаек дип табылган үз әсәрләребездән Гомәр Бәшировның «Намус»ы белән Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»е күпчелек союздаш республикалар халыклары телләрендә басылып чыкты. Болгар, венгр, кытай, немец, поляк һ. б. телләрдә сөйләшүче әдәбият сөючеләр дә нәкъ шул елларда Совет чоры татар әдәбияты үрнәкләре белән таныша алдылар. Әмма "Сталин дәвере» узганнан соң безнең әдәбият вәкилләренә андый мөмкинлекләр кабат тудырылмады инде.

Бу өлкәдә ирешелгәннәр белән канәгать булмау хисе, бәлки, миңа гына хастыр. Миңа гына шулай тоеладыр? Югыйсә байтак кеше бит тәрҗемә әдәбиятка әһәмият бирми диярлек. Бу халәт, бәлки, кайчандыр үземнең дә әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнгән кеше булуымнан киләдер. Андый эшне оештыруда беркадәр тәҗрибәм бар иде шикелле. Ун ел чамасы Язучылар берлеге каршындагы тәрҗемәчеләр секциясенең җитәкчесе булдым. Дөрес, ул секция, нигездә, башка телләрдән татарчага тәрҗемә итүчеләрне берләштерде. Аз санлы «рус телле» тәрҗемәчеләр русча иҗат итүче язучылар секциясенә беркетелгән иде. Узган гасырның 60-80нче елларында рус, белорус, казакъ, украин, үзбәк, әзәрбайҗан, грузин һәм кайбер чит ил телләрендә нәшер ителгән иң күренекле әсәрләрне үз телебездә бастырып чыгарырга тырыштык. Әлбәттә инде, ул еллардагы берләнбер нәшриятыбыз мөмкинлек биргән кысаларда. Матур әдәбият сөючеләр кулына ул заманнарда елына кимендә җиде-сигез тәрҗемә әдәби китап барып ирешер иде.

Үз илебездә һәм бөтендөнья күләмендә танылган авторлардан Михаил Шолохов, Мохтар Әүэзев, Константин Симонов, Чыңгыз Айтматов, Виктор Астафьев, Василь Быков, Юрий Бондарев, Әнүәр Әлимҗанов, Роман Солнцев, Валентин Распутин, Нодар Думбадзе, Әсгать Мохтар, Гафур Голәм һ. б. әсәрләре бу чорда татар укучысы тарафыннан хуплап кабул ителделәр. Классик әдипләрдән Лев Толстой, Алексей Толстой, Абай, Иван Тургенев, Федор Достоевский, Александр Куприн әсәрләренең яңа буын тәрҗемәчеләре тарафыннан эшләнгән үрнәкләре дә уңышлы булды. Әйе, бу дәвердә Чыңгыз Айтматовның барлык повесть һәм романнары да әнисенең туган теленә тәрҗемә ителде. Аның утызар мең данә тиражлы китаплары тиз арада таралып бетәр иде. Хәер, ул елларда үз авторларыбызның әсәрләре дә, тәрҗемә китаплар да укучы кулына тиз барып ирешә, кибет киштәләрендә озаклап ятмас иде. Чөнки ул елларда китап сәүдәсенә дә житди әһәмият бирелде. Хәтеремдә әле, казакъ язучысы Сайын Моратбәковның «Әрем исе» китабы бездә 1986 елда нәшер ителде. (Сүз уңаеннан әйтеп үтим, аның әнисе дә татар милләтеннән. Бер очрашу вакытында ул: «Анам Сәхипҗамал да, киленем Надия дә сезнең кавемнән",—дип әйткән иде.) Бер елдан соң автор безнең якларга килеп чыга, ләкин тугыз мең данәдә басылган үз китабын таба алмыйча китеп бара.

Ул елларда бездә рус, әзәрбайҗан, казакъ, төрекмән һ. б. халыклар әдипләренең күмәк хикәя яки повесть, шигырь җыентыклары да даими рәвештә туплап басыла килде. Мәсәлән, каракалпак халкы әдәбияты антологиясе «Арал дулкыннары», Идел буе республикалары язучыларының күмәк җыентыклары, казакъ авторлары повестьлары тупламалары «Ак дөя», «Җәйләүдә», «Дала гөлләре», союздаш һәм автономияле республикалар әдипләренең сайланма хикәяләр җыентыгы «Дуслык аланы» һ. б. бездә зур тиражлар белән нәшер ителделәр. Кардәш әдәбият вәкилләре дә бурычлы булып калмады. Казакъстанда «Дуслык көтепханәсе» сериясендә күләмле «Татар повестери» китабы, Үзбәкстанда «Йиллар ва йуллар», Каракалпакстанда «Татар гүрринглери» исемендә хикәя җыентыклары, Украинада «Свети меня, Чулпан-заря» дип исемләнгән шигырь тупламасы һ. б.лар дөнья күрделәр. Әзәрбайҗан белән Кыргызстанда да шундый ук күләмле җыентыклар басылып чыкты. Әлбәттә, ул республикаларда андый күмәк җыентыклардан тыш та татар әдипләре әсәрләре тәрҗемә ителә иде. Шул җәһәттән аеруча казакъ кардәшләрне аерым билгеләп үтү

урынлы булыр. Сугыштан соңгы чорда Казакъстанда һәр елны диярлек икешәр-өчәр татар китабы дөнья күрде. Г. Тукай, М. Җәлил җыентыклары да даими рәвештә басыла торды. Үзбәк уртаклар да алардан калышмаска тырышты. Үзбәкстанда татар әдәбияты таралышына зур әһәмият бирүчеләрдән милләттәшләребез Габдулла Уразаев белән Әсгать Мохтарны аерым искә алу кирәктер.

Ул заманда СССР һәм чит дөнья халыклары әдәбияты үрнәкләрен татар телендә чыгаруда актив эшләүче язучылардан дистәләгән роман вә повестьлар тәрҗемә иткән Рәис Даутов, Яхъя Халитов, Кыям Минлебаев, Таһир Нурмөхәммәтев, Әнәс Хәсәнев, Шаһидә Максудова, Фәния Гайнанова, Наилә Вәлитова, Люция Нәҗмиеваны билгеләп үтәсе килә. Ул чорда шагыйрьләребезнең дә байтагы үз күңеленә хуш килгән үрнәк әсәрләрне ана телебезгә күчереп бастыруны мәртәбәгә санады. Тәрҗемәләре даими рәвештә татар вакытлы матбугатында дөнья күргән шагыйрьләрдән Нури Арслан, Зәки Нури, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Әхмәт Рәшит, Шамил Маннап, Әхмәт Гадел, Госман Садә исемнәре һәрберебезгә мәгълүм. Ул чорда Абай (күмәк тәрҗемә), Гомәр Хәйям (Н. Арслан), Давыт Кугелтинев (Г. Рәхим), Американың XIX йөз әдәбияты классигы Уолт Уитмен (М. Шабай) һ. б.ның шигырь җыентыклары, Евгений Евтушенконың «Казан университеты» поэмасы (М. Шабай) татар телендә басылып чыкты. Кардәш төрки телләрдән тәрҗемә итүче осталар рәтендә Сәрвәр Әдһәмова, Нури Арслан, Әхмәт Исхак, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен һәм Тәүфикъ Әйди дә ул дәвердә бик актив эшләделәр. Мин дә бу тармакта көч сынап карадым. Казакъ, каракалпак, үзбәк телләреннән чәчмә әсәрләр тәрҗемә иттем. Тәкъдим булган очракларда рус телле авторлар әсәрләренә дә житешкәләдем. Шул рәвешле Юрий Бондарев (тумышы белән Орск шәһәреннән), Павел Бажов һ. б. хикәяләрен, Василь Быковның СССР Дәүләт бүләгенә лаек дип табылган ике повестен берләштергән «Һәйкал» китабы минем хикәяләүдә үз телебездә дөнья күрделәр.

Житмешенче-туксанынчы еллар аралыгында Язучылар берлеге идарәсе тырышлыгы белән классик әдипләребезнең һәм әйдәп баручы шул чор авторларының байтак китабы рус теленә тәрҗемә ителде, басылып чыкты. Ул китапларның күпчелеге Мәскәүнең «Детгиз», «Советский писатель», «Современник» нәшриятларында, бик сирәкләре «Художественная литература», «Молодая гвардия» кебек үзенчәлеклерәк басма йортлары имзалары белән дөнья күрделәр. Ләкин шунысы аянычлы, ул вакытлардагы тәрҗемәләрнең байтагының сыйфаты зыялы укучыны канәгатьләндерерлек түгел. Ул тәрҗемә авторларының күпчелеге татар мохитен начар белә, кемнәр тарафыннандыр эшләнгән сүзгә-сүз тәрҗемәләр («подстрочниклар») ярдәмендә генә эш итә. Ә арзан хак түләүле ул подстрочникларны исә үз кешеләребез ашык-пошык әзерләп бирә иде. Квалификацияле подстрочник эшләүче бер-ике кеше (мәс., Ил Саттаров) үзләренә охшаган авторлар белән генә эш йөртәләр, барысына да өлгерә алмыйлар. Ә ниндидер бер студентның ашык-пошык әвәләгән подстрочнигына нигезләнеп тәрҗемә ителгән китапның сыйфаты нинди буласын күз алдына китерү кыен түгел, әлбәттә.

Дөрес, соңга табарак татарчадан русчага тәрҗемә итүче үз кешеләребез дә пәйда булды. Алар, ике телне дә камил белеп, әсәрнең эчтәлегенә зыян китермичә эшли башладылар. Ләкин, санаулы санда булулары сәбәпле, алар исән, дәрәҗәлерәк язучылар белән генә хезмәттәшлек итүне хуп күрделәр. Мәсәлән, Гомәр Бәшировның Мәскәүдә нәшер ителгән күпчелек әсәрләре Разия апа Фәизова хикәяләве аша рус телле укучыга барып ирешә. Әмирхан Еники, Фатих Хөсни дә тәрҗемәче сайлауга бик таләпчәннәр иде. Архивымда Фатих аганың тәрҗемәчесенә таләпләр куеп язган бер хат нөсхәсе саклана. Нурихан Фәттахның «Этил суы ака торур» романын булачак Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Марсель Зарипов тәрҗемә итте. Марсельнең шуннан соң кемнең дә булса әсәрен тәрҗемә итүен хәтерләмим. Элегрәк, Әлмәттә бергә яшәгән дәвердә, бу өлкәдә Гариф Ахунов белән хезмәттәшлек иткәнлеге генә мәгълүм.

Классик әдипләрдән Фатих Әмирхан хикәяләрен Мәскәүдә яшәүче әдәбият галиме Галия Хантимерова, Шәриф Камалның «Таң атканда» романын Азалия Балюгина, Шәйхи Маннурның «Агым суларга карап» романын язучы Светлана Гыйльметдинова,

яшьрәк буын авторларының берничәсенең әсәрләрен язучы Җәмил Мостафин бик уңышлы тәрҗемә итеп чыгардылар. Тиздән болар төркеменә Мәскәүдәге Әдәбият институтында тәрҗемәче һөнәрен үзләштерүгә биш ел гомерләрен сарыф иткән ун яшь тәрҗемәче килеп кушылырга тиеш иде. Ул вакыттагы Язучылар берлеге идарәсе рәисе Зәки Нури тырышлыгы белән Горький исемен йөртүче Әдәбият институтында 1972 елда татарчадан русчага тәрҗемә итүчеләр курсы оештырылды. Өметләр тулаем акланмаса да, Солтан Шәмси, Роза Баубекова-Кожевникова, Фирдәүс Әһлия кебек каләм әһелләре тәрбияләнеп чыкты ул төркемнән. Укуын тәмамлагач ук С. Шәмси классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестен һәм хикәяләрен тәрҗемә итеп бастырды. Мирсәй Әмир белән Ләбибә Ихсанованың аерым хикәяләрен вакытлы матбугатка эшләп бирде. Роза Кожевникова да татар поэзия үрнәкләрен тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә зур абруй казанды. Фирдәүснең тәрҗемә өлкәсендәге уңышлары алай зурдан булмаса да, ул үзенчәлекле прозаик буларак иҗат итә. Вакытлы матбугатта аның театр әһелләренә багышланган кызыклы язмалары, очерклары бик еш күренә.

***

Туксанынчы елларда төрле-төрле нәшриятлар барлыкка килүенә карамастан, татар китабының язмышы, аңа булган мөнәсәбәт кискен үзгәрде. Ә тәрҗемә әдәбият чыгудан туктады дип әйтерлек. Чөнки китап сәүдәсенә бөтенләй дә әһәмият бирелми башлады. Татар әдәбиятын үз итүчеләр, яратып укучылар башлыча авылда яши. Авыл халкына хезмәт итүче төп сәүдә оешмасы элгәре елларда Татпотребсоюз җәмгыяте иде. Базар мөнәсәбәтләрен үзләштерәбез дигән сылтау белән иң әүвәл ул оешманың китап сәүдәсе бүлекчәсе бетерелде. Авылда түгел, хәтта ки район үзәкләрендә дә китап кибетләрен яптылар. Янәсе, китап сәүдәсе аз керемле. Ә аракы сәүдәсенең кереме хәтсез-чиксез, әнә. Шул хәтсез күп керемгә алданып хәзер авылның «үзен» дә бетереп барабыз шикелле. Дөрес, авыл үзе бар-барын. Тик анда элекке авыл җәмгыяте, авылча яшәү тәртибе генә тәмам таркалу хәлендә. Рухи халәт бик зәгыйфь, һәм әлегә ул көннән-көн зәгыйфьләнә генә бара. Шундый хәлгә төшүебез зур табыш китерүче аракы, сыра кибетләренең һәм ресторан-барларның күпләп ачылуына да бәйле, билгеле.

***

Хәзерге нәшриятларда тәрҗемә әдәбиятка әһәмият бирелми, дидек. Нәтиҗәдә төрле телләрдә иҗат итүче әдипләрнең бер-берсе белән аралашуына да чик куелды. Бу хәл бигрәк тә үз мәмләкәтләрен булдырган элекке кардәш әдәбият вәкилләре белән араны өзүгә китерде. Болай дәвам итсә, тиздән без бөтенләй дә изоляциядә калачакбыз. (Әдәбиятка, телгә булган мөнәсәбәтләр үзгәрмәсә, мөгаен безне резервациядә үк калу көтәдер.)

Шушы ук дәвердә татар әдәбиятын башка халыклар укучысына җиткерү, башка телләргә тәрҗемә итү эше дә нык аксый башлады. Бу эшнең бөтенләй туктап торган еллары да күз алдында. Соңгы вакытта гына бераз кыймылдарга керештек шикелле. Рус теленә тәрҗемәләр әз-мәз күренгәли башлады. Кардәш милләтләрдән казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән h. б. бүген татар язучысының китабын кулга тотып караудан бөтенләй мәхрүм ителгән. Татарстанда яшәүче рус телле «кардәшләребезнең» хәле бераз җиңелрәк Хәзер алар өчен Казанда елына ике-өч китап тәрҗемә ителә. «Идель», «Казань» кебек рус телле журналларда да аерым тәрҗемәләр күренгәли. Бу җәһәттән «Идель» журналының активрак булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ә Мәскәү нәшриятлары һәм журналлары әлегә безне танымый, тиң күрми. Чынбарлыкта без Россия Федерациясенә керүче төп халыкларның берсе саналабыз югыйсә. Сан ягыннан икенче урында торабыз бит.

Яңа гасырга кергәч чәчмә әдәбиятны русча тәрҗемәдә бастырып чыгаруны әлегә ике дәүләт нәшрияты—«Мәгариф» белән Татарстан китап нәшрияты җайга салырга омтылалар сыман. Матур әдәбиятны рус теленә тәрҗемә итүчеләр сафына сәләтле яңа көчләрнең килә башлавы да сөендерә. Мәсәлән, «Идель» журналы битләрендә Фаяз Фәизев, Гадел Хәеров, Гәүһәр Мәһдиева-Хәсәневаларның тәрҗемәләре ешрак күренә

башлады. Гәүһәрнең «Идель»дән тыш Мәскәүдә чыгучы «Современник» журналында күренгәләп китүе дә сөендерде. Соңгы вакытларда ул А. Гыйләҗев, М. Галиев, Р. Зәйдулла һ. б. хикәяләрен, Ф. Яруллинның «Йөртә безне язмышлар» повестен рус телле укучы хөкеменә тапшырды. Улым Булат Хәмидуллинның тәрҗемәләре дә ешрак күренә башлады. 2001 елда ул Г. Ахуновның соңгы елларда иҗат иткән өч повестен берләштергән «Тимерханның күргән-кичергәннәре» китабын, 2005 елда В. Имамовның «Казан каласы» романын нәшер итте. «Дәрдемәнд» фото-альбомын чыгаруда да тәрҗемәче буларак катнашты. Ара-тирә аның хезмәтләре вакытлы матбугат битләрендә дә күренгәләп китә. Соңгы вакытта Язучылар берлеге каршында теркәлгән Тәрҗемәчеләр секциясе эшендә актив катнашкан Наилә Краеваның да уңышлары күзгә ташланырлык. «Мәгариф» нәшрияты белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә рус телле әдәбият сөючеләр хөкеменә аның тәрҗемәсендә Фатих Хөсни, Гариф Галиев хикәяләренең кечерәк тупламалары тәкъдим ителде. Аның Айдар Хәлим белән җитди хезмәттәшлек итә башлавы турында да мәгълүмат бар. Ишетеп белүемчә, Айдарның бер китабы инде аның тәрҗемәсендә басылган да. Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Венера ханым Вәлиеваны әле санап үтелгән яшьләр рәтенә кертеп булмый, билгеле. Әмма аның Тукай шигырьләрен дистә еллар дәвамында эзлекле рәвештә тәрҗемә итүен хупларга кирәктер.

***

Шигырь тәрҗемәсенә килгәндә, бик авыр, бик катлаулы эш ул. Шигъри сүзҗөмләне башка телгә зур төгәллек белән күчерү осталары бик сирәк очрый. Бигрәк тә ике телне камил белүчеләр бик аз. Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Һади Такташ кебек олуг шагыйрьләребезнең иҗади мирасын рус дөньясына танытырга җөрьәт иткән элекке шундый тәрҗемәче шагыйрьләрдән фәкать Вил Ганиев, Шамил Анак-Мәхмүдев, Равил Бохараев кына хәтергә төшә. Аллага шөкер дип әйтик, бүген аларга алмашка ике телне дә яхшы белүче Роза Баубекова-Кожевникова, Рөстәм Сабиров, Лилия Газизовалар килде. Татар телле мохиттә яшәгән, шигъри әсәрләрне бик теләп, яратып тәрҗемә иткән рус шагыйре Сергей Малышевны да шушы төркемгә кертеп буладыр, мөгаен. Ул хәзерге татар шигъриятен иң күп һәм оста тәрҗемә итүчеләрнең берсе иде. Мәрхүм Марк Зарецкий да татар әдәбиятын, татар шигъриятен үз итеп, рухи якын күреп эшләүчеләрдән булды. Олуг шагыйрьләребездән Дәрдемәнд, Габдулла Тукай шигырьләре дә аның тәрҗемәсендә бик килешле итеп эшләнеп, рус телле укучыга тәкъдим ителде. Чөнки соңгы ике автор (Сергей белән Маркны истә тотуым), тумыштан рус телле булсалар да, Мәскәү тәрҗемәчеләре кебек кемдер язып биргән подстрочникка таянып кына эш итмиләр, шигырьнең татарча яңгырашын тоярга, сүз-җөмлә аралыгына салынган мәгънәви эчтәлекне тирәнрәк аңларга тырышып тәрҗемә итәргә омтылалар иде. Моның шулай икәнлеген М. Зарецкий белән китап нәшриятында бергә эшләү елларыннан яхшы беләм. Берәр әсәрне тәрҗемә итәргә керешсә, ул аның эчтәлеген, яңгырашын төгәл чагылдыру ниятеннән чыгып, бүлмәдәше Кыям Миңлебаев, күрше бүлмәдәге Рәис Даутов, шагыйрь Харрас Әюп һ .б. белән аралашып, киңәшеп чыгар. Тәрҗемә иткән вариантларын каләмдәшләренә кат-кат укып күрсәтер иде. Әлмәт каласында, татар мохитында күпмедер вакыт яшәп алган Мария Аввакумова да (Мәскәү) кайбер чордаш шагыйрьләребезнең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итеп, аларның ил күләмендә танылуына үз өлешен кертте.

Ике телне белмичә, фәкать сүзгә-сүз тәрҗемәләр (подстрочниклар) белән эш итүче шагыйрьләр еш кына шигырь эчтәлеген ярлыландыралар. Алар формаль рәвештә шигырь юллары, сүз иҗекләре санын сакларга тырышкан була. Ягъни, тышкы, формаль тәңгәллеккә омтыла. Андый тәрҗемәләрдә еш кына шагыйрьнең укучысына әйтәсе, җиткерәсе фикере нык гадиләштерелә. Тәрҗемә белән шөгыльләнүчегә ике тел мохитын да күпмедер дәрәҗәдә белү кирәклегенә мисал итеп, әдәбият галимнәре еш кына Самуил Маршакның бер тәрҗемә үрнәген китерәләр. У. Шекспирның сонетларын тәрҗемә иткәндә ул, инглиз телен дә белүе сәбәпле, сонетларга хас ундүрт юллыклар белән генә чикләнмичә, юллар санын арттырып тәрҗемә итә. Шул рәвешле рус телендә сонетларның мәгънәви эчтәлеген тулырак бирүгә ирешә. «Аның

тарафыннан иң унышлы тәрҗемә ителгән сонет егерме дүрт юллы булып чыккан. Ләкин моның өчен берәү дә аны гаепли алмый—шул рәвешле ул шигырьнең тулы эчтәлеген укучысына җиткерә алган», дип язалар әдәбият галимнәре. Ә үзебезнең милли телләрдән тәрҗемә итүче шагыйрьләрнең күпчелеге исә еш кына формаль тәнгәллеккә ирешү белән чикләнделәр һәм «Һади Такташ, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләрнең катлаулы эчтәлекле шигырьләрен рус телле укучы кабул итәрдәй дәрәҗәдә эшләү бик авыр»,—дип зарланалар.

***

Тәрҗемә эшен оештыруга карата булган фикерләремне дә әйтеп үтим. Алда санап кителгән унышлар һәм ул унышка ирешкән тәрҗемәчеләр, нигездә, авторлар белән килешеп, алар белән еш аралашып эшләүчеләр булды. Соңгы ун-унбиш елда исә тәрҗемәгә карата мөнәсәбәт шактый сүрелде. Әйе, туксанынчы еллардан башлап андый эшне оештыруга җиң сызганып тотынучы батырлар, никтер, күренмәде. Шушы дәвердә сайланган Язучылар берлеге идарәләре дә мәшәкатьле һәм күпмедер күләмдә акча тоту таләп ителгән ул вазифаны үтәүдән читләшергә тырыштылар шикелле. Күпмедер чыгым кирәклеге турында әйткәндә мин классик әдипләребез иҗатын пропагандалауны күздә тотып әйтәм. Алар инде үзләре рус, инглиз яки төрек телендә сүзгә-сүз тәрҗемә вариантларын эшләп бирә алмыйлар. Элек андый эшне оештыру бурычы Язучылар берлеге идарәсенә йөкләнгән иде. Шул йөкләмәне башкарып чыгу өчен дип Татарстан хөкүмәте ел саен билгеле бер күләмдә акча да бүлеп бирә иде. Хәзер әсәрен башка телдә чыгару һәр авторның үз эше дигән караш өстенлек итә. Ә бит татар йөзен ачардай матур үрнәкләр биргән, әмма классик әдипкә тиешле дәрәҗәгә формаль рәвештә ирешә алмаган, бүгенгечә иттереп әйтсәк, дәүләт бүләге иясе булмаган, халык язучысы яисә халык шагыйре исемен даулап йөри алмаган Шәйхи Маннур, Салих Баттал, Нәби Дәүли, Хәсән Сарьян кебекләрнең иҗатын пропагандалау белән кем шөгыльләнергә тиеш? Әлбәттә, Язучылар берлеге идарәсе. Дөрес, андый җаваплылыкны Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре карамагына калдыру ягында торучылар да бар. Кем хаклыдыр, киләчәк үзе күрсәтер. Совет хакимияте дәверендә андый эшләр белән башлыча Язучылар берлеге идарәсе шөгыльләнә иде. Ә фәнни институт әдәби мирасыбызны барлап-туплап, тәртипкә китереп, үз телебездә нәшер итү бурычын үтәде. Ике оешмага да акчаны, мыскаллап кына булса да, Татарстан хөкүмәте бүлеп бирә иде. Хәзер исә бу изге эшләрне башкаруга милли җанлы иганәчеләрне дә җәлеп итү мөмкинлеге туды шикелле. Әнә бит Татнефть акционерлык җәмгыяте карамагында оештырылган «Рухият» фонды соңгы унеллыкта гына никадәр зур эшләр башкарып ташлады. Онытылып барган татар әдипләренең, татар галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләренең китапларын нәшер итеп, халыкка, китапханәләргә таратты. Андый мактаулы эшләрне оештыруда күренекле академигыбыз Миркасыйм Госмановның өлеше дә зур. «Рухият» һәм «Җыен» фондлары нәшер итеп чыгарган милли әдәби-иҗтимагый мирасыбызның байтагы аның кайгыртуы һәм оештыруы нәтиҗәсендә дөнья күрде.

Бүгенге көндә, бәлки, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен рус, инглиз, француз, гарәп һ. б. телләргә тәрҗемә итү эше белән шөгыльләнердәй махсус бер төркем булдыру кирәктер. Тәрҗемәчеләрне табу, яллау, кирәк чакта сүзгә-сүз тәрҗемәләр булдыру, нәшриятлар һәм сәүдә оешмалары белән килешү төзү—хәзерге заманда булдыклы бер башкаручы төркем оештыруны сорый, минемчә. Ул төркем Язучылар берлеге кул астында яисә әлеге фәнни институт карамагында булырга мөмкин. Ләкин аның алдына махсус бурыч куелган, эш планы бирелгән булырга тиеш. Чит телләргә әдәби мирасны тәрҗемә итүдә беркадәр тәҗрибәсе булган ПЕН үзәк тә читтә калмаска тиештер, шөт. Әмма турыдан-туры Татарстан хөкүмәте белән гамәли-финанс бәйләнеше булмаган бу җәмгыять төп вазифаны үтәүче була алмыйдыр, мөгаен.

***

Төрек кардәшләр белән бәйләнешкә мөнәсәбәтле берничә сүз әйтисе килә. Соңгы вакытта Төркия Җөмһүрияте белән арадашлык мөнәсәбәтләре күзгә карап үсә, кинәя кебек. Аларның эшмәкәрләре, галимнәре безгә килгәләп йөри. Безнең галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре дә аларда еш булалар. Ара-тирә әдәбият әһелләренә дә андый бәхет эләгеп куйгалый. Әмма арадашлыгыбыз әлегә, аеруча әдәбият өлкәсендә, еш кына коры сүзгә генә кайтып кала шикелле. Бу җәһәттән сәнгать әһелләребез бәхетлерәк—төрле фестивальләрдә катнашып, үз иҗатларын кардәш милләткә дә җиткерә алалар. Ә менә татар китапларының Төркиядә (төрекләрнекенең Татарстанда) басылып чыгуы хакында мәгълүмат бик аз. Җитәрлек күләмдә эшләнмәгән эшне эшләнде дип әйтеп тору да читендер шул. Ара-тирә анда, яшерен-батырын кемнәрдер үз әсәрләрен бастыргалаган икән, үзбәк кардәшләр әйтмешли, бик хуп. Әмма безнең Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Габделҗәббар Кандалыйларыбыз, Дәрдемәндләребез иҗатын шул рәвешле генә чит-ят җирләрдә чыгарып булмастыр. Монда төпле, нигезле оештыру кирәклеге көн кебек ачык. Узган гасыр башларында ук Төркиянең әдәбият галиме Фуад Көпрелү тарафыннан иҗаты югары бәяләнгән Г. Тукайның әдәби мирасы анда соңгы тапкыр кайчан нәшер ителде икән? Төрек кардәшләр илендә укыган заманда каләм тибрәтергә керешкән Дәрдемәнд, Фатих Кәрими кебек шәхесләребезнең иҗаты белән анда кем дә булса танышмы икән?

***

Юл уңаеннан гына булса да әйтеп китәсе килә—күренекле һәм классик әдипләребезнең чит төбәкләрдә, бигрәк тә милли республикаларда һәм чит илләрдә басылган китаплары еш кына Казанга килеп җитми. Мондый хәл хәтта оештыру эшләре шактый ук җайга салынган Совет хакимияте дәверендә дә очраштыра иде. Урта Азия республикаларында йөргәндә андый басмаларны барлап, табылганнарын биштәремә төяп кайткалаган чакларым еш булды. Олуг язучыларның юбилейларын үткәргәндә, күргәзмәгә куярга дип, аларны миннән алып та торгаладылар. Үзем дә шундый берничә китапны Милли музейга да, Казан милли-мәдәни үзәгенә дә бүләк итеп тапшыргаладым. Кайбер китаплар әле дә үземдә саклана. (Бу җәһәттән мәрхүм Тәүфикъ Әйди күпкә өлгеррәк булды, тугандаш төрки телләрдә басылган китаплар санынча аның китапханәсе күпкә бай иде.)

Ә үзебез бүген төрек әдәбиятын беләбезме? Аны үзебездә пропагандаларга әзерме без? Юктыр, мөгаен. Мәрхүм Тәүфикъ Әйдинең төрек-татар әдәбиятлары арадашлыгына багышланган җитди бер хезмәте «Казан утлары» журналында басылып чыккан иде. Аны һәм шуңа тартым хезмәтләрне китап киштәләренә куярлык, китапханәләргә таратырлык итеп, аерым бастырып чыгару да кирәктер, мөгаен.

Төрек кардәшләребез соңгы вакытта барлык кыйтгалардагы төрки кавемне бик сөендерде: төрек әдибе Орхан Памук Халыкара Нобель бүләге лауреатлары исемлегенә кертелде. Ә без ул әдипне беләбезме соң? Әсәрләре бездә басыламы? Юк бит. Безгә аларны турыдан-туры авторның ана теленнән күчереп нәшер итү зарур. Былтырларда рус йортташларыбыз русча бастырып чыгарган нөсхәләрдән түгел. Төрек телен яхшы үзләштергән осталарыбыз бар ич бүген. Мәсәлән, Асия Рәхимова инде шундый берничә китапны тәрҗемә итеп бастырып чыгарды. Дөрес, саф төрек әдәбияты үрнәкләрен түгел, үзебезнең анда барып сыенган милләттәшләребезнекен. Шул ук эшне оста башкарып чыгарга сәләтле язучыларыбыздан Азат Ахунов, Рөстәм Сүлти, Чулпан Зарипова кебек, төрекчә белүчеләребез дә байтак хәзер. Ул эшне фәкать оештырып җибәрү генә сорала.

***

Галимнәребез бәян итүенчә, узган гасыр башында җирле рус зыялылары арасында татар әдәбияты белән кызыксыну арта. Казанда керәшен мәктәбендә татар теле дәресләрен укыткан Николай Ашмарин 1901 елда «Очерки литературной

деятельности татар-мухамедан в 1880-1895 г. г» дигән китабын бастырып чыгара. Ул китап сонрак, 1913 елда Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә (Оренбург) үз телебездә дә кабат басыла. 1906, 1908 елларда «Волжско-Камская речь» газетасында Сәгыйть Рәмиев иҗатына багышлап ике мәкалә урнаштырыла, шигырьләре басылып чыга. Мәсәлән, С. Рәмиев иҗатын тирәнтен өйрәнгән галим Ш. Садретдинов аның турында беренче мәкаләне татар авылында үскән поляк Альберт Пинкевич, икенчесен Г. Коләхмәтов яза, дип белдерә. Шул ук Пинкевич шагыйрьнең «Таң вакыты», «Мин», «Син», «Ул» шигырьләрен тәрҗемә итеп тә рус дөньясына чыгарган икән («Татар әдәбияты тарихы, 3 том, 172-183 битләр). Ул газетаның кайбер саннарында яңа басылып чыккан китаплар исемлеге дә китерелгән икән. Ш. Садретдинов 1908 елгы шундый бер исемлектә С. Рәмиевнең «Низамлы мәрәсә» китабы чыкканлыгы турында мәгълүмат теркәнгәнлеген дә күрсәтә. Ул исемлекләрдә тагын кемнәрнең исемнәре аталган, кемнәрнең чыккан китаплары турында хәбәр ителгән икән соң?

Шул чорның рус газеталарында Габдулла Тукай иҗатына да мөрәҗәгать ителә, дигән сүзләр дә булгалады. Ләкин үзе исән вакытта басылып чыккан тәрҗемәләре һәм иҗатына бәя биргән язмалар турында әлегә язма мәгълүмат юк шикелле, һәрхәлдә, миңа андыйлар очрамады. Ә шагыйрьнең вафатыннан соң шул ук тел белгече Николай Ашмаринның үзе укып чыккан институт бастырган бер җыентыкка «Шүрәле» поэмасын 1914 елда тәкъдим иткәнлеге турында хәбәрләр бар. Ашмарин укыган «Лазарев исемендәге шәркый телләр институты»н 1827 елда Мәскәүдә Еким Лазарян дигән бер әрмән морзасы ачкан була. XX гасыр башына чаклы эшләгән ул институтны байтак кына мәгълүм шәркыять галимнәре тәмамлыйлар. Шул институтны тәмамлаган татарлар да бар. Әйтик, И. Рәми белән Р. Даутов төзеп чыгарган «Әдәби сүзлек»тә анда Габдулла Гыйсмәтинең укыганлыгы әйтелә. Г. Гыйсмәти 1913 елда С.-Петербургта оештырылган «Г. Тукай стипендиясе» фонды исәбенә анда белем ала. Шул институт нәшер иткән җыентык һәм журналларда татарларга багышлы хезмәтләргә дә урын бирелгән булса кирәк. Ләкин ул хезмәтләр әлегә безнең әдәбият галимнәре тарафыннан тәфсилләп тикшерелмәгән бугай.

Шул ук 1914 елда Г. Тукайның «Пар ат» шигыре, инглиз теленә тәрҗемә ителеп, Лондонда чыгучы «Рашен ревью» («Россия хәбәрләре») журналында дөнья күрә. Рус телендә берничә шигыре тупланган тәүге китабы 1920 елда Ташкент шәһәрендә басыла. Ул «Избранные стихи» («Сайланма шигырьләр») җыентыгына кергән шигырьләрне Сергей Есенинның якын дусты шагыйрь Валентин Вольпин тәрҗемә иткән. Тирән эчтәлекле, күләмле кереш мәкаләне ул вакыттагы Төркестан автономияле республикасының мәгариф комиссарияты хезмәткәре Ибнеәмин Янбаев язган. Ә 1921 елның октябрь аенда исә Казанда, рәссам һәм шагыйрь Павел Радимов тәрҗемәсендә, бөек шагыйребезнең икенче русча китабы «Разбитая надежда» («Өзелгән өмет») басылып чыга.

Шул традицияләрнең, күпкә арттырылып һәм үстерелеп, хәзер дәвам иттерелүен генә телисе кала.

# МӘХӘББӘТ ИЛЕ

Мин бу китапны баш очымдагы бүтәннәре янына куйган идем... Биредәге хәзинәләр—минем дус-каләмдәшләремнең, талантлы шагыйрь-әдипләрнең култамгалары язылган ядкярләр, үзләренчә мина хәерхак теләүче шигъри мәктүбләр. Вакыт-вакыт мин шуларны кулыма алам һәм... бу минем яшьтәшләрем өчен дә бик табигый тойгыдыр—без дә бит шулай идек, мәхәббәт илләрен гизгән идек, дип уйланасың. Күнелле дә, монсу да булып китә... Әмма мәхәббәт тойгысы кешене гомере буена ташламый, ул төрле яшьтәгеләрнең дә башларын идерә, диләр. Әлеге "баш очымдагы" "сердәш" китаплардагы әсәрләргә карата туган фикерләрем күнелдә озак йөреп, яисә кабатлана торгач, үзләренең беренче тәэсирләрен югалталар, дөресрәге, артык гадиләшәләр кебек. Шуның өстенә алардагы күп кенә тәсмерләр, хис-тойгылар синең өчен инде күптән билгеле "танышлар"га әйләнеп, күрәсең, артык "үз булып" китәләр. Әмма вакыт сынавын кичергәннәре үзләренчә иләнә-иләнә, алтын бөртекләре сыман, күнел төбендә утырып калалар. Алдымдагы ошбу китап турында билгеле бер фикергә килү дә, шунлыктандыр, шактый катлаулы булды. Шуның белән бергә, шагыйрьнең күнел чырагын кабызган Мәхәббәт чаткылары синең күнелдә дә очкын кабызырга тиеш бит!



Инде, ниһаять, мәсьәләнең асылына якын килергә, китапның түренә үтәргә вакыттыр.

"Мәхәббәтнамә"дә тупланган шигырьләр беренче карашка гади, әмма кешенең ин катлаулы кичерешләренә кагылган, үтә нәзберек хис-тойгылар—нюанслардан торган Мәхәббәт дөньясына, гашыйклар иленә багышлана.

Халык шагыйре Равил Фәйзуллинның әлеге шактый саллы тупламасын Мәхәббәткә мәдхия, йәки мәхәббәт тойгыларының шәхси антологиясе диярго була. (Алдан ук искәртим, бу минем шәхси карашым, шунлыктан, үз "күзлегемне" башкаларга такмыйм). Өстәвенә (бәлки, бәхеткәдер!) без тәлгәдәбият тәнкыйтьчеләре түгел. Үзебезчә кичерәбез, үзебезчә язабыз. Язуы кыен, ә бәя бирү жинелрәктер...

Китапның беренче битен ачып, "түренә" үткән саен калейдоскоп сыман, хис-кичерешләр, коллизияләр үзгәрә тора, инде ярты юлда тукталасы да килми, бит саен үзенне гаҗәеп метаморфозалар илендә итеп тоясын...

Бөек Мәхәббәт дидек. Хәзер, кызганычка каршы, әлеге төшенчә артык шәраләнде. Ә инде гашыйк жаннарны йолдызларга күтәргән, хыяллар артына канатландырган платоник мәхәббәт, гамәлдә булу түгел, инде термин буларак та юкка чыга бугай. "Мәхәббәтнамә"дә шагыйрь мәхәббәт идеалы итеп үзе үк санап

Равил Фәйзуллин. Мәхәббәтнамә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

киткән Ләйлә—Мәҗнүн, Таһир—Зөһрә, Ромео—Джульетта, Хәлил—Галиябану һ. б. гыйшык-гашрәт каһарманнары киләчәктә кабатланырлармы? Китабына кереш сүзендә автор болар хакында шактый кин туктала. Дөнья әдәбияты тарихыннан жыя китсәң, шагыйрьләрнең һәм алар язган мәхәббәт каһарманнарының исемнәре генә дә томнар тәшкил итәр иде мөгаен. Көнчыгыш һәм көнбатыш әдәбияты классикларыннан күпме мисаллар китерергә булыр иде! Үземнең дә студент елларда, әлеге югары хисләр белән канатланып, Милли китапханәнең "Мәгарә" ("Грот") дип аталган серле залында Шиллер белән шашканым, Вольтерның Тристан һәм Изольда мәхәббәте турында укып тәэсирләнгән кырсез минутларым күз алдыма килә! Китапханәләр тынлыгы, вокзаллар шавы, көзге пристаньнар моңсулыгы, көздән кышка кереп баручы тоныкелга агышы, жикән-камышлар сагышы, суда йөзеп барган сары яфрак—болар да, шигърияткә азык булу белән бергә, мәхәббәт язмышларына ишарәле түгелме? Мәхәббәт хисләрен яшь кыз-кыркыннарның, борыннарына дәрт исе кергән үсмерләрнең тәүге керсез тойгылары, яшерен сөю-гыйшык шигырьләре теркәлгән гади генә альбомдагыча да аңлатырга булыр иде ул.

Ә бит "Мәхәббәтнамә" исеме белән дә зурга дәгъвалый түгелме? Ә мин әлеге китапка карата үз фикерләремне житкерәсем килеп кулыма каләм алган идем. Юкка алынмаганмы икән? Инде искеләрне генә кабатламыйммы? Әмма бөек Такташ әйткәнчә: "мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, әмма һәрбер йөрәк аны яңарта"... Әнә бит, шуңа кушылып, Равил Фәйзуллин да:

*Бу төшләрне генә язсаң да!—*
*Мәхәббәт поэмасы!*

дип, үз дөньясын ача...

"Мәхәббәтнамә"—яраткан гашыйк йөрәкнең яну-көюләрен, бәхетле һәм сагышлы мизгелләрен эченә алган рухи яшәеш елъязмасы ул дияр идем. Укучы биредә әсәрләрнең форма һәм эчтәлек ягыннан төрле үрнәкләре белән очраша. Анда күңел утының кабынып кына сүнгән мизгелләре дә, бәхетле кичерешләрдә дәвамлы яшәп алу да—бар да сыйган.

Автор, язганнарымны кемнәрдер ревизияләмәгәйләре дигәндәй, утка каршы ут ягып, дулкынга каршы дулкын йөгертеп, үзен аңламаучылардан яклый, аралый кебек. Моның өчен дәлил итеп ул "Мәхәббәтнамә"сенә гаять тәфсилле, гыйбрәтле мисаллар тулы "кереш сүз"ен язган. Мәхәббәт турында фәнни трактат диярсең! Шундый илаһи исемгә нигезләнгән китап тикле китапны ачырга җөрьәт иткәннәр хәлне, андагы төрле коллизияләрне аңламас иделәр микәнни? Бер караганда бүгенге укучыга бәйнә-бәйнә аңлату, чәйнәп бирү алай ук кирәк булды микән? дисең. Юкса, шагыйрь үз китабына бәяләмәне үзе язырга алынган сыманрак фикер кала. Хәер, бу минем шәхси фикерем. Башкалар алай уйламас та. Каләм алуга, үзем дә шагыйрьнең шундый төпле фикерләренә мин ниләр өсти алырмын икән, дип уйлап куйган идем. Керешеп китә калсаң, бар икән ул әйтер нәрсәләр... «Кем белә,—ди автор,—бу якты дөньяга без, бәлки, шушы Бөек Мәхәббәт хисен тояр өчен генә киләбездер әле! Икеләнәсе дә юк, шагыйрь! Нәкъ шулай, дияр иде миннән башка берәве дә. Асылына төшеп карасаң, барлык юллар да... коммунизмга түгел, ә Мәхәббәткә илтә икән, чөнки барыбызны да Сөннән түгел. Мәхәббәт чишмәсеннән алып кайтканнар бит! Мәхәббәт! дип, кулга каләм алганбыз, җыр язганбыз, көнләшеп сырт йонын кабартканбыз, елаганбыз-көлгәнбез, дуэльләрдә атышып үлгәнбез... Биредә шагыйрь әйткәннәрне тоташ җөпләп баруны яисә аның белән ниндидер бәхәскә керүне дә кирәк күрмим. Ул соралмый да. Ара-тирә, әлеге "Мәхәббәтнамә" кысаларыннан чыгып, гомумән бүгенге мәхәббәт шигъриятенә кереп китсәм, шәт мине гафу итәрләр. Мәхәббәт кыйссалары, мәхәббәт фәне адәм яралу чорыннан ук булмаса да, бик борынгыдан киләдер ул. Тик биредә бер нәрсә ачык: ничекләр итеп кенә "бөек хис-тойгы мәхәббәт"ен, платоник мәхәббәтне югары күтәрсәләр дә, җисми мәхәббәт барыбер җиңеп чыккан. Моны парадоксларга кертеп булмый, чөнки тере дөньяны соңгысы хәрәкәткә китерә. Мәхәббәткә монополия салып булмый. Ул—һәркемнеке!

"Кешене киеменә карап каршы алалар" дип башланган тәкъбирне һәркем

белә. Бу яктан "Мәхәббәтнамә" кебек китапны кулга алу да үзенә бер бәйрәм, ул хәстәрле, бәрәкәтле бәйрәм настроениесен искә төшерә, янарта. Мондый шедевраль кием эчендә сәләмә затлар, белмим, очрар микән? дисен. Поэзия китабы, аеруча мәхәббәткә дан җырлаганы, ул, минемчә, нәкъ шулай булырга тиештер дә. Әйдә, киеменә карап каршы алсыннар, ни рәвешле озату соңгы бәя, нәтиҗә—укучыдан. Бусы—аның эше, китапны төзү ягы да бар бит әле. Полиграфия сәнгатендә дә ин югары бәягә ирешкән китапларның берседер бу дияр идем.

Равил Фәйзуллинның иҗатын, аның үсеш баскычларын шактый әйбәт белгән өлкән каләмдәше буларак, ин беренче шуны әйтим: шагыйрь күпләребез ябышып яткан рифма колы гына түгел. (Болай дип әйтү, бәлки, кемгәдер тапталган фикер булып тоелырга да мөмкин). Шагыйрь өчен билгеле бер халәтнен нюансларын тоту, хәтта халәтләрнең, шуларга китергән сәбәпләрнең азакы фазасын, мизгелләр нурланышын "аулау" әһәмиятлерәк:

*Тайгалады минем йөрәк тә*
*Шома күзләрдә.*
*...Күпме акыллы баш ярыла*
*Матур тезләрдә!*

Укыдылар, ди. Ә анладылар микән? Ай-һай. Яшүсмерләр кызлар альбомындагы примитив, әмма гөнаһсыз, беркүзәнәк шигырьләргә охшамаган шул образлы сурәтләрдән торган әлеге юллар. Берәүләр моны үзенчә "сүтәргә" дә мөмкин: ничек инде шома күзләрдә йөрәк тайсын да, матур тезләрдә акыллы башлар ярылсын, ди? Әйе, "мангайга бәреп" әйтелгән сүзләрне генә анлап, ничек әйтелгән, шулай кабул итүчеләр өчен катлаулы шул чын шигърият дигән өлкә! Ниһаять, шигырьне хәрефкә-хәреф анларга тырышу дингез суын учына алып анын элеккеге төсен эзләүгә тиндер. Минем бер шигыремдәгечә: "су булып су да үзгәрә, аерсаң олы судан..." Хәер, бүгенге көндә, хәтта кампитр шигырь язу сәләтенә өйрәнеп килгәндә, техник идарә өлкәсен роботлар яулаганда, психолог ясалма интеллект тудыру өстендә баш ваткан заманда метафорага, афоризмга мул шигъриятне генә укучы анламас түгелдер инде. Әлеге шигырьләрне укый торгач, мин үземә бер кечкенә генә ачыш ясадым кебек. Башка беркемнен дә иҗат алымына охшамаган әлеге шигырьләрдәге аһәннәр, кабынып-чаткыланып киткән халәт мизгелләре сюрреалистик сурәтләрне хәтерләтәләр. Телебезне бай дип мактыйбыз да, әмма анарда мин "мгновение"гә тәнгәл мәгънәле сүз табалмадым. Пушкинда: "Я помню чудное мгновение" диелә. Ә менә "мизгел" сүзе аны алыштыра алмый кебек. Тагын: "сиюминутное"ны нинди сүз белән алыштырырга соң? Болар бар да эчке халәт белән бәйле сыйфатлар. Ә Р. Фәйзуллинның мәхәббәт шигырьләрен ачу өчен әнә шул чаткыланып китүләрне, мизгелләрне алыштыручы сүзләр табу кирәк. Шагыйрь хис-тойгы сурәтен шул җаннын кузгалган халәтендә, экспрессив ноктада сынландыра, шунлыктан ана ситуацияләрне ничек булган, шул рәвешчә бирергә туры килә:

*Балконлы йортлар артыннан—каядыр*
*Безнең халәтләргә иш булып,*
*Тальян гармун шыңшып торды*
*Балачактан газиз бер көйне...*

Шигырьнең азагы болай:

*Безне такси озатып йөрде берәм-берәм*
*Моңсу, җылы җәйге төндә*
*Яралы лабиринт урамнар буйлап*

Әлеге кимәлдәге шигырьләрнең ин характерлысын укучы "Сау чакта, яки "шул" хакта" дип исемләнгәненнән табар:

*Шамук мәчесыдәй кайтып кизәм*
*Коры салкынлыктан кар шыгырдый*
*Шыгыр,*
*Шыгыр,*
*Шыгыр...*

Азагы:

*Ә шулай да*
*Яшәү шәп бит,*
*Анасын саткыры!*

Ә менә бу очракта нәкъ менә шул "сиюминутное" сүзен алыштырырдае кирәк иде! (Сиюминутное настроение!) Үзебезчә моны "халәт мизгеле" дип әйт-

мичә булмый. "Ә" дигәнче уза торган халәт. Мизгеллек халәт дияргә дә була. Шагыйрь үз фикерләренә "утырырга", "тонарга" ирек бирми: ана нәкъ менә шул мизгел кирәк, кузгалган, "болганган" хәлендә кирәк, күрәсен...

Элегрәк, итальян фильмнарын караганда үземчә бернәрсәгә гажәпләнә идем. Аларда декорация дә юк. Сәхнә—соры урам, уенчылары, катнашучылар өсләрендә ни булса, шунын белән. Урамнын ике ягын бер итеп кайтып килүче сәрхуш—оператор өчен менә дигән табыш... Тар тыкрыкка охшаган урамнар, балкондагы асылынган керләр, урам аша гына булган йортларнын террассаларында, бөерләренә бик эшлекле кыяфәттә таянып, хатын-кызлар нидер "бүлешә", әрепләшәләр... Бу итальян киносәнгатендә үзгә бер агым—неореализм дип атала икән... Неореализм, сюрреализм. Ә бездә күп заманнар соцреализм зәхмәте белән авырдылар. Мин Р. Фәйзуллиннын күп шигырьләрен сюрреалистик сурәтләр янәшәсенә куям. Мона мисаллар житәрлек. Французларнын атаклы сюрреалист рәссамы Анри Матисс полотнолары реаль сурәтләрдән бераз читләшкән булсалар да, алар бик тә шигъри буяулардан, нюанслардан, ачык төсмерләрдән тукылган. Алардан шигърият анкый! Минем алдымда ничә еллар Матисснын мәшһүр "Кызыл балыклар" полотносы торды. Әлеге юнәлеш бәйләнчек түгел, ул туйдырмый. Шагыйрь Гийом Аполинер шигърияте дә шулай...

"Мәхәббәтнамә"дә төрле алымдагы, төрле юнәлештәге, төрле үлчәм-калыптагы шигырьләр булганы белән бергә, төрле кимәлдәгеләре дә (шәпләре дә, кайтышлары да) жентекләсән шактый табылыр иде. Алдан әйткәнемчә, без шагыйрьләр әдәбият тәнкыйтьчеләре түгел. Күбрәк матурларын, күнелгә азык бирердәйләрен эзлибез. Ә андыйлар, шөкер, житәрлек.

Ана китсә, авторнын халыкчан тел сурәтләре афоризмга әйләнердәйләре дә шактый китапта:

*Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга*
*Житә сирәге!*
*Матурлар күп... Ә күңелгә*
*Син иң кирәге!*

Яисә:

*Иркен идек—тар калдык,*
*Күмәк идек—таркалдык!*
*...Бер көн килде—таң калдык!—*
*Парлы-парлы так калдык.*

Мәгълүм Козьма Прутковнын: "Кочак житмәстәйне беркем дә кочмас", дигән мәгънәле тәкъбире бар. Мәхәббәт темасын да, аерым алганда "Мәхәббәтнамә"гә кергән шигырьләрне дә, бер утыруда гына коча алмассын. Гомумән, кочып кына булыр микән аларны?!

Инде китапнын сонгы битен ябып, шагыйрьнен үзенә охшатыбрак әйтәсе килә: кеше мәхәббәтен укып чыктым, кеше ләззәтендә ләззәтләндем, кеше учагында жылындым, кеше хисләрендә коендым...

Инде үз учагынны тергез, шагыйрь.

Әлеге китапта бәхетле хис-тойгылар да, мәхәббәтнен үзенә тартым монсу кичерешләре дә житәрлек. Мәхәббәт Илендә нинди хәлләр булмас димсез?..

**Роберт ӘХМӘТҖАН.**
*20 сентябрь, 2006 ел.*

**Искәрмә.**

*Шагыйрь Роберт Әхмәтҗановның бу язмасы редакциягә моннан ике ел элек кергән иде. Төрле сәбәпләр (беренче чиратта, авторның үз шигырьләрен бирү максатыннан) аркасында мәкалә вакытында басылмый калды. Соңлап булса да, мәрхүм шагыйрьнең бу хезмәтен укучыларга ирештерергә булдык.*

***Тәнкыйть бүлеге***

# БАЛАЧАККА СӘЯХӘТ

Татар сүз сәнгатендә барган күтәрелеш-янарыш балалар әдәбиятында да үзен сиздерә, авторлар әхлакый проблемаларны яктыртуның яңа юлларын эзлиләр, үзгә алымнарга мөрәҗәгать итәләр. Әлеге сыйфат һәм сан үзгәреше балалар өчен басылган китапларның саны, эчтәлеге, идея-эстетик хасиятләре, сәнгатьчә алымнар төрлелеге белән дә билгеләнә. Бикә Рәхимованың күптән түгел дөнья күргән "Җайдак малай" шигырьләр җыентыгы да балалар әдәбиятына матур сәхифә булып өстәлде. Шагыйрь үзе дә укучысына "Беләм: шигырь сөясең. Шигырь укыйм!"—диясең Шигырь китапларына Тагын берсе өстәлсен!" кебек тезмәләрне юллый.



Шагыйрьнең яңа китабы балалар өчен кызыклы, мажаралы һәм гыйбрәтле шигырьләрне бер бәйләмгә туплый. Б. Рәхимованың лирик герое гадәти булмаган сыйфатларын күрә белүче, дөньяны үзгә кабул итүче һәм анарга омтылучы герой буларак алга чыга. Аның бу сыйфаты "Җайдак малай" шигырендә ачып бирелә һәм җыентыкта урын алган шигырьдән шигырьгә үстерелә бара.

Бер төркем шигырьләрне кояш, болыт, җил, кар-буран кебек метафорик, бүре, куян, төлке кебек аллегорик образлар бергә туплый, алар аша әхлакый проблемалар күтәрелә. Мәсәлән, "Куяннар" шигырендә йомшак, куркак, бәйрәмгә җыелган дус куяннар белән усал, ләкин ялгыз бүре арасында каршылык тудырыла:

*Кырык куянны күргәч*
*Калтырана, шурли, ди,*
*Куркуын яшерә, ди*
*Хәтта үз-үзеннән дә,*
*Ләкин бик яшерсә дә,*
*Сизелә үзеннән дә:*
*"Нигә инде бу кадәр?*
*Берсе белән дә туям.*
*Берәм-берәм очраса,*
*Эх, шушы кырык куян!"*

Әлеге аллегорик образлар, әкияти алымнар һәм соңрак каршылыкның куяннар файдасына хәл ителүе—барысы да бердәмлек идеясен, бердәм булырга кирәклекне, дуслык, бердәмлек алдында теләсә нинди авырлыклар да җиңелә дигән фикерне ныгыта. "Шук болытлар, батыр җил, якты кояш" шигырендә дә метафорик сурәтләр яктылыкның, матурлыкның, Хакыйкатьнең барыбер өскә чыгуы, җиңүе хакындагы мәгънәне үткәрә.

"Гөрләвек" шигырендә Газыймның кечкенә генә йомычка белән кирпечне төшереп калдыруы, шуның нәтиҗәсендә күршедәге ерганакка кушылам дип ашыгып аккан гөрләвекнең шуларга эләгеп туктап калуы, малайның аны кабат тәзәтүе сурәтләнә. Әлеге сурәтләр, шушы кечкенә генә әдәби детальләр авторга әхлакый идеяне үткәрергә ярдәм итә, шигырь балаларны тырыш булырга, үз артыннан һәрвакыт җыеп йөрергә, пөхтә булырга өнди. "Күрше әби" шигыре олыларга ярдәм итүнең изге гамәл икәнен бала күңеленә сеңдерә. "Җил малае Җилгали", "Ач калды", "Күке" һ. б. шигырьләрдә балалардагы сүз тыңламау, тискәрелек, ялкаулык, мактану кебек тискәре сыйфатлар төрле күренешләр, шартлы, әкияти алымнар аша тәнкыйтьләнә, кире кагыла. Мәсәлән, "Җил малае Җилгали турында әкият" сюжетлы шигырендә Җил малаеның, әти-әни сүзен тыңламыйча, аларны югалтуы, сүз тыңлаучан, унган малайларның үз өйләренә юл алуы хакында сөйләнелә. (Бүгенге заманның ачы җимеше булган урам малайларын—кечкенә бомжларны—уйлап тетрәндерә...) Җил малаеның хис-кичерешләре, ачы язмышка дучар булуы баланы әти-әни сүзенең иң кадерле, төпле

Бикә Рәхимова. Җайдак малай. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007.

булуы турындагы фикергә алып килә һәм "ата-ана сүзеннән чыкканнарны ачы язмыш көтә" дип кабатлый:

*Җилгәли аптыраган*
*Тагын да нык елаган.*
*Җилнең елап сызгыруы*
*Менә шул чактан калган.*

Аерым шигырьләр балаларда милли хис тәрбияләүгә басым ясый. Б. Рәхимова аның да үзенчәлекле ысулларын, алымнарын тәкъдим итә, ә ямьсез, чит күренешләр баланың эчке рухи үсешүзгәреше аша кире кагыла. Бу яктан "Китсен" шигыре авторның матур бер табышы булып тора. Әсәрдә Айсылу һәм Барби курчаклар каршылыгы тудырыла:

*Әбисе менә Барбины*
*Яратып бетермәгән.*
*"Тапкансың уенчык,—диеп,*
*Оныгын битәрләгән. -*
*Үз курчагың нинди матур,*
*Үзе нинди инсафлы.*
*Чәчен-башын туздырмаган,*
*Ходай биргән иң сафны."*

Шагыйрь гади генә курчакның да балада нинди тойгылар уята алуын Айгөлнең кичерешләре аша күрсәтә һәм милли хисне тәрбияләүнең шуннан башланырга тиешлеген, чит күренешләрнең балага ят булуда тискәре тойгылар уятуын дәлилли. Бикә Рәхимованың шул исемдәге шигырендә кечкенә генә, көчсез генә әкәм-төкәм дә безнең балаларда милли хис тәрбияли!

*Үземнекен үз итәм,*
*Өем күтәреп йөртәм...*

Әйе, татарның өй дигән сүзенә өейорты—курасы-каралтысы, гаиләсе, иле-көне, теле, нәселе-нәсәбе, киләчәге сыйган. Татар өен-илен үзе кайгыртырга, яшәтергә тиеш, әкәм-төкәмнән үрнәк алып булса да... Бу, билгеле, бөтен татар илен яшәтүгә дә кагыла.

Пейзаж лирикасына караган "Кыш", "Яз", "Җәй", "Көз" шигырьләрендә табигать сурәте тудырыла, һәр образ, деталь балага табигатьне яратырга, ел фасылларының һәркайсының үз матурлыгын күрергә, табарга ярдәм итә. Табигатькә "шигъри картина" ясап, Б. Рәхимова балада авылга, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли, табигать байлыгын, матурлыгын кеше хезмәтенең нәтиҗәсе итеп күтәрә. "Авыл баласы" шигырьләр циклындагы һәр шигырь әлеге фикер-идеяне үстерә, камилләштерә. "Татарстан буйлап сәяхәт" шигырендә республиканың төрле төбәкләренә "сәяхәт" оештырыла һәм ул баланың дөньяны күзаллау, танып-белү чикләрен киңәйтә. Авторның шигырьдә һәр төбәкнең тарихи вакыйгаларын, бүгенгесенең иң матур якларын ачып бирә алуы куандыра. Бу шигырьләр балаларда "Ватанны, үз милләтеңне ярату хисе, әхлак бөтенлеге туган төбәгеңне яратудан, аның үткәнен белүдән, тирә-яктагы матурлыкны күрә алудан башлана" дигән фикергә китерә:

*Мин күргәннәр бер тамчы*
*Сәяхәт диңгезеннән.*
*Тамырлар өзелмәсен*
*Туган ил нигезеннән.*
*Барсын күреп булмады -*
*Ерак-озын аралар.*
*Илне гизеп йөрергә*
*Сезгә кала, балалар!*

"Тукай Казаны", "Укыйк Казан тарихын", "Казан метросы", "Казанны саклыйк", "Корбан бәйрәме" кебек шигырьләр дә шул идеяне ныгыта, балаларда милли тарихка, Казан каласына мәхәббәт тәрбияли.

"Бионика", "Лилия һәм компьютер", "Сыр нигә тишекле?", "Оча торган тәлинкәләр", "Сәгать-чәйнек", "Исем" кебек шигырьләр комик ситуацияләр ярдәмендә тормышта шактый зур урын алган фән-техниканың аерым өлкәләре яки тормыш күренешләре хакында кызыклы, гыйбрәтле мәгълүматлар җиткерә. "Әти бәйрәме көнне" исеме белән бергә тупланган шигырьләр бәйләмен исә традицион бәхетле балачак иле идеясе берләштерә. "Әти бәйрәме көнне", "Кош теле", "Өйгә керче, бәбкәем!", "Бүген минем бәйрәм", "Тагын әбием күзлеге турында" шигырьләрендә бәхетле гаилә образы үзәккә алына. Лирик геройның шатлык хисе, күтәренке интонация дә шуна бәйләп бирелә, әсәрләр бәхетле гаилә рухи яктан бай, үз-үзе белән гармониядә яшәүче бала тәрбияләүнең нигезендә тора дигән идеяне ныгыта.

Шул рәвешле, Б. Рәхимова һәр шигырен әхлаклы булу, туган җирне ярата алу—бәхет, әхлаксызлык исә бәхетсезлекнең башы дигән фикер тирәсенә җыя.

**Нурфия ЙОСЫПОВА**



Идрис
Газиев,
Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты.

# ТАТАР ҖЫРЫ–ЙӨЗ ЕЛ ЭЛЕК...

Билгеле булганча, җыр сәнгате татар халкының тормышында элек-электән зур урын алып тора. Кайда гына яңгырамый безнең җырлар! Радио, телевидение аша миллионлаган тыңлаучыларга ишетелә, күпсанлы тираж белән дисклар рәвешендә сатуга чыга. Нинди генә җырлар юк та, нинди генә башкаручылар юк. Башкаручыларның һәрберсе бүгенге эстрада аша зур тормыш сәхнәсендә үзенең урынын эзли. Зур концерт заллары, мәдәният сарайлары, авыл клубларымы, соңгы елларда гаять модага кереп киткән рестораннар, төнге клуб сәхнәләре, дискотекалармы—бүген болар барысы да популяр музыка өлкәсендә эшләүчеләрнең иҗат мәйданына әверелеп бара. Ә төрле юбилейларда, туйларда һәм банкетларда җырлау кайбер җырчыларыбызның төп кәсебенә әверелүе, бүгенге көн татар җыры һәм музыкасының бер чагылышы дип кабул ителә.

Шаулап, гөрләп кайнаган бу попмузыка казанында татар эстрада җыры үзенең төп эшен башкара—ул күпсанлы кулланучыларның күңелен ача, билгеле. Сорау туа: татар эстрадасында күңел ачу музыкасының барлыкка килүе кайсы вакытларга карый икән соң? Концерт эшчәнлегенең, башкаручанлыкның башында нинди үзенчәлекләр булган? Нинди җырлар яңгыраган, һәм иң кызыклысы—ул җырларны кемнәр башкарган? Музыка, җыр сәнгате—вакыт кинлегендә яңгыравышлы сәнгать. Йөз ел элек халкыбыз тыңлаган көй һәм җырлар, аларны башкарган җырчылар турында нинди дә фикер йөртер өчен без, әлбәттә, төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә тиешбез.

Бу чыганакларның иң мөһиме, нинди дә могҗиза аркасында сакланып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән йөз еллык граммофон тәлинкәләре. Бик аз санлы ул тәлинкәләр хәзерге көндә кадерләп саклана торган антиквариатка әйләнделәр. Мин бу мәсьәлә белән җитди кызыксына башлагач, Казанда яшәгән кайбер зыялылар кулында шундый тәлинкәләрнең барлыгын ачыкладым. Аларның берсе—Татарстан милли китапханәсендә эшләгән Айрат әфәнде Заһидуллин.

Ул үзенең коллекциясен күрсәтте, ә мин бу очрашудан соң кыйммәтле тәлинкәләрдә язылган җырларны тизрәк яңгыратыр өчен антиквар кибетләрендә патефон эзләп йөри башладым. Яхшы сыйфатлы бер портатив уйнаткычны мин Уфаның бер кибетендә табып, Казанга алып килдем. Беренче тапкыр граммофон тәлинкәләрен кулга алып, анда язылган җырларны, көйләрне тыңлап, җырларның, башкаручыларның исемен укып, сөйләп бетерә алмаслык хисләр кичердем, кат-кат тыңладым, шаккаттым. Патефонның очлы энәсеннән чыккан нинди дә кыштырдау, шытырдау аша минем колагыма татар моңының йөз еллык сулышы килеп кагылды сыман. Скрипка, гармун моңнары, төрле җырчылар башкарган җыр аһәңнәре мина Тукай, "Сәйяр", "Шәрекъ" клубы вакытларын бүгенге көн белән бәйләгән кебек тоелды. Октябрь революциясенә

кадәрле граммофон дөньясының торышы, ул чор музыкасының менәрләгән тираж белән чыгарылуы, аны төрле милли басмаларда рекламалау, ул тәлинкәләргә кергән жырлар һәм көйләрнең каталоглары булу—болар барысы да күп нәрсә турында сөйли.

Әлбәттә, йөз ел элек, халкыбызның үзаны уяну дәверендәге бай күренешнең бер чагылышы булган граммофон музыкасы буш урында барлыкка килмәгән. Беренче чиратта моның нигезе—XIX гасыр азагы XX гасыр башында илдәге барган социаль-икътисади хәлләр, татар халкының рухи дөньясында барлыкка килгән үзгәрешләр белән бәйле булган янарыш чоры. Бу дәвер яңа буржуаз мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе, мәгърифәтчелек идеологиясен формалаштырган сәләтле көчләрнең дөнья мәйданына чыгуы белән характерлы. Йөзәрләгән еллар хөкүмәт белән ризалыкта яшәп, мөселманнар арасында үзләренең тыныч, салмак тормышларын алып барган борынгы сәүдәгәрләр династияләренең вәкилләрен, әйтик, Апанаевлар, Азметьевлар, Бурнаевлар, Юнысовларны алмаштырып, яңа типтагы коммерсантлар килә: Галиевлар, Галикәевлар, Казаковлар, Сәйдәшевлар. Аларның күбесе чыгышлары белән авылдан булып, үзләренең сәләтләре, тырышлыклары аркасында бик зур байлыкларга ия булалар. Барысы да диярлек рус телен бик яхшы беләләр, рус сәүдәгәрләре һәм промышленниклары белән тыгыз элемтәдә булалар. Хөсәеновлар, Казаков һәм Сәйдәшев кебек эшкуарлар чит илләрдә үзләренең контораларын ачалар. Мөселман мохитенә нинди дәрәҗәдә тугры булган бу яңа тип эшкуарлары татар халкы тормышында ныклы яшәгән ислам традицияләрен заманга яраклаштыруга, якынайтуга шактый көч салалар. Гаспринский, Рәмиев, Максуди, Алмаев һ. б. кебек бай сәнәгатьче зыялылар Европа илләренә сәяхәт кылып, андагы көнбатыш цивилизациясенең тәҗрибәсен өйрәнеп, үзләренең бу сәяхәтләре турында төрле фәһемле китаплар бастырып чыгаралар. Татарлардан чит ил университетларында укучылар да аз булмый.

Капитализмның үсүе һәм милли буржуазиянең барлыкка килүе татар мәгърифәтчелегенең тууы, аның үсеше белән бик нык бәйле. Бу бәйләнешнең нәтиҗәсе булып татар җәмгыятендә прогрессив омтылышлы җәдитчелек дип аталган хәрәкәт барлыкка килә.

Шәһәр мәдәнияте кысаларында татар профессиональ музыка традицияләренең формалашуы нәкъ шул үзгәрешләр чорына, XX гасыр башына туры килә. Бу традицияләрнең барлыкка килүен күрсәткән берничә үзенчәлекне билгеләп китәргә кирәктер. Беренчедән, ул чорда күпмилләтле халык яшәгән шәһәрдә (монда Казаннан башка Уфа, Оренбург, Троицк, Уральск, Сембер кебекләрне дә күздә тотарга кирәк) татарларның төпләнеп, бер төп бистә булып яшәүләре. Икенчедән, шәһәр татарлары арасында кискен рәвештә социаль бүленү һәм аның нәтиҗәсендә ачык рәвештә чагылган мәдәни кызыксынулар, кулланууларның аермалы булуы. Өченчедән, дини рухани контрольнең йомшара төшүе нәтиҗәсендә татарлар тормышында либераль мөнәсәбәтләрнең урнашуы. Дүртенчедән, Европа кыйммәтләрен эченә туплаган рус мәдәниятенең тәэсир көче.

Казан шәһәре, билгеле булуынча, ике өлешкә бүленгән була. Кабан күле һәм Болакның бер ягында руслар, икенче ягында татарлар тора. Һәрбер як үзенә генә хас булган тормыш-көнкүреше, дине, менталитеты белән яши. Шәһәрнең рус өлеше элек-электән бай музыкаль тормыш эчендә кайный. Театрлар эшли, данлыклы опера җырчылары, музыкантлар иҗат итә, гастролерлар килә. Татарларның менә шул рус музыкаль тормышы белән кызыксынуы арта. Ул чорда Казан операсына татар тамашачыларының йөрүе дә бер прогрессив күренешкә әверелә. Опера театры репертуарында көнчыгыш мотивлары белән сугарылган сәхнә әсәрләре урын ала. Бу беренче чиратта театр эшлекләләренең актив рәвештә татар тамашачысын җәлеп итү теләгеннән чыгып та эшләнелгән, күрсен. Хәтта кайбер операларның, әйтик, "Князь Игорь"нең либреттосына татарча аңлатмаларның бастырылуы да билгеле.

XX гасыр башы татар милләтенең югары катлам кешеләренең тормыш-

көнкүрешенә хас булган әһәмиятле үзгәрешләр барлыкка килә. Бай кешеләрнен йорт интерьерларына Европанын мәдәни тормышы белән бәйле булган әйберләр килеп керә: рояль, граммофон, төрле механик музыкаль тартмалар. Өй шартларында фортепианода, гармунда, мандолинада уйнау, башка халыкларнын көйләренә, жырларына булган кызыксыну үз чиратында татарлар өчен музыканы профессиональ дәрәжәдә үзләштерү мөмкинчелеген ача. Бу инде ижатка һәм концерт башкаруына алып бара. Татарлар арасында Европа үрнәгендәге профессиональ белем алган музыкантларнын килеп чыгуы да шул чорга карый. Аларнын чыгышы күбесенчә бай гаиләләрдән була. Скрипкачылар Исмәгыйль Аитов, Барый Кәримов, Вәли Апанаев, флейтада уйнаучы Мансур Солтанов башкару белән укыту эшен дә бергә алып баралар.

Революциягә кадәр күпмиллэтле Казан халкынын югары катламы, әйтеп үтелгән опера һәм классик концертлар белән кызыксынудан башка, шул чорнын үзенчәлеге булган, әлеге катламны канәгатьләндерүче "күнел ачу музыкасы"н да үз итеп кабул итә. Ул гына да түгел, бу демократик музыканы шәһәрнен башка катлам халкы да читкә какмый. "Күнел ачу музыкасы" шул чорда эшләп килгән рестораннарда, кабакларда, паркларда, пароходларда һ.б. жирләрдә янгырый. Ә бу жинел музыканы халыкка житкерүчеләр кемнәр сон? Монда без бер мөһим әйбергә тукталып китәргә тиешбез. Татарларда профессиональ музыка сәнгатенен барлыкка килүен, гадәттә, Октябрь революциясеннән сонгы чор белән бәйлиләр. Бу беренче чиратта Европа үрнәгендәге профессионализмга кагыла. Ә бит, бу үрнәктә белем алган профессиональ музыкантлар белән беррәттән, революциягә кадәр татарлар арасында, борынгы традицияләрне дәвам иткән халык музыкантлары һәм жырчылары да үз эшчәнлекләрен алып баралар. Аларнын үзенчәлекле сәнгатен без авыз ижаты традицияләрендәге профессиональ сәнгать дип билгелибез. Бу профессионалларнын үзенчәлекле башкаруы төрле ярминкәләр һәм базарларнын эшчәнлеге белән тыгыз бәйле. Казанда, Идел буе һәм Урал якларында элек-электән уздырыла торган, бик күп төрле милләт кешеләрен үзенә жыйган бу ярминкәләр татар башкаручылары өчен үзенә күрә мәдәни учак ролен үтәгәннәр. Борынгы заманда сату-алу, базар кысаларында үткәрелгән күнел ачу чаралары өчен, анда чыгыш ясаган һәм ярышкан музыкантлар, жырчылар өчен махсус мәйданнар, биналар, ачык сәхнәләр куелган була. Болгардагы "Зур базар" чорларыннан килгән бу традиция сонрак Казанга, шуннан Мәкәржәгә һәм Түбән Новгородка күчкән, шулай ук Минзәлә, Бөгелмә, Ирбит (Эрбет), Петропавловск, Актүбә һ.б. шәһәрләрдәге ярминкәләрдә туктамыйча яшәп килә. Базарлар һәм ярминкәләр музыкантларнын, жырчыларнын ижади үсешен билгеләгән. Бу өлкәдә эшләгән музыкантлар, скрипкачылар Гайсә Мәкәржә, Ончы Фәхри, Мөхәммәтша Мостафин, Гыйльметдин Ижбулдин, гармунчы-жырчы Мирфәиз Бабажанов, жырчы Мәрьям Искәндәрова кебек күренекле башкаручыларнын исемнәре тарихка кереп калган. Истәлекләргә караганда, алар башкарган татар милли репертуар да, башка милләтләрнен жыр һәм көйләре дә бердәй уныш белән тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә. XX гасыр башында менә шундый башкаручылар профессиональ эшчәнлек белән актив шөгыльләнә башлыйлар. Алар уйнаган, жырлаган жирләр ярминкәләр, базарлар гына түгел, ә югарыда искә алынган рестораннар, парклар, трактирлар, чәйханәләр, клублар, ачык (түләүле) кичәләр һәм театр. Берәүләрне анда акча эшләү тартса, икенчеләрне музыкага, жыр-монга булган мәхәббәт алып килә. Үткән гасыр башындагы шәһәр музыкасы өлкәсендә барлыкка килгән әлеге күренешкә аерым тукталып китәргә кирәк. Ул да булса, милли концертлар оештыру һәм аларны үткәрү, татарлар яшәгән төбәкләрдә гастрольләрнен жанлануы. Музыкантлар һәм жырчылар оештырган концерт эшчәнлеге матди чыганак кына булып калмый, ә милләт тарафыннан татар мәгърифәтчелегенен яна бер формасы буларак та кабул ителә. Ләкин шунысын әйтеп китәргә кирәк, публика өчен ачык концертлар оештыру бик күп каршылыкларга очрый. Реакцион дин әһелләре һәм патша жандармериясе тудырган бу каршылыкларны бик көчле ихтыярлы,

чын мәгънәсендә милләт өчен янган, аның мәдәниятенең, җыр-моңының яшәргә хокукы барлыгын һәрчак әйтеп килгән кешеләр генә җиңеп чыга алгандыр.

Безне аеруча кызыксындырган әйбер—шәһәр музыкасындагы янарыш, төрле үзгәрешләр чорында җыр сәнгатенең торышы. Бу проблеманы ачыклаганда без, әлбәттә, үткән гасырның башында үзләренең эшчәнлеге белән милләт тарихында урын алган җырчыларыбызның иҗатын һәм тормышын, аларның репертуарын һәм аларның халык арасындагы популярлыгын күздә тотабыз. Бүгенге көндә билгеле булган һәм шулай ук гасыр барышында бөтенләй онытылып, югалып калган татар җырчыларының исемнәрен искә алып китү кирәктер. Бу җырчылар: Камил Мотыйгый, Фәттах Латыйпов, Мирфәиз Бабаҗанов, Газиз Әлмөхәммәдев, Ибраһим Адамантов, Хөсәен Йосыпов, Сәлахетдин Гаязетдинов, И. Галиәкбәров... Хатын-кыз җырчылардан—Абруй Сәйфи, Мәрьям Искәндәрова, Хәдичә Позднякова, Фатыйма Моратова, Хәдичә Гимбитская, Фатыйма Гомәрова, Әминә Бәхтизина... Бу җырчылар башкарган җырларның халык арасында популярлашып китүе XX гасыр башында граммофон музыкасының Россия күләмендә киң колач җәеп таралуы белән дә бәйле. Бүгенге көнгә кадәр сакланып калган граммофон тәлинкәләрендәге җырлар һәм көйләр безгә шул чордагы җыр сәнгатенең торышы турында байтак мәгълүмат бирә.

Монда бераз читкәрәк китеп язучы, драматург Г. Исхакыйның музыкага, җырга кагылышлы бер киңәшен искә алыйк. Яшь буынга милли тәрбия бирү күзлегеннән чыгып ата-аналарга, өлкәннәргә әйтелгән ул: "Белсәнез, татар көйләрен көйләнез, ерланыз. Белмисез икән, Казаннан матур көйле пластинкалар алдырыныз. Граммофонмы, башкамы, музыка коралы алыныз... Милли музыкага ерларга өйрәтенез...". Бу мисал XX гасыр башында граммофон музыкасының шәһәр көнкүрешендә мөһим урын алып торуын тагын бер тапкыр дәлилли.

Кызганычка каршы, танылган җырчылардан булган К. Мотыйгый һәм Ф. Латыйповларның язмаларын мина тыңларга туры килмәде. Шулай да кайбер чыганакларга таянып шуны әйтергә кирәк, ул чорда К. Мотыйгый-Төхфәтуллин башкаруында байтак кына җыр тәлинкәләре чыгарылган була. "Казан татарлары җырларының исемлеге, 1912 елның ноябре" дигән рус телендә бастырып чыгарылган мәгълүматлар китабында җырчының "Корсын балам, бу кала", "Гайшә", "Сәлим бабай", "Кызлар хәле" җырлары искә алына. Язучы Әхәт Гаффар, үзенең бер мәкаләсендә, 80 нче еллар уртасында К. Мотыйгыйның бер тәлинкәсен тыңлаганнан соң туган уй-тәэсирләре турында яза. Анда ул, җырчы башкарган "Тотса мәскәүләр якан" (Г. Тукай сүзләре), "Мәхбүс Шәһзадә" (Г. Камал сүзләре) җырларын да искә алып уза. "Амур граммофон рекордъ (Пишущий Амур)" җәмгыяте тарафыннан яздырылып, Рига шәһәрендә "Граммофон" ширкәтендә эшләнгән сыйфатлы, төсле рәсемле граммофон тәлинкәсеннән яңгыраган татар халык иҗаты җәүһәрләреннән булган "Гәйшә" җырының тәэсире турында аеруча җылы итеп яза әдип. Шунда ук Ә. Гаффар бер мөһим әйбергә басым ясап үтә: "Арада Г. Тукайның үткер шигыренә чыгарылган җыр җырлану ("Тотсын мәскәүләр якан") К. Мотыйгый-Төхфәтуллинны сәнгатьтә, Шаһит Әхмәдиев әйтүенчә, һич тә талымсыз, зәвыксыз итеп сыйфатламый. Киресенчә, бу—аның үтә зәвыклы, чын милли сәнгать әһеле икәнлегенә дәлил". Күренекле галим И. Рәминең "Әдәби сүзлеге"ндә без 1910-1913 елларда "Пате" граммофон ширкәтендә Г. Тукай әсәрләре буенча язылган пластинкалар сериясе чыгарылуы һәм анда К. Мотыйгый башкаруында "Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?", "Кемне сөяргә кирәк", "Эштән чыгарылган татар кызына" ("Зиләйлүк" көенә), "Ләззәт вә тәм нәрсәдә?", "Мәгъшукамә"(мәхәббәт шигырьләре) җырлары булуы турында мөһим мәгълүмат табабыз.

Инде турыдан-туры граммофон тәлинкәләрен барлауга күчик. Мин иң башта югарыда искә алынган җырчы-гармунчы Мирфәиз Бабаҗановның (1867-1942) язмаларын тыңладым. Халык телендә "Троицкий Мирфәйзә" кушаматы белән билгеле бу җырчы Оренбург губернасындагы Троицк шәһәрендә яшәгән. Чыгышы белән Урта Азиядән булып, татар музыкасына кереп киткән шәхес.

"Хәтердә калган минутлар" әсәренең бер эпизодында Сәйфи Кудаш жырчыга кагылышлы фактны искә алып яза. Казах даласында язучы бер акын белән очраша. Сөйләшергә бик яраткан бу акын "һәр елның җәендә Троицкига барып, ул чакта граммофон пластинкаларындагы жырлары белән билгеле булган жырчы Мирфәиз Бабажановның кымызханәсендә бераз үлән (жыр) әйтеп кайта икән". С. Кудашның кызы Сөембикә ханым белән бер очрашканда ул мина элек әтисенең пластинкалары арасында М. Бабажановның да язмалары булуы турында әйтеп үтте.

Жырчының кымызханә тотуы заманында аның хәлле кеше булуы турында сөйли. Кымыз эчемлеге тәкъдим ителгән бу залның идәненә гадәт буенча киез паласлар, көрпәләр түшәлгән, уртасында зур табын. Кымыз эчәргә, әңгәмә корырга, уен-жыр тынларга килүчеләр кичләрен шунда жыелып , кемнең хәле ничек, шулай сыйланганнар. С. Кудаш искә алган акын кебек башка халыкларның музыкантлары, курайчылар да бу кымызханәдә барган мәжлесләрдә үзләренең һөнәрләрен күрсәтеп китә икән. Кымызханә хужасы үзе дә жырлавы, уйнавы белән күңел ачуда катнашкан. Шунысын да әйтергә кирәк, М. Бабажанов еш кына төрле ярминкәләргә барып, анда чыгыш ясый. Күренекле актер, режиссер Г. Кариевның Г. Тукай турындагы истәлекләрендә М. Бабажановның эшчәнлегенә кагылышлы кызыклы бер мәгълүмат бирелә. Түбән Новгородтагы "Мәкәржә" вакытында "Двухсветная" кунакханәсендә идарә иткән Тимерша Соловьев татар театры артистлары һәм Г. Тукай катнашындагы концерт программасын ярминкәгә килеп ресторанда ашап-эчкән байларга, сәүдәгәрләргә тәкъдим итә. Эшләр жайланып китеп, артист халкының тамагы туя башлап бер атна вакыт үткәч, "гөнаһ шомлыгына каршы, әллә кайдан бер гармунчы мишәр килеп чыкты. Ул гармунчы мишәр дә Тукайның капельмейстерлыгы тәхтендә без жырлаган сәхнәгә менеп, гармунны әйттерә, үзе уйнаганда, хатыннар тавышы берлә мишәрчә әллә нинди урам жырлары жырлый башлады. Бу мишәрнең һөнәре халыкка тагы да ошады булса кирәк: халык шатлыгыннан урынында тора алмыйча, төрлечә үзенең шатланганын изһар итәргә тотынды. Ни эшләргә белми, кул чабулар кирәкме, урындыклар берлә дөбердәтүләр кирәкме, хасил, бөтен "Двухсветная" ду куба иде. Бу мишәр безгә караганда да ун өлеш артык муаффәкыять казанды. Бәгъзе танышлар безнең янга килеп, безне үртәгән сыман, шатлыкларын белгертеп: "Йөзе кара, шәп жырлый бит, ә?"—дип, сөаль биреп китәләр иде. Бу гармунчыны халык шулкадәр яраткач, Тимерша әфәнде дә аны Мәкәржә буена жырларга алды". Күренекле китапчы, галим, библиограф И. Рәминең "Әдәби сүзлеге"ндә китерелгән бер истәлек безнең өчен аеруча игътибарга лаек. "1913 ел. Мәкәржә ярминкәсе. Хөсәенов подворьесе аталган чәйханә залы. Урта яшьләрдә булыр, мәһабәт гәүдәле берәү эстрадага чыкты. Өстендә ыспай гына билле бишмәт. Ясалма энжедән чиккән кәләпүш. Чалбар балагын читек куңычы өстеннән салындырган. Сакал-мыегы да саф мөселманча төзәтелгән. Әгәр кулында гармуны булмаса, бу бай абзый сәхнәгә ни өчен чыкты икән дип уйлар идең. Сүз юк, оста уенчы, моңлы уйный. Әле ул жырларга да тиеш. Бу чаклы дәү кешедән чыккан тавыш бу залга сыяр микән дип уйлыйсың. Менә гармунга кушылып жырлап та жибәрде ул:

*Киләдер лә кәрван, һай, киләдер...*
*Үргәнечтән түгел, Хивадан...*

Сулышы иркен, инде тавышы... Ничек дип әйтергә дә белмим. Ирләр тавышы түгел, хатын-кыз тавышына да охшамый. Тенор да түгел. Мин ул тавышны ничек дип атарга да белмим. Бу уенчы-жырчы—"Троицкий Мирфәйзә" диген атаклы Мирфәиз Бабажанов иде". Халык арасында йөргән риваятьләргә караганда, М. Бабажанов үзе дә күп көйләр ижат иткән. Бу турыда С. Габәши үзенең "Татар музыкасы" мәкаләсендә әйтеп уза.

Бу көйнең инструменталь вариантын А. Ключарев үзенең "Татар халык жырлары" китабында (1 кисәк) китерә. Ул анда "Троицк Мирфәйзә" исеме

белән бирелгән. М. Бабажановның җырлавыннан һәм уйнавыннан алынган язмаларны Рига шәһәрендәге "Сирена грандъ рекордъ" граммофон ширкәте үзенең тәлинкәләре аша кулланучыларга тарата. Җырчы-гармунчының сакланып калган бернечә язмасы гына да аның иҗатын күз алдына китерү, аны ачыклау, аңа характеристика бирү, эзләнү һәм өйрәнү юлында ышанычлы чыганак булып калалар. Ул язмалар арасында М.Бабажановның гармунда башкарган "Гыйззелбанат" (N 7025) һәм "Сатыра енгә" (N7024) көйләре игътибарга лаек. (Күрсәтелгән N-лар граммофон ширкәте чыгарган каталогтагы җыр һәм көйләрнең тәртип саны). Бу язмаларда гармунчы-музыкант татар халык көйләреннән булган "Гыйззелбанат"ны бик моңлы, тирән хис белән язып калдырган.

Җырчы-музыкант башкаруындагы халык җырлары теркәлгән ике тәлинкә безнең өчен аеруча кадерле. "Сирена грандъ рекордъ" граммофон ширкәте чыгарган бу тәлинкәләрдә М. Бабажанов тарафыннан дүрт җыр яздырылган. Беренчесендә татар халык җырларыннан "Фазлуш" (N7002) һәм "Карлыгач" (N7003), икенчесендә "Сәҗидә көе" (N7006) һәм "Кашы кара" (N7007). Бу язмалар җырчы-музыкантның үз уенына (гармунга) кушылып җырлавыннан алынган. Минутына 78 тапкыр әйләнгән тәлинкәләрдәге җырларны тыңлаганда, күз алдына И. Рәминең югарыда китерелгән истәлегендәге үзенчәлекле җырчы образы килеп баса. Тирәнерәк уйлап карасаң, XX гасыр башында калкып чыккан татар эстрадасының үзенчәлекләрен үзенең иҗатында чагылдырган беренче карлыгачлардан булмагае, бу Троицкий Мирфәйзә?! Җырчының тышкы кыяфәтендәге эксцентрикасы, башкару манерасы, репертуары һәм аның гастроль тормышы—болар барысы да шуңа ишарәли.

"Сирена грандъ рекордъ" ширкәте тиражлаган тәлинкәләрдә ул чордагы җырчылардан Сәлахетдин Гаязетдиновның җырлары да теркәлгән. "Йосыф—Зөләйха көе" (N12124) һәм "Катарҗан көе" (N1325) җырлары язылган бер тәлинкәдә, башкаручының "известный татарский певец и гармонист" булуы турында белешмә күзгә чалына. Җырчының тавышы да, М. Бабажанов планындагы, югары регистрда янгыраган специфик тавыш. Җырлар үзләренең эмоциональлеге, оригиналь янгырашлы булулары белән хәтердә калалар.

Монда бер әйбергә басым ясап китү кирәк. Сакланып калган язмаларны тыңлап, аларны анализлаган вакытта, шәһәр көнкүреш музыкасындагы бер кызыклы күренеш игътибарны җәлеп итә. Кайбер ир-ат җырчыларның тавышлары, нигездә, югары регистрда берникадәр ясалма, кычкырыбрак һәм ярым—фальцет катыш "чинабрак" янгыраган, шул ук вакытта, хатын-кыз тавышларына да бераз охшаган үзенчәлекле тембрдан тора (югарыда искә алган җырчының халык арасында "Мирфәиз" исеме белән түгел, ә "Мирфәйзә" кушаматы—хатын-кыз исеме белән танылуы да шуның белән бәйледер). Кайбер Көнчыгыш илләрендә һәм Кытайда борынгы чорлардан ясалма югары тавыш белән җырлау профессиональлекне күрсәткән бер күренеш итеп кабул ителгән. Борынгы Рим бәйрәмнәрендә музыканың ясалмалыгы күп очракта җырчылар һәм музыкантлар тарафыннан бай катлам кешеләренең таләпләрен канәгатьләндерү күзлегеннән чыгып эшләнелүе тарихта билгеле. Үзләренең хуҗаларына ярарга тырышып ир-ат җырчылар хатын-кыз тавышы белән генә түгел, хәтта балалар тавышы белән җырларга да әзер булганнар. Борынгы Мисыр музыкаль традицияләреннән килгән табигый булмаган җырлау сәнгатенең әлеге чорларга тиклем саклангнаы да билгеле. Мисырда мондый ясалма тавыш белән җырларга өйрәнү өчен бик күп укырга туры килгән. Табигый булмаган тавыш белән җырлау башкаручының абруен төшерү түгел, киресенчә, бермә-бер күтәргән генә. Шулай итеп, ясалмалык сәнгатьнең бер мөһим сыйфаты булып саналса, натураль янгыраш түбәнлекне күрсәткән. Бер япон әйтеме болай янгырый: "Табигый тавыш белән йөк ташучы гына җырлый".

Безнең очракка килгәндә, кайбер чыганаклардан билгеле булуынча, мондый ясалма җырлауны, бу күренешне тәнкыйтьләүчеләр әлеграк нииндидер бер кимсетү, мыскыл итү, шундый тавышлы җырчылар өстеннән көлү мөнәсәбәтен

белдереп, "алар кастратлар булган икән, имеш" дигән хаксыз бәя биргәннәр. Искә төшереп китәргә кирәк, Европаның жыр сәнгате тарихында жырчы кастратлар ижаты итальян музыкасы, аның операсы белән бәйле була һәм бу күренешнең XVII-XVIII гасырларда алган урыны бик мөһим. Без татар жырчыларының шундый "ярым ир, ярым хатын-кыз" тавышларын, бүгенге көн жыр сәнгатендә норма булып саналган классификациясенә туры китереп, контр-тенор дип атый алабыз.

М. Бабажанов, С. Гаязетдинов үрнәгендә без югарыда әйткән тембр үзенчәлегеннән башка бу жырчыларга хас булган жырлау манерасын да ачыклау мөһим. Мәсәлән, М. Бабажановның башкаруы үзенең эмоциональлеге белән аерылып тора. Гармунның яңгырап торган ачык тембры да башкару процессына үзенең характерлы үзенчәлекләрен өсти. Мондагы музыкаль фикерләүнең яссылыгында шәһәр музыкасына хас булган күтәренкелек, дәртлелек кебек сыйфатлар ята. Типтереп яшәгән эре һәм вак буржуа гына түгел, башка катламнарның да тормышын бизәгән күңел ачу музыкасының шундый репертуардан торуы табигый хәл. М. Бабажанов үзенең башкарган жырларында еш кына төрле үзенчәлекле алымнар куллана: жыр юлларындагы аерым ижекләрдә интонацион басымнар ясый, бер аваз белән икенчесен тоташтырган глиссандолар бик еш очрый, тавыш һәм гармунда яңгыраган көй күп очракта унисон алып барыла.

Граммофон тәлинкәләрендә язмалары сакланган тагын бер жырчыга тукталып китик. Революциягә кадәр татар жырлары кергән язмалардан сакланып калганнары арасыннан Хөсәен Йосыпов исемле жырчы тарафыннан яздырылганнары сан ягыннан иң күбесе дип әйтсәк, ялгыш булмас. Бу тәлинкәләр Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИ фондында сакланалар. Алар белән мине танылган музыка белгече, фольклор фәне өлкәсендә байтак мөһим эшләр башкарган Макаров Г. М. таныштырды. Патентланган (N348505) әлеге тәлинкәләрне (жырчының исеме анда "Хусаинъ Юсиповъ" дип язылган) "Пате" граммофон ширкәте чыгарган. "Дискъ Пате" дип тиражланган язмалар арасында түбәндәге жырлар бар: "Айхали Зиләли" (N 25920), "Волков сазы" (N 25921), "И ха-ха, трепака" (N 25674), "Каторжан жыры" (N 25773), "Тай да тройка" (N25914), "Порт-Артур" (N 25915), "Агыйдел" (N 25928), "Ай, бәгърем" (N 25929). Язмаларга караганда, Х. Йосыпов заманасы өчен шактый әзерлекле жырчы булган, күрәсең.

Сакланып калган язмалар арасында ZONOPHONE RECORD граммофон ширкәте чыгарган бер тәлинкә аеруча кызыксыну уята. Баритон тавышлы жырчы И. Адамантовтан яздырылып алынган "Корсын балам" (NX-4-102827) һәм "Ашказар" (N X-4-102826) исемле халык жырлары фортепианога кушылып башкарылган. Монда бер кызыклы күренешкә туктап китү кирәк. Сүз ул чорда шәһәр халкы арасында киң таралган башкорт халык көйләреннән һәм жырларыннан ни сәбәпледер бер жырның аеруча мөһим урын алып торуы турында бара. Башкорт халык жырларыннан булган "Ашказар" шул чордагы башкаручыларның, скрипкачыларның, гармунчыларның һәм, әлбәттә, жырчыларның репертуарында ныклы урын алып торган жырлардан санала. Бер яктан, башкаручыларны жырның гажәеп моңы, аның тирән трагик эчтәлекле легендасы жәлеп итсә, икенче яктан киң диапазонлы, техник яктан шактый катлаулы булган бу жырны, фәкать, күпмедер дәрәжәдә профессиональ әзерлеге, осталыгы булган музыкантлар, жырчылар тарафыннан гына башкарыла алуы белән дә бәйле. Г. Тукайның, башка озын көйләр ("Уел", "Әллүки", "Зиләйлүк", "Порт-Артур", "Әминәкәй гүзәлем") белән беррәттән, "Ашказар" көен дә шәкерт чорларыннан ук яратканы һәм ул жырны көйләп йөргәне турында күпләребезгә билгеле. Аның борынгы көйләрне саклап, аларны даими халыкка ишеттереп, житкереп торуның кирәклеге, ул жыр мирасының киләчәк буыннар өчен әһәмияте зур булуы турындагы борчылулары, шагыйрьнең бу мәсьәлә буенча чыгыш ясаулары, борынгы көйләрнең шәһәр музыкасы кысаларында актив яңгыраш табуына да тәэсир иткәннәрдер. Түбәндә моны дәлилли торган мисалларга

тукталып китик. Ул чорның танылган музыкантларыннан булган И. Козловның "Шәрекъ" клубы кичәләрендә "Ашказар" көенең легендасын сөйләп, шуннан соң аны скрипкада башкаруы турында билгеле. Язучы һәм тәржемәче Солтан Рахманколыйның жырчы да булуын, аның сәхнәгә чыгып көр-яңгыравыклы тавышы белән моңга бирелеп озын көйләрне, бигрәк тә "Ашказар"ны жырлап тыңлаучыларга тирән тәэсир ясавы турында И. Рәмиев "Әдәби сүзлек"тә билгеләп уза. Казан музыка мәктәбе профессоры Р. А. Гуммерт (1861-1922), 1907 елны, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев башкаруыннан алып, "Ашказар" көенең ноталарын язып алып бастыруы да күп нәрсә турында сөйли. С. Рәмиевнең түбән тембрлы матур тавышлы булуы, репертуарында борынгы көйләрнең замандашлары тарафыннан яратылып тыңлануы турында без шул дәвердәге истәлекләргә таянып әйтә алабыз. Г. Тукай, үзенең данлыклы "Милли моңнар" шигырен, жырчы-шагыйрьнең халык жәүһәрләреннән булган "Әллүки"ен тәэсирләнеп тыңлаганнан соң ижат итүе дә безнең өчен кызыклы мәгълүмат. Тагын да бер кызыклы факт: яшь чактан ук көр баритон тавышлы, табигать биргән сәләте белән чын мәгънәсендә профессиональ жырчы булырлык күренекле рәссам, сынчы Бакый ага Урманче гомер буе үзе, дуслары, якыннары өчен жырлаган "Ашказар" жырын шәкерт елларында "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең мөгаллиме булган Вәли Карый исемле кешедән өйрәнеп алган. Бу мөгаллимнең өендә физгармониясе дә булып, бер төркем шәкертләр мәдрәсәдәге укуларыннан соң анда барып төрле жырлар өйрәнә торган булганнар. Үзенең концерт эшчәнлеген бик яшьли башлап, заманының танылган жырчысы булып киткән Әминә Бәхтизинаның да башка жырлар арасында беренче булып өйрәнгән һәм башкарган жырларыннан "Ашказар" жыры була. Безнең көннәргә чаклы килеп житкән И. Адамантов һәм "Билгесез хатын-кыз жырлавы"ндагы граммофон язмаларында "Ашказар"ның булуы жырның заманасында ачык концерт сәхнәсендә дә, күңел ачу урыннары булган кабакларда да популяр булуы турында сөйли. "Волжско-Камская речь" газетасы (N141) 1908 елның 7 мартында Казандагы Яна клубта үткән бер кичә турындагы мәкаләдә рус хатын-кыз жырчыларыннан булган Г. А. Трейтер ханым башкаруында тирән трагизм белән сугарылган "Ашказар"ны, татар халык жыры "Озын көй"не тыңлаучылар тәэсирләнеп кабул итүләре турында язып үтә. Бу кичәдә булган татар зыялылары жырчының онытылып барган милли жырларны шундый ихласлык белән башкарганы өчен үзләренең рәхмәтләрен белдереп ачык хат язалар. Г. А. Трейтер ханымның хезмәтен югары бәяләп, зыялылар бу хатта мөселман хатын-кызларының публика алдында жырламаулары сәбәпле, халык жырларын хатын-кыз тарафыннан шулай искиткеч итеп башкаруын беркайчан да болай ишетергә мөмкин булмавы турында язалар. Имза куючыларның арасында Тукай фамилиясе беренче урында тора. Шулай итеп, гасыр башындагы жырчыларның репертуарында яңгыраган "Ашказар" жыры аерым бер урын алып торган. Бу жырны башкара алу ул чор жырчысының сәләтен дә, әзерлеген дә күрсәтә торган үзенә күрә бер эталон булып калган дип фараз итәргә була.

Татар милли сәхнә-концерт башкару сәнгатенең барлыкка килү чорында хатын-кызлар арасыннан жырчыларның һәм артисткаларның киң публика алдына чыга алуы ул дәвернең бер үзенчәлеге. Демократик караштагы кешеләрнең татар хатын-кызларның хокукларын яклап чыгыш ясаулары безгә мәгълүм. Йөзләрен дә ачарга рөхсәт ителмәгән татар туташларының, ханымнарының сәхнәгә чыгып, кеше алдында жырлап, уйнап үз һөнәрләрен күрсәтеп, сәнгатькә, милләткә булган сүнмәс мәхәббәтләрен чагылдырулары һәм бу юлда төрле киртәләргә очрап, яман каршылыкларны жиңеп чыгулары—боларның барысын да батырлык дип тә, кыюлык дип тә билгеләргә кирәктер. Монда тагын шунысын әйтеп китү дә урынлы булыр. Жыр, музыка, театр сәнгатенең алга киткән чорында бик күп эшне туташлар, яшь ханымнар алып бара. Алар төрле хәйрия кичәләрен, концерт һәм спектакльләр оештыруда катнашалар. Шул чор язучысы, журналист Ш. Әхмәдиев әйтүенчә, бу туташлар, хәйрия кичәләре өчен, "билетларны әүвәлдән ук йөреп сатып бетерәләр".

XX гасыр башында жыр, концерт эшчәнлекләрен алып барган кайбер хатын-

кыз жырчыларнын исемнәре төрле чыганакларда, истәлекләрдә очрый. Безнен көннәргә чаклы билгеләрдән Мәрьям Искәндәрованы искә алырга кирәк. Бу жырчы турында зур булмаган мәгълүматны без И. Рәмиев язмаларында табабыз. Әйтик, автор бу жырчынын Мәкәржә ярминкәсендәге югары класс ресторанннарында жырлавы Казан, Оренбург, Троицк кебек шәһәрләрдә концертлар биреп йөрүе турында яза. И. Рәмиев үзенен истәлекләрендә шулай ук М. Искәндәрованын Петербургтагы Федотова исемле ханымнын курсларындамы, әллә башка бер музыка-жыр мәктәбендәме укыганлыгы турында бер мәгълүматнын күзгә чалынуы турында да әйтеп уза.

"Йолдыз" газетасынын 1914 елдагы бер санында чыккан мәкаләдә жырчыга кыска гына характеристика бирелгән. Зур булмаган бу мәгълүмат безнен өчен бик тә кызыклы. "Искәндәрова ханымнын зыялы татар дөньясында кадере, хөрмәте булмаса да, ул шансонеткалар рәвешендәрәк жырласа да, анын тавышы ярыйсы, хәтта чибәр дә. Әллә нинди нәзек, көмеш тавышлы ул. Жырлаганда анын тавышынын кайбер урыннары бәгъзан өзелеп, ... "үзгәреп" китә. Менә шул үзгәрү, әзем бик матур була. Нечкәртеп жибәргәндә дә күнелле генә чыга. Гомумән, Мәрьям ханымнын тавышын көмеш тавыш дисәк, мөбаләга булмас. Жырларынын сүзләре дә матур гына". М. Искәндәрова башкарган аерым жырларны граммофон ширкәтләре дә яздырып алалар. Бу ханымнын төрле концертларда шагыйрь, шул ук вакытта бик яхшы жырчы да булган С. Рәмиев белән дуэтлар башкаруы да билгеле: мәсәлән, "Жизнәкәй" жыры. Аларны хәтта пластинкаларга да яздырганнар. Бу мәгълүматны безгә Р. Гайнанов калдырган (Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том, 348). Г. Тукайнын С. Рәмиев һәм Д. Мөхәммәдовлар белән бергә, Әстерханнын "Аркадия" исемле жәйге бакчасында М. Искәндәрованын концертын каравы турында без шагыйрьнен "Тормыш һәм ижат елъязмасы"нда укыйбыз. Концерттан сон жырчы Тукай утырган өстәлгә килеп шагыйрь белән таныша, сөйләшә. 1911 елда була бу очрашу.

М. Искәндәрова белән концертлар биреп йөргән Нәфисә Позднякова исемле жырчыны да искә алырга кирәк. "Ул жырчынын да тавышы чибәр, жырлавы музыкальный. Ул ни жырлаганын белеп жырлый. Анын "Кара урман", "Тәскирә"се бар",—дип язды югарыда искә алган "Йолдыз" газетасы. Әйткәндәй, "Тәскирә" жыры XX гасыр башы татар жәмгыятендә кин таралган, популяр жырлардан санала. Бу көй С. Габәшинен "Милли моннар" жыентыгында китерелгән.

М. Искәндәрова һәм Н. Позднякова турында шул ук "Йолдыз"да түбәндәгене укыйбыз: "Бу ике ханым чибәр генә жырчылар, һәйбәтрәк тәрбия, гыйлем алсалар, без бу ханымнар илә, ихтимал, мактана да алыр идек". Жырчыларнын замандашы язган бу сурәтләүләрне безгә кабул итеп алырга һәм аларга кушылырга гына кала. Ә инде Нәфисә Поздняковага килгәндә жырчынын "ПАТЕ" ширкәте чыгарган граммофон тәлинкәсендә "Су өсте" (N 25945) жырынын язмасы сакланган. Н. Позднякованын шулай ук жырчы Фатыйма Моратова (кызганычка каршы, бу башкаручы турында исеменнән башка мәгълүмат очрамады) белән бергә дуэтта жырланылган "Ижбулдин" (N 25946) һәм "Әхмәт-Сафа көе" (N25947) жырлары да тәлинкәгә теркәлгән. Ф. Моратованын ялгыз башкаруындагы "Озын Эрбет"(N 25942) жыры кергән һәм Хадичә Гимбитская исемле ханымнын тавышы теркәлгән N 25944 саны астындагы "Уртада жиләс" көенен граммофон язмалары башка тәлинкәләр белән бергә, шулай ук, Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИ сәнгать бүлеге фондында сакланалар.

Үткән гасыр башындагы хатын-кыз жырчылардан замандашларынын хәтеренә кереп калган тагын да бер жырчы булган. "Идел" газетасы 28 маендагы (557) санында драматург Гаяз Исхакыйнын 1913 елда Казанга килеп китүе турындагы бер мәкаләдә, анын "Шәрекъ" клубындагы бер концертны каравы турында язып чыгара: "...скрипкачы Гали Зайпин әфәнденен милли көйләремезне уйнавы һәм 12 яшьлек Фатыйма туташнын милли жырларымызны жырлавы Гаяз әфәндегә бик охшап, аны шатландырды". Бу яшь туташ, Фатыйма Гомәрова исемле жырчы Казандагы "Шәрекъ" клубы чорларында өметле башкаручы буларак килеп

чыккан. Баштарак төрле кабакларда җырлаган, зур талантлы, матур тавышлы җырчы, соңрак зур уңыш белән ачык концертларда чыгыш ясый башлый. Аның репертуарында татар көйләре генә түгел, рус җырлары да шактый урын алган була. Ләкин шунысы кызганыч, җырчының сәхнәгә бик яшьли чыкканлыгымы, әллә тавышының тиешле дәрәҗәдә тәрбия ителмәвеме, талантының гомере кыска була. Фатыйма туташ соңрак, гомумән, тавышыннан мәхрүм кала.

Уфа шәһәреннән чыккан хатын-кыз җырчылар арасыннан Абруй Сәйфи һәм Әминә Бәхтизиналарның эшчәнлекләре дә безнең игътибарны җәлеп итәләр. Абруй Сәйфи заманасында танылган җырчы булып илебезнең төрле калалары буйлап гастроль чыгышлары белән йөргән. Аның репертуары шул чордагы шәһәр музыкасындагы популяр җырлар белән беррәттән татар, башкорт көйләрен дә үз эченә алган. С. Габәши үзенең "Милли моңнар" җыентыгында Абруй Сәйфи җырлавыннан алынган бер халык җырының ноталарын китерә. Җырчы репертуарындагы бу борынгы матур көй "Ишкәкче карт" дип атала.

Уфа шәһәренең мәдәни мохитеннән чыгып, киләчәктә танылган җырчы булып киткән Әминә Бәхтизинаның иҗат юлы да безнең өчен бик кызыклы. Беренче тапкыр нәни җырчы, шагыйрь Шәехзадә Бабичның мандолина уенына кушылып, Г. Тукай сүзләренә "Зиләйлүк" җырын җырлый. Уфаның приказчиклар клубында 1913 елның октябрь аенда уздырылган әдәби-музыкаль кичәдә 8 яшьлек бу бала үзенең гаҗәеп таланты белән халыкны таң калдыра ("Совет Башкортостаны" газетасы, 1969 ел, 1 март, N 51). Җырчының шулай бик зур сәләтле булуы аның этисе Хәлил абзый гади һөнәрче-бүрекче, шул ук вакытта Уфадагы иң танылган халык музыканты—скрипкачысы булып дан казануы белән дә бәйледер. Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, М. Гафури кебек әдипләр бу музыкантның үздереп-үздереп халык көйләрен уйнавын тыңларга, аның белән аралашырга ашкынганнар. Әминә бала чактан ук халык моңнарын тыңлап, җырлап үсә. Әтисенең уйнавына кушылып җырлаган яшь җырчыны әйтеп узган әдипләр онытылып тыңлаганнар. 10 яшеннән Әминә музыкадан дәресләр дә ала башлый. Варшава консерваториясен тәмамлаган пианист Эдуард Шульц аның укытучысы була.

"ZONEPHONE RECORD" граммофон ширкәте чыгарган тәлинкәләр арасында берничәсе аеруча кызыклы һәм игътибарга лаек. Тәлинкәләрдә җырларның исемнәре язылган, ә башкаручысының кем икәне билгесез. Җырчының исеме урынына "женское соло" (хатын-кыз җырлавы) дип кенә язылган. Җырчыларның шулай билгесез булып калырга тырышуы бер яктан гасыр башындагы дини реакцион көчләрнең һөҗүменнән яшерену чарасы булса, икенче яктан, шәһәр мохитендәге "бозык йортлар"да борынгы кәсеп белән шөгыльләнүче матуррак тавышлы хатын-кызларның, үзләреннән алынган бу язмаларда исемнәрен күрсәтергә теләмичә, билгесез булып калуларына ишарә ясый. Шунысы кызыклы, безнең көннәргә чаклы килеп җиткән кайбер көйләрнең исемнәре әнә шундый хатын-кыз җырчыларның кушаматларын йөртә. С. Габәши үзенең "Татар музыкасы турында" мәкаләсендә бу көйләрне гасыр башында туган яңа җырлар исемлегенә кертә һәм аларны искә алып үтә: "Солтанкай", "Праход Махуб", "Кәнәри", "Дунай". Бу көйләрнең авторлары да әнә шул исемсез хатын-кыз җырчылар булмагае дип тә фараз итәргә була. "Праход Махуб" көенең оркестр тарафыннан башкарылган варианты, X-2-100869 номеры астында граммофон тәлинкәсенә яздырылган бик матур бер озын көй. Ә "Солтанкай" көенең ноталарга теркәлгән вариантлары С. Габәшинең "Милли моңнар" җыентыгында, А. Ключаревның "Татар халык җырлары" китабында (1нче кисәк) бу көй "Мәликә" исеме астында китерелгән, М. Мозаффаровның "Татар халык җырлары" җыентыгында да "Солтанкай" көе теркәлгән. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, югарыда искә алынган тәлинкәләрдәге язмалар менә шул җырчыларның берсеннән алынган булуы бик тә мөмкин. Бу язмалар арасында шәһәр традицияләрендәге кыска җырлардан булган "Әйе шул" җыры (N X103752) үзенең тиз характердагы темпы, куплетларның күп булуы һәм аларның аеруча дәртле итеп башкарылуы, шул чорның "кутеж"—типтереп күңел

ачу—атмосферасы белән сугарылган характеры белән истә кала:

*Акбуз атның яхшысы*
*Ал чәчәкне таптамас,*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Ал чәчәкне таптамас;*
*Җебеп торган егетләрне*
*Бер китап та мактамас,*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Бер китап та мактамас.*

(Тарихи һәм лирик жырлар, 319 б.).

Югарыда китерелгән язмаларның тагын да бер кыйммәте, ул да булса анда яңгыраган жырларда XX гасыр башындагы концерт-башкару практикасына хас булган бер традициянең чагылышы. Кызганыч, бу үзенчәлекле, матур башкару күптән инде кулланыштан төшеп калган. Музыкантлардан Ф. Туишев, жырчылардан Г. Сөләйманова—бу традицияне үзләренең эшчәнлекләрендә соңгылардан булып кулланган шәхесләр. Сүз—бер концерт номеры эчендә озын көйне кыска жыр белән бергә бәйләп башкару турында бара. Ягъни стиле буенча да, эчтәлеге буенча да бер-берсеннән аерылып торган ике жырны үзенчәлекле итеп сюиталы циклга берләштерү. Үткән гасыр башы музыкантлары һәм жырчылары өчен әлеге бәйләп башкару табигый булган әйбер. Мисал өчен М. Мозаффаровның "Татар халык жырлары" жыентыгында әлеге традицияне үз эченә алган ике жырның бәйләнмәсен китерергә була. Ул "Ончы Фәхри һәм Солтанкай" дип атала. Монда "Ончы Фәхри" дип аталган озын көйгә "Солтанкай" жырының такмаклары өстәмә жыр итеп кушылган.

Югарыда искә алынган "Камәр", "Бакиров", "Ашказар", "Сакмар" жырларын "исемсез" жырчы нәкъ шул традиция калыплары эчендә башкарган. Монда бер сорау туа, бу күренеш ничек барлыкка килгән дә, тыңлаучылар тарафыннан бу башкару ничек кабул ителгән соң? Әйтик, "Ашказар" жыры. Тирән эчтәлекле борынгы матур көй. Инструменталь ансамбльгә кушылып жырчы салмак кына аның ике строфасын башкара. Монда бер мөһим әйберне билгеләргә кирәк. Жырчы тавышындагы кайбер кытыршы жирләре, берникадәр корылыгы, жырның схематик рәвештә башкарылуы анда яңгыраган аккомпанимент ягыннан тулыландырыла, төзәтелә, характеры һәм темпының үзенчәлекләре ачыла. Халык музыкантларының скрипкада һәм гармунда яңгыраткан бизәкләре, андагы булган динамика, башкарылган жырныербөтен итәргә ярдәм итә, тыңлаучыны шул чорның музыкаль мохитенә алып керә.Монда шунысы аеруча кызыклы: драматик характердагы жыр тәмамлану белән, бөтенләй икенче характердагы дәртле контраст такмак жырланыла башлый...

Шәһәр көнкүреш музыкасындагы авыз ижаты традицияләренең бер үзенчәлеге шул чорда яңгыраган жырларның күп өлешендә чит интонацияләрне, аһәңнәрне үзләштерү ысулларының төрле формаларда чагылыш табуында. Мондый үзенчәлек жырчыларның репертуарында традицион татар жыр үрнәкләре белән беррәттән рус, украин, Европа халыкларының жыр һәм көйләреңең шактый урын алып торуында күренә. Бу—беренче чиратта XX гасыр башындагы концерт-башкару практикасында үзенчәлекле формаларның барлыкка килүе. Әйтик, рус көйләрен үз "туган телләге" текстлар белән башкару. Бу юнәлештә аеруча К. Мотыйгый һәм Ф. Латыйпов кебек жырчыларның шәһәр рус көнкүреш музыкасындагы киң танылган көйләрне татар текстлары белән яңартып үз репертуарларына кертүләрен күз алдында тотабыз. Мәсәлән, рус халык жырларыннан булган "Дунай, мой Дунай, веселый Дунай" жыры К. Мотыйгый тарафыннан татар сүзләре белән башкарылган. Жырчының "Кисмәк төбе" дип аталган жыры, краковяк көенә татар куплетларын кушып: "Мин жырламый, кем жырласын, эчем тулы ат мае..." дип жырлаганы да билгеле. К. Мотыйгый шулай ук үзенең концертларында рус опералрындагы көйләрне татар сүзләре белән

башкарган. Жырчының М. Глинканың "Руслан һәм Людмила" операсыннан алынган фарсы хорының көен Г. Тукай шигыренә жырлавы мона бер ачык мисал. Х. Йосыпов репертуарында "Тай да тройка" исемле рус жырының булуы да, аның хәтта граммофон тәлинкәсенә яздырылуы да бу күренешнең бер чагылышы. Шулай итеп, милләтара мәдәни йогынты нәтиҗәсендә барлыкка килгән "рус жырлары—татар сүзләре" феномены игътибарга лаек бер күренеш булып кала. Ул чордагы истәлекләргә, басма чыганаклардагы мәгълүматларга таянып шуны әйтергә кирәк: бер яктан, бу "катнаш" ниндидер бер эклектик-көлкеле жанр итеп кабул ителсә, икенче яктан, әйтелгән "катнаш"ның эстрадага, балаганга хас булган эксцентрик образлы булуы, аның заманасы өчен гадәттән тыш популярлыгын да күрсәтә. Замандашларының истәлегенә караганда, шул ук К. Мотыйгыйның халык арасында танылып китүе дә әнә шундый жырларның жырчы репертуарында төп урын алып торуында. Шуның өчендәдер татарлар арасында К. Мотыйгыйны "татар Шаляпины", Ф. Латыйповны "татар Собиновы" дип атаулар да милләтара үзләштерүләрнең бер гомумиләштергән чагылышы булып кала. Совет чорының башлангыч дәверендә бу практика бик каты тәнкыйтьләнсә дә, шунысына басым ясарга кирәк, шәһәрнең төрле катлам татар тыңлаучысы тарафыннан уңай яктан кабул ителгән бу күренешкә, ул чордагы мәдәни янарышларның төрле сыйфатларда чагылуына безнең яктан объектив карашның булуы кирәктер.

Шәһәр музыкасының авыз иҗаты традицияләре кысаларында тагын да бер үзенчәлекле форманың барлыкка килүе рус һәм Европа музыкасындагы интонацияләрне турыдан-туры булмаган үзләштерү принципы белән бәйле. Гасыр башында барлыкка килгән бик күп яңа жырлар традицион татар музыкасына хас булмаган интонацияләр, авазлар белән тулыландырыла, җанландырыла. Бу үзенчәлекле "яңа сулыш"лар татар жырларының яңгыравышын әлегә хәтле билгеле булмаган сыйфатлар белән бизи.

Читтән кергән интонацияләрне үз эченә алган кайбер характерлы жырларны искә алып китәргә кирәк. Алар арасында "Әйе шул", "Мамәтҗан", "Порт-Артур", "Абау, уф Алла", "И ха-ха трепака", "Аллы гөлле гөлчәчәк", "Молдавия", "Әйдә, халыкка хезмәткә" жырлары. "Билгесез" бер хатын-кыз жырчының граммофон язмалары арасындагы шәһәр мохитендә популяр булган "Әйе шул" жыры (N X103752) әнә шул яссылыкта барлыкка килгән көй.

Заманында киң билгеле булган "Порт-Артур" жыры да яңа аһәңнәрне үзләштерү юлы белән иҗат ителгән шәһәр жыры. С. Габәши жыентыгындагы бу жырны анализлаган музыка белгече Г. Макаров көйнең башлангыч өлешендә бәетләргә хас интонацияләр булуын, ә урта өлешендә һәм каденциясендә исә кырым татарлары һәм украин музыкасының тәэсирендә барлыкка килгән интонацияләрнең булуын билгеләде. Шулай итеп, шәһәр татар көнкүреш музыкасы үз дәверенең музыкаль тәэсирләрен үзләштереп, профессиональ концерт-башкару өлкәсендәге алга бару процессына үзенең өлешен кертә.

Концерт-башкару эшчәнлегенең активлашуы, үз чиратында, жырчыларның һәм музыкантларның татарлар яшәгән шәһәрләр һәм төбәкләр буйлап гастрольләр белән йөреп чыгыш ясауларына алып килә. Еш кына бу юлда жырчы артистлар төрле каршылыкларга очрыйлар. Концерт куярга рөхсәт алу мәҗбүри булып, аның өчен жандармериягә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Түземсезлек белән көтеп алынган рөхсәт тә бу оешма тарафыннан куелачак концерт программасына шикләнеп карап, аны тикшереп иләк аша үткәргәннән соң гына бирелә. Куелган концерт та тикшерүчеләрнең игътибарыннан читтә калмый. Гастрольләр белән йөргән татар жырчы һәм музыкантлар өчен каршылыкларның иң авыры, мөгаен, кайсыбер төбәкләрдә, әйтик, Самара шәһәрендә, реакцион милләттәшләр ягыннан артистларның бу эшенә аяк чалулары, куелачак концертларын куйдырмыйча, аларны эзәрлекләп, куркытып шәһәрдән чыгып китәргә мәҗбүр итүләре булгандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, гастроль эшчәнлеге аркасында ил буйлап сибелеп яшәгән һәм моң яраткан татарларга үз милләтенең жыр-музыкасын тыңларга киң мөмкинчелекләр ачыла.

XX гасыр башы җырчылары репертуарларында төп өлешне, әлбәттә, шәһәр көнкүреш лирикасы ала. Мондый җырларның киң халык арасында таралып популяр булуының сәбәбе көйләренең гадилеге, ритмикасының катлаулы булмыйча, җырларның бик тиз хәтердә калуы. Шулай ук гастроль чыгышлары белән йөргән җырчыларның репертуарында әлеге җырларның яңгырап торуы. Янә шул ук җыр һәм көйләрнең бик зур тираж белән граммофон тәлинкәләрендә һәм музыкаль тартмалар өчен эшләнелгән тимер пластинкаларда да таралуы моңа сәбәпче. Ул гына да түгел, җырларның популярлашуы гасыр башында җыр китапларын, җыентыкларны заманасы өчен шактый тираж белән бастырып чыгару эшенең дә уңышлы булуы белән бәйле. 1907 еллардан башлап җырларны сериялэп, бәйләм-бәйләм итеп бастырып чыгару бик керемле коммерциягә әверелә. Башлап Казанда, соңрак Оренбургта басылып чыккан бу җыр бәйләмнәре нинди генә исемнәр астында халык арасында таралмаган: "Шэп җырлар", "Менә диген шэп җырлар", "Төрле-төрле шэп җырлар", "Татлы җырлар", "Хикмәтле җырлар", "Тәмле җырлар" һ. б. Шәрәфләр, Кәримовлар, Хөсәеновләрнең нәшриятлары җыр җыентыкларын, гомум алганда, йөзәрләгән мең тираж белән бастырып сатканнар. Вак товарын тартмага тутырып, авылдан авылга йөреп сатучы "кырык тартмачылар" да, үзләренең вак товарларыннан башка, төрле китапларны таратуда да булышлык күрсәткәннәр. Җыр китаплары да алар тарафыннан күпләп таратылган. Китапчы Кәримовлар һәм Хөсәеновләр үз басма китапларын шундый кырык тартмачылар аша иң караңгы почмакларга, авылларга гына түгел, казакъ даласындагы киез өйләргә чаклы илтеп житкергәннәр (И. Рәми. "Әдәби сүзлек". 155 б.).

Башка житди әдәбият күзлегеннән чыгып караганда бу китаплар, җыентыклар югары таләпләргә җавап биреп бетермәсәләр дә, иң мөһиме шунда: анда урын алган традицион халык җырлары, шәһәр көнкүреш музыкасындагы бик күп популяр һәм яңа җырлар, бөтен ил буйлап таралган татар халкының төрле катлам кешеләре арасындагы музыка, җыр сөючеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндергән.

Югарыда әйтелгәннәрнең барысын да гомумиләштереп шуны әйтергә кирәк. XIX гасыр азагы—XX гасыр башында татар җәмгыятендә барган янарыш чорында, шәһәрнең мәдәни мохитендә профессиональ музыка традицияләренең формалашуы алгы планга чыга. Бу үзгәрешләр тәэсирендә җыр сәнгатендә яңа формалар барлыкка килә. Концерт-башкару эшчәнлеге активлаша, татар музыкантларына һәм җырчыларына ил буйлап гастроль чыгышлары белән йөрергә мөмкинчелек ачыла. Төрле граммофон ширкәтләре татар җырларын һәм көйләрен яздырып чыгара, ә милли нәшриятлар татар җырларын бик күпсанлы китап һәм җыентыклар аша музыка, җыр сөючеләргә тарата. Ул чорның вакытлы басма битләрендә җыр сәнгате өлкәсендәге эшләр даими игътибарда була. Болар барысы да татар милләтенең киләчәктә Европа үрнәгендәге югары профессиональ музыка сәнгате барлыкка килүгә ныклы нигез булып хезмәт итә.

# ИЛ АГАСЫ ӘЛМӘНДӘР

## "Әлмәндәре—Әлдермешнеке, Шәүкәте—безнеке!"

Сәхнә кешеләре турында язу өчен, бәлки, кара-каршы сөйләшеп утыру әлләни кирәкмидер дә. Тормышлары, башкарган хезмәтләре болай да күз алдында бит. Кичләрен йөзләгән халык алар тудырган сихри дөнья белән хозурлану өчен театр залларына жыела. Яраткан артистың уйнаган спектакльләрне карый-карый ул инде туганың кебек якын, дустың кебек кадерле кешегә әйләнә. Урамда очраганда исәнләшәсең, авырып китсә хәлен белешәсең, жай чыкса гәпләшеп утырасың килә башлый. Ул—кеше Шәүкәт ага Биктимеров кебек ил агасы дәрәжәсендәге якташың булса, бигрәк тә. Әңгәмә корунын шул ягы күнелле: әңгәмәдәшең яшерәк кеше икән, аның уй-хыялларына карап сокланасың, өлкәнрәк булса, уйланасың, гыйбрәт аласың. Була шундый сөйләшүләр, нигә язмыш мине бу кеше белән алданрак очраштырмады икән?—дип уфтанып та куясың. Бу юлы да шулай булды. Шәүкәт аганың холык-фигылендә дә, яшәү рәвешендә дә үрнәк булырлык, киләчәк тормышына өлге итеп алырлык сокланырлык яклары бик күп.



Театр-сәхнәне, жыр-биюне яратсалар да, безнең як кешеләре тир түгеп эшләүне, төплерәк хезмәт башкаруны кулайрак күрәләр. Шәүкәт аганың да бала чагы авыр сугыш елларына туры килә. Әтисе Хәсән ага сугышта, үги ана... (Үз әнисе Шәүкәт сабыйны тудыргач та вафат була) 12-13 яшьлек Шәүкәт жәйләрен көтү көтеп, кышларын почта таратып жан асрый. Һәркемдә тамак кайгысы... Кырык ямаулы күлмәген каплаган рухи дөньяңны әле күрмиләр, бик үк күрергә дә теләмиләр... Ни кадәр генә ач, ялангач булса да, Шәүкәт абый бала чагын авырсынып искә алмый. Ул гомумән дә зарлана белми, ахрысы. Язмышка да, дөньяга да, кешеләргә дә бары тик рәхмәтле генә.

**—Шул көтү көткәндә табигатьнең матурлыгын күрергә, табигать белән аралашырга-сөйләшергә өйрәндем. Ул болынлыклар, артыш-әрәмәлекләр—иллә дә матур бит безнең яклар. Әле менә кулымдагы таягымны да Сабай белән Миңгәр арасындагы артышлыктан алган идем,—ди ул таягына күрсәтеп.—Инде зур исемнәргә ирешкәч тә, гаиләм яки кунаклар белән булмаганда Саба белән Миңгәр арасын арыш басулары буйлап гел жәяү кайта идем.**

—Ә кешеләре?

**—Кешеләре дә әйбәт. Адәм балаларында була торган иң яман сыйфат—хөсетлелек безнең як кешеләре өчен ятрак. Мин моны иң авыр чакта—сугыш вакытында ук тойдым. Ә кеше авырлык килгәндә сынала да инде.**

Шулайдыр. Югыйсә, бабасы мулла булган Шәүкәт ага нәселенә теге кара елларның корымы йокмый калмас иде.

Туган якларда Шәүкәт ага турында яратып хәзер дә:

—Әлмәндәре—Әлдермешнеке, Шәүкәте—безнеке!—диләр.

## Кызыл галстуклы пионердан—Әлмәндәргә кадәр

...Бәхетенә дими ни дисең—әтисе сугыштан исән-имин әйләнеп кайта. Элек укытучыларны гел күчереп торганлыктан, Саба районының күп авылларында укыта Хәсән мөгаллим. Шулай ук безнең Сабай авылында да. Ул—минем әниемнең дә

беренче укытучысы. Өлкән кешеләргә хас булганча, хатирәләр янартырга яраткан 85 яшьлек әнием Хәсән аганы әле хәзер дә хәтерли, хөрмәт белән искә ала.

Бик күп балаларга гыйлем биргән Хәсән ага 1945 елны үзенен малае Шәукәтне дә житәкләп Казанга—театр техникумына юл тота. Күпне күргән, күпне кичергән мөгаллим, улынын ни-нәрсәгә сәләтле булуын, бәлки, аз-маз чамалагандыр да. Авыл активлары укытучылар кичләрен спектакльләр куйганда улы анын уйнаганын этисе булганы өчен генә шулай йотлыгып карап утырмыйдыр бит?! Ә авылга театр килгәндә, этисе ягыннан якын туганы күренекле артистка Галимә Ибраһимова кайтканда, анын театр дигән серле дөнья турында кызыклы хәлләр сөйләгәндә юкка гына әсәрләнеп тынламыйдыр. Өстәвенә, әбисе (әнисе ягыннан) күренекле язучы Мөхәммәт Галинен туганы... Баласынын урыны, һичшиксез, зыялы кешеләр арасында булырга тиешлеген сизенгәндер.

**—Техникум дигәне гап-гади урта мәктәп булып чыкты. Коридорда кайда керергә белмичә эзләнеп йөргәндә каршыбызга бер кыз бала очрады. “Рәхим итегез!”—диде ул бер бүлмәнен ишеген ачып. Авылда ишетеп өйрәнмәгән бу сүздән күнелләр күтәрелеп китте, әйтерсен лә мине анда инде көтеп үк торалар. Бүлмәгә килеп кергәндә комиссия членнары жыелышып нәрсәдер сөйләшәләр иде. “Бар, бас, әнә шунда”,—диде берсе. Сәхнә кебек әйбер күренми, мин инде артист кеше биектә торырга тиештер дип уйлап почмакта торган рояль өстенә үрмәли башладым. Чабатам тая гына бит, менәлмим. Ничек кирәк алай менеп басуым булды, берсе (Сәет Булатов) ачулы тавыш белән кычкырып жибәрмәсенме! Коелып төштем. Идәнгә сикереп төшкәнемне сизми дә калдым...**

И самими күнелле авыл баласы! Чебиләп беткән аяклары белән тормышка юл ярганда кайсыбыз гына мондый ихлас хаталарны ясамады икән?! Авылыннан чыгып киткәндә, гомерендә бер тере урыс та күрмәгән килеш, имтихан биргәндә сөйлисе темасын бик яхшы белсә дә, тел байлыгы житмәгәнлектән, кайсыбыз гына гадел булмаган билгегә риза булып, күз яшьләрен түкмәде икән?

Нәрсәләрдер эшләргә кушкач Шәукәт мәсәл укып һәм Г. Камалнын “Беренче театр” комедиясеннән Хәмзә бай булып уйнап күрсәтә. “Булмый, егет, бармый”,—ди икенче ир-ат (Шириязданов Сарымсаков). Шул чакта янындагы хатын-кыз ашыга-ашыга: “Була, була, өмет бар, үземә алам,”—ди. Театрдагы бик күп артистларнын икенче әнкәсенә әйләнгән Кәшифә Тумашева, шулай итеп, Шәукәт Биктимеровнын актерлык язмышын хәл итеп куя.

Шәукәт ага сөйләгәндә уйлап куйдым: әллә, мәрхүмә әнисенен рухы аналар арасында гына була ала торган изге бер анлашу аша Кәшифә Тумашеванын күнеленә улынын зур талант иясе буласын сиздерде микән?

**—Сәхнә кешесендә булырга тиешле төп сыйфатларнын берсе—буй-сын, кыяфәт белән әлләни алдыра алмый идем, жирән чәч, кыска буй. Мәһабәт гәүдәле, чибәр-горур кыяфәтле Айрат Арсланов, Вәкил Закировлар янында мин бала-чага кебек кенә идем. “Карама беләккә—кара йөрәккә”,—дигәндәй, техникумда укыган вакытларда үк күмәк рольләрдә катнаша башладым, ә 1947 елда С. Михалковнын “Кызыл галстук” әсәре буенча куелган спектакльдә Чашкин роле беренче ролем булды дип әйтергә була...**

1949 елда кулында артистлык дипломы булган Ш. Биктимеров Г. Камал театрына эшкә билгеләнә. *Ләкин...* Тормышта очрый торган “ләкин”нәр аны да читләтеп үтми, ул армия хезмәтенә алына һәм үз теләге белән армиядә калырга карар кыла. Ялтырап торган кием-салым, әйбәт хезмәт хакы—инде өйләнеп үк жибәргән егеткә артист акчасы белән әллә кая китеп булмас күк тоела. Әле ярый офицерлар үзләре үк үгетләп аны бу теләгеннән кире кайтаралар.

Армиядән кайтып янадан театрда эшли башлауга ана өч-дүрт көн эчендә И. Абдуллиннын “Бажалар” дигән спектаклендә Гадел ролен бирәләр.

Театр ул чорларда рус һәм европа классиклары әсәрләрен дә еш сәхнәләштерә. Шулардан А. Н. Островскийнын “Талантлар һәм аларга баш иючеләр” драмасында Мелузов, “Сонгы корбан”да *Дульчен*, *Л. Леоновнын* “Ябырылу”да Фаюнин, Ф. Горбатовнын “Бер төн”ендә Кривохатский h. б...

Европа һәм рус классикасына мөрәҗәгать итү актерларның уйнау осталыгын үстерүгә ярдәм итсә дә, милли театрның йөзен беренче чиратта милли әсәрләр билгели. Халыкка Тинчуринның "Зәңгәр шәл"е, Миннуллинның "Әлдермештән Әлмәндәр"е, Ш. Хөсәеновның "Әни килде"се һәм башка үзебезнең драматургларның әсәрләре якын. Ш. Биктимеровка да Х. Вахитның "Беренче мәхәббәт" драмасындагы Тәлгать роле танылуга юл ача.

**—Ул вакытта миңа утыз яшь иде. Ә Тәлгать унҗиде яшьлек егет. Әй яратып уйнадым да соң үзен,**—ди Шәүкәт абый әлеге роле хакында сүз чыккач.

—Озак еллар театрда эшләп тә ачыла, зур уңышларга ирешә алмаган актерлар бар. Алар исә "режиссер вакытында күрмәде, уйныйсы килгән ролемне бирмәде",—дип үпкә белдерәләр...

**—Роль артистны үзе таба ул. Сизгер күңелле актер пьесаны җыелышып укыганда ук бу рольнең кемгә тиешлеген чамалап утыра. Мин исә һәрвакыт икенче кешене дә билгеләгез дип әйтә идем. Дөнья бит, спектакль көнне генә авырып китүең дә бар...**

Иҗат эшчәнлегенең баштагы өлешендә Ш. Биктимеров күпчелек уңай геройларны уйный. Ф. Хөснинең "Бертуган Таһировлар"да—Заһит, И. Айтматовның "Гүзәлем әсәл"ендә Байтимер, Н. Исәнбәтнең "Зифа"сында Алмаз, М. Әмирнең "Тормыш җыры"нда Фәрит һ.б.

Уңай герой образын тудыру, билгеле, рәхәт тә, күңелле дә. Ләкин гел әйбәт булуның да бер начар ягы бар: актер буларак син шушы биеклектә генә калырга да мөмкинсең. Актерның башкару осталыгы күбрәк характерлы рольләрдән чыгып та билгеләнә, ачылырга катлаулы образлар ярдәм итә. Ш. Биктимеровка аерым бер хөрмәт белән караган танылган режиссер М. Сәлимҗанов аңа тискәре рольләрне бирә башлый. Н. Исәнбәтнең "Миркәй белән Айсылу"ында—Дәүли, Ш. Хөсәеновның "Әни килде"сендә Ислам образлары аша Ш. Биктимеров үзен тискәре характерлы геройларны да яхшы итеп уйный алучы актер итеп таныта.

Ә Ш. Маннурның "Муса" романы буенча эшләнгән телеспектакльдәге Муса һәм Т. Миннуллинның "Моңлы бер җыр"ындагы Палач! Никадәр капма-каршылык! Мондый рольләрне башкарып чыгу өчен үз-үзенә нык ышану һәм чын мәгънәсендәге талант иясе булу кирәк шул. Ш. Биктимеровның иҗат эшчәнлегенең үзәнчәлекле ягы тагын шунда да: аңа күп кенә тарихи шәхесләрне иҗат итәргә туры килә. Әлеге рольләр исә эзләнүчәнлек, белем дә таләп итә.

Ш. Биктимеровның һәрбер уйнаган роле аерым бер сөйләшүгә лаек. Тик аларга тукталып бетү мөмкин түгел. Өч йөз роль—өч йөз кеше язмышы, өч йөз холык. Шул ук вакытта аларны читләтеп үтеп тә булмый. Әйтик, үткән гасырның иң бөек фигураларыннан берсе булган Ленин образын (Н. Погодин. "Баһадирлар") ничек әйтми калып була! Бу рольне башкарганда сөйләмендә "р" хәрефен төшереп калдырып, кул хәрәкәтләрең белән "Алга—коммунизмга!"—дип нотык тотуың гына җитми, халыкны әнә шул коммунизмның инде бик якында гына, моның өчен нәрсә эшләргә икәнлегенә ышандыра белергә кирәк. Тамашачы артист белән образ арасындагы аермалыкны сизәргә тиеш түгел. Ул тере Ленинны күргән, аның акыллы сүзләрен үз авызыннан ишеткән сымак булырга тиеш. Талантның көче, сере дә әнә шул ышандыра белүдә бит. Өстәвенә, юлбашчы образы ул чорга хас булганча дәүләт хезмәткәрләре күзәтүе астында. Димәк, синең уйнавың да... Билгеле бер рамкадан читкә чыга алмыйсың.

Мин исә Шәүкәт агадан бу пьеса турында сүз чыккач, ул чакта халык арасында таралган: "Шәүкәт Биктимеровны кыйнаганнар икән..."—дигән сүз турында сорыйсы иттем.

**—Әйе, булды андый хәл. Кич белән спектакльдән кайтканда троллейбуста бер кыз баланы хулиганнардан яклаган идем, артымнан чыгып үземне кыйный башладылар. Минем исә үз гомеремдә бер тапкыр да кешегә сукканым юк, типкәлиләр генә. "Биткә генә сукмагыз",—дим. Ленинның 100 еллыгы, Мәскәүгә гастрольгә китәсе көннәр. Кем әйтмешли, бу йөз хәзер бит инде гади йөз генә түгел, Ленин йөзе дә. "Ни өчен?"—диләр. "Артист кеше мин, Ленинны уйныйм",—дим. "Ах, әле син Ленинны уйнап йөрисеңме",—дип отыры катырак кыйный башладылар. "Алкышлар"ның**

**андыен да күрергә туры килде...**

Инде килеп монарчы ижат иткән рольләрнен берсенә дә охшамаган К. Тинчуринның "Зәңгәр шәл" ендәге Ишан роле... Бу вакытта ана 42 яшь була. 50 яшьтә исә 91 яшьлек Әлмәндәр образын тудыра. Әлмәндәр исә, гади образ гына түгел, дөньяга, кешеләргә бары тик игелек кылыр өчен генә яратылган изге күңелле ил карты, ил агасы.

**—Чын мәгънәсендә мәктәп дип аталырлык зур шәхесләр мәктәбе үттем. Остазларыма рәхмәтлемен. Авыр, әмма бәхетле гомер кичтем...**

...Әйләнә сәхнә, әйләнә... Әнә шул 61 еллык сәхнә әйләнешендә Шәүкәт ага Биктимеров кызыл галстуклы пионердан ил агасы Әлмәндәргәчә юл үтеп Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, Россиянен Станиславский премияләренә, СССРның халык артисты исеменә лаек була.

—Пьесаны укып чыккач та әшне нәрсәдән башлый идегез, Шәүкәт ага?—дим.

**—Беләсезме, нәсел, чыгыш үзенекен иткәндер күрәсең. Текстны кулга алуга башына: "*Лә илләһә илләллаһу Мухәммәдур-расүлуллаһ*" дигән сүзләрнең баш хәрефләрен язып куя идем. Үзем әле театрның партоешма секретаре да бит...**

Ислам диненнән азмы-күпме хәбәрдар кеше дә белә булыр—бу исә иман китерү.

## "Яратам. Кадереңне белермен. Сакламын."

Гади хезмәт иясенекеннән аермалы буларак, ижат кешесенең тормышы күпкә катлаулы. Катлаулылыгы да әнә шул гади, гадәти булмавында. Кемдер хезмәтен тәгәллләп өенә, гаиләсе янына кайтканда сәхнә кешесе, киресенчә, хезмәттә. Ярый ла янәшәндә синен уңышларына сөенә, борчылуларына көенә, аңлый-уртаклаша, ачык йөз белән озатып калып, каршы ала торган кеше булса! Техникум ишеген ачып театр дөньясына кертеп жибәргән кызның шәхси тормышында да бәхет ишеген бергә ачарбыз дип егет белән кыз әле ул вакытта уйлый алдымы икән?

**—Озак вакыт дуслашып йөргәннән соң Рәмзия көннәрдән бер көнне: "Шәүкәт, әйдә, язылышабыз",—дип әйтеп куймасынмы! "Әйдә",—дим. Егет кеше кыз баланың сүзен аяк астына салмас бит инде. Язылышуын языльштык, тик яшәр жир юк. Өстәвенә, минем армия вакыты килеп житте. Мөнәсәбәтләр егет белән кыз югарылыгында калган килеш дүрт ел армия хезмәтен үтеп кайттым. Рәмзия тугры килеш көтте. Без бер-беребезгә биргән вәгъдәләргә гомер буена хыянәт итмәдек. Ул белән кыз үстердек, 50 елдан артык матур гомердә яшәдек...**

Үзенең тормыш юлын актриса булам дип башлаган, инде сәхнәдә Шәүкәт Биктимеров белән бергәләп спектакльләрдә уйнаган Рәмзия Даутова иренең чын мәгънәсендәге сәхнә кешесе икәнен күрү белән театрдан китә, белемен арттыра, башка һөнәргә күчә. Акыллы хатынның зирәк адымы дими ни дисең!

**—Бар да әйбәт иде, юкса. Тормышлар яхшыргач, Рәмзия генә менә бакый дөньяга иртәрәк күчте. Бер дә алай булыр кебек түгел иде...**

—Әллә теге чактагы кебек анда да ишек ачып көтеп торырга уйлады микән, Шәүкәт ага,—дим бераз киеренкелекне йомшартырга теләп.

Пәйгамбәребезнең хәдисендә: "Үзеннән соң тәрбияле балалар калдыру ата-ананың изге бурычы"—диелгән. Балалары тәрбияле булгач Рәмзия апаның Шәүкәте өчен күңеле тынычтыр. Шәүкәт ага үзе дә ялгызлыгыннан зарланмый, үзен ялгыз итеп тоймый. Юкса, Әлмәндәр карт Йөзембикәсе урынына Хәмдебануны табарга теләгәндәй, Рәмзиясе кебек акыллы, сабыр башка берәүне иш итә алыр иде дә...

**—Урамга чыккач карчыклар: "Картайгансың икән инде, Тәлгатьне уйнаганда без сиңа гашыйк идек бит",—диләр,—ә чынлап әйткәндә, мин алай әллә ничә тормыш белән бүгәләнеп яши алмыйм. Яшәү—минем өчен бер бөтен...**

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА.**

# ТАҖЕДДИН ЯЛЧЫГОЛ (1768–1838)

ТУУЫНА—240, ҮЛЕМЕНӘ—170 ЕЛ

Ни сәбәптәндер, тарих безгә рәхимсез булган, бәла-казаларны өеп кенә торган; вакыт агышының һәр мизгеле безне сынаган, имтихан бирү халәтендә тоткан. Мондый вазгыять аеруча XVI гасырдан соң көчәя. Татар халкы, милли дәүләтчелеген югалтканнан соң, аяусыз эзәрлекләүләргә, коточкыч геноцид сәясәтенә дучар ителә. Әмма шуңа да карамастан, ул, гәрчә зур югалтулар белән булса да, үзенең милли асылын, динен, телен, моңын саклап, аларны алдагы буыннарга тапшыра килде. Бу гаять кыен, әмма игелекле эш-гамәлләрнең үзәгендә халкыбызның фидакарь уллары, аеруча зыялылары булды. Алар арасында исеме, эшчәнлеге күпләргә мәгълүм булган Таҗеддин Ялчыгол да үзенә лаеклы урынны алып тора. Аның тормыш юлы шактый катлаулы, сикәлтәле.



Таҗеддин Ялчыгол (Ялчыкол) якынча 1768 елның октябрендә, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Әй һәм Арша елгалары арасындагы Курмаш-елга авылында» дөньяга килә. Галимнәр моны Көньяк Уралга, Башкортстанга нисбәт итәләр. Фәндә Таҗеддин Ялчыголның туган җирен Троицк, Орск төбәкләренә бәйләп карау да бар. Әдип кайвакыт, яшәгән урыннарына мөнәсәбәттә, Башкорди, Оруви, Болгари тәхәллүсләрен дә (кушаматларын да) куллана.

Таҗеддиннең әнисе, туганнары хакында мәгълүматлар хәзергә билгеле түгел. Ул чирек гасырга якын гомер юлын әтисе белән бергә уза. Ялчыгол мулла—тугыз мәртәбә хаҗда булган күренекле рухани. 1776 елда ул углы Таҗеддин белән (мөгаен, Пугач хәрәкәтеннән соңгы эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә) Әстерхан, Дагстан якларына күчеп килә. Биредә аның берничә ел балалар укытуы, руханилык вазифаларын башкаруы мәгълүм. 80 нче еллар башында ата белән угыл Төркиянең Диарбәкер шәһәренә киләләр. Таҗеддин мәдрәсәгә урнаша, әтисе хаҗга китә. Дүрт елдан соң аларның очрашуы, Истанбулда ике еллап яшәве билгеле. Аннан бу гаилә Дагстан якларына китә. Кайбер авторлар Ялчыгол мулланың улы белән берлектә «Жаксай шәһәрендә» «дәрес әйтүен» искәртәләр. Бер елдан соң бу гаилә янә сәфәргә чыга: Мәскәү, Түбән Новгород, Казан... Әмма туган якларына—«Троицк төбәкләренә» кайтырга ниятләгән Ялчыгол мулланың гомер юлы 65нче яшендә Мамадыш тирәләрендәге Кече Сөн авылында өзелә. Улы әтисен җирләгән төбәктә «өч ел дәрес әйтә». Аннан

Зәй буйларына күчеп килә. Анын 1792—1799 елларда Зирекле (Жирекле, Каенлы), 1799—1824 елларда Кызыл Чапчак авылларында яшәве мәгълүм. Гомеренең соңгы 14 елын хәзерге Зәй районы Мәлем (Югары Налим) авылында уздыра, балалар укыта, руханилык вазифаларын башкара, табиблык белән дә шөгыльләнә. Бервакыт ул хәзерге Зәй һәм Түбән Кама шәһәрләре арасындагы Иманлебаш авылына барып чыга. Кинәт авырып, шунда үлә. «Кайда үлсәм—шунда жирләгез» васыятен истә тотып, аны Иманлебаш зыяратына жирлиләр. Кабер ташының искесе дә һәм соңгы елларда куелган янасы да бар. Зәй һәм Түбән Кама төбәкләренең халкы аны олылап «Тажеддин хәзрәт» дип кенә йөртә. Зәй шәһәренең Үзәк мәчете һәм бер урамы бу олуг затның исеме белән аталган.

Гарәп, фарсы һәм төрки телләрен, Шәрык гыйлемнәрен һәм мәдәниятен яхшы белгән, дөнья гизгән Тажеддин Ялчыгол—төрле тармакларда эшләгән энциклопедик табигатьле кеше. Ул халыкны белемле, тәрбияле, динле итүгә үзеннән зур өлеш кертә. Анын китаплар күчерү, шәрехләү белән шөгыльләнүе дә мәгълүм.




Тажеддин Ялчыгол тарих, әдәбият, фәлсәфә, медицина (тыйб), фикъһе (хокук), илаһият һәм кайбер башка тармаклар буенча дистәдән артык китап язган: «Хәдисел-баб», «Кафия...», «Тәнбиһел-гафилин» ( ...«Ваемсызларны искәртү»), «Гыйльме тыйб» һ. б. Болар арасында фән һәм мәдәният өчен аеруча иксе игътибарга лаек. Чөнки алар элек-электән укылып, өйрәнелеп килә.

«Тәварихе Болгария» (1805.—Аны кайчак «Тарихнамәи Болгар» дип тә йөртәләр)—жанры белән шәжәрәи, ягъни нәсел-нәсәбне гәүдәләндергән ядкарь. Анда кеше исемнәре, этнонимнар, тарихи атамалар һ. б. телгә алына. Кыска-кыска сюжетлар да бар. «Тәварихе Болгария»—тарихи, әдәби башлангычларның бер җыелмасы, синтезы. Бу китабы белән автор үз халкының борынгы тарихлы булуын, аның күренекле шәхесләргә, истәлекле вакыйгаларга байлыгын, жир йөзендә башка кавемнәр белән берлектә лаеклы яшәргә хаклы икәнлеген раслый.

Әдипнең икенче күренекле әсәре—чәчмә һәм тезмә юллар белән язылган, зур күләмле «Рисаләи Газизә» ядкаре (1806). Ул тәүге мәртәбә 1847 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан (372 бит). Аннан соң Казанда күп тапкырлар (40 мәртәбәгә якын) дөнья күрә. Кулъязмалары да шактый. Халык яратып укыган. Хәтта мәктәп-мәдрәсәләрдә әсбаб рәвешендә дә кулланылган. «Рисаләи Газизә»нең аерым өлешләре 1998 елда «Иман» нәшриятында дөнья күрде (57 б.). Ә инде тулы басмасы 2001 елда нәшер ителде.

“Рисаләи Газизә”—Урта Азиядә яшәгән, этник чыгышы белән “нугай” (татар) булган атаклы Суфый Аллаярның (1616-1713) “Сөбател-гажизин” (“Көчсезләрнең ныклыгы”) әсәренә (поэмасына) шәрех. Әйтергә кирәк, бу шагыйрь татарлар арасында бик популяр була. Анын әсәрләре кулъязма һәм басма формада халыкта киң тарала, мәктәп мәдрәсәләрдә әсбаб рәвешендә файдаланыла, татар әдәбиятына зур йогынты ясый. Г.Утыз Имәни, Ш.Мәржани, К.Насыйри, Г.Чокрый, М.Акчурина, Г.Рәхим, Г.Газиз һәм кайбер башка авторлар, мәсәлән, “Сөбател-гажизин” әсәрен югары бәялиләр; аның шәрехләре дә бар.

“Рисаләи Газизә” китабының төп өлешен Тажеддин Ялчыгол аңлатмалары, аның чәчмә һәм тезмә юллары тәшкил итә. Әмма алар Суфый Аллаяр шигырьләре белән табигый керешеп, бер идея-сәнгати бөтенлек тудыралар. Менә кадәр үк халык яратып укыган “Сөбател-гажизин” әсәренең китапта тулы чагылышы, Тажеддин Ялчыголның аңа төпле һәм тирән шәрехе “Рисаләи Газизә”нең киң таралышын һәм дәрәжәсен тагын да арттыра.

«Рисаләи Газизә»—әхлакый, фәлсәфи, дини-суфыйчыл карашларның тулы бер

сандыгы, сәнгати энциклопедиясе. Китапта кызыклы гына сюжетлар, мотивлар, шигъри сурәтләр, тарихи, лингвистик аңлатмалар, белешмәләр бар. Арада Тажеддин Ялчыголның тәрҗемәи хәленә мөнәсәбәтле факт-мәгълүматлар да очрый.

Китап гомуминсани рух белән сугарылган. Автор, Мөхәммәдьяр кебек, авыр хәлдә калганнарга ярдәм кулын сузарга чакыра:

*Әгәр мәртәбәң ирер әгълаи афак (күкләргә җитсә дә),*
*Екылган хәстәләрнең халигә бак.*

Әдип үз укучыларын яманлыктан ерак торырга ("Ямандин кач, ямандин кач, ямандин"), кешеләр белән "сары май кеби... мөлаем" булырга, дусларны "сөт өстендә каймак кеби" тотарга өнди. Өмми Кәмал, Колшәриф традицияләрен дәвам итеп, Тажеддин Ялчыгол да нәфескә иярүне, мал-мөлкәткә, хакимияткә чиктән тыш кызыгуны кискен тәнкыйтьли.Аның өчен иң әүвәл инсанның вөҗданлы, намуслы булуы, үз-үзен рухи яктан пакьләве, үз шәхесен танып белүе мөһим ("Аслына бак, аслына, әй җане пакь"; "Кыл эчне халис", ягъни саф...). Тажеддин Ялчыгол гаилә коруны, бала тәрбияләүне һәркем өчен зарури саный. "Пәйгамбәр г.-м әйде ки,—ди ул.—Һәркем хатындан вә балачыкларындан качыб, нәфәка бирмәен (аларны туендырмыйча, тәрбияләмичә" йөрсә, ул кемсәнәнең аслан (чыннан да) кылдыкы гыйбадәте кабул дәгелдер",—диде". Әдип үзе бу яктан үрнәк була. Аның 7 баласы (4 улы, 3 кызы) мәгълүм. Тажеддин Ялчыгол аларны тәрбияли, укыта, кеше итә. Уз китабын кызы хөрмәтенә "Рисаләи Газизә" дип атавы да бик мәгънәле. Әтисе "күзем нуры", "бәгърем парәсе" дип йөрткән Газизәнең кабере Мәлем зыяратында. Еллар узган, ничәмә-ничә буын туфрак булган. Кабер өсләрендә агачлар үскән. Әмма кызын хөрмәтләп язган "Рисаләи Газизә" ядкаре, вакытның агышына, җил-янгырларына бирешмичә, һәйкәл кебек яшәвен дәвам итә. Шунысын да искәртик: олуг нәселдән чыккан Тажеддин Ялчыголның үзеннән соңгы нәсел шәҗәрәсе дә шактый бай, күптармаклы. Анда руханилар, мөгаллимнәр, инженерлар, табибләр, хәтта язучылар һәм генераллар да бар. Мәсәлән, Татарстан Республикасының Эчке эшләр министры генерал-лейтенант Әсгать Сәфәров—әдипнең күпсанлы оныкларыннан берсе.

"Рисаләи Газизә"—әдәбиятны, динне, телне, мәгарифне, гореф-гадәтләрне, гыйлем тарихын тикшерүдә дә мөһим чыганак. Аны үзләштерү әхлаклылыкка, хәтерләр дәвамчанлыгына өйрәтә.

* * *

Тажеддин Ялчыголның тормышы, мирасы, эшчәнлеге әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Кызганыч, әсәрләренең дә бер өлеше генә бүгенге укучыларга мәгълүм. Шулай да соңгы вакытта әдип турында файдалы гына язмалар чыгып тора, аерым әсәрләре дә басыла: Татар әдәбияты тарихы. I том.—К.: Таткитнәшр., 1984.—443-452 б.; Х.Миңнегулов. Тажеддин Ялчыгол һәм аның «Рисаләи Газизә» әсәре / Х.Й.Миңнегулов. Гасырлар өнен тыңлап...—К.: Мәгариф, 2003.—59-90 б; Тажеддин Ялчыгол. Рисаләи Газизә / Әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) һәм кереш мәкалә авторы... Х.Миңнегулов.—К.: Иман, 2001.—480 б. һ.б.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

# Ж, Җ

**ҖАМАНАКЛЫ** (псевд. чын исем-фамилиясе Рәшидов Кәрим Рәшид улы) (21.1.1905, Таврия губ. Кизләү өязе Жаманак а.—1.8.1965, Алабуга ш.), шагыйрь, фольклорчы, әдәбият галиме. Кырым-татар һәм рус телләрендә язды. 1934 елда Симферополь пед. ин-тын тәмамлый. 1941 гә кадәр Бакчасарай шәһәрендә яши. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәҗбүри рәвештә туган ягыннан сөрелүгә дучар була. 1944 тә Сәмәрканд ун-тында укыта, 1945 тән Алабуга пед. ин-тында. Беренче шигырьләре 1924 тә «Яңа дөнья», «Яшь куәт» г—таларында, «Элгәре» ж—лында дөнья күрә. Бакчасарайда басылып чыккан «Азадлыкъ йырлары» (1927), «Балаларга Ленин акъкында» (1939), «Ананынъ йыры» (1940), «Бахытлы халкъынынъ йырлары» (1940) һәм «Достларга» (Ташкент, 1978) шигъри җыентыклар авторы. Кырым-татар фольклорын өйрәнү һәм бастырып чыгару б-н шөгыльләнә. Кырым-татар шагыйрьләре Х.Туктаргази, У.Инчи иҗатларын өйрәнә. Аерым хезмәтләре Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил иҗатларына багышланган.

Әд.: Крымскотатарская энциклопедия. Симферополь, 1993; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

Автор: В.Х.Ганиев.

**«ҖӨМҖӨМӘ СОЛТАН»**, 14 йөз татар әдәбияты ядкаре. Авторы Хисам Кәтиб. Ф.Гаттарның шул ук исемдәге фарсы телендә язылган әсәренә назирә дип фаразлана. Бу дини-дидактик эчтәлекле лироэпик әсәрдә сүз төп геройның авыр язмышы, аның ахирәттә күргән михнәтләре турында бара. Хикәяләү чүлдә Гайсә пәйгамбәр б-н очрашып җанланган, аңа үткән гомере турында сөйләүче баш сөягеннән бара. Җөмҗөмә солтан тиңсез байлыкларга, меңләгән коллар һәм кәнизәкләргә ия була. Фәкыйрьләргә һәм дәрвишләргә карата юмарт булса да, үл үлеп җәһәннәмгә эләгә һәм чиксез газаплар кичерә. Бу хәлне «Җ.С.»ның авторы Җөмҗөмә солтанның Аллаһы Тәгаләгә, аның кодрәтенә ышанмавы б-н аңлата. Ләкин Аллаһы Тәгалә әмере б-н ул үзенең иске кыяфәтендә яңадан терелә, ислам кабул итә һәм калган гомерен намаз укуда һәм тәүбә кылуда уздыра. Әсәрнең 30га якын кулъязма нөсхәсе сакланган, алар Казан, С.-Петербург, Ташкент, Париж архив һәм китапханәләрендә саклана. 1872 елдан алып «Җ.С.» Казанда берничә тапкыр басылып чыга. Әсәрне өйрәнүгә Җ.Алмазов, Х.Госман, Г.Таһирҗанов, Х.Курбатов, Р.Исламов һ.б. үз өлешен кертте. 1881 дә М.Юмачиков әсәрне татар вариантыннан казакъ теленә тәрҗемә итте (барысы 10 басмасы чыкты).

Әд.: Жуковский В. Джумджума-наме. Легенда об Иисусе и черепе в персидском стихотворном сказе Аттара // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т.7; Исламов Р.Ф. Письменный памятник татарской литературы XIV в. «Джумджума султан» // Катановские чтения: Сб. статей. К., 1998; Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. К., 1981; Әхмәтҗанов М. «Җөмҗөмә дастаны» тәрҗемәсе // Әдәби мирас. К., 1996. 3 кит.; Хөсәм Кятиб. Җөмҗөмә солтан. К., 2000.

Автор: А.М.Ахунов.

**ЖУРАВЛЁВ** Тихон Кононович (13.8.1913, хәзерге Воронеж өлкәсенең Лискин р-ны Залужное а.—24.1.1985, Казан), язучы. 1937—46 елларда Мәскәү хәрби округы «Красный воин» («Кызыл сугышчы») г—тасында, «На разгром врага» («Дошманны тар-мар итәргә»), «Суворовец» («Суворовчы»), «На страже Родины» («Ватан сагында») фронт г—таларында эшли. 1949 дан Казанда яши. Сугыш, патриотизм язучының гомере буена төп темалары булды: «Рядовой Антипов» (1950) повесте, «Сугыш турында хикәяләр» («Рассказы о войне», 1958), «Плацдарм» (1960), «Солдат турында сүз» («Слово о солдате», 1962), «Батырлык» («Подвиг», 1963), «Хәрби повестьлар» («Военные повести», 1972) хикәя һәм повестьләр җыентыклары, «Сугыш булды» («Была война», 1961) новеллалар җыентыгы. «Комбайнерлар» («Комбайнеры», 1954) повесте, «Курган» (1955), романы, «Авыл өстендә йолдызлар» («Звёзды над селом», 1966), «Авыл повестьлары» («Сельские повести», 1980) повесть җыентыкларына кергән әсәрләр авыл тормышыннан алып язылган. Ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б—н бүләкләнә.

Әд.: Шкерин М. Военные повести Тихона Журавлёва // Красная звезда.

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

1958. 15 июля; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЖИҺАНГИРОВА** Шәмсия Гатуф кызы (28.2.1951, Мөслим р-ны Баек ав. туа), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1981-88 елларда Татарстан китап нәшриятында корректор, соңрак мөхәррир булып эшли. 1988-92 дә ТР Мәдәният министрлыгының Республика фәнни-методик үзәгендә бүлек мөдире. 1992 дән "Татарстан" ДТРК сендә: мөхәррир, музыкаль тапшыруларны алып баручы. "Төсле моң" (1985), "Балачак кая китә?" (1989), "Ни өчендер безнең язмыш шундый" (1996), "Жирсу" (2001) шигырь жыентыклары авторы. Шигырьләре нечкә лиризм, гражданлык пафосы белән сугарылган. "Яшел гармун" повестында әдәп-әхлак проблемаларын күтәрә. Композиторлар Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари, И.Дәүләтшин, А.Монасыйпов, З.Хәйретдинов белән бергә иҗат иткән жырлары халык арасында популярлашты.

Әд.: Рәшит Ә. Кояш нуры тамган шигырьләр // Мирас. 1997. №3; Әюп Х. Якты моңнар иясе // Казан утлары. 2001. №2.

*Г.М.Габделхакова.*

# З

**ЗАБОТИН** Иван Петрович (9.10.1908, С.-Петербург — 17.3.1955, Казан), язучы. Казанда 1919 елдан. Казан урман—техника ин—тын тәмамлый (1930). Күперләр, плотиналар, сәнәгать объектлары төзелешендә эшли, Казан шәһәр депутатлар советының төзелеш бүлеген житәкли, Бөек Ватан сугышы елларында оборона предприятиеләрендә хезмәт итә. 1947—55 елларда Татарстан Язучылары берлегендә рус язучылары секциясен житәкли. 1950 елларда беренче әсәрләре басылып чыга башлый. Балалар өчен язылган «Безнең балалар бакчасы» («Наш детский сад», 1952), «Бөркет кыйссасы» («Сказание об орлах», 1953), «Тиздән мәктәпкә» («Скоро в школу», 1958) хикәяләр жыентыклары авторы. «Лобачевский» (1953) романы авторны укучыга таныта. Рус теленә М.Гафуринең «Без бәләкәй чакларда» («В далёком детстве», 1948) хикәяләр жыентыгын, А.Әхмәтнең «Үги кыз» («Падчерица», 1948) һәм «Серләр» («Тайны», 1948) пьесаларын, М.Әмирнең «Миңлекамал» («Минникамал») пьесасын, Ш.Камалның «Хикәяләр» («Рассказы», 1952) жыентыгын, «Акчарлаклар» («Чайки», 1952) повестен һ.б. тәрҗемә итте.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЗАКИРОВ** Исхак Кадыйр улы (14.9.1911, Казан - 14.7.1944), шагыйрь. Казан. финанс.-эконом. ин-тын тәмамлый (1934). 1941 елга кадәр Татар. китап нәшриятында, ТАССРның Язучылар берлегендә эшли. Беренче, патриотизм һәм интернационализм б-н сугарылган, шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1930 елларда күренә башлый. Бөек Ватан сугышы елларында фронт г-таларында, "Совет әдәбияты" ж-лы битләрендә басыла. Аның шигырьләре "Татар поэзиясе антологиясе"нә (1956), "Жыр һаман яңгырый" (1956), "Алар сафта" (1961), "Утлы еллар поэзиясе" (1972) коллектив жыентыкларга кергән. Бөек Ватан сугышында катнашып, Витебск ш. тирәсендә барган сугышта һәлак була.

Әдәб.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЗАКИРОВ** Локман Фатыйх улы (19.2.1928, Мамадыш р-ны Түбән Ушма ав. туа), язучы. Рус телендә яза. Киев гражданлык авиациясе инженерлары ин-тын тәмамлый (1967). 1952-69 елларда Сов. армиясенең авиация частьләрендә офицер булып хезмәт итә. 1970-80 дә Татарстан Минжилкомхозында, 1980-95 тә Сәламәтлек саклау министрлыгында инженер булып эшли. "Абитуриенты" ("Абитуриентлар", 1993), "Вынужденная посадка" ("Самолетны мәжбүри утырту", 1995), "Лётная книжка" ("Очучылар китабы", 1995), "Мустафа" ("Мостафа", 1995) повестьлары, "Гнездо кукушки" ("Күке оясы", 2003) публицистик мәкаләләр жыентыгы авторы.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Кәрия–Зәкәрия–каммая...

Авылда ир затыннан булган кешеләр күзгә күренеп азайды. Бөтен эштә, һәммә төштә инде хатын-кызлар командирлык итә иде. Хәтта ашын ашаган, яшен яшәгән карт абзыйлар да килен-киленчәкләренә, кыз-кыркыннарына буйсынырга мәҗбүр булды. Нишлисең бит, ирләр кимесә, ирдәүкәләр арта—табигать кануны! Әле кайчан гына курчак кебек ясанып, иннек-кершән ягып фырт-фырт йөргән кызыкайлар, телогрейкалар, бүрекләр, олтанлы итекләр киеп алгач, ир-атлардан да уздырып эре-эре атлап, алпан-тилпән килеп йөри башладылар.

Ләкин тормыш барыбер сүнмәгән иде әле. Егет-җилән сугышка китеп беткәч, борыннарына кызлар исе керә башлаган яшь-җилкенчәк бу бушлыкны тутырырга ашыкты. Кайберләре, ут күрмәгән ут күрсә көндез чыра яндырыр, дигәндәй, бөтенләй мәнсезләнеп, олы-олы апаларына йомры-йомры сүзләр дә әйтә, хәтта аларның куеннарына кул тыгарга да җөрьәт итә башладылар. Оят белү дигән нәрсә кайда—җүнсезрәкләре хәтта урам буйлап:

*Ал бәйлиләр, гөл бәйлиләр*
*Үгез мөгезләренә;*
*Унҗидедән узган кызлар*
*Ферма үгезләренә,—*

дип җырлап йөрүне дә егетлеккә саный иде.

Көннәрдән бер көнне әнинең күпмедер вакытлар Кызыл Орда шәһәрендә көн иткән сеңелесе Мәсрүрҗиһан апа кайтып төште. Аны, сугышның иң кызган чагында Зөя станциясе белән Ульяновск арасында тимер юл төзү өчен "трудармиягә" алганнар да, ул шунда бик каты авырып китеп, безнең авылга, әни янына сыенырга мәҗбүр иде. Ләкин яшьлек тора-бара үзенекен итте—апа, ниһаять, савыкты. Авыл кызлары белән дә бик тиз уртак тел тапты, күрәсең, аның матур итеп җырлавы һәм иң мөһиме—авыл җирендә гомергә булмаганны!—гармун уйнавы әсир иткәндер. Кызларның аулак өйләргә, кичке уеннарга җыелулары авыр сугыш чоры булса да, тукталып тормады. Боек күңелләрне аз-маз юатыйк әле диптер инде, кызлар бер-берләренә карый-карый моңаешып җыр сузалар. Аннан, урыннарыннан җәһәт кенә сикерешеп торалар да, суына башлаган өй җылынмасмы дигәндәй, тыпыр-тыпыр бии башлыйлар, "алтылы" әйләнәләр, "йөзек салыш"тан ярышалар, кулга-кул тотынышып әйлән-бәйлән уйныйлар. Уйларында да, телләрендә дә—моң белән сагыш кына.

*Мәк чәчәкләре коела*
*Былбыл кагынган саен;*
*Мәк чәчәкләренә карыйм*
*Сине сагынган саен.*

---

*Дәвамы. Башы журналның 8, 9 саннарында.*

*Кәрия-Зәкәрия-каммая,*
*Кәрия-Зәкәрия-каммая*
*Кәри кемгә, Зәкәр кемгә,*
*Зәкәрия-каммая.*

Ул Кәринең дә, Зәкәриянең дә кем икәнлекләрен белмим инде белүен, әмма кызларның култыкка-култык тотынышып зыр-зыр әйләнүләре минә иллә дә ошый. "Мине дә алып бар инде",—дип кат-кат ялынам апага ул матур киемнәрен кия башлаган саен. Ул, бераз икеләнеп тора да, мине житәкләп ала. Апа андый аулакларга мине гел-гел ияртеп йөрде. Әй аның җырлаулары!.. Соңрак кына белдем—тавышы нәкъ җырчы Зифа Басыйрованыкы шикелле аның. Гармунга ул абыйсыннан—Гыйлажетдин абыйдан өйрәнгән иде. Мин генә ул, гомер буе хыялланcам да, әллә нинди мөмкинлекләрем булса да, ул һөнәрне тәки үзләштерә алмадым.

Кайбер яшьләрнең яшь кызлар янында тәрбиясез кыланулары гына эчен пошыра иде апаның. Хәтерлим әле, ничектер, авыл яшьләренә ияргә тырышып, бер заман мин дә иртән урыннан кузгалырга иренеп:

*Карурманга кереп булмый,*
*Шомырт чәчәк атмыйча;*
*Яшь кызларны танып булмый,*
*Бер кочаклап ятмыйча,—*

дип җыр шыншый башлаган идем, өстемә апа кулындагы тукмак килеп төште. Аннан ул:

—Оятсыз... Кайдан өйрәндең шундый әшәке җырны?—дип мине орыша башлады. Ә болай бик якын күрә идем мин апаны, мин йоклаганда китеп бармасын тагын дип, ул ябынган юрганны астыма кыстырып ята торган булдым. Ә апа барыбер китте, шул үзе яшәгән Кызыл Ордага китте. Әни, уган бәрәңгегә барлы-юклы он катыштырып, берничә икмәк пешерде дә, аны яңа гына ачылган Буа станциясенә озатып куйды. Аннан инде мин апаны озак еллар кабаттан күрә алмадым.

Тормышлар елдан ел авырлаша барды. Икмәк безнең өйдә сирәк сыйга әйләнде. Кышларын инде без кемнәргәдер өйдәш булып үткәрә идек. Көне-төне колхоз эшендә чиләнгән әнинең дә сәламәтлеге нык какшады. Сугышның соңгы елында ул бөтенләй бетереште. Өйдә инде он-мазар гына түгел, бәрәнге дә бетте. Әни, язгы пычракларны ера-ера, узган ел урылмый калган басулардан башаклар җыеп кайта да, шуларны киптереп, күршедәге Кәлимулла абыйларның кул тегермәне аркылы чыгара иде. Җир кипшенә төшкәч, бакчалардан черек бәрәнге җыеп, шуннан "кәтергиләр" пешерә башлады. Алабута, кычыткан, каз тәпие, кузгалак ишеләр ул чакларда, мөгаен, деликатеслардан саналгандыр. Ләкин алары да житәрлек түгел иде шул. Ачлык бик күпләрнең бугазыннан кысып тотты—авылдагы һәр ике гаиләнең берсенә үлем куркынычы яный иде. Берәр баерак малайның кулларына ипи кисәге күтәреп, мактанып йөрүләрен күрсәк, и өзгәләнә иде инде күңелләр!

*Ә бер көнне әни дәшеп алды,*
*Йомшак кына әйтте, җай гына:*
*—Әллә, улым, барып кайтасыңмы*
*Соранырга чуваш авылына.*
*Анда, улым, сине кем дә белми,*
*Кем булса да, үртәп торамы?*
*Әнә мулла бабаң карчыгы да*
*Йорттан йортка йөри сораныр,*
*Шулчак үксеп елап җибәрдем мин—*
*Кимсенүле иде күңелем.*
*Куз яшьләрем борчак-борчак булып*
*Әни итәгенә түгелде.*
*Ачуланмый гына башым сыйпап:*
*—Йә, елама,—диде,—туз генә...*

*Ничек тә бер Ходай бирер әле...*
*Елый иде әни үзе дә.*

Безнең әни горур да иде бит әле. Житеш гаиләдә туып үскән. Берәр гозере төшсә, күрше Норлатка, бабайның энесе Низаметдин абыйларга баргалый иде. Ут алырга исә күрше Әминә абтыйларга чүмеч тотып мин чаба идем—урыннары җәннәттә булсын—бервакытта кире бормадылар. Аннан... кешедән дә гел-гел генә сорап булмый. Кулга тотарлык киемнәре генә түгел, әвеслектә тезелеп торган сайгаклар да хәлле кешеләр милкенә күчте. Колхоздан бер грамм икмәк бирмиләр иде бит. Китапларда һәм кинофильмнарда гына ул авыл тормышы ал да гөл булып күрсәтелде. Иң аянычы шул: бу ачлык-ялангачлыкларны көн саен үз җилкәбездә татысак та, сабыйларча, без бәхетле илдә яшибез дип ихлас күңелдән ышана идек. Рәхәт яшәүчеләр булгандыр анысы. Әнә, сугыш башлангач, башкаладан качкан кайбер кешеләр "Мәскәү паегы" дигән нәрсә алалар иде. Алар шырпыга да, тозга да, керосинга да, азык-төлеккә дә аптырамадылар. Ә ниндидер юллар белән ашлыгын, бәрәңгесен таба алган хәлле кешеләр, кемгәдер ярдәм иткән булып, кием-салымлы да, каралты-куралы да, урыс капкалы һәм рәшәткәле дә, хәтта тегү машиналы яки велосипедлы да булып алдылар.

Мин инде беренче класска укырга кергәндә, мәктәпкә әтидән калган хром итекләрне киеп, байларча кыяфәттә барырмын дигән идем. Кая ул! Хром итек түгел, кулга тотардай башка нәрсәләр дә тү-тү итте. Яланаяк тәпиләргә туры килде. Аннан башмактыр, чабатадыр өстерәдем.

Укуын яхшы укыдым мин. "А" классында укучыларның безне—"Б"дагыларны "яртынчы класс" дип үртәүләре генә гарьләндерә иде. Укытучыбыз да җиде класс кына тәмамлаган, Кайбыч кызы Галия апа булды. Ләкин ана карап тормышта беребез дә төшеп калмадык. Безгә хәреф таныткан, саннарны кушарга, алырга, тапкырларга һәм бүләргә өйрәткән ул чибәр апабыз бер ел буе безнең белән чиләнде дә, кире туган авылына, Кайбычына китеп барды. Анда ничәдер ел звеньевой булып эшләп, бодайдан югары уныш алган өчен районда беренчеләрдән булып ниндидер орденга да лаек булды. "А" классындагыларның борынына менә шулай да чиерттек без...

Шәхсән минем үземә ул гомер буе сагынырлык кадерле шәхес булып калды. Иң беренче булып авыл сәхнәсеннән мина шигырь сөйләткән кеше дә шул—Галия апа иде...

Ниндидер урысча шигырь иде ул. Ничек аталганын да, авторы кем икәне дә истә калмаган. Тик:

*Машины грохочут,*
*Машины рычат,—*

дигән ике юлы гына хәтердә сакланган. Ятладым мин ул шигырьне, үзем дулкынланудан дер-дер киләм—халык алдына беренче чыгу бит. Ул вакытта Париж Коммунасы көнен дә зур тантана белән бәйрәм итәләр иде бит. Шул мөһим вакыйгага бәйләнгән иде безнең кичәбез дә. Әни юата:

—Сәхнәгә чыккач та, атаң кебек тамак кырып куй, кычкырып, ачык итеп сөйлә, курыкма, ди.

Әтинең бер сыйфатын шулай үзләштердем. Ә шигырь мәсьәләсендә... Ярар, анысын соңрак сөйләрмен. Кайбер хикмәтләре турында аз-маз әйтеп үттем дә бит инде.

## Үзәк... чыннан да өзелә икән ул...

Әни ташулар киткән чакта ук авырый башлаган иде инде. Әмма авырганын безгә—балаларына да, чит-ятка да сиздермәскә тырышты. Сабыр иде ул, горур иде—башкаларга сер бирәсе килмәгәндер. Минем инде башка уй төшә башлаган чак. Май ахырлары иде бугай. Әни эштән бик-бик арып кайткан иде. Өйгә кергәч ашап-эчеп тә тормады (хәер, ашарга берәр нәрсә булды микән?!), "Иртәгә тора алмам инде..."—диде дә түшәккә ауды. Сулыш алганы да сизелми. Минем башка әллә нинди куркыныч уйлар килә башлады. "Әни!", "Әни!" дип дәшеп тә карыйм. Ә ул кыймылдамый да. Инде әнисез дә калдык микәнни?! Күземнән ачы яшьләр атылып

чыга. Мин елый-елый туктаусыз "Әни!", "Әни!", "Әни!" дип аны җилтерәтәм, күз яшем битенә төшеп аны уяттымы, ул шул чакны гына ыңгыраша-ыңгыраша торып утырды. Аннан мине кочаклап кабаттан түшәккә ауды. Мин дә, тынычланып, әнинең исән булуына сөенеп, аның назлы куенында изрәп йокыга киттем.

Авыр булса да, бакчаны да, ындыр өлешен дә казып, бәрәңге утырттык ул елны. Әнинең авыруы көчәйгәннән көчәя барды. Житмәсә Буадан симәнә алып кайтканда, Норлат белән Чәчкап арасындагы урта чокырда ташу суына да эләккән, анда бөтен өсте-башы чыланып нык кына салкын да тидергән иде. Авыл карчыкларының өшкерүе дә, кемнендер кинәше белән, табада суалчаннар кыздырып, шуна озак кына аякларын куеп утыру да ярдәм итмәде. Ничек кенә теләмәсә дә, Буа шифаханәсенә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Әни башта кулга тотардай әйберләрне: самоварны, табак-савытны да, әбидән мирас булып калган, ул үзе суккан җәймәләрне дә, затлы киемнәрен дә Норлатка, бабайның энесе Низаметдин абыйларга илтеп куйды. Сенелем Фәүзия дә алар тәрбиясенә күчте. Авылда әти салган зур йортны саклап мин берүзем калдым. Берүзем дигәч тә... мина күз-колак булырдай, ашатып-эчертеп торырдай безгә кардәш тиешле Габсаттар абый белән аның күптән инде мөселманлыкны алган хатыны Фатыйма абтый (чын исеме ничек булгандыр инде—анысын белмим!)—карамагына күчтем. Үз балалары Габделнасыйр абыйның үле хәбәре килгәч, мин, күрәсең, бу карт белән карчык өчен ниндидер бер юаныч булып калганмындыр—бервакытта да, хәтта кайбер тәртипсезлекләрем булганда да, рәнҗетмиләр иде алар мине.

Әни шифаханәдә озак, бик озак ятты. Ул елларда кеше кайгысымыни?! Әтинең бер туганы Каюм абый сугыштан кайткач кына, аны Буадан алып кайтырга мөмкин булды. Ләкин әни барыбер аякка басар хәлдә түгел иде. Берәр атнадан, күрше-күлән, туган-тумача майдыр, балдыр, тавык шулпасыдыр китерә башлагач, йөзенә алсулык та куна башлаган иде югыйсә. Мин дә, кешеләр сорашканда, әни, Аллага шөкер, терелеп килә, дип сөенеп хәбәр итә, ул гынамы әле, һичшиксез, аның аякка басачагына, ниһаять, матур итеп яши башлаячагыбызга ихлас күңелдән ышана идем. Ләкин...

Көннәрдән бер көнне (гомердә онытасым юк—каһәр суккан 25 август таңы иде ул!) мине сак кына уяттылар да, елый-елый: "Әниең үлде шул инде",—дип коточкыч хәбәр әйттеләр. Әй, шул мизгелдә җанымның ничек телгәләнгәнен белсәгез?! Үзәк өзелү дигән халәт шулай буладыр инде ул. Каядыр тирән упкынга төшеп киттеммени?! Бу ачы хәбәрне Каюм абыйларга әйтергә барган идем—тавышым чыкмады—күз яшьләремнән аңладылар. Яшьтәшләрем белән "Җеназага барыгыз!.." дип бер урамнан икенчесенә сөрән салып йөргәндә, мием тәмам түңгән, зиһенем фани дөньядан аерылган, үзем бернәрсә дә аңламый башлаган идем. Шулай итеп сенелем белән мин бөтенләй ятим калдык һәм... абыйның дүрт баласы өстенә ике артык кашык булып өстәлдек. Фәүзия, балалыгы беләнме, минем кебек өзгәләнмәде бугай, абый белән җиңәчигә бик җинел генә "әти", "әни" дип йөри башлады. Башыбызга нинди бәла төшкәнне, нинди фаҗигагә юлыкканыбызны ул соңрак, үзен бу гаугалы гаиләдә күгәрченнәр арасында ике чәүкә булып яшәүнең беренче ачы сабакларын татый башлагач кына аңлагандыр. Тамактан бик аермасалар да, чит идек без аларга, чит идек. Бар низаглар, кычкырышулар еш кына безнең аркада килеп чыга иде—бу ызгыш-талашлар сугыштан соңгы авыр елларның матди чагылышы да булгандыр. Югыйсә без ятимнәргә колхоз сөтен, икмәген дә биргәли, "Америка ярдәме" буларак ераклардан килгән кием-салымнан да өлеш чыгара, районның социаль тәэминат бүлегеннән килеп хәлебезне белеп, безне карау, тәрбияләү абыйга авырга туры килсә, балалар йортына урнаштырырга мөмкин икәнне искә төшереп торалар. Әмма абыйның карары нык: "Үзебезнең сөяк үзебездән авыр түгел" дип тәмле генә сөйләшә дә, район үзәгеннән килгән Мөршидә апа Курамшинаны кире борып җибәрә. Үз балаларыннан аермаска, безне ятимлек ачысыннан араларга тырыша. Ә менә җиңәчи... Юк-бар сылтау табып безгә бәйләнергә генә тора. Бигрәк тә сенелгә эләгә. Без мондый ызгыш-талашка өйрәнгәнмени?! Фәүзия дә, мин дә яшьләр тулы күзләр белән шулай да була микәнни, дип гаҗәпләнеп, мөлдерәп карыйбыз да, чарасызлыктан гаҗиз булабыз. Әле ул гынамы—абыйның мич яга-яга тын гына елап утырганы бүгенгәчә хәтеремнән чыкмый минем. "Әхмәт энем,—диде ул көннәрдән бер көнне.—Мин кая булса да китәрмен инде... Бәрәңгегез үз йортыгыз

артында, базда. Казып алырсыз..." Мин гомумән ир кеше елаганга тыныч кына карый алмыйм—ул мина гайре табигый булып күренә. Абыйның, ап-ак абыйның шулай елап утыруы гаҗәпләндергән, бик гаҗәпләндергән иде мине.

Китәм, дисә дә, авылдан китмәде абый. Хәер, ул елларны колхоз тәртәләре арасыннан ычкыну мөмкин дә түгел иде. Аның туксан тугыз һөнәр белүе, бервакытта да бер эштән дә чирканмавы, авыл түрәләре белән дә уртак тел таба алуы ана бик күп көнкүреш кыенлыкларын җиңәргә, тормышларны аз-азлап җайга салырга ярдәм итә иде. Кирәк икән, әти кебек үк шигырен чыгара, кирәк икән, берәр гыйбрәтле кыйсса сөйли—авылдашларны бик оста итеп авызына карата белә иде ул. Ә йокларга яткач, ул безгә кызык-кызык әкиятләр сөйли. "Бабагыз сөйли иде",—дип башлый да, без нәвем базарына киткәнче әллә нинди әкияти дөньяларда сәяхәт иттереп кайта иде.

1945 елда кышка керер алдыннан авылыбызга халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю өчен Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Халидә Гатина дигән кешеләр килде. Андый чакта абыйны читтә калдыралармы соң?! Без, малайлар, бу язучы абыйларга сүз кушарга да кыймыйбыз—алар яныннан үтеп киткәндә, башыбыздан бүрекләрне салып, ояла-ояла: "Исәнмесез?"—дип дәшәбез дә, шундый зур кешеләр белән очрашуга сөенеп өйләргә таралышабыз. Ул вакытта кайчан да булса Гомәр абый белән дә, Хәмит абый белән дә, Халидә апа белән дә якыннан аралашып яшәячәгем ике ятып бер төшемә керми әле. Абый исә көн саен алар белән була, әкият тә сөйли, бәет тә әйтә. Сонрак аның бер әкияте сайланып 12 томлык "Татар халык иҗаты" китабының татарча һәм урысча басмаларына да керде. Мин малайчакта ишеткән "Кәтән Иваныч" 30 елдан соң әллә ничә "Әкиятләр" китабында дөнья күрде.

Һөнәрләре күп иде Каюм абыйның. Итек басарга, тире иләргә, ярма ярырга, сугыштан соң авылда балаларны интектергән төрле хәтәр шешләрне дәваларга, мич чыгарырга, кәрҗин үрергә, безнең өчен саламнан кызыклы итеп биюче курчаклар һәм канатын киң итеп җәйгән кошлар ясарга, тагын әллә ниләр эшләргә оста иде. Фронтта ул утка-суга кермәгән, бары бик оста повар-пешекче генә булган. Кемнәргә диген әле. Өлкән офицерларга. Авыл халкы умач, токмач һәм чумара белән әвәрә килгәндә, ул үзе үк әмәлләгән примуста борщ, щи, рассольник кебек ят ризыклар пешерә, шулар белән еш кына авыл түрәләрен дә сыйлый һәм, әлбәттә форсаттан файдаланып аларга берәр гозерен дә җиткерә иде. Казларны ул елның елында 4-5 баш асрады—кышка таба чормага 35-40 түшкә эленеп торыр иде. Шуна күрә микән ана "Ата каз" дигән кушамат та тактылар. Аннан тагын "Мичурин" дип тә йөртәләр иде әле. Яна Чәчкап авылы халкы яшелчәгә, җиләк-җимешкә нишләп шулкадәр битараф булгандыр инде—суган да утыртмыйлар иде бит. Ә абыйның бөтенесе бар—суганы, сарымсагы, кыяры, помидоры, кишере, шалканы, редискасы, кәбестәсе!.. Хәтта соныннан тирес өеме өстендә кавын-карбыз үстерергә дә һәвәсләнеп китте ул. Эше күп инде күбен. Суны кул арбасына 20 чиләк сыешлы мичкә куеп, елгадан өчәүләп-дүртәүләп җигелеп ташыйбыз. Иртәнгене ашар алдыннан абый бөтенебезне бакчага чүп утарга куып чыгара, берәр сәгать эшләп алыгыз, физзарядка булыр, аппетитыгыз ачылыр, ди. Аппетит болай да һәрвакыт ачык инде безнең. Яшелчә барын бар, тик менә ипи дигән нәрсәне генә сирәк күрәбез. Инде алда әйткәнемчә, бартер юлы гына кала: без малайларга—тансык булган кишер, кыяр, суган, ә алар безгә—ипи сыныгы. Бу алмашулар дөньялар бераз рәтләнгәнчегә кадәр дәвам итте.

Күрше-күләннәр, туган-тумачалар без—ике ятимне—ничек кенә кызганырга һәм ярдәм итәргә тырышмасыннар, күнелләр барыбер китек иде шул. Көндез бертоташ эш белән мавыгып, кайбер нәрсәләр вакытлыча онытылып тора, ә кичен, йокларга яткач йөрәкне гомерлеккә яралаган югалту хисе билэп ала. Күзләремә яшь бәреп чыга. Мин нәрсәгәдер өметләнеп, ниндидер өстен көчләргә ышанып, белгән догаларымны укый-укый Ходай Тәгаләгә ялвара башлыйм. Алла кодрәт иясе бит ул—өлкәннәр һәрхалдә шулай диләр. Әнине бер көнгә, хәтта бер сәгатькә, юк, юк, биш минутка булса да, җир йөзенә кайтармасмы—ул бөтенесен булдыра ала ич. Бер атна ялварам мин ана, бер ай, менә ел да узып бара. Һәм... ул аны... Җир йөзенә кайтарды. Төшемдә... Күкләр күкрәп, күк гөмбәзе урталай ярылып, ниндидер яктылыкта зур сакаллы карт пәйда булды. Күрәм: кече якта, урын өстендә әни ята. Менә аның йөзләренә алсулык йөгерә. Ул торып утыра. Без сөенешеп сөйләшә

башлыйбыз—бер-беребезнең хәлләрен сорашабыз. Шул ук мизгелдә тәрәзәдә әти шәүләсе чагыла. Ни өчендер куллары, аяклары калын тимер чыбыктан ясалган. Без бер-беребезгә бер сүз әйтергә дә өлгермибез, күк янадан гөрселди. Әти дә, әни дә кинәттән юкка чыгалар. Колагымда дәһшәтле тавыш: "Жи-тә-р-р-р, нә-фе-сен-не тыйый..." Мин Аллага тагын ялварам, "Тагын биш минут кына",—дим. Ләкин тирә-юнемдә өнсез тынлык кына. Күк гөмбәзен дә кара болытлар каплаган. Мин Алла дип инанган көрәк сакаллы карт та гаип булган. Мин тиргә батып уянам да, озак кына уйланып ятам. Андый төш инде башка кермәячәк. Мин дә җиргә төн ингән саен елый-елый, белгән догаларымны укый-укый инде беркайчан нәүмизләнеп кемгәдер ялынмаячакмын. Бу сәер төш мине тәмам дәһри итмәсә дә, иманым какшаган, шактый нык какшаган иде.

Әни вафат булып, икенче класста укып йөргәндә, мин инде мәктәпкә беренчедәгечә ашкынып түгел, шулай кирәк булганга, өлкәннәр кушканга гына йөрим, күңелдә ниндидер бушлык, бөтен нәрсәгә битарафлык пәйда булган—дөньяның, яшәүнең кызыгы калмаган иде. Мине инде табигый зиһенем генә өстерәп алып баргандыр—элекке "бишле"ләр сирәгәйде, "икеле"ләр дә күренә башлады. Мигә "барыбер түгелмени?!" дигән мәкерле уй кереп оялады. Әнә, әтиләре булган малайлар тәнәфес саен кабартма ашыйлар (мина да бер кабымлык эләгеп куя), матур, ямаусыз киемнән йөриләр, ә минем майка-трусикны әйткән дә юк, хәтта күлмәгем дә юк—өстемдә инде катып, яньчелеп беткән, әллә кайчангы сарык тиресеннән тегеп биргән тун гына. Кышкы салкында да, җәйге челләдә дә мин шуны киеп йөрим.

1945—1946 еллар халыкның ачлыктан, ялангачлыктан, беттән, кандаладан иң интеккән чагы булгандыр. Кешеләр гаиләләре-гаиләләре белән авырдылар. Тиф таза-таза ирләрне дә аяктан екты. Минем якадан ул кисәк кенә эләктереп алды. Бу үлемнең мина өченче тапкыр янавы иде инде. Математика дәресе иде—кинәттән генә тәннәрем кызыша, күзләрем ниндидер караңгылыкка чума, башым чатнап авырта башлады. Житмәсә, укытучыбыз Сафия апа мина дәресне сөйләргә—тапкырлау җәдвәлен яттан кабатларга куша. Мин башлавын әйбәт кенә башладым: "Ике икең—дүрт, ике өчең—алты, ике дүртең..." Зур саннарга киткәч, әллә нәрсә булды. Бер саннан икенчесенә сикердем: "җиде җидең—кырык алты, тугыз-тугызын—сиксән тугыз",—дип тузга язмаган сүзләр сөйли башладым да, кисеп аударган агач кебек парта өстенә аудым. Мине ничек өйгә кайтарганнардыр—хәтерләмим. Мин туктаусыз саташа башлаганмын. "Берәр нәрсә булмасын тагын", дип абый мине өстәл аягына бәйләп куйган. Тәмам тамактан калганмын. Суның да "кәнүшни" коесыннан алып кайтканын гына эчә алганмын. Бер айдан артык үз-үземне белештерми ятканмын. Мин авырган арада бабайның энесе Хөсәен абый теге дөньяга китеп барган—"икебезнең беребез үлә инде",—дип әйткән булган икән, шул тиф зәхмәте килеп ябышкач. Авыру тиз генә чигенмәде—хәлем бераз рәтләнә башлагач, әй, ашыйсым килә, әй, ашыйсым килә—әйтергә генә кыенсынам. Абый әллә кайдан сизеп алды минем халәтемне. Хатынына: "Мина берне булса да йомырка пешер әле. Әллә нәрсә аппетитым килеп тора",—диде. Жинәчи, өстәлгә йомырканы куеп, почмак якка кереп киткәч, абый колагыма гына пышылдап: "Мендәр астына куям. Жинәчән юк чагында алып ашарсың",—диде. Мин әнә шул "күчтәнәче" өчен аңа гомер буе рәхмәтле булдым... Гафу ит инде, каләмем. Бәлки бу хәсрәтле көннәр турында сөйләргә дә кирәкмәгәндер. Нигә кешеләрне боектырырга. Әллә аларда андый гына кайгылар юкмы? Дөнья бит бу...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# МИРСӘЙ ӘМИР ГАЕПЛЕМЕ?

Зәки Зәйнуллинның "Казан утлары"ның быелгы 7—8 саннарында басылган "Кави Нәҗми дигән язучы" исемле әсәрен зур кызыксыну белән укып чыктым.

Ин элек шуны әйтәсем килә: автор әсәрнең жанрын роман дип билгеләгән. Чыннан да, әсәрнең Кава Нәҗминең балачагын тасвирлаучы башлангыч өлешләре чын рәссамнарча, Зәки Зәйнуллинга хас әдәби осталык белән, матур итеп тасвирлап язылган. Әмма әсәрнең калган өлешләре андый түгел. Автор вакыйгаларның эченә кереп, образлы итеп язмый, өстән-өстән вакыйгаларны санап, сөйләп кенә бара. Шулай итеп, әсәрдә роман элементлары булса да, нигездә аны документаль, публицистик әсәр дип атарга була.

Шуна да карамастан, әсәр зур кызыксыну белән укыла. Автор К. Нәҗминең тулы бер образын тудыра, аның фаҗигале язмышын күрсәтә алган. Язучылар биографиясенә багышланган житди әсәрләр, кызганычка каршы, бездә бик сирәк басыла. Югыйсә укучылар андый документаль рухтагы әсәрләрне көтеп ала, яратып укый.

Әмма кулыма каләм алырга мине бүтән нәрсә этәрде.

Әсәрнең икенче яртысында (№ 8, 64 бит) автор Мирсәй Әмирнең бер "кыек эше" турында яза. Анынча, М. Әмир Кави Нәҗминең хатыны Сәрвәр Әдһәмова өстеннән шикаять язган. Автор моны болай итеп тасвирлый: "Кабинет ишеген эчтән бикләп, Мирсәяф япа-ялгызы кичкә кадәр утырды. Уйлады да уйлады. Һәм башына килгән бик хәвефле бер уйдан арына алмады: "Әгәр кызулыгы өстенлек алып, башы эшләүдән туктап, Сәрвәр минем өстән язып НКВДга шикаять тапшырса? Бетте бит минем баш! Кавины бер гаепсезгә илтеп тыктылар. Өстәп Сәрвәр минем өстән язса, мине дә илтеп тыгачаклар. Баш бетә бит!"

Шуннан соң, әсәрдә язылганча, "куркудан коты очкан Мирсәй Әмир, Сәрвәр өстеннән шикаять язып, икенче көнне иртән НКВДга тапшыра". НКВД хезмәткәрләре эшне кыска тоталар—шул көннәрдә үк Сәрвәр Әдһәмованы кулга алалар. Шулай итеп, З.Зәйнуллин фикеренчә, С. Әдһәмованың фаҗигасендә тулысынча Мирсәй Әмир гаепле.

Чынлыкта эш ничек булган соң?

Үткән гасырның алтмышынчы еллар башында мина Мирсәй ага белән Язучылар берлегендә эшләргә туры килде. Ул—идарәнең рәисе, мин исә җаваплы сәркәтибе идем. Бервакыт идарәгә ниндидер йомыш белән Сәрвәр Әдһәмова кереп чыккан иде. Ул киткәч, Мирсәй ага белән сөйләшеп утырганда, ул мина болай дип әйтте:

—Беләсеңме, Рафаэль туганым, мин бит Сәрвәр апаң алдында беркадәр гаепле...

Һәм ул мина 1937 елда булган вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Шул елны аны көчләп диярлек берлекнең рәисе итеп сайлап куялар. Күпмедер вакыттан янына Сәрвәр Әдһәмова керә. Аның сүзләренә караганда, элекке рәис Ләбиб Гыйльми ана үзенең бер повестен русчага тәрҗемә итәргә биргән икән. С. Әдһәмова бик тырышып бу эшне башкарган. Ул арада Ләбиб Гыйльмине

"халык дошманы" дип кулга алалар. Шуна да карамастан, С. Әдһәмова яна рәистән башкарган эше өчен түләүне таләп итә. Ул вакытта К. Нәҗми үзе төрмәдә, өйдә ач бала җылый, бер тиен акчалары юк...

Әмма Мирсәй Әмирнең хәле дә хәл. Ул чорда "халык дошманы" әсәрен тәрҗемә иткән өчен түләү түгел, аның исемен атарга да ярамаган. Нәкъ шул вакытларда Язучылар берлегенең бухгалтерын кулга алалар. Гаебе: "халык дошманнары"на акча, ягъни эш хакы түләп торган. Житмәсә, Сәрвәр Әдһәмованың ни договоры, ни башка рәсми документы булмый. Менә шуннан низаг килеп чыга да инде. Ач кешенең ачуы яман, диләр. С. Әдһәмова, кызып китеп, Мирсәй Әмирне Язучылар берлегендә "капиталистик тәртипләр" урнашуда гаепли (башкарылган эшкә түләмәү), "Сезнең барыгызны да кулга алачаклар, хәзер бөтен кешене дә утырталар!"—дип яный.

Хәзерге күзлектән караганда—пүчтәк эш, чүп кенә сыман. Кем белән кем талашмый да, кызып китеп нинди генә сүзләр ычкындырмый. Әмма ул чорда... Күпме кешенең белеп тә хәбәр итмәгән өчен (русчасы—"за недоносительство") башы китте! Житмәсә, С. Әдһәмованың кычкырганын шактый кеше ишеткән. Алар арасында, Мирсәй аганың белүенчә, НКВДның ирекле әләкчесе дә була. Шуннан соң Мирсәй ага, уйлап-уйлап торгач, бу низаг турында үзе хәбәр итәргә була. Әйе, үз кулы белән гариза яза.

Язуын яза, әмма беркемгә дә бирми дә, күрсәтми дә. Саф күңелле, намуслы кеше буларак, ул бу эшнең ямьсез гамәл икәнен яхшы аңлый. Әгәр дә бу турыда башка кеше язып, аны НКВДга чакыртып сорау ала башласалар, ул әлеге шикаятьне күрсәтер, менә, яздым ич, тик җибәрергә генә өлгермәдем, дип әйтер, чакырмый икән—шул көе үтәр дип уйлый.

Бу шикаять КГБ архивында сакланган. Мин аны үз күзем белән күрдем. Шуңа игътибар иттем—гаризаның кайбер юллары сызылган, кайбер сүзләре төзәтелгән. Ягъни аны каралама дип кенә атарга була. Ничек әлэгә соң ул НКВД кулына?

Гариза 1937 елның 14 ноябрендә язылган (әлеге вакыйга да, димәк, шул көнне булган булса кирәк). Ә шул ук елның 4 декабрендә Мирсәй Әмирнең үзен, нахак бәла тагып, кулга алалар. Шулай итеп, пиджак кесәсендәге шикаять тә әлеге оешмага барып керә. Тагы бер ай вакыт үтүгә (1938 елның 4 гыйнварында), Сәрвәр апа Әдһәмованы да кулга алалар.

Шулай итеп, бу очракта Мирсәй Әмирне гаепләп буламы? Ул үзе дә бу гаделсез чорның корбаны бит. Монда Сталин чорындагы законсызлык, тоталитар режим гаепле.

Шулай да С. Әдһәмова бөтен гаепне М. Әмирдән күрә. Лагерьдан язган бер хатында ул: "Ялган яла белән мине шул хәлгә төшергән Мирсәй",—дип яза. Бу субъектив фикерне аның улы Тансык та әледән-әле кабатлап тора, хәтта матбугатта да язып чыга. Заманында мин бу турыда "Советская Татария" газетасында язган да идем инде (29.09.90 ел). Шул ук газетада М. Әмирнең туганнары да протест белдереп хат бастырдылар.

З. Зәйнуллин 1938 елның 11 августында С. Әдһәмова өстеннән булган суд турында да яза. "Сәрвәрнең судына аны (М. Әмирне .—Р. М.) шаһит итеп чакыралар... Мирсәй Әмир язган шикаятеннән баш тартып карый. Тик эш узган—суд аны исәпкә алып та тормый. Батыр йөрәкле хатынны Мирсәй Әмирнең куркудан язган шикаяте аркасында ун елга лагерьга озаталар һәм биш елга хокукыннан мәхрүм итәләр".

Авторны төзәтеп, шуны әйтергә кирәк: М.Әмир бу вакытта үзе дә тоткын булып төрмәдә утыра. Әмма ул С. Әдһәмовага яла якмый.

Чынлыкта исә С. Әдһәмованы төрмәгә керткән төп "гаеп"—аның "үзенең гаебен таныган халык дошманы" хатыны булуы. К. Нәҗми һәм М. Әмирләр өстеннән суд 1939 елның мартында үткәрелә. Ул—16, 17 һәм 19 мартта—өч көн

буена бара. Беренче көннәрдә К. Нәҗми бөтен гаепләүләр белән дә ризалаша, М. Әмиргә һәм башкаларга каршы ялган мәгълүматлар бирә. Мирсәй Әмир исә үзен бик нык тота, бернинди гаепләрне дә танымый. Моны күреп, Кави Нәҗми дә элек раслаганнарын кире кага. Шунын нәтиҗәсендә Мирсәй Әмирне иреккә чыгаралар. Бераздан, 1939 елның азагында, Кави Нәҗми дә төрмәдән чыга. 1940 елның июлендә акланып, ноябрьдә С. Әдһәмова да азат ителә. Аларның иреккә чыгуында М. Әмирнең роле бик зур. Гомумән, 1929-40 елларда кулга алынган 36 татар язучысы арасында үзен егетләрчә тоткан берничә кешенең берсе ул.

Шулай да С. Әдһәмова Мирсәй агага нәрсә өчен үпкәләгән соң? "Дело"дан күренгәнчә (Дело № 13563 по обвинению Адгамовой С. С. Архив № 2—1785, т.I, л. 28—29), тикшерүче М. Әмир сүзләрен үзгәртеп, үзенә ничек кирәк, шулай яза, С. Әдһәмованы контрреволюцион ниятләрдә гаепли. Бу бит астына кул куйганда М. Әмир, "Записано с моих слов верно,"—дип машинкада басылган сүзләрдән соң "За исключением второго вопроса"—дип өстәп язып куя. Ягъни ул низаг булганын таный, әмма С. Әдһәмованы контрреволюцион ниятта гаепләми. Суд барышында исә беркетмәләрнең бу урынын өстәмәне әйтми генә укыйлар. М. Әмир үз чиратында, ана сүз биргәч, бу гаепләүдән баш тартып карый. Әмма аның сүзләренә игътибар итмиләр.

С. Әдһәмова эшеннән күренгәнчә, М. Әмир сорау алулар вакытында да, судта да Сәрвәр апага үзе дә яла якмаган, башкалар яккан гаепләрне дә раслаудан баш тарткан. Теге вакыйганы исә ничек булган—шулай сөйләгән. С. Әдһәмованы кулга алу да, гаепләү карары да,—барысы, барысы законны бозып эшләнгән. Моны ул чорда ук СССРның Югары суды таныган. 1940 елның 2 июнендә СССРның Югары суды коллегиясе С. Әдһәмованы аклап карар чыгара (төгәл булсын өчен, мин аны ничек язылган, шулай, ягъни русча китерәм): "Адгамова С. С. осуждена за то, что, зная о к/р деятельности своего мужа Нежметдинова, не сообщила об этом органам Советской власти и, будучи тесно связана с к/р буржуазно-националистическими элементами, сама распространяла клевету по адресу Советской власти и ее органов. По материалам дела обвинение Адгамовой С. С. по ст. 58—10, ч 1 и 58—12 УК не доказано. По делу нет доказательств, уличающих Адгамову в связях с к/р организацией. Высказывания Адгамовой, о которых давал показания Амиров, по своему содержанию не являются антисоветскими, других доказательств для обвинения Адгамовой по ст. 58—10, ч 1. УК РСФСР в деле нет".

Шулай итеп, З. Зәйнуллин әсәрендәге төгәлсезлекне төзәтеп, тарихи дөреслекне өстен куярга кирәк. Мондый эпизод М. Әмирнең якты истәлегенә тап төшерә, ана яла ягу буларак кабул ителә. Мин Мирсәй ага белән күп еллар якыннан аралашып, аны намуслы, саф күңелле, кешеләргә игътибарлы шәхес буларак беләм. З. Зәйнуллин, эшнең асылына төшенмичә язып, бер М. Әмирнең рухын гына түгел, балаларын, туганнарын һәм аның иҗатын яраткан меңләгән укучыларны да рәнжетте.

**Рафаэль МОСТАФИН**

## Искәндәр Гыйләҗев



Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев 1958 елның 31 августында язучы Аяз Гыйләҗев гаиләсендә туган. Урта мәктәптән соң, 1979 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Мәскәүдә СССР Фәннәр Академиясенең Тарих институтында аспирантурада белемен арттыра.

Университетта укыган елларында ук И. Гыйләҗев фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнә башлый, остазы Миркасыйм Госманов житәкчелегендәге археографик экспедицияләрдә катнаша. 1982-1985 елларда ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли, күренекле тарихчы һәм әдип Газиз Гобәйдуллинның сайланма хезмәтләрен дөньяга чыгаруда катнаша. 1983 елда ул XVIII йөзнең икенче яртысында Урта Идел төбәге татар крестьяннарының социаль-икътисадый тарихына багышланган кандидатлык диссертациясен яклый.

Халкыбызның каһарман улы Батырша, Казанның татар бистәләре, 1773-1775 еллардагы Е. Пугачев житәкчелегендәге Крестьяннар сугышы тарихына караган гарәби язулы татар документлары һәм башка бик күп проблемаларга караган дистәләгән мәкалә-язмаларын бер-бер артлы бастырып чыгара.

1985 елда Казан дәүләт университетына күчеп эшли башлаган И. Гыйләҗевкә педагоглык хезмәтенең барлык рәсми баскычларын узарга туры килә: ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор.

Үзгәртеп кору, хәбәрдарлык дәвере башланып, "тимер пәрдә" төшү И. Гыйләҗевнең тормышына турыдан-туры йогынты ясый. Немец телен камил үзләштергән галим, Германиядә стажировкада булып, немец архивларында эшләп, икенче бөтендөнья сугышы дәверендә әсирлеккә төшкән милләттәшләребезнең ачы язмышына караган күпсанлы тарихи чыганаклар туплый.

Аның төп хезмәтләренең берсе—докторлык диссертациясе рәвешендә якланган хезмәте—Икенче бөтендөнья сугышы дәверендә Идел-Урал татар коллаборационистлары кебек үтә катлаулы һәм четерекле проблемага багышланган. Бу проблеманы И. Гыйләҗев чыганаклар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә, объектив тикшерүгә иреште. Хәзерге вакытта И. Гыйләҗев XIX-XX йөзләрдә татар диаспорасы, Европа һәм Азиядәге татар эмиграция тарихы проблемалары белән шөгыльләнә, Бөтенроссия һәм Халыкара конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясый. Газета-журналларыбызда басылган, бигрәк тә татар теле язмышына багышланган мәкаләләре җәмәгатьчелеккә яхшы таныш.

Ул—Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты.

Хәзерге вакытта Искәндәр Гыйләҗев житәкләгән Казан университетының Татар филологиясе һәм тарихы факультеты мәдәниятебез өчен кадрлар әзерләү үзәге дә. Татарстан Язучылар берлеге әгъзаларының күпчелеге нәкъ менә шушы факультетны тәмамлаган. Бүген дә факультет яшь иҗат көчләрен үзенә туплаган бер үзәкне тәшкил итә. Студентларның "Әллүки" берләшмәсе эшләп килә, "Тәрәзә" исемле газета да нәшер ителә.

2008 елның 18 апрелендә Т. Галиуллин, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов тәкъдимнамәләре нигезендә Кабул итү коллегиясе һәм Идарә Искәндәр Аяз улы Гыйләҗевне Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.

## Алмаз Хәмзин



Хәмзин Алмаз Наил улы 1947 елның 18 сентябрендә Татарстанның Түбән Кама районы Ташлык авылында (шагыйрь Разил Вәлиев, жырчы Рафаэль Сәхәбиев тә шушы төбәктән) туа. Түбән Камада урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә, армия хезмәтенә алынганга кадәр бернечә ел авыл хужалыгы һәм инженер-төзүчеләр институтында укый. Армиядән кайткач, үзен сәнгать дөньясына багышларга карар кыла, Казан педагогия институтының музыка факультетына укырга керә һәм аны 1977 елда уңышлы тәмамлый. Студент елларында Рифкать Гомәров житәкләгән мәшһүр "Саз" ансамблендә жырчы буларак чыгышлар ясый. Талантлы егетне филармония житәкчеләре тиз күреп ала һәм аны үзләренә эшкә чакыралар. Ул бер еллап Вафирә Гыйззәтуллина, Римма Ибраһимоваларның ижат төркемнәре белән СССРның төрле почмакларында гастрольләрдә йөри.

Алмаз Хәмзин сәнгати оешмаларның төрлеләрендә, төрле елларда, төрле вазифалар башкарды: Куйбышев исемендәге мәдәният сараенда директор урынбасары, "Комсомолец" клубында директор, Казан телевидениесендә—алып баручы һәм сценарийлар авторы, филармониядә -режиссер... Бу еллар эчендә ул күпсанлы тапшырулар башлап жибәрүчесе ("Алмаз плюс", "Шаяру", "Шаян сәхнә" "Капка төбе" һ. б.), йөзләгән концертларның төп алып баручысы булды. Шуңа күрә дә тамашачы аны яхшы белә, ихтирам итә.

Хәзер А. Хәмзин Казан театр училищесында эстрада бүлеге житәкчесе.

Соңгы елларда А. Хәмзин талантының тагын бер юнәлешен үстерүгә аерым игътибар итә башлады. Ул жырлар яза ("Зәйтүнәм", "Өмет", "Миләшкәем", "Туган көн", "Сине көтәм" һ. б.), эстрада өчен юмористик хикәяләр, пьесалар ижат итә. Аерым басмаларда аның үз рубрикаларын ("Татарстан яшьләре"ндә—"Алмаз бөртекләре", "Безнең гәжит"тә—"Алмаз Хәмзетдин", "Шәһри Казан"да—"Юмор баганасы") да булдырды ул. А. Хәмзин, шулай ук, матбугатта публицистик мәкаләләр белән дә чыгышлар ясый, Татарстан радиосында газета-журналларыбызның яңа чыккан саннарына житди анализлы күзәтүләр алып бара. Аның юмористик әсәрләре "Казан утлары" журналында да бернечә мәртәбә дөнья күрде. 2007 елда Алмаз Хәмзинның "Озак яшисегез килсә" дип исемләнгән китабы Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

1997 елны татар мәдәнияте өлкәсендәге казанышлары өчен Алмаз Хәмзингә "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде. 2008 елның 25 гыйнварында Татарстан Республикасы Президенты Указы белән татар мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүдәге казанышлары өчен ул "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе 2008 елның 18 апрелендә уздырылган утырышында Кабул итү коллегиясенең карарын раслап, (тәкъдимнамә бирүчеләр: Разил Вәлиев, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон) Алмаз Наил улы Хәмзинне Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итте.



"Казан утлары" журналы редакциясендә. Сулдан уңга – Роберт Батуллин (Рабит Батулла), Вакыйф Нуруллин, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Яхъя Халитов. 1968 ел.



Илче Назиф Мириханов – Татарстан Республикасының Россия федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиле. "Казан утлары" журналының редколлегия әгъзасы. 2006 ел.



Матур уйныйлар! Заһидулла Яруллин (уртада) яшь музыкантлар Мирсәет Яруллин (сулда) һәм Фәтхерахман Әхмәдиев белән. 1956 ел.



*Зәки Нуриның Мәскәүдә – Югары әдәби курсларда укып йөргән вакытлары.*
*Сулдан уңга – Камчы Жунусов (Кыргызстан), Паслюс Ширвис (Литва),*
*Семен Данилов (Якутия), Зәки Нури (Татарстан). 1956 ел.*



*Рәшит Ягъфәровның иҗат кичәсендә. Уңда – җырчы Сәнифә Рангулова. Казан. Язучыларның Г. Тукай клубы. 2001 ел.*



*Язучы Фәүзия Бәйрамова Болгарда чыгыш ясый. 1989 ел.*

## РЕСПУБЛИКАНЫҢ ТӨП БӘЙРӘМЕ

Инде унсигезенче тапкыр 30 август көне башкалабызда олуг бәйрәм итеп билгеләнеп үтелә. Соңгы елларда ул шәһәр көне дип тә йөртелә башлады. Әмма, асылда ул—Республика көне. Чөнки 1990 елның 30 августында Татарстан Республикасының суверенитеты турында тарихи Декларация кабул ителде. Ә мондый Декларация, табигый, аерым бер шәһәр яки төбәк өчен генә игълан ителми.

Тантананың асыл мәгънәсе бер булса да, һәр елны бәйрәмнең үзгә аерымлыклары, яңалыклары... Быел да шулай булды.

Киров районында төзекләндерелгәннән һәм үзгәртеп корылганнан соң халыкның яратып ял итә торган урыны—Петров паркы яңадан ачылды. Тантаналарда Президент Минтимер Шәймиев тә катнашты.

Президент аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Александр Гусев, яшьләр эше, спорт һәм туристлык министры Марат Бариев, Казан мэры Илсур Метшин белән берлектә, Минтимер Шәймиев данлыклы Елга арьягы ветераннары белән очрашты, Ватан сугышында һәлак булган кировлылар хөрмәтенә торгызылган мемориал янында тукталды, аңа чәчәк бәйләмнәре салды.

Президент М. Шәймиев паркны үзгәртеп кору һәм яңа спорт комплексы төзүдә зур тырышлык куйганы өчен "Баско" финанс-төзелеш компаниясе директоры Валерий Калмыковка рәхмәт әйтте, аны республиканың атказанган төзүчесе исеме бирелү белән котлады.

Яңа Боз сараенда Президент "Ак Барс" хоккей клубы җитәкчеләре һәм команда уенчылары Алексей Морозов, Александр Степанов белән сөйләште, яңа сезонга әзерлекнең торышы белән кызыксынды. Яңа спорт комплексы 2013 елда үтәчәк Универсиадага әзерләнүдә спортчылар өчен төп күнегүләр үткәрү базасы булачак. Бирелә "Виктория" балалар-үсмерләр спорт мәктәбе ачыла.

Чал Кремль стеналары янындагы Меңъеллык мәйданында бик күпләргә ярдәм кулы сузган игелекле зат Әсгат Галимҗановка бронзадан скульптура композициясе ачылды. Аны—Асыя Миңнуллина җитәкчелегендәге скульпторлар төркеме иҗат иткән.

Казан шәһәренең мактаулы гражданы Ә. Галимҗановның, көнкүрештәге азык калдыкларын җыеп, терлек симертүе, шул рәвешле туплаган акчасын балалар йортларына биреп баруы һәркемдә соклану уята. Спитакта җир тетрәүдән, Чернобыльдә атом фаҗигасеннән зыян күрүчеләргә, мәгълүм вакыйгалардан соң Көньяк Осетия балаларына да ярдәмгә килде ул.

Г. Тукай мәйданында, шагыйрь һәйкәле янында традицион Шигырь бәйрәме узды. Анда Республиканың күренекле шагыйрьләре чыгыш ясады.

Республика көнендә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен тапшыру күркәм традициягә әверелде. Шунысы да игътибарле, бу премия ярты гасыр элек гамәлгә куелган иде.

Быелгы премияләр шагыйрь Рәдиф Гаташка ("Газәлләр" һәм "Мәңгелек сусау" китаплары өчен); рәссам Виктор Аршиновка (Г. Тукай һәм М. Җәлилгә багышланган график әсәрләре өчен); "Шагыйрь мәхәббәте" операсы өчен композитор Резеда Әхиярова һәм М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының иҗат төркеменә; соңгы еллардагы концерт программалары һәм "Мин яратам сине, Татарстан!" җыры өчен җырчы Салават Фәтхетдиновка, композитор Роберт Андреевка, шагыйрь Роберт Рәкыйповка (үлгәннән соң) бирелгән иде. Премияләрне Президент М. Шәймиев тапшырды. Тантанада шулай ук Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева катнашты.

Меңъеллык мәйданында халыкара рок музыкасы фестивале үтүе быелгы бәйрәмнең иң үзәк өлеше булды. Казанның Меңъеллык мәйданына 100 меңнән артык тамашачы җыелды. Халык дингезе алдында дөньякүләм билгеле коллективлар чыгыш ясады. Ун сәгатькә сузылган бу концерт музыка дөньясында зур вакыйга дип бәяләнде.

Казанда бәйрәм тантаналары төнге салют белән тәмамланды.

## МИЛЛӘТ ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ

Август ахырында Казанда Бөтендөнья татар яшьләренең III форумы уздырылды. Җыелуының төп максаты—үзара аралашу, фикер алышу, элемтәләрне ныгыту иде. Форумда чит илләрдән—153, Россия төбәкләреннән—218, Татарстаннан 100 делегат катнашты. Быел, беренче тапкыр буларак, форумга Израильдән, Голландиядән, Румыниядән, Чечен Республикасын-

нан, Ставрополь краеннан да яшьләр килгән иде.

Билгеле булганча, Бөтендөнья татар яшьләре форумы беренче тапкыр Казанда 2004 елда үткәрелде. Ул вакытта Россиядә яңа оешкан татар яшьләре оешмаларының Координация советы активлык күрсәтте. 2006 елда үткән II форум мәдәният, сәнгать, спорт өлкәсендә зур казанышларга ирешкән яшь милләттәшләребезгә бай булуы белән аерылып торды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров быелгы форумга да иң актив, иң булдыклы яшьләрнең генә чакырылуын белдерде.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова Президент Минтимер Шәймиевнең делегатларга котлавын ирештерде. "Бүгенге форумда татарча сөйләшә белмәүче яки туган телен аңламаучы бер генә милләттәшебез дә юк. Димәк, Казанга чын-чынлап үз милләтен сөючеләр җыелган. Татар милләте бүгенге көндә үсеш кичерүче халыклардан санала. Залда утыручы яшьләр—милләтебезнең алгы сафында баручылар",—диде Р. Ратникова.

Р. Закиров үз чыгышында 200 меңнән артык татар кешесенең Татарстанга күченеп кайту теләге булуы турында әйтте. Республиканың сәнәгать өлкәсендә уңышларга ирешүе, житештерүчәнлекнең артуы, тормыш шартларының яхшыра баруы аларны үзебезгә кабул итәргә мөмкинлек бирә. Татарстан эшче кулларга кытлык кичергәндә аларның кайтуы зур файда булачак. Читтә яшәүче татар яшьләре өчен Татарстан югары уку йортларында 600гә якын квоталы урын булдырылды.

—Иң зур бурычларның берсе—яшьләрне икътисад тармагына тарту, төзелә торган сәнәгать предприятиеләренә, эре төзелеш корылмаларына җәлеп итү. Казанда, Чаллыда, Түбән Камада, "Алабуга" махсус икътисади зонасында, спорт корылмаларын һәм Универсиада авылын төзүдә яшь белгечләр бик кирәк,—диде яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министры урынбасары Хәлил Шәйхетдинов.

Секцияләрдә, "түгәрәк өстәл"ләрдә бүген яшьләрне борчыган мәсьәләләр каралды. Милли үзенчәлекләрне саклап калу, милли театр, кино, әдәбият, телевидение, Интернет, радио—барысы да яшьләр күзлегеннән бәяләнде. "Татарстан Яңа Гасыр" телевидениесенең милли мәсьәләләрдән читләшә баруы билгеләп үтелде. Үзебезнең милли телевидение кирәклеге хакында каткат искәртелде. Аерым бер сайт ачып, анда яшьләр тапшыруларын, татар фильмнарын куясы иде. Җыр репертуарына халтураның үтеп керүе, театрларга яхшы әсәрләр җитмәве дә бүген генә килеп туган проблемалар түгел.

—Сез инглиз телен белмичә Америкага барсагыз, зур уңышка ирешә алмассыз. Мәскәүдә дә рус телен белмәсән, авырга туры килә. Татарстанда татар телендә сөйләшмәсән дә, рәхәтләнеп яшәргә мөмкин,—дип, Финляндиядән килгән милләттәшебез Әнәс Зыялы үзенең гаҗәпләнүен дә белдерде.

Һәркем милләт язмышын үзенчә бәяли, проблемаларны үзе аңлаганча яктырта. Мөгаен, ул шулай булырга тиештер дә. Әмма бу форумның татар милләте үсешенә этәргеч бирәчәге бәхәссез. Хәзер татар милләте яңалыкка, үзгәрешкә мохтаҗ. Ә аны бары тик яшьләребез генә хәл итә ала.

Форумга җыелган яшьләр 30 август көнендә үткән тантаналарда да катнаштылар.

## ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ ГАЛИМНӘРЕ ҖЫЕНЫ

Казанда Ислам дөньясы Фәннәр академиясенең "Ислам дөньясының тотрыклы үсеше өчен фән, технологияләр һәм инновацияләр. Сәясәтчеләр һәм галимнәрнең якынаюы" дигән XVI халыкара конференция булып узды. Анда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, Татарстан Президенты М. Шәймиев: "Хөрмәтле конференция кунаклары! Сезне кунакчыл Татарстан җирендә—башкалабыз Казан шәһәрендә ихлас сәламлим. Мондый мәртәбәле Ислам форумы Россия Федерациясендә тәүге тапкыр оештырыла. Конференциянең Казанда узуы очраклы түгел, дип ышанам, Татарстан күп кенә Ислам илләре белән фәнни-техник, сәүдә-икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр урнаштырды",—диде. Аның сүзләреннән аңлашылганча, Ислам конференциясе оешмасының 57 әгъзаиле колачлаган конференцияне Казанда уздыру фән һәм технологияләр үсешенә яңа шартлар тудыру өчен уртак тырышлыкларның берләшүенә йогынты ясый. "Бу дөнья галимнәренең уртак максатны күзлә тоткан берләшү мисалы булып тора",—дип белдерде республика башлыгы.

***

Ислам дөньясы Фәннәр академиясе Президенты Абдел Салама Маджали Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевкә фән һәм технологияләр үсешенә Татарстанда һәм, гомумән, халыкара дәрәҗәдә зур өлеш керткәне өчен Ислам дөньясы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы дипломын тапшырды. Республика җитәкчесенә матур бизәлешле Коръән-Кәрим дә бүләк ителде.

***

Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мәҗһәров "Ислам дөньясының тотрыклы үсеше өчен фән, технологияләр

һәм инновацияләр. Сәясәтчеләр һәм галимнәрнең якынаюы" дигән XVI халыкара конференция кысаларында үткәрелгән IAS әгъзалары генераль ассамблеясында Ислам дөньясы Фәннәр академиясенең вице-президенты итеп сайланды.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ЯД ИТҮ

25 августта Казанның 1 Май мәйданындагы М. Җәлил һәйкәле янында җәлилчеләрне искә алу мәрәсиме булды.

Аны Татарстанның халык шагыйре "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин ачып җибәрде һәм алып барды. Аннары Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева сүз алды.

—Җәлилчеләр теләсә нинди сынаулар вакытында да безгә чын батырлык үрнәге булып тора,—диде ул.—Быел җәлилчеләрнең берсе—язучы Абдулла Алишның тууына 100 ел тула. Республикада бу юбилейга җитди әзерлек алып барыла. Бөтен мәктәпләрдә дә әлеге мәшһүр балалар язучысына багышлап чаралар үткәрелә.

Аннан соң Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов чыгыш ясады.

—Ни кызганыч, милләттәшләребезнең батырлыгы турында Туган илдә 11 елдан соң гына беләләр. Анарчы алар хыянәтчеләр исемлегендә йөртелә. Без, татар һәм Татарстан язучылары, Җәлил һәм җәлилчеләрне яд иткәндә, яуда башларын салган 30 каләмдәшебезне, тән һәм җан ярасы алып, бу дөньядан вакытсыз киткән тагын 100ләп язучыбызның рухларын да яд итәбез.

Шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова үз чыгышында бары тик Казанга килгәч кенә чын бәхет хисе кичерүе турында әйтте.

—Чөнки без әти белән Казанда хушлаштык. Моннан соң да, үзем исән вакытта, җәлилчеләрне искә алу көненә ел саен киләчәкмен,—диде ул.

Хәтер җыенында шулай ук җәлилчеләрне өйрәнүче язучы-галим Рафаэль Мостафин, А. Алишның авылдашы, язучы Әнәс Хәсәнов, профессор Абделхан Әхтәмҗан (Мәскәү), М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, шагыйрьләр Газинур Морат һәм Ләбиб Лерон, А. Алиш исемендәге әдәби бүләк иярәре, шагыйрьләр Рафис Корбан, Йолдыз Шәрәпова, театр артистлары Ренат Таҗетдинов, Минвәли Габдуллин, җырчылар Резеда Галимова, Айдар Габдинов һ. б. чыгыш ясады.

Митингтан соң тантанага җыелган язучылар Кол Шәриф мәчетенә кереп, өйлә намазы укыды һәм җәлилчеләр рухына багышлап дога кылдылар.

Ә төштән соң Татарстан Милли музеенда галимнәр һәм язучылар катнашында җәлилчеләр һәм "Идел-Урал" легиончыларына багышланган "түгәрәк өстәл" уздырылды.

## ТАБИГЫЙ ТАРИХ МУЗЕЕ

Дәүләт тарихи-архитектура сәнгать музей-тыюлыгында Татарстанның табигый тарихына багышланган музей ачылды. Ул 2005 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча оештырылган һәм Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев булышлыгы белән төзелгән. Музейның максаты: төбәкнең геологик мирасын саклап калу һәм пропагандалау.

Табигый тарих музее республика өчен уникаль проект. Күргәзмәне классик ысул белән төзүдән тыш, мультимедиа технологияләре дә кулланылган. Анда Татарстанның геологик тарихы, җир байлыклары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, минераль байлыклар турындагы бай мәгълүмат бар. Күргәзмәнең нигезендә—Казан дәүләт университетының А. А. Штукенберг исемендәге геология музееның һәм "Казан Кремле" музей—тыюлыгының тупланмалары. Музей экспозицияләре элеккеге Юнкерлар училищесының беренче һәм икенче катларындагы бүлемнәрдә һәм ике күргәзмә залында урнаштырылган. Анда якынча 1000 экспонат бар.

## АВСТРАЛИЯ ТАТАРЛАРЫ КАЗАНДА

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Австралиядә яшәүче бер төркем милләттәшләребезне кабул итте. Алар Аделаид шәһәре татарларының бик абруйлы—Садри, Вәлифф һәм Маски гаиләләре вәкилләре.

Чит-ят җирләрдә җирсеп, туган туфракка аяк басу турында хыялланып яшәгән ата-бабаларының нигезенә кайтып, янәдән үзләренең тамырларын барлаган милләттәшләребезнең бу гамәлен Президентыбыз: «Бик изге эш эшлисез»,—дип бәяләде. Президент милләттәшләребезнең ана телен саклауларына сокланып гаиләдә нинди телдә аралашулары белән дә кызыксынды. Сөйләшү вакытында икътисади һәм рухи, мәдәни бәйләнешләр хакында да сүз барды.

Очрашудан соң Айша Маски һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров журналистларның сорауларына җаваплар бирделәр.

## КАЗАННЫҢ ИҢ БИЕК КУНАКХАНӘСЕ

Казанда Татарстанның иң биек отеле һәм шәһәрнең иң биек бинасы—«Ривьера» кунакханәсенең ачылу тантанасы узды. Ул «Казан Ривьера»сына бер ел тулу белән туры килде. Кызыл тасманы кисү тантанасында Казан мэры Илсур Метшин да катнашты.

4 йолдызлы һәм 26 катлы «Ривьера»

кунакханәсенең биеклеге 85 метр. Биредә 210 бүлмәдә 367 кешелек урын бар. Шулай ук кунакханәдә 6 люкс бүлмә, мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен дә номерлар бар.

## МӨСЕЛМАН КЫЗЫ НӘГЫЙМӘ

«Нәгыймә» исемле кыска метражлы фильмны төшерү эшләре тәмам. Казанда яшәүче мөселман кызы Нәгыймә турындагы фильмны башкаланың Дзержинский, Декабристлар, Чистай урамнарында, Дәрвишләр бистәсендәге балалар йортында, 4 нче бала тудыру йортында төшергәннәр. Фильмга заказ бирүче—«Татаркино» оешмасы, сәнгать житәкчесе—Эстониянең танылган кинорежиссеры Арво Ихо. «Нәгыймә»дә Тинчурин театры артисты Айгөл Әхмәтова (Нәгыймә), шулай ук Римма Фәхретдинова (Айсылу), Олеся Лядова (Лина), Радик Нургаев һәм танылган журналист Искәндәр Сиражи уйный. Тамашачыларга яна фильмны быел «Алтын мөнбәр» фестивалендә тәкъдим итәргә планлаштыралар.

## ТАТАРЛАРНЫ БЕРГӘ ТУПЛАП

Берлинда татар, рус һәм немец телләрендә чыгарыла торган «АлТаБаш» журналының берләштерелгән июль-август санында төрле илләрдә гомер итүче татарлар турында кызыклы материаллар урнаштырылган. Аерым алганда, басмада Берлин, Бавария, Стокгольм (Швеция), Семипалатинск (Казахстан) шәһәрләрендә күп милләттәшләрне бергә җыйган Сабан туйларыннан репортажлар, кызыклы очрашулар турындагы язмалар урын алган.

## "ӨЧ АРШЫН ЖИР" ТӨРЕКЧӘДӘ

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләжевнең "Өч аршын жир" дигән мәгълүм повесте төрек телендә дөнья күрде. Үткән гасырның 60нчы елларында язылган бу әсәр үз вакытында әдәбият дөньясында вакыйга буларак кабул ителгән иде. Повесть буенча Г. Камал театрында спектакль дә куелды. Төркиянең "Сетун" исемле нәшриятында чыккан бу повестьны төрекчәгә Фатыйх бәй Котлы тәржемә иткән.

## ДИННӘР ТАРИХЫН БЕЛӘСЕҢМЕ?

2007 елның 1 сентябреннән республикабызның 71 мәктәбендә «Диннәр тарихы» дигән яңа фән кертелде. Татарстанның 58 мәктәбендә меңгә якын укучы диннәр тарихын факультатив фән буларак өйрәнә. Ә 116 мәктәптә диннәр тарихы түгәрәге эшләп килә. Аларда 3 меңгә якын бала төрле конфессияләр турында мәгълүматлар ала. Ләкин алга таба әлеге тәжрибә киңәйтелмәячәк. Бу турыда ТР мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев хәбәр итте. Моңа кадәр диннәр тарихын укыткан мәктәпләр эшләрен шул рәвешле дәвам итәчәкләр. Ә калганнарга яңалык мәжбүри рәвештә кертелмәячәк.

## "КЫЗЫЛ БАЙРАК"—СӘЙДӘШ АЛАНЫ...

Югары Ослан районының Илел буенда урнашкан Кызыл Байрак авылында быел да бөек композитор Салих Сәйдәшевкә багышланган сәнгать бәйрәме узды.

Һәр елны август аенда үткәрелгән бу бәйрәм сан буенча тугызынчысы булды. Сәйдәш аланында үтә торган бу "Иҗат Сабантуе" елдан-ел кинрәк колач ала, аның иҗтимагый әһәмияте арта гына бара. Ул музыка әһелләрен генә берләштереп калмыйча, күптән инде сәнгатькәрләрнең, шагыйрь—язучыларның иҗади аралашу урынына әверелде. Бу бәйрәмгә Казаннан гына түгел, бүтән районнардан һәм күрше авыллардан да байтак тамашачы килә.

Сәйдәш бәйрәмен А. Шутиков житәкләгән халык инструментлары оркестры ачып жибәрде. Сәхнәдә эстраданың атаклы жырчылары бер-берләрен алыштырып торды: И. Газиев, В. Ганиева, Г. Ибушев, Х. Тимергалиева, Р. Маликов, Э. Жәләлетдинов, Р. Галимова... Бәйрәм концертын шагыйрә-журналист Флүрә Низамова алып барды. Бәйрәмнең гамәли оештыручысы, галәттәгечә, Г. Камал театры булды (директоры Шамил Закиров).

Сәнгать бәйрәмендә Татарстан Республикасының Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады.

## ЯЗУЧЫЛАР ИГЕНЧЕЛӘР ЯНЫНДА

Урып-җыю чорында язучыларыбыз Республиканың кайбер районнарында авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре белән очрашулар оештырды. Әхәт Гаффар, Вакыйф Нуриев, Госман Гомәр, Ләбиб Лерон, Хәбир Ибраһимнардан торган төркем Кайбыч районында; Мәдинә Маликова, Госман Садә, Вакыйф Нуриев, Алмаз Хәмзиннар группасы—Түбән Камада; Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов житәкчелегендәге делегация (Ркаил Зәйдулла, Шамил Маннапов, Бикә Рәхимова, Рафис Корбан, Шәмсия Жиһангирова, Фарсель Зыятдинов, Искәндәр Сиражи) Әлки төбәгендә булдылар, игенчеләр белән очрашып фикерләштеләр, китап сөючеләр алдында чыгышлар ясадылар.

## ЮБИЛЕЙГА—КҮРГӘЗМӘ

Казанның үзәк Эрмитажында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рабис Саләхованың шәхси күргәзмәсе ачылды. Ул остаһың 50 еллык юбилее уңаеннан оештырылган. Рабис Саләхов—нәкыш сәнгате, керамика, монументаль рәсем

буенча зур уңышларга ирешкән рәссам. Татар фольклоры, заман шигърияте рәссам иҗатында аерым урын били. Төрек мифологиясе һәм Евразия мәдәнияте дә аның бик күп әсәрләрендә урын алган.

### КАРТАЮ БЕЛМӘС ҖЫРЧЫ

Ш. Камал музеенда һәртөрле кичәләр күп уза. Күптән түгел бирелә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Эмиль Җәләлетдиновка 75 яшь тулуга багышланган "Күңелдә мәңге яз" дигән мәдәни-музыкаль кичә булып узды.

Музейга бу көнне Эмиль Җәләлетдиновның иҗатын хөрмәт иткән сугыш һәм хезмәт ветераннары килгән иде. Кичәне әзерләгән һәм алып барган музейның өлкән фәнни хезмәткәре Равилә Мөбәрәкшина тамашачыларны җырчының тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Сәмәркандта туып-үскән Эмиль бер үк вакытта ике уку йортында—музыка һәм медицина училищеларында белем ала. Совет Армиясе сафында хезмәт иткәндә дә егет музыкаль сәләтен эшкә җигә, хор оештырып, аңа дирижерлык итә. Эмиль Җәләлетдинов Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, озак еллар Татар дәүләт филармониясе солисты булып эшләде.

Җырчының күңелендә әле һаман да яз кебек. Музейда үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә дә Эмиль Җәләлетдинов композиторлар Ю. Виноградов, А. Ключарев, Р. Яхин җырларын башкарды. Тамашачылар аның әле дә көчле, матур тавышын бик яратып кабул итте.

Композиторларыбызның әсәрләрен исә пианинода концертмейстер Зөлфия Ибраһимова уйнады.

### ҮЗЕНЕКЕ—ҮЗЕНӘ

Казан шәһәре мэриясе Василий Аксеновка 76 яшь тулу уңаеннан язучының балачак еллары үткән агач йортны аңа бүләк итәргә карар кылган. Йортны 2008 елның көзенә төзекләндереп, бүләк итәрлек хәлгә китереп житкерәчәкләр. Аны төзекләндерү эшләре март башында башланган иде инде. Язучы туган йорт тышкы ягы белән шул чорны хәтерләтергә тиеш, ә эчке ягы исә Аксеновның һәм аның гаилә әгъзаларының хатирәләре буенча торгызыла. Бу йортта әдипнең музей-бүлмәсе, шулай ук әдәби салон һәм язучы өчен уңайлы фатир да булачак. Аскы катында джаз-клуб ачылырга тиеш.

### ТҮБӘТӘЙГӘ ҺӘЙКӘЛ БУЛАЧАК

Чаллыда "2/18" бизнес үзәге өчен иң шәп түбәтәй эскизына конкурс игълан ителде.

Бәйгене оештыручылар бина эчендәге мәйданчыкта милли баш киеменә һәйкәл кую карарына килүне чаллыларның "2/18" бизнес үзәген инде күптән "түбәтәй" дип йөртүләре белән аңлаталар.

Бәйгенең премия фонды 100 мең сумны тәшкил итә. Беренче урынга—50 мең, икенче урынга—25 мең, өченче урынга 15 мең сум бирү күздә тотыла.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, фән һәм мәгарифне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне, татар халкының әдәби мирасын саклап калудагы һәм пропагандалаудагы зур казанышлары өчен В. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире **Миңнегулов Хатыйп Йосыф** улы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

* * *

2008 елның 25 августында 79нчы яшендә күренекле язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Мәгъсүм Хәмит улы Хуҗин** вафат булды.

* * *

2008 елның 25 августында 63нче яшендә язучы, галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе **Рәшит Фәйзрахман улы Ягъфәров** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* **XVI гасыр Казаны.** *Р. Заһидуллин картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Локман Бадыйкшан**.

# Яңа китаплар




**Надир Дәүләт.** 1917 октябрь инкыйлабы вә төрек-татар Милләт Мәҗлесе (эчке Россия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе. 1917—1919).—Казан: "Җыен", "Милли китап" нәшриятлары, 2008.—384 б. Тиражы—1000 данә.

XX гасыр башындагы төрки халыкларның милли-азатлык хәрәкәтендә Милләт Мәҗлесе күренекле урын тота. Совет дәверендә аның эшчәнлеге берьяклы һәм тенденциоз бәяләнде. Төркиядә яшәүче милләттәш галимебез Надир Дәүләтнең бу хезмәтендә Милләт Мәҗлесе тарихы шактый ук объектив яктыртыла. Чөнки бу хезмәт төрле илләрдәге бай архив материалларына, безгә мәгълүм булмаган чыганакларга нигезләнеп язылган. Аны "XX йөз башында шаулап узган Милләт Мәҗлесе турында XX гасырның ахырында гына башкарылган беренче һәм иң төпле, иң тәфсилле гыйльми-тикшеренү җимеше" дип саный академик М. Госманов. 1998 елда Истанбулда басылып чыккан бу хезмәтне төрекчәдән татарчага Рәшид Кадыйров тәрҗемә иткән. Бу басма татарның дәүләтчелек тарихы, гомумән, төрки дөнья белән кызыксынган һәркем өчен гыйбрәтле.




**Вазыйх Фатыйхов.** Язлар көтә күнел. Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.—159 бит. Тиражы—2000 данә.

Туган җиреннән читкә китмичә, үз туфракларында яшәп, уңышлы гына иҗат итүче язучыларыбыз, шагыйрьләребез бар безнең. Мөслимдә—Фоат Садриев, Балтачта—Гарифҗан Мөхәммәтшин, Азнакайда—Илдус Гыйлаҗев, Мамадышта—Рафаил Газизов, Сабада—Тәлгат Нәҗмиев, Сарманда—Дамир Гарифуллин... Вазыйх Фатыйхов та әнә шундыйлардан. Ул—Балык Бистәсендә яши, "Авыл офыклары" газетасының баш мөхәррире булып эшли. Ул шагыйрь буларак та укучыларга яхшы таныш. Төрле нәшриятларда аның унга якын китабы дөнья күрде. Бу китапка шагыйрьнең соңгы елларда язылган шигырьләре, җырлары тупланган.



Локман Бадыйкшан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)